# казан утлары

1

ЯНВАРЬ-1974



С. ХӘКИМ.



Р. ТӨХФӘТУЛЛИН.



Г. АФЗАЛ.



М. ХӘМИТОВ.



Ф. МИҢНУЛЛИН.

## 1973 ЕЛДА «КАЗАН УТЛАРЫ» ЖУРНАЛЫ БҮЛӘГЕН АЛГАН АВТОРЛАР

Журнал редколлегиясе 1973 елда чыккан әсәрләре өчен түбәндәге авторларны бүләккә лаек дип тапты:

**Сибгат Хәким** — 2 санда басылып чыккан «**Кырларда давыл...**» шигырьләр циклы өчен;

**Рафаил Төхфәтуллин** — 1 санда басылып чыккан «**Бөтнек үләне исе**» хикәясе өчен;

**Гамил Афзал** — 2 һәм 11 саннарда басылып чыккан «**Нигә төшкә керә...**», «**Әлмәт яклары**» шигырьләр циклы өчен;

**Малик Хәмитов** — 3 һәм 11 саннарда басылып чыккан «**Егет булып йөрер чаклар иде**», «**Кабат кайтты яшьлек**» очерклары өчен;

**Фарваз Миңнуллин** — 9 санда басылып чыккан «**Прозаның гражданлык йөзе**» мәкаләсе өчен.

# Казан утлары



АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

1

ЯНВАРЬ
1974

## Бу санда

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ VIII СЪЕЗДЫН КАРШЫЛАП

**Р. МОСТАФИН.** Яңа теманы үзләштерү юлында . 3
**Г. АХУНОВ.** Ардуан батыр. Повесть . . . . . 12
**Р. МИНГАЛИМОВ.** Җитди итеп әйтәм. Шигырьләр . . . . . 43
**Г. САДӘ.** Тимерче. Шигырьләр . . . . . . . 46

Р. ТӨХФӘТУЛЛИНГА 50 ЯШЬ

**Р. ТӨХФӘТУЛЛИН.** Акбүз ат. Повесть . . . . 48

**С. СӨЛӘЙМАНОВА.** Эңгер төшеп килгән кышкы көннең. Шигырьләр . . . . . 81
**Ф. ЧАНЫШЕВА.** Бер төенчек идең. Шигырь . . 86
**Н. ХӘМИДИ.** Фәүзия кияүгә чыга. Хикәя . . . 87
**Г. АФЗАЛ.** Салават батыр. Шигырьләр . . . . 96
**Ү. САТТАРОВ.** Кызым хикәяләре . . . . . . . 101

ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

**Н. КӘРИМОВА.** Дусларым-иптәшләрем. Парчалар. 107

ОЧЕРКЛАР

КамАЗ елъязмасы . . . . . . . . . . . . 113
**Д. ВӘЛИЕВ.** Җамалиевлар династиясе . . . . . 116
**Д. ЗӨБӘЕРОВА.** Әманәт . . . . . . . . . . 135
**К. РӘХИМ.** Табигать белән очрашканда . . . . 141

ЯКТАШЛАРЫБЫЗ СӘЯХӘТТӘ

**М. ЗӘКИЕВ.** Ай һәм йолдыз яктысында . . . . 155

КИТАП КҮЗӘТҮ

**Ф. ХАТИПОВ.** Тарихыбызның поэтик сәхифәсе . 173
**С. АЛИШЕВ.** Татарстандагы авыл исемнәре . . . 176

УКУЧЫ ТРИБУНАСЫ

**Ш. ӘХМӘДУЛЛИН.** Киләчәкне уйлап . . . . . 178

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

**Ф. ВӘЛИЕВА.** Профессор Мөхетдин Корбангалиев. 183
**Ф. Яруллин** . . . . . . . . . . . . . 185

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*
Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар. Баш редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52,
бүлекләр — 2-39-52.

Баш редактор: **Гариф Ахунов**

Редколлегия: **Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

Производствога бирелде 10/X-1973 ел. Басарга кул куелды 10/XII-1973 ел. ПФ 07162. Кәгазь форматы $70\times108^{1}/_{16}$. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 87,000 экз. Заказ Л-173. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе,
Казан, Декабристлар урамы, 12.

Рафаэль Мостафин

# ЯҢА ТЕМАНЫ ҮЗЛӘШТЕРҮ ЮЛЫНДА

Днепрогэс, Магнитка, Комсомольск на Амуре диюгә — хәтердә этиләребезнең героик хезмәт сәхифәләре җанлана. Җир өйләр һәм палаткалар, кәйлә һәм көрәк кебек иң гади эш кораллары... Хәтердә шул чор үзе җанлана.

Волга — Дон, Братск, Волга автомобиль заводы дидеңме — шунда ук күз алдына бөтенләй башка чор килеп баса.

Һәм менә хәзер безнең республикада яңа бер гигант төзелеш бара — КамАЗ туып килә. Партиябез һәм хөкүмәтебез Кама буендагы автогигантны тугызынчы бишьеллыкның иң зур төзелеше дип игълан иттеләр. Капитал салымнарның күләме буенча КамАЗ ул — Тольяттидагы хәтле ике автомобиль заводы дигән сүз. КамАЗда биш миллион дүрт йөз мең кубометр күләмендә бетон эшләре башкарылачак. Бу — тагын бер Братск ГЭСы дигән сүз. Төзелеш мәйданнарында башкарылачак җир эшләренең күләме ягыннан аны Волга — Дон каналы белән генә тиңләп була.

КамАЗның тагын бер әһәмиятле үзенчәлеге бар. Ул моңарчы беркайда күрелмәгән темплар белән төзелә. Мин Чаллыда беренче тапкыр 1970 елның башларында булган идем. Ул чагында әле КамАЗ хакында сөйли генә башлаган һәм Чаллыга эшчеләрнең беренче отрядлары гына килеп төшкән көннәр иде. Кабат КамАЗда 1972 елның маенда булырга туры килде. Бу чакта инде яңа шәһәрнең һәм заводлар комплексының контурлары ачык булып белена башлаган иде. Булыр-булмас ике ел эчендә бу якта булган үзгәрешләрне күреп шаккаттым. Озакламый КамАЗ беренче автомобиль эшләп чыгарачак...

РСФСР язучылар союзы секретариатының Казанда уздырылган утырышында чыгыш ясап, Д. Кугельтдинов шундый бер мәзәк вакыйга сөйләгән иде. Башкала клубларының берсендә танылган әдипнең бәйрәм кичәсе бара икән. Чираттагы кеше булып, сәхнәгә чал чәчле генерал күтәрелә. Юбиляр аның яшьлек дусты була. Бөтен кеше алдында генерал дустын кочып-үбеп ала. Шул чак сәхнәдә юбиляр тирәсендә йөгереп йөргән фотограф кызганыч тавыш белән:

— Тагын бер генә үбешегез инде, төшерергә өлгерми калдым,— дип өзгәләнә.

— Без, язучылар, тормышта еш кына әнә шул хәсрәт фотограф хәлендә калмыйбызмы икән,— дип сүзен дәвам иткән иде Д. Кугельтдинов.— Без бүгенге тормыштагы иң мөһим, иң дулкынландыргыч вакыйгаларны онытып калдырмыйбызмы икән? Тормыш бит юбилей кичәсе түгел. Аны безнең өчен генә тагын бер кат үбешергә мәҗбүр итеп булмый...

Бәхеткә каршы, безнең татар язучылары республикабыздагы гигант төзелеш алдында бурычлы булып калмадылар. КамАЗны төзүчеләр турында роман, пьеса, поэма, берничә повесть, күп санлы шигырьләр язылды, йөзләрчә метр кинохроника эшләнде (шулар арасыннан Казан студиясенең «Югары нота» исемле доку-

ментальь киноочеркын аеруча билгеләп үтәсе килә); язучылар тарафыннан язылган дистәләрчә очерк басылып чыкты. Ул очеркларның күбесе Татарстан китап нәшрияты чыгарган «Камадагы батыр» исемле җыентыкка тупланган.

Бу мәкаләдә минем, барыннан да бигрәк, публицистика жанрында язылган әсәрләргә киңрәк тукталасым килә. Мәгълүм булганча, публицистика ул — әдәбияттагы иң сугышчан, иң оператив жанрларның берсе. Публицистика ул язучының турыдан-туры тормышка үтеп керүе, аның гражданлык активлыгының чагылышы дигән сүз.

Шулай бер вакыт партиянең Чаллы шәһәр комитеты секретаре Р. Беляев белән очрашып сөйләшергә туры килгән иде. Мин аннан КамАЗга багышланган әсәрләр турындагы тәэсирләрен сорашТЫМ. Гаҗәпкә каршы, ул газета-журналларда басылган күпчелек материаллар турында шактый югары фикердә булып чыкты. Югыйсә, алардагы кимчелекләрне, җитешсез якларны ул теләсә кайсыбызга караганда да күбрәк белә бит инде.

— Язучыларның һәм журналистларның игътибарына без ифрат мохтаҗ,— диде Рәис Кыямович.— Безнең алда торган гаять зур һәм мөһим эшләрне уңышлы хәл итү өчен, КамАЗдагы һәр төзүченең, ул кайсы гына тебәктә эшләмәсен, әхлак һәм идея ягыннан тотнаклы булуы бик мөһим нәрсә. Безгә һәр көнне йөзләрчә кеше килә. Хезмәт биографияләре, квалификацияләре һәм характерлары ягыннан гаять төрле-төрле булган шул кешеләрдән бердәм коллектив туплау өчен зур тырышлык сорала. Иң элек алар ни өчен, нәрсә хакына эшләүләрен аңларга, гомуми эш өчен яна белергә тиешләр. Нәкъ менә шушы мәсьәләдә безгә язучы сүзе, аларның ярдәме кирәк тә...

Бик урынлы һәм тирәнтен уйлап әйтелгән сүзләр! Әгәр бүген КамАЗ төзелешендә югары хезмәт күтәренкелеге хөкем сөрә икән, әгәр төзелештә эшләүче һәр кеше үзенең эше белән чын-чыннан горурлана, үзен бишьеллыкның зур эшләренә катнашы бар кеше итеп саный икән — монда, һичшиксез, язучыларның да өлеше бар. Мисал төсендә шундый бер факт китерергә мөмкин. Г. Паушкинның «Чаллы җирендә» дип исемләнгән очерклар китабы Казан кибетләрендә күз ачып йомганчы сатылып бетте, ә Чаллының үзендә ул сирәк очрый торган китап санала.

Күптән түгел Бауман урамында Чаллыдан килгән бер танышымны очраттым. Култык астында зур гына төргәк китаплар — «Камадагы батыр» дигән очерклар җыентыгы. Нигә шул кадәр күп алдың, дип кызыксындым.

— Котылу өчен! — дип шаяртты ул.— Делегация арты делегация килә, мәктәп балалары, пионерлар килә, язучылар һәм фотографлар турында әйткән дә юк инде... һәркайсына күрсәт, аңлат, сөйлә... Беләсеңме, моңа күпме вакыт үтә? Ә менә монда бөтенесе язылган.— Аннан җитди тонда дәвам итте.— Китапны гомуми торакларның кызыл почмакларында җыелып тикшерәчәкбез. Пропагандистлар һәм агитаторлар өчен менә дигән материал булачак. Алмасам курыктым, ул бит безгә килеп тә җитмәячәк. Нибары алты мең данә.

Мин төзүчеләрдән В. Росляков, Г. Бакланов, М. Ганина, Р. Кутуй, Д. Вәлиев, А. Злобин, Я. Винецкий, М. Зарипов кебек авторларның әлеге төзелешкә багышланган әсәрләре турында сораштым. Билгеле, төрле кешенең фикере төрлечәрәк булып чыкты. Аерым әсәрләр белән килешмәүчеләр дә бар иде, әмма ул әсәрләр эзсез югалып калмаган. Шулай да бу әле безгә тынычланырга хокук бирми.

Язучыларыбызның КамАЗ турындагы әсәрләрен бер-бер артлы рәттән укырга тотындыңмы, борчылырлык, уйланырга мәҗбүр итәрлек нәрсәләр дә күзгә ташлана. Кабатлауларның, шаблонга әйләнгән алымнарның шактый күп булуы күңелне борчый. Әйтик, КамАЗ турында очерк язган авторларның бик азы гына төзелешнең тышкы панорамасын, аның масштабын сурәтләүдән котыла алган. «Әлмәт тракты буйлап далага — автозавод төзелеше мәйданына агылган машиналар ташкыны бераз кими төшкәнче, юл аша аркылы чыга алмый көтеп тордым. Төзелештә моторлар улавы колакларны тондыра, тәгәрмәчләр әйләнүеннән күз аллары чуарлана, әмма офтанудан файда юк: һәр җирдә хәрәкәт, тавыш, шау-шу. Күтәрү краннарының уклары йөреп тора, экскаваторларның тимер тешләре җир кимерә, шунда ук үрдәк борынлы бульдозерлар казына. Күзгә тәбәнәк күк астында галәмәт зур цех гүли, далага таш, металл һәм кешеләр ташучы автомашиналар галәмәт озын транспортерны хәтерләтә».

Бу өзек Г. Паушкинның «Чаллы җирендә» исемле очерклар китабыннан алын-

ды. Шундый характердагы тышкы бизәкләрне (бәлки алар ачыграк, тәэсирләрәк тә язылганнардыр) Р. Кутуйның «Үзгәртелгән җир» очеркында да, А. Злобинның «Көндәлек дәфтәреннән» дип исемләнгән язмаларында да, Я. Винецкий, М. Зарипов, М. Глухов, Р. Максудов, И. Якименко кебек журналистларның һәм язучыларның репортажларында да очратырга мөмкин. Дөрес, мондый язмалар да кирәктер, алар үзе Чаллыда булмаган кешегә күпмедер дәрәҗәдә төзелешнең колачын күзалларга, газета, радио аша ишеткән коры саннарны реаль эчтәлек белән тулыландырырга, бишьеллыкның әлеге төзелеше белән якыннанрак танышырга булышалар. Әмма ул очеркларны рәттән укырга тотындыңмы, күңелдә үзеннән-үзе бер шик туа: безнең очеркистлар берберләренең әсәрләрен укыйлармы икән? Төрле вариацияләрдә уннарча мәртәбә кабатлана торгач, әлеге бизәкләр шактый туйдыра башлый, аннан да бигрәк, аларның өстән-өстән генә эшләнгән булулары эчне пошыра.

«Фундамент салу өчен казылган чокырлар, бер читкә өеп куелган кара туфрак таулары, кызыл төстәге балчык валлары, колонналар өчен фундаментлар, кайбер урыннарда булачак корылмаларның метал скелетлары... МАЗлар, КрАЗлар, үзбушаткыч машиналар үкерә, бульдозерлар, скреперлар казына» [1].

«Төннәрен пресс-рам заводы эчтән прожекторлар белән яктыртыла — ул челтәрле тимердән ясалган, төтенләп, бөтерелеп торган яктылык белән тулы галәмәт зур ал читлекне хәтерләтә. Шундый матур...» [2]. Кама ярларын сурәтләү дә (әгәр очеркист пароходта яки «Метеор»да йөзеп килә икән), актарылып ташланган җирнең өстән, югарыдан ничек күренүен тасвирлау да (бусы самолетта очып килгәндә) ялыктырып, туйдырып бетерде. Очраклы юлчылар: кулларына гитара тоткан, аркаларына рюкзаклар аскан озын чәчле егетләр белән әңгәмә куерту алымы да шаблонга әйләнеп бара. КамАЗга багышланган шигъри әсәрләрдә дә (ә алар хәзер шактый) төзелешнең колачы, масштаблары белән соклану өстенлек итә. Дөрес, арада әйбәтрәкләре дә юк түгел. Мисалга Р. Мингалимовның «Күз карасы» исемле поэмасын, С. Хәким, Р. Харисов һәм башка шагыйрьләрнең шигырь циклларын китерергә булыр иде. Поэзия әсәрләренең үз законнары һәм үз алымнары бар, шуңа күрә мин аларга тукталып тормыйм, алар махсус сөйләшүне сорый.

Күрәсең, баштагы чорларда тышкы бизәкләр белән мавыгудан, шаблон һәм кабатлаулардан җиңел генә котылып та булмыйдыр. Тик шул урында тукталып калмаска, тирәнгәрәк керергә, бүгенге көн кешеләрен, төзелештә барган тормыш процессларын ныграк өйрәнергә кирәк. Ахыр чиктә хикмәт бит әлеге тышкы детальләрдә түгел, аларны аңлый белүдә, алар артында торган ниндидер закончалыкларны ача белүдә.

Беренче мәртәбә Чаллы читендәге вагончыклар шәһәренә килеп чыккач (КамАЗда бу урынны энтузиастлар поселогы дип йөртәләр), күңелдә туган каршылыклы уйлардан бүген дә арынып бетә алмыйм. Шунда яшәүчеләрнең берсе әйткәнчә, гадәттә очеркистлар бу «кәрван сарай»ны читләтеп узарга тырышалар, чөнки ул вакытлы күренеш, мәҗбүрият аркасында, торак җитмәү аркасында туган күренеш. Чыннан да, читтән караганда бертөсле, тар вагоннар рәте күңелсез хисләр уята. Менә 20—30 елларның калдыгы, дисең. Әмма якынрак килүгә күрәсең: һәр вагонга электр һәм пар кертелгән (бүржуйка миче ягып азапланасы түгел). Һәр вагон түбәсендә диярлек телевизор антеннасы. Вагоннарда чыннан да таррак, аның каравы, чиста (хатын-кыз кулы сизелә — биредә гаиләле кешеләр яши). Һәркемдә яңа мебель, күбесе полировкалы. Вагон араларындагы буш урыннарда берничә «Жигули» машинасы күренә. Юк, бу инде 30 нчы еллар түгел!

* * *

Төзелешнең кайнап торган көндәлек ыгы-зыгысында бүгенге көн өчен генә хас ниндидер яңа якларны тотып алу җиңел эш түгел. Нәтиҗәдә КамАЗ турындагы беренче очеркларның авторлары ихтыярсыз төстә саннар белән артык мавыга башлыйлар. Саннар я үзләре генә китерелә, я баш инженер, ул булмаса, төзелештәге башка берәр начальник белән әңгәмә рәвешендә бирелә. Саннар гаять зурлар, билгеле, әмма хәтердә кал-

[1] В. Росляков. Первое знакомство. Рус телендә. «Новый мир» журналы. 1972 ел. 1 сан, 188 бит.

[2] М. Ганина. Дождливой осенью. Рус телендә. «Новый мир» журналы. 1972 ел. 3 сан, 159 бит

мыйлар. Күрәсең, бу да шулай ук яңа теманы үзләштергәндә котылгысыз төстә очрый торган «балалык авыруыдыр». Укучыга эмоциональ тәэсир ясауның образлы чараларыннан файдалану, ихтимал, киләчәк эшедер.

Минемчә, чын әдәби очерк образлар иҗат итүдән башлана. Автор замандашларыбызның эчке дөньясына керә алганмы, аларны тормыштагыча җанлы итеп күрсәтә алганмы — очеркистның уңышын әнә шул хәл итә. «Һәм менә мин уйлыйм: кемнәр алар, нәрсә хакында уйлыйлар, үзләрен ничек аңлыйлар, үз-үзләренә, башкарган эшләренә, безгә, өлкәннәргә, ничек карыйлар, кешелек җәмгыятенә, мәхәббәткә, гаделлеккә, азмыни шундый нәрсәләр?.. Әйтик, менә бусы — чәчләре җилкәсенә кадәр төшеп торганы, ике кәкре кылычка охшаган бакенбардлысы?» «Беренче танышу» исемле очеркында В. Росляков шулай уйлана.

Кызганычка каршы, автор әлеге сорауларга канәгатьләнерлек җавап кына бирә алмаган. Автор КамАЗда бик аз вакыт булган, тәэсоратлары шактый очраклы һәм җиңелчә, хикмәт бәлки шундадыр. Шулай да бер урында пәрдә бераз ачылып киткәндәй була. Мин әдәби берләшмә утырышын сурәтләгән битләрне күздә тотам. Түгәрәк члennарының ахыргача эшләнеп җитмәгән, әмма чын күңелдән язылган шигырьләрен автор зур игътибар белән тыңлый, ул шигырьләрдән озын-озын өзекләр китерә һәм сиздерми генә безне КамАЗ төзүчеләрнең эчке дөньясына алып керә. Һәм шул чак бетончы Руслан Галимов — «муенына әллә галстук, әллә шарф, әллә косынка бәйләгән», «кара бакенбардлы, озын кара чәчле, кара-күчкыл йөзле таза чибәр егет», язучыга башта күренгәнчә, «кара лорд Байрон» булып түгел, ә йомшак табигатьле, киң күңелле, саф һәм мөлаем егет булып чыга. КамАЗның башка геройлары да безнең алда бөтенләй башка яклары белән ачылып китәләр.

Василий Росляков — тәҗрибәле язучы. Ул, күрәсең, теманың иксез-чиксез булуын да, яңа материалның җиңел бирелмәячәген дә яхшы аңлаган. Шуңа күрә дә очеркын «Беренче танышу» дип кенә атаган. Кызганычка каршы, калган күп кенә очеркларда кешеләр белән әнә шундый беренче танышу да булмый кала. Геройның фамилиясе, исеме, һөнәре, планны ничә процентка үтәп баруы хәбәр ителә һәм эзлекле төстә биографиясе сөйләп чыгыла — тыштан караганда портретлыкка дәгъва кылган очеркларда шуннан башка әйбер табып та булмый.

Язучы А. Злобин да үзенең «Көндәлек битләреннән» дигән язмаларында яңа теманы үзләштерүнең авырлыгы хакында уйлана. «...Хәзергә микъдари материал туплау процессы бара, бу һәр эштә кирәк... Башта мин кубометрларга һәм тонналарга күмелдем, хәзер менә конструкцияләргә һәм технологиягә кереп баттым...»

Әмма ни генә булмасын, тормышны җентекләп өйрәнү, тырышлык бушка китми. Г. Паушкинның «Чаллы җирендә» дигән очерклар китабы шул турыда сөйли. Китап тормышны тирәнтен өйрәнеп, җаваплылык хисен нык аңлап язылган. Ул материалга байлыгы белән генә түгел, ә барыннан да бигрәк, дөньяны үзенчә индивидуаль төстә күрә белүе белән игътибарны җәлеп итә. Китапта дистәләрчә кызыклы кешеләр белән очрашасың, әмма шулар арасыннан иң кызыклысы — автор үзе, автор образы. Юк, автор үз шәхесен популярлаштыру белән мавыкмый, шул ук вакытта үз-үзеннән качарга да тырышмый. Менә ул Чаллы җирендә урнашкан «Гигант» колхозының председателе Зыя Закиров белән очраша. Автор өчен ул гади очерк герое гына түгел, аның фронтташ дусты, полкташы. Зыя белән бергә алар башта ил чигеннән алып Кавказ тауларына кадәр чигенү ачысын татыганнар, аннары бергәләп дошманны зәңгәр Дунай ярларына кадәр кире куганнар. Аларның сөйләшерлек, искә төшерерлек уртак әйберләре күп. Фронтташ дусты алдында да ачылмаса, Зыя Закиров тагын кем алдында ачылыр, үзенең иң яшерен серләрен һәм уйларын тагын кем белән уртаклашыр иде икән?!. Әлеге дулкынландыргыч очрашуга багышланган битләр — Г. Паушкин китабының иң яхшы урыннары.

Үзенә бөтенләй таныш булмаган кешеләр белән очрашканда да автор аларга сугыш утларында чыныккан кеше күзе белән карый, чагыштыра, уртак якларны, аермаларны эзли.

«Бу егетләрне беренче күрүем, әмма алар белән кайдадыр очрашканмын кебек тоела, ләкин кайда? — Һич хәтергә төшерә алмыйм. Күңелдән узган елларны барлыйм, вакыйга, фактлар, очраклы хәлләр аша эчкә, тирәнгә узам... Һәм кинәт хәтергә Доу кичүе килә. Кырык икенче

ел. Филимонов — старшина Аникин икән ләбаса! Шундый ук озын буйлы, ак йөзле, ике бит уртасында чокырчыклар. Кичүнең иң биек ноктасына баскан да боерыклар биреп тора: «Әйдә-әйдә, оялма!» — ди».

Автор фикеренең менә шундый эзләнүчәнлеге, дөньяга карашның сугыш уты белән үткенәйтелгән үзенә бер төрле ныклыгы укучыны да битараф калдырмый.

Әгәр Г. Паушкин безнең яшь замандашларыбызның уйларына һәм күңелләренә ачкычны үзенең сугышчан үткәне һәм зур тормыш тәҗрибәсе аша эзләсә, яшь язучы Равил Вәлиев башка юл белән, авыр юл белән, әмма тапталмаган юл белән бара. Казан университетының тарих-филология факультетын тәмамлаганнан соң, ул Вазыйх Мәүлиховның комсомол-яшьләр бригадасында гади ташчы булып эшли башлый. Ике ел буена бригада членнары белән бергә бөтен кыенлыкларны бүлешә. Аның «Каурыйлар чыныкканда» дигән очерклар сериясе («Казан утлары» журналы. 1972 ел. 2—4 саннар) әнә шулай языла. Автор төзелештәге бөтен нәрсәне колачларга тырышмый, бер генә сан да китерми, төзелештәге кыенлыкларны һәм җитешсезлекләрне яшерми. Ул нибары бер бригада, үз бригадасындагы кешеләр турында гына сөйли, ә шулай да аның очерклары белән танышканда, без бөтен төзелеш сулышын тоеп торабыз. Р. Вәлиев очерклары бик хаклы рәвештә узган елгы очерклар арасында иң яхшылары дип табылды һәм «Казан утлары» журналының махсус бүләгенә лаек булды.

Гомумән, КамАЗга багышланган очерклар белән танышканда шундый нәтиҗәгә киләсең: әгәр язучы төзелешнең рухына керә алмаса, аның кешеләрен ныклап өйрәнеп һәм яратып өлгермәгән булса, аны бай тәҗрибә дә, зур исем дә коткара алмый. Ф. Видрашкуның «Вахта» исемле очеркы («Новый мир» журналы. 1973 ел. 3 сан.) шул турыда сөйли. Әсәрдә йөрәк җылысы сизелми, шуңа күрә ул коры протокол язмаларын хәтерләтә. Мондый материаллар фонында Р. Вәлиев очеркларының кыйммәте тагын да ачыграк күренә.

* * *

КамАЗда илледән артык милләтнең уллары һәм кызлары эшли. Монда, фокустагы кебек, төрле милләт кешеләренең үзара дуслыгы һәм бердәмлеге, аларның Ватанга булган чиксез мәхәббәте, гомуми эш өчен яну-көюләре чагыла. Хәер, бөтен зур төзелешләрдә дә нәкъ шулай булган. Магнитка төзелеше тарихына, мәсәлән, иң яхшы бетончылардан Галиуллин һәм Сәгъдиев бригадаларының ярышы дулкынландыргыч сәхифә булып кереп калган. Х. Галиуллинның Татарстанның Апас районы егетләреннән төзелгән комсомол-яшьләр бригадасы бетон кою буенча дөнья рекорды куя. Сменага норма буенча 200 кубометр урынына 1196 кубометр бетон сала. Бригаданың бу көне В. Катаевның «Вакыт, алга!» исемле романында сурәтләнгән.

«Мак-ки» фирмасының механикалаштыру һәм бетон эшләре буенча баш инженеры Дэвис, 1931 елның җәендә Советлар Союзында булып кайткач, аңа аңлашылмый торган хезмәт күтәренкелеге турында сөйләргә мәҗбүр булган, нинди дер татарлар дөнья рекордларын яңартканга, америкалыларны артта калдырганга аптыраган.

Хәзер менә бишьеллыкның иң зур төзелеше безнең республика территориясендә бара. Шуңа күрә очеркистларның, бигрәк тә читтән килгәннәренең, ничек тә булса мондагы милли үзенчәлекне күрсәтергә тырышулары аңлашыла торган хәл. Әгәр 20—30 елларда татарлар тышкы кыяфәтләре, гореф-гадәтләре һәм тел үзенчәлекләре белән дә башка милләтләрдән шактый аерылып торсалар, хәзер мәсьәлә күп мәртәбә катлауланды. Тышкы аерымлыклар бетте диярлек, һәрхәлдә, алар элекке кебек күзгә ташланып тормый. Бүгенге зур төзелешнең милли үзенчәлеге нидән гыйбарәт һәм гомумән бармы ул?

«Беренче танышу» исемле очеркында В. Росляков КамАЗ сүзен төрлечә төрләндереп карый һәм ул сүз аның өчен күпмедер дәрәҗәдә татарча яңгырый башлаган кебек тоела: КамАЗ, кыз, кымыз, чулпан, батыр. М. Ганина милли үзенчәлекне зур төзелеш җиле әлегә килеп җитмәгән ерактагы бер авылдан эзли («Яңгырлы төндә»). Ул олы яшьтәге татар хатыннарының өс киемнәре, яулыклары турында тәфсилләп яза:

«...Не наискось углом платок сложен, а просто два параллельных конца завязаны под подбородком, белый же четырехугольник распущен по спине — называется платок-джаулык или шаль-джаулык, если это шелковая богатая шаль с кистями. Ну и платья иные — широкие,

собранные на кокетке, из яркой однотонной материи — кульмяк называется такое платье».

Ул сырган юрганны да — «джургак» (дөрес яза гына белмәгән), берсе өстенә берсе өелеп, түшәмгә хәтле җиткән мендәрләрне дә — «джастык» һәм урын өстендә гыйбадәт кылып утыручы картны да күреп ала, квартир хуҗасы хатынының акцент белән сөйләшүенә шунда ук игътибар итә. («Алла-алла, господи помилуй! Чай пить давай. Картошка вона есть горячий, суп есть... Кушать хочется, дорога, устала, да?»)

Ләкин беренче очракта да, икенчесендә дә милли үзенчәлекнең өстә яткан тышкы детальләренә генә игътибар ителгән. Ә бит КамАЗ төзелешендә меңнәрчә татарлар — төзүчеләр, шоферлар, бульдозеристлар, прораблар, инженерлар, проектчылар, галимнәр эшли. Аларның күбесе русча дөрес, акцентсыз сөйләшә. Шулай ук берәү дә кәләпүшләр, камзуллар киеп йөрми. Әгәр кемдер милли үзенчәлекне бирергә тели икән, аның өчен кешенең күңеленә үтеп керүдән, аның фикерләү үзенчәлеген, психологиясен, характерын ачып бирүдән башка юл юк.

Ю. Любимовның «Прораб Халиуллин» исемле зур булмаган очеркында без эшче кешенең портретын нәкъ шулай сурәтләргә омтылуның матур бер мисалын күрәбез. Автор татар халкының күпләгән улларының берсе, илнең барлык зур төзелешләрендә диярлек булган, Мисырда Асуан плотинасын төзешкән, хәзер Татарстан җиренә КамАЗ төзешергә кайткан Халиуллин турында гади һәм ышандырырлык итеп яза. Аның гадилегендә һәм тыйнаклыгында, үз-үзен тотышында, хәтта өлкән кешеләргә һәм үзеннән кечеләргә булган мөнәсәбәтендә үк ачыктан-ачык милли характеры сизелеп тора.

* * *

КамАЗга багышланган дистәләрчә очерклар арасында иң зур урынны я тасвирый очерклар, я портрет очерклар алып тора. Е. Лопатинаның КамАЗ тирәсендәге яшел зона турындагы очеркын («Новый мир» журналы. 1973 ел. 1 сан.) исәпләмәгәндә, КамАЗга багышланган бер генә проблемалы очерк та чыкканы юк шикелле. Очраклы хәлме бу? В. Росляков, проблема күтәрергә ярата торган язучылардан ачыктан-ачык көлеп, болай яза: «Ул чагында төзелеш өч көн буена тик торды. Котлованнарны су басты, ә бит басмаска тиеш булган, җитәкче кешеләр нидер карап җиткермәгәннәр. Проблема күтәрергә ярата торган язучыга менә кайда мәйдан! Биредәге озакка сузылган яңгырлар вакытында бөтен кимчелекләр, бөтен җитешсезлекләр өскә калкып чыкты, тагын да ачыграк булып күренә башлады. Менә шушында тотып китерергә иде ул язучыны, дип уйлыйм. Проблема таба алмаса, ул бит кибә, ябыга, кайгыра башлый, әмма ахырдан барыбер берәр проблема уйлап чыгара һәм шауларга, дөреслекне күзгә бәреп әйтергә тотына, дәүләтне һәртөрле әрәм-шәрәм итүләрдән йолып калу өчен чаба башлый... Проблема күтәрүчеләрне кайчандыр мин үзем дә ярата идем. Хәзер туйдырдылар. Укучыны кайда һәм ничек итеп кадак сугарга өйрәтүләрен тыңлап торасым килми» [1].

Мин аның бу ирониясен уртаклаша алмыйм. Үзеннән-үзе аңлашылса кирәк, укучыны кадак кагарга өйрәтүнең әллә ни мәгънәсе дә, кирәге дә юк. Язучының производстводагы технология мәсьәләләренә тыгылуыннан файда зур булмас. Ләкин төзелештә моннан башка мөһим проблемалар азмыни? Әйтик, нәрсә төзергә — бараклар һәм вакытлы өйләрме, әллә капиталь йортлармы? Яшьләр өчен гомуми торакларммы, әллә аерым квартиралармы? Тирә-юньдәге табигатьне, туфракның уңдырышлы катламын ничек сакларга? Гүзәл Каманы ничек пычранудан сакларга?

Р. Вәлиевнең телгә алынган очеркларында исерек бригадирның «наряд юу өчен» бригада члennарыннан ничек итеп берәр сум акча җыеп йөрүе языла. Традиция, янәсе, шундый. Бирмисең икән, нарядны шундый итеп яба — кулыңа берни ала алмыйсың. Бу соң проблема түгелмени? Әмма мондый проблемаларны эләктереп алыр өчен, төзелеш белән якыннан таныш булырга кирәк. Мондый мәсьәләләрне күтәрү өчен төзелештә берничә көн булып китү генә җитми.

КамАЗ турындагы күпчелек материалларга чын мәгънәсендәге проблемалылык җитми. Проблемалылыкны теге яки бу кимчелекләрне, җитешсезлекләрне ачу белән генә бәйләп карау мәҗбүри түгел. Тормышта яңа башлангычларның урын алуы, хезмәт коллективында яңа, коммунистик мөнәсәбәтләрнең туып килүе —

[1] «Новый мир» журналы. 1972 ел. 1 сан, 202 бит.

болар соң язучыларны дулкынландырырлык проблема түгелмени?! Кызганычка каршы, без тормыштагы матур башлангычларга тиешле дәрәҗәдә игътибарлы түгел. Бүген безне иллюстратив очерклар, биографик очерклар гына канәгатьләндерә алмый. Укучы әдәби очерклардан тирән аналитик фикер, тикшеренү пафосы көтә. Шул чагында гына әдипләребезнең чыгышы зур иҗтимагый яңгыраш алачак.

Тагын бер мәсьәлә. Кайчагында хәтта танылган язучыларның очеркларын укыганда да аптырап каласың, бездә әле һаман очерк жанры турында җиңелчәрәк караш яшәп килә. Янәсе, килдең, күрдең, яздың. Әбит очерк жанрының үз кануннары, үз таләпләре бар. Очерк язганда, материалны җентекләп белүдән тыш, бөтен сурәтләү чараларын төп, хәлиткеч публицистик фикергә буйсындыра белү осталыгы сорала. Башкача әйткәндә, очеркист, барыннан да бигрәк, үзе ышанган нәрсәгә укучыны да ышандыра белергә тиеш. Әгәр шул булмаса, менә дигән стиль дә, матур итеп язылган табигать күренешләре дә авторны уңышсызлыктан коткара алмый.

* * *

Бу бер очеркларга гына карамый, теге яки бу дәрәҗәдә прозаның зур форматлы жанрларына да кагыла. 1972 елда «Казан утлары» журналында КамАЗ төзелешенә багышланган ике повесть басылды. Аларның берсе — Б. Камаловның «Урамнар киңәя» исемле повесте, икенчесе — М. Хәбибуллинның «Тау белән тау очрашмаса да» исемле повесте. Әдәби ел йомгакларына багышланган җыелышта бу повестьларның икесе дә бик үк уңышлы булмаган әсәрләр рәтеннән саналды. Бу бәя белән килешергә туры килә.

КамАЗ төзелешенә багышланган проза әсәрләре арасында хәзергә уңышлырак саналганы — Ә. Баяновның «Ут һәм Су» романы. Ул әсәр турында махсус рецензия чыкканга күрә («Казан утлары». 1973 ел. 10 сан.), биредә аңа тукталып тормыйбыз.

КамАЗга багышланган әсәрләр арасында хәзергә иң уңышлысы Д. Вәлиевнең «Дәвам»[1] пьесасы (Мәскәүнең Ермолова театрында ул «Дарю тебе жизнь» дигән исем белән, ә ВТО театрында «Погода на завтра» дигән исем белән бара) булды шикелле. Аны хәзер илебезнең егермеләп театры куя. Асылда ул — бөтен Союз аренасына чыккан беренче татар пьесасы.

Д. Вәлиев пьесасы буенча куелган спектакльләр матбугатта төрле фикерләр уятты. Әсәрнең сәхнәгә куелышын бер читкә куеп торып, минем драматургик материалның үзе турында сөйлисем килә. Драматургның уңышы нәрсәдә соң?

Бу пьеса киң сулышлы булуы, чынбарлык күренешләрен сәнгатьчә тирән чагылдыруы белән игътибарны үзенә тарта. Зур эш җитди проблемалар да, олы характерлар да тудыра. Автор төзелешнең башлангыч чорында очрый торган кыенлыкларны һәм каршылыкларны яшерми. Ул аларны шундый итеп күрсәтә ки, аларның тиздән бетереләчәгенә без шикләнмибез. Менә пьесадан бер кечкенә эпизод:

«ВИКТОР. Өченче көн гравий ташыдым. Ярты көн каңгырап йөрдем, клиентларны тапмадым. Юлларда бернинди күрсәткеч язулар юк. Кемгәдер бушаттым шунда. Кичә бетон. Ката башлады. Кайда да булса тукта да кузовтан лом белән чокып азаплан. Ярый әле, юл салып яткан ниндидер хатыннар очрады. Аңладыңмы?

САТТАРОВ. Аңладым.

ВИКТОР. Бүген тагын бетон, ә алар аны юл читенә. Бетонга заявка биргәннәр, ә үзләренә кирәкми. Хәзерләнмәгәннәр! Аудар чокырга! Икенче тапкыр алып килдем — анысын да шунда. Аңладыңмы?»

Гади эшче егетнең бу кайнар сүзләре шул яктан әһәмиятле, анда аптырап калу, зарлануның әзе дә юк. Виктор боларны кем очрады шуңа түгел, ә горком секретарен үзенә әйтә. Һәм аның сөйләшү тонына карап күреп торабыз: аның өчен бетонны кайда бушату барыбер түгел (югыйсә, эш хакы барыбер килә бит). Юк, Виктор эштәге кимчелекләр белән килешеп яшәүчеләрдән түгел. Чөнки ул үзен төзелешнең тулы хокуклы гражданины итеп саный, гомумән эшнең шәбрәк баруы өчен кайгырта.

Шунысы кызык, шундыйрак хәл М. Ганиның «Яңгырлы көздә» исемле очеркында да языла. Участок бетонга заявка бирә, ләкин яңгыр юлларны эштән чыгара, МАЗлар күчәрләренә кадәр сазга бата, аларны хәтта бульдозерлар да сөйрәп чыгара алмый. Һәр көнне диярлек шул хәл кабатлана. Шул чак измә-бетон узеленың начальнигы (ул күптән инде кон-

[1] «Театр» журналы. 1972 ел. 12 сан.

тораны бетон белән күмәргә янап йөргән була) үзе махсус участокка килә һәм бөтен бетонны контораның ишек төбенә бушаттыра. М. Ганина шул төштә нокта куя. Д. Вәлиев исә шул ноктадан башлый гына һәм төзелешнең беренче буталчык айларында ничек итеп идарә итүнең яңа стиле туа килүен, төзелешнең яңа этабына җавап бирерлек, фәнни-техник революция дәверенә лаек булырлык идарә итү алымнары тууын күрсәтә. Д. Вәлиев пьесасының буеннан-буена кызыл җеп булып кешенең социаль активлыгы, аның хезмәтенең иҗтимагый роле, тормышта үз урыныңны сайлау турындагы уйланулар сузыла.

— Кеше һәм аның эше дигән нәрсә турында синең беркайчан да уйланганың юкмы? — дип сорый горком секретаре Саттаров төзелеш начальнигы Байковтан.— Эш кешедән зуррак булганда кеше нинди хәлдә кала, бу хакта уйланганың юкмы? һәм кеше эштән вәграк булганда эш нишли?

Төзелешнең күренмәгән колачы Д. Вәлиев пьесасында кешенең зурлыгын, нык-лыгын сынау чарасына әйләнә. Менә беренче карашка эпизодик бер персонаж — проект институтының вәкиле Гоголев. Болай акыллы гына, белемле, шәһәрчә киенә белә торган кеше. Кайчандыр Сатынский аны үзенең иң талантлы шәкертләреннән санаган. Хәзер исә ул Сатынскийның субайлы фундаментлар турындагы идеясенең иң төп дошманы. Бәлки, Гоголев әлеге идеянең яңалыгын аңламыйдыр? һич алай түгел. Ул аның әһәмиятен бик шәп аңлый, үзара сөйләшкәндә Сатынский идеясенең оригиналь булуын һәм ифрат зур экономия бирәчәген әйтә. Бәлки, ул вак һәм көнче кешедер? Алай да түгел. Ул бары мундир аклыгын, үз ведомствосын, ахыр чиктә, үз иминлеген, үз карьерасын саклый. Сатынский идеясе турындагы тискәре фикерен дә Мәскәүдә үк, дәүләт сынауларына кадәр үк әзерләп куйган була.

Гоголевның яшерену өчен уңайлы фәлсәфәсе бар. «Без бәләкәй кешеләр» — аның бөтен асылы менә шушы сүзләрдә чагыла. «...Минем шеф шулай ук бик бәләкәй кеше. Безнең рангтагы кешеләр каршында ул зур кеше, ә гомумән алганда — шулай ук бәләкәй. һәм минем шефның шефы да бәләкәй... һәм безнең һәммәбезнең бәләкәй балаларыбыз бар. һәм әлеге бәләкәй балаларны без бик яратабыз. һәм үзебезнең белгән урыныбызны яратабыз...» Сизелеп тора, Гоголевның үз-үзе белән беренче генә каршылыкка керүе түгел. Ләкин кешене, белгән положениесенә дә карамастан, нәрсә бәләкәй итә соң — Гоголев шуны әйтеп бетерми. Кешене — сөйләргә тиешле урында дәшми утыру, намусына каршы барып булса да, һәр кушканны үтәргә әзер тору вагайта.

Дәүләт комиссиясенең икенче бер вәкиле Качаева баштарак шулай ук бәләкәй кеше булып күренә. Ахырдан ачыклана, ул Сатынский идеясенең әһәмиятен аңлап җиткермәгән булган икән. Гоголевның оятсызларча үз-үзен фаш итүе аның күзләрен ача. Ул үзендә баштагы карашларыннан ваз кичәрлек көч таба, үзе эшләгән институтның проектына каршы чыга. Нәкъ әнә шул моменттан башлап ул бәләкәй кеше булудан туктый һәм укучы каршында кинәт үсеп китә.

Шул ук проблема, дөрес, бераз башкарак яссылыкта, төзелеш начальнигы Байков образы мисалында да күтәрелә. Байков — зур, үзенә күрә ун каль шәхес. Ул тырыш, ихтыярлы, үз эшенә бирелгән кеше. Ләкин Камадагы төзелешнең колачы шул хәтле зур ки, әлеге төзелеш фонында хәтта Байков та ничектер югалып, вагаеп кала. Ул фронттагыча эш итәргә гадәтләнгән кеше. Артиллерия ярдәменнән башка гына, пулемет уты астында чәнечкеле тимер чыбык киртәләрен үтәргә кирәкме?!. Кирәк икән, ул үтә һәм ротасын атакага күтәрә. Теләсә нинди юл белән план үтәргә кирәкме, ул үти, бу эш хәтта артык кыйммәткә төшсә дә. Баш инженер Дунаев белән алар арасындагы конфликт та шуннан башлана. Запаслы ат армас дигән принцип белән яшәргә өйрәнгән Байков дәүләттән яңа миллионнар, йөзләрчә яңа бульдозерлар, яңа техника сорый. Дунаев, кирәккә-кирәкмәскә дәүләт кесәсенә кермик, булган кадәр техникадан рациональ файдаланыйк, ди.

«БАЙКОВ. Үз төзелешеңне яратмыйсыңмыни? Биредә син чит кешеме әллә? Әгәр шулай икән, минем беркайчан да үз янымда төзелешнең патриоты булмаган кешеләрне көчләп тотканым юк.

ДУНАЕВ. Төзелешнеңме, әллә синеңме? Юк. Мин җиңел генә китмим. Үз теләгем белән эштән җибәрегез дип гариза язмаячакмын! Минем андый теләгем юк. Син миңа икенче нәрсәне әйт: кайчанга хәтле без төзелешнең мөһим-

леге белән спекуляция ясарга һәм дәүләтне таларга җыенабыз?.. Сатынский идеясен тормышка ашырырга кирәк, ә без техника да акча даулыйбыз».

Күрәсез, монда ике төрле характер гына бәрелешеп калмый, эшкә ике төрле мөнәсәбәт, төзелешне оештыруга һәм аның белән идарә итүгә ике төрле караш бәрелешә. Әгәр эш кай ягы беләндер кешедән зуррак икән, моннан, беренче чиратта, эшкә зыян килә. Ләкин бит хикмәт шунда, һәр эш кеше өчен, аның киләчәге өчен башкарыла. Шуңа күрә, Д. Вәлиев әсәрендәгечә, эшне кешегә артык кискен тестә каршы кую урынсызрак. Алар берберсеннән аерылгысыз. Кешенең эчке дөньясы, ышанулары һәм ул башкара торган эш арасындагы шундый органик бердәмлекне без Саттаров, Сатынский, Алсу образлары мисалында күрәбез.

Горком секретаре Саттаров образын яшь драматургның җитди уңышы дип бәяләргә кирәк. Ул актив, эшлекле кеше, вакыйгалар арасыннан иң мөһимен тотып алырга, үз артыннан башкаларны ияртергә сәләтле кеше. Миңа калса, әсәр ахырында аны үтерү мәҗбүри түгел иде. Әйе, Саттаров үз-үзен жәлләми, кешедән үзенең авыру икәнен дә яшерә. Семьясы белән дә аерылган кешене үтереп тә куйгач, әллә ничегрәк килеп чыга.

Пьесада башка төрле кимчелекләр дә бар. Ул ничектер таркаурак чыккан, хроникаль-репортажга тартым. Гомумән алганда, кызыклы тотылган, әмма икенче дәрәҗәдәге персонажлар күп, алар бер күренеп алалар да аннан бөтенләй югалалар. Авторга бөтен вакыйгаларны бер төенгә туплау осталыгы җитенкерәми. Ләкин драматург иң зурын уңышлы хәл итә алган: зур төзелешнең сулышын, заман рухын, замандашларыбызның характерларын, аларның омтылышларын, уйхисләрен бирә алган. Шуның өчен дә әдәби ел йомгакларына багышланган җыелышта «Дәвам» пьесасы узган елның иң уңышлы әсәрләре рәтеннән саналды.

Ә. Баянов һәм Д. Вәлиевләр ясаган башлангыч бездә яңа теманы чын мәгънәсендә сәнгатьчә, зур социаль һәм психологик тирәнлек белән чагылдырырга сәләтле көчләр булуы турында сөйли. Әлегә әдәби яшьләр үз сүзләрен әйтмәде. Аларга мин зур өметләр баглыйм. КамАЗда, кою заводы төзелешендә бетончы булып ике әдәби җыентык авторы, шагыйрь Мәхмүт Газизов эшли. Авторның КамАЗ турындагы шигырьләре аерым бер ышандыру көченә ия булулары белән аерылып торалар. Аның бу зур төзелеш турында күләмлерәк әсәрләр иҗат итәргә дә көче җитәр дип уйлыйм. Алабугадан Чаллыга прозаик Э. Касыймов күчеп килде. Дөрес, хәзергә аның КамАЗ хакында язылган әсәрләре күренгәне юк. Киләчәктә булыр дип уйлыйк. Чаллыда яшь һәм башлап язучыларның әдәби берләшмәсе оешты, ул берләшмәгә бетон-изма заводының мотористкасы шагыйрә Сәлимә Шәрипова, прозаик Рәүф Гатауллин, яшь шагыйрь Шәүкәт Сибгатуллин кебек язучылар йөри. Алар үзләренә булган ышанычны акларлар дип уйлыйк.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә була: КамАЗ темасын үзләштерү нигездә уңышлы бара. Бүгенге очерклар һәм репортажлар, төзүчеләр турындагы мәкаләләр иртәгә тарих байлыгына әйләнер. Бу зур тема бәлки безнең әдәбиятка күп кенә күләмле әсәрләр бирер. Шуңа күрә КамАЗ турында язылганнарны инде бүген үк күздән кичерергә кирәк. Бу эш элекке хаталарны кабатламау, тапталган юллардан гына йөрмәү өчен, шул ук вакытта ирешелгән казанышлардан, тупланган тәҗрибәдән иҗади файдалану өчен кирәк.

Гариф Ахунов

# АРДУАН БАТЫР

ПОВЕСТЬ

Укытучым Гази ага Кашшафка багышлыйм.

1



Березники каласында һәйкәл бар. Дәү такыр башлы, мыеклы бер кеше биек постаменттан уйчан гына карап тора. Һәйкәлне карарга килүчеләр мәрмәргә чокып язылган сүзләрне укыйлар:

Мирсәет Ардуанов

*1886—1959*

Укыйлар да уйга калып торалар. Пушкинга һәйкәл бар — шагыйрь. Чайковскийга һәйкәл бар — композитор. Чапайга һәйкәл бар — сугыш герое. Кем ул Ардуанов? Ник аңа һәйкәл куйганнар?

2

Ардуан Мирсәетен замана давыллары кайларга гына илтеп ташламады. Ун яшеннән байларда көтү көтте. Һашим байның йортын яндырышкан өчен бер ел төрмәдә утыртып чыгардылар. Аннары — Казан пекәрниләрендә утын кисте, ипи пешерде, атлы эштә йөрде. Өйләнеп гаилә рәхәтен татырга өлгермәде — герман сугышы чыкты. Патша армиясендә ипилек-тозлык урысча өйрәнде, грамота алды. Ике дөнья бугазга-бугаз килгән дәвердә, кызыллар ягында торып, гаделлек өчен сугышты, егерме беренче елны гына өенә әйләнеп кайтты.

Кайтса — дөнья үзгәргән, дөнья — ярлыныкы.

Совет җир бирде. Сукала, тырмала, чәчүеңне чәч. Кемдер әйтте: «Тукта, энем, ашыкма!» — диде. Еллар буе ярлы-ябагайның җелеген

суырган Һашим байлар тик ятар дисеңме? Ятмый торсын! Адмирал Колчакны җир читенә тәгәрәтеп, Япон диңгезенә төшергәнгә күп тә узмады, купты сәнәкчеләр фетнәсе. Минзәләдән башланды, Актаныш төбәген айкап, Карабашка таба китте. Һашим бай куштаннары кызыл сугышчы Мирсәетнең дә эзенә төштеләр. Аны күрше авылда тотып, җиргә егып салдылар, өстенә менеп, сикерә-сикерә таптадылар. Бәлки ул, әле беркайчан да рәхәт күрмәгән бу фани дөнья белән бәхилләшеп, аяк та сузган булыр иде, табигать әллә ничә кешелек итеп биргән куәте, мәйдан тоткан батырлыгы ярдәм итте — исән калды. Өенә, Мәүгыйзәсе янына кайтканда, бите бәлеш чаклы булып шешкән, күз урыннары сызык кына булып калган иде. Аның күгелҗем-зәңгәрләнеп, тимгел-тимгел булып күгәргән битенә карап Мирсәет икәнен тану кыен иде. Хатыны таныды.

Башны ташка орып булмый, хәсрәтне эчкә йоттылар да совет биргән җирне чәчәргә чыктылар. Игеннәр уңып китсә ни дияр идең кана! Син дигәнчә генәмени?! Яз башыннан бер бөртек яңгыр төшмәде, җир кипте, яргаланды, таш булып катты.

Егерме беренче елны иген-таруны, мал-туарны кырып килгән ачлык афәте Ардуан Мирсәетенә дә кара кайгы китерде. Хәзер ул ялгыз башы түгел иде инде, ике бала, хатыны, үзе — барысы дүрт кашык. Бүрек белән киңәшеп, башны кашып торгач, туган ягы Актаныш авылларыннан: Иске Кормаштан, Зияштән, Каентүбәдән грузчиклар эртиле оештырды, шулар белән бергә Идел — Кама буйларын айкарга чыгып китте. Бер чыккач, Чистае да, Казаны да, Сарапулы да калмады. Еллар газаплы булып, арка-җилкәне ачы тир белән юып, маңгайга сырлар сызып уза торды, Ардуан Мирсәетен, аның эртилен бер нәрсә куа торды — акча. Йорт җиткезергә, атлы-тунлы булырга, адәм рәтле яши башларга кирәк иде. Җилкәдә йөргән күмер кабы, тоз капчыгы, утын пүләне, күпме генә чиләнсәң дә, йорт җиткезерлек рәт бирмәде. Менә шунда килер көнеңне уйлар чак җитте. Уйланырга мәҗбүр итәрдәй кешесе дә табылды.

Ардуановның унбиш кешелек эртиле Пермь пристанена килеп туктаган «Волгарь» баржасыннан тоз бушата иде. Өч сәгать чамасы эшләгәч, эртил ялга туктады. Әле генә баржадан күтәреп чыккан унике потлы тоз ящигының берсен яр буена куеп, шуның өстенә тезелешеп утырдылар да пристань буендагы бер йортта пешертеп алган бер сарыкны, ике казан бәрәңгене, өч бөтен ипине турап-таратып, әвен сугарга тотындылар.

Чирекле шешәдән берәр кружка аракы да әйләндергәч, күңелләре почмакланып, шаулап сөйләшергә керешкәннәр иде, болар янына күн курткалы, картузлы, күрер күзгә утыз яшьләр тирәсендәге бер кеше килеп туктады.

— Ардуанов эртиле шушы буламы?

— Булса ни диярсең?!

— Эшкә ялланырга килдем,— диде күн курткалы, батыр гына.

— Бик мәслихәт,— дип, Ардуанов ике метрлы гәүдәсе белән салмак кына кузгалып, тегенең янына килде. Эш сораучы аның култык астыннан гына иде.

— Эш авыр бит безнең, туган,— диде Ардуанов, аның хәленә кереп.

— Эшнең беркайда да җиңеле юк аның, абзый,— диде күн курткалы.

Бу хәл эртилчеләрне кузгатып ук җибәрде.

— Сынап кара, Мирсәет абзый, сынап кара!

Ардуанов егетләренә ящик өстеннән төшәргә кушып ым какты.

— Менә, туган, шушыны күтәреп, баржага кертеп куйсаң, алабыз.

Күн курткалы ящикка тотынырга уйламады да.

— Син бит аны үзең дә күтәрә алмыйсың,— диде, ирен чите белән елмаеп.
Егетләр ду килделәр:
— Бу ниткән нахаллык!
— Бер йолкыштан мыскыллатып торабыз!
— Анасының иманын!
Ардуанов, ике кулын берьюлы күтәреп, егетләрен тынычландырды да, күн итекле аяклары белән җиргә каты-каты басып, ящик янына килде, иелеп, бер сулышта ящикны җирдән кубарды һәм, күкрәк турысына күтәргән көйгә, баржага таба китте.
Күн курткалы аның аяк астында басманың сыгылып-сыгылып килүен исе китеп сокланып карап торды.
Ардуанов әртилендә мондый хәлләр әледән-әле кабатланып торганга күрә, күн курткалы да онытылган иде инде, ләкин өч-дүрт көннән соң ул тагын грузчиклар барагына килеп чыкты. Зур һәм шыксыз баракның аргы башында карта суккан грузчиклар, таныш күртканы күргәч, дәррәү аның янына җыелып, яңа бер мәзәк күрергә әзерләнделәр. Күн куртканың йөзе бу юлы бик җитди иде.
— Пристаньнарда болганып йөрүегез җитәр мәллә, якташлар? — дип, бик кинәт башлады ул сүзен.— Чын эшкә тотынырга вакыт түгел микән?
— Ә син кем? Сиңа бездән ни кирәк? — диде Бәхтияр-грузчик.
— Фамилиям минем Нурисламов, исемем Нәриман,— диде килүче дусларча.— Мин үзем Казан татары. Дәгъвалашырга килгән дип уйласагыз, ялгышасыз. Миңа сездән ни кирәк дип сорыйсыз икән, әйтәм. Сезнең миңа үзегез кирәк.
Әртилчеләр аны тыгызрак уратып алдылар. Муеннар сузыла төште.
Нурисламов башыннан картузын салды, чәче сирәкләнә башлаган маңгай түбәсен кулъяулыгы белән ашыкмый гына сөртеп торды,— әйтерсең шуннан да мөһимрәк бер генә эше дә юк иде,— кинәт йөзе алсуланды, коңгырт күзләре чаткыланып кабынды.
— Специальность кирәк сезгә, якташлар,— диде.— Профессия, белдегезме? Илдә бик зур эшләр башланырга тора бит. Әйе, әйе. Яңа заводлар, электр станцалары салырга торабыз. Партия әйтә, Совет власте ач мужигы, кырык ямаулы басулары белән әллә кая китә алмас, ди. Тракторлар кирәк, ашлама кирәк, бик күп итеп иген үстерергә кирәк, ди.
— Син якташ булсаң, якташ бул, Нурисламов, бик озаклап әгитләмә. Озын-озак сөйләшергә чама да юк, вакыты да ул түгел дигәндәй, турысын гына әйтеп бир: кая барырга кушасың безгә? И кемгә мөрәҗәгать итәргә? — диде Мирсәет абзый.
Нурисламов, тешләрен күрсәтми генә, калын иреннәре белән балаларча елмаеп куйды. Якташының крестьянча нык, практик акылы аны елмаерга мәҗбүр итте.
— Березнәктә химкомбинат салабыз. Партиянең карары бар. Кил син безгә, Ардуанов.
— Үзем генәме?
— Әртилеңне дә ал. Ничә кеше сез?
— Унбиш.
— Бик шәп. Безгә унбиш мең эшче кирәк.
Моңарчы тыенкы гына тыңлап торган әртилчеләр кинәт шаулаша башладылар:
— Ә без анда барып хур булсак?
— Син бүген монда, иртәгә әллә кайда!
— Ала канатлар бетмәс монда. Пашшул!
Ардуанов күз карашы белән егетләрне тынычландыргач, Нурисламовка өстән аска карап әйтте:

— Ярый, иптәш. Алай да булсын. Бардык, ди. Без соң анда нәрсә отабыз?

— Сез бүген, Ардуанов, унике пот күтәрә аласыз. Әйе, әйе, ә биш елдан? Биш елдан сез күпме күтәрә алырсыз? — диде ул, тынып калган егетләрне күздән үткәреп.— Березнәктә сез һөнәр аласыз, кадровой эшче буласыз. Мин сезне көчләмим. Мин сезгә яхшылык теләп әйтәм.

— Подъемный бирәләрме?

— Бирәбез.

— Туктале, торып тор. Бирәбез дә бирәбез дисең? Син үзең соң кайдан? И кем буласың?

— Кадрлар бүлегеннән мин. Стройкага эшче җыям.

— Күптән шулай диләр аны!

— Бел аны, эш уңмаса, шәфкать көтмә, якташ!

Әртилчеләрне күндереп, пристаньнар белән исәп-хисапны өзгәнче, «Березникхимстрой» дигән хикмәтле сүз халык теленә бик ныклап кереп урнашты. Ардуанов әртиле пароходка төялеп Нурисламов әйткән урынга килеп төшкәндә, борынгы тоз заводларының иске генә бер амбарын өр-яңадан җиһазлап, ишек түбәсенә «Березникхимстрой конторасы» дигән такта элеп куйганнар иде инде.

Амбар тирәсенә котомкалы, фанер чемоданлы кешеләр, атлы олаулар килеп тулган. Шау-шу, ыгы-зыгы. Базар да базар, амбар яны да базар.

Ардуанов якташлары юкмы дип белеште. Һәм исе китте. Әле химкомбинатка кадәрле үк монда биш мең татар эшләгән, шуларның бер мең җиде йөзе Казан якларыннан икән. Арчадан, Кукмарадан, Апастан киләләр, иң күп килүчеләр Актаныштан иде.

Килүчеләрнең кигәне — киндер күлмәк, алача ыштан, тула оек белән чабата. Алар төркем-төркем җыелып сөйләшеп торалар, яки контордан чыккан берәрсен уратып алып хәлләрне сорашалар. Эш шартларының нинди икәнен, акчаның күпмерәк төшәсен белгәч, шуны күңелләрендә йөрткән уйлары белән чагыштырып, чаманы чамага китереп карыйлар да: өметле күренә, бәлкем оттырмабыз дип, үз юлларына китеп баралар. Ара-тирә күн итекле, сатин күлмәкле, пинжәкле, чиртсәң кан тамардай кызыл чырайлы тук кешеләр дә очраштыргалый, аларын нинди нужа куган — хода белсен...

Зырянка белән Талыч елгасы буена кешеләр землянка казый. Атна-ун көн уздымы-юкмы, землянкалардан зур бер кала төзелде. Аш пешерергә дип учаклар ягып җибәргәндә, иртә-кичен елга буйлары аксыл төтен баганалары белән тула иде.

Озак селкенергә ирек бирмәделәр. Килүчеләр баш-күз алуга, грамоталырак кешеләрдән башлыклар сайлап, әртилләр оештырдылар. Ардуановның ул яктан эш җайлырак булып чыкты. Пермьнән үк оештырып алып килгән унбиш кеше янына татар-башкортлардан тагын бер йөздән артык кеше кушылып, алар әртиле бер йөз дә унҗиде кешегә җыелды. Сайланып-кыршылып торырлык затлы һөнәрләре юк иде, беренче көннәрне кая җибәрсәләр, шунда эшләделәр. Урман кистеләр, төп кубардылар, ботак-сатакны, чүп-чарны җыеп яндырдылар. Әртил гомер буе кара эш эшләп, кул көче белән тамак туйдыручылардан җыелган иде — норманы үтәп бардылар. Ай тулганда кулга «получкы» дигәннәре дә, урнашу өчен бирелгән «подъемный» да эләккәч, әртилнең күңеле күтәрелеп, анда-санда вак төркемнәр мәҗлес сыман нәрсә дә коргаладылар. Мирсәет Ардуанов үзе эштән дә, мәҗлес уйнауларыннан да канәгать түгел иде. Ник дисәң — якташлары Нурисламов аларны чын эшкә, специальность алырга дип чакырды. Аннан ары килеп, получка алган саен мәҗлес кора башласаң, кая китә ул! Юк, ярамый болай, эшләгән эшең дә, тәртибең дә аермачык булсын.

Бер-ике ай узуга халык арасында сүз таралды.

— Урман эше беткәч, халыкны торф сазлыгына куып кертәчәкләр.
— Акча дип кенә инде риматиз алыр хәл юк!
— Дайош резин итек!
— Спецовка бирсеннәр! Сазламыкка басма салсыннар! — дип ду килде Курган мужиклары.

Бер атна дуладылар да тындылар. Берәү дә сазламыкка куып кертмәде. Эшкуар Строгановларның борынгы солеварняларыннан бушаган амбарларда ашханә ачтылар. Каралып беткән нарат бүрәнәләрдә кырылмый калган тоз бөртекләре елык-елык итә, эртилләр көндез чиратлашып ашый, кичен шунда ук җыелышка җыела иде.

Дисциплина турында, булачак зур эшләр турында сөйлиләр. «Профсоюз» дигән, «комсомол» дигән сүзләр сөйләнә. Төзелешкә килгәннәр басынкы гына тыңлыйлар, каршы сүз әйтүче юк. Һәркем күңелендә, алданмагаем, кирәк түгелне әйтеп хур булмагаем, дигән уй саклый, эченнән тынуны кулайрак күрә.

Ардуанов үз эртилен җыелышка төп-төгәл алып килә, төп-төгәл алып китә. Профсоюзга да кумәкләп язылдылар: гыйбрәтле сүзләр тыңлыйлар, взнос түлиләр, кырмыска оясыдай кайнап торган зур коллектив белән элемтәләре хәзергә шуннан артмый.

Сентябрь башларында Ардуановны төзелеш башлыгы Крутановка чакырдылар. Әртил хәвефкә калды. Нигә микән? Юньлегә булырмы?

Һәркем хәлле хәленчә Мирсәет абзыйга киңәшен бирергә тырыша. Әртилдә күбесе яшьләр, башлыкларын олылап «абзый» дип дәшәләр.

— Син анда нит... түрәләр алдында бик җебеп төшмә, яме, Мирсәет абзый,— ди Яңа Кормаш егете Нурләхмәт Фазлыев.— Аяк терәп сөйләш, без рабучий сыйныф диген, рабучий сыйныф влачны алды, и шулай булгачыннан безгә барлык кәнкрит шартлар тудырылырга, эш закун буенча йөртелергә тиеш, диген. Ничу монда алдатырга!

Аны Бәхтияр абзый куәтләп җибәрә:

— Сине, кордаш, өйрәтеп торасы юк. Үз акылың үзең белән. Гомер буе тоз ташыган кеше син. Тозлы суга кереп китмәссең дип ышанабыз. Иллә дә мәгәр шунысын да хәтереңнән чыгарма, җаен-җайга китереп кенә, түрәләрнең хәтерен калдырмаслык итеп кенә сөйләш. Дуамаллык белән бу дөньяда пычагым да кырган кеше юк әле.

— Ә сазламыкка керергә дисәләр?! — дип чәчрәп каршы төшә Нурләхмәт.

Бәхтияр абзый башны чайкап куя:

— Менә анысына риза булма, кордаш, дәгъвалашма да, күтәрелеп бәрелмә дә, үз туксаныңны туглап: «Ниту, ниту»,— дип тик утыр.

Ардуанов грузчик заманнарда тозланып беткән иске фуражкасын кулында йомарлап, эртилчеләренең сүзен тыныч кына тыңлый, тыңлаган берен үз бизмәненә сала, мыегына урый; барысы сөйләп, бирәсе киңәшен биреп бетергәч кенә әйтеп куя:

— Шулаен ул шулай да, туганкайлар, ә бүтән эш бирмәсәләр, нишләрбез?

— Ие шул,— дип килешә аның белән Бәхтияр абзый. Төзелешкә ул хатыны, бала-чагасы белән килгән, йортын, мал-туарын сатып килгән, кире борылыр җае юк аның.— Пока без әйбәт чутта торабыз. Без белгән кирелекне генә белә торгандыр нәчәльстуа. Әллә, мәйтәм, аллага тапшырып, җир казуда эшләп карыйбызмы?

— Беләсезме, егетләр, хитри булырга кирәк,— дип сүзгә кушыла Нәфүш-Сайрар кош, ул арада иң яше, туктаусыз сөйләп тә армый торганы.— Тәмле тел белән алдырырга, тәмле тел белән. Син, Мирсәет абзыкаем, песием генә кереп бас түрәләр янына, җайлап-майлап кына болай диген: күбәләгем-түгәрәгем, диген, нәчәльнигем-түрәкәем, диген, сайрар кошым-сандугачым, диген, минем эртилгә җүнлерәк бер эш тапсана, сазлыкларда йөртмәсәнә, диген.

Әртилчеләр дәррәү көлеп җибәрделәр.

Ардуанов дагалы күн итеген, сатин күлмәген, кешелеккә кия торган пинжәген киеп, конторга китеп барды.

Әртилчеләр өмет белән аны озатып калдылар.

## 3

Әле иртәнге сәгатьләр булса да, гөрселдәп агач ауган, Курган мужикларының ачы сүгенеп ат куалаган тавышлары ишетелә; чуар киемле, чабаталы, кайберсе чикмән, беришеләре хәтта кайры тун кигән ирләр, сарафанлы, озын күлмәкле хатын-кыз төркем-төркем булып Строгановлар амбарына — иртәнге ашка баралар, аларның чыр-чу килеп сөйләшкәне, көлешкәне ишетелеп тора.

Урманнар өстенә күтәрелергә өлгергән кояш актарылып ташланган чокырларны, ауган наратларның әле кибәргә өлгермәгән яшел ылысларын, саргайган каен ябалдашларын яктырта.

Иске Кормашта да көздер инде. Өй түрендәге каен саргайгандыр. Ягарга утын әзерли алдылар микән? Получкасыннан үзенә вак-төяккә генә унбиш тәңкәсен калдырып, калганын хатыны Мәүгыйзәгә салган иде. Ат алырга кушты. Атсыз йорт йортмыни ул. Әзрәк җунатсә, бозау алып җибәрерләр. Карыйсың — ике елдан сыер. Олы улы Мирзануры мәктәпкә йөри. Авылда мәктәп ачканнар! Кәшифәсе дә быел мәктәпкә керә болай булгач. Мирзанур дүрт елын чит авылга йөреп укыды. Быел үзләрендә укыр. Балалары белемле булып үсәр, өс-башларын җунатәсе, кеше арасында әдәм рәтле йөртәсе бар...

Мирсәет абзый, үзәге өзелеп, ундүрт яшьлек Мирзанурын, тугыз яшьлек Кәшифәсен, алар белән булашып йөргән чая телле Мәүгыйзәсен күз алдына китерде.

Контор янына җыелган яңа килүчеләрне карый-карый эчкә узды. Коридорга кергәч, стена буйларына чүмәшкән кешеләрнең кәрҗин-чемоданнары аша атлый-атлый, кадрлар бүлеге яныннан үтеп китте. Монда да халык, монда да яңа килүчеләр. Документ көтәләр, сакалмыегы кырылмаган, яшьме-картмы икәнен дә белерлекләре калмаган кешеләр, артык кычкырмый гына, бер-берсеннән хәл белешәләр:

— Пашпорт бирмәделәрме?

— Кире кайтасы булсаң ни хәл итәрсең!

— Әй, голобый, куда лезешь?

— Яп авызыңны, корчаңгы! Салып торып җибәрермен!

— Пашул вон! Микулай заманы түгел бу сиңа!

— Тише!

Мирсәет абзый коридор тулы халыкны ырып-ерып узды да, төзелеш башлыгы кабинетына җиткәч, бик хәтәр дулкынлана башлады. Башыннан фуражкасын салды, коры булса да, итекләрен каккалап, ишек төбендә таптанып алды, шуннан соң гына тәвәккәлләп, ишекне ачты.

— Рөхсәт микән?

Җавап бирүче булмады, чөнки аның тавышы янә шау-шу эчендә күмелде. Бактың исә монда да халык тулган.

— Мөмкин булырмы? — диде ул, ишек төбендә туктап. Ишетүче булмагач, тамак кырып, катырак итеп дәште.

Халык уратып алган фанер өстәл яныннан бер баш күтәрелде. Куе кара чәчләрен ике толым итеп үреп салган, әнис алмадай аппак-алсу йөзле, унтугыз яшьләрендәге бер кыз халык арасыннан килеп чыкты.

— Иптәш Ардуанов түгелме? — диде ул саф татарча.

Мирсәет абзыйның эченә җылы йөгерде.

— Мин идем шул, ускәнем. Кемдер чакырган, имеш, диделәр. Чын булса?

— Әйе. Сезне сәгать сигезгә чакырдык. Әле унбиш минут вакыт бар. Чак кына сабыр итеп торыгыз. Мин Никифор Степановичка хәбәр итим. Менә минем урындыкка утырып торыгыз.— Урындык китереп бирде дә, идәнгә шык-шык басып, түр бүлмәгә кереп китте.

Ардуанов бары тик шунда гына үзе кергән бүлмәнең әле башлык бүлмәсе түгел, алгы бүлмә икәнен шәйләп алды. «Шундый тупас халык арасына каян килеп эләккән бу оҗмах кошы?» — дип үзалдына елмаеп куйды, яшьлеге, кыз урлаган вакытлары исенә төшеп, күңеле рәхәтләнеп китте. Кыз куйган урындыкка утырам дигән иде, егыла язып калды, аны алып киткәннәр иде инде. Күрәсең, эшләрен бүлдергәнгә ачулары килгәндер. Әнә бит бер дистә күз әле дә аңар төбәлеп, өнәми генә карап тора.

— Рәхим итегез, иптәш Ардуанов,— дип, әлеге чибәр кыз аны усал күз карашларыннан коткарды.

Башлык кабинетында аны коңгырт чәчләрен ян-якка тарап куйган, костюмлы, галстуклы кеше каршылады. Буйга ул Ардуановтан аз гына калыша, әмма гәүдәгә шактый ук чандыр иде.

Ардуанов бүлмәгә күз йөртеп алырга өлгерде. Монда да, алгы бүлмәдәге кебек, фанер шкафтан, зур имән өстәлдән һәм ике-өч урындыктан башка берни дә юк иде.

Башлык үзен «Крутанов Никифор Степанович» дип таныштырды, кунагын урындыкка утыртып, үзе дә аның янына урындыгын тартып утырды да, Мирсәет абзыйга күптәнге танышы кебек карап, гади генә сүз башлады:

— Килеп яхшы иткәнсез, иптәш Ардуанов.— Пинжәгенең түш кесәсеннән чынаяк зурлыгындагы чуен сәгать чыгарып, күз төшереп алды.— Килмәсәгез үзем барырга тора идем.— Пауза ясады.— Укый-яза беләсезме?

— Беләм,— диде Ардуанов.

— Бик яхшы, алайса. Менә шушы газетаны карый торыгыз әле. Ул сезнеңчә язылган. Минем ашыгыч язу җибәрәсем бар иде.— Сөйләгән уңайга газетаны дүрткә бөкләп, уч төбе белән кирәкле урынын каплап күрсәтте.

Газета Мирсәет абзыйга таныш, Свердловскида чыга торган «Социализм юлы» газетасы иде. Ул аны грузчик булып эшләгән чагында ук ил хәбәрләрен, кайда эшче кирәклеген белү өчен караштыргалый иде.

Крутанов күрсәткән урынны имән бармагын йөртеп укырга кереште: «ВКП(б) Үзәк Комитеты карары. Березники химия комбинатын төзү турында...» Бармак йөрткән уңайга аның иреннәре дә кыймылдый иде. Кинәт ул Крутановның кәгазь язмавын, аны бик зур игътибар белән күзәтеп торуын сизеп алды, башын газета битеннән күтәргәч, Никифор Степановичның җилдә яргаланган юка иреннәре елмаерга итенүен күрде. Әнә шул елмая башлаган юка иреннәр Крутановның какча йөзендәге житдилекне алып ташлаган, җете зәңгәр күзләре җылы бөркеп карыйлар иде.

Үз гомерендә бик күп күзләр күргәне булды Ардуановның: башлыкларның күбесе үз кул астындагылар белән күзгә карамыйча, кәгазьгә карап сөйләшәләр. Бу күзгә карый, елмаеп карый. Эшнең хәтәрен кушарга җыена булса кирәк. Нык бул, Мирсәет, бирешмә.

Крутанов өстәл янынnan чыгып, янә Мирсәет абзый янына килеп утырды.

— Шушы көннәрдә «Уралсевтяжстрой» тресты Березникида химкомбинат салырга керешә. Хикмәт шунда, иптәш Ардуанов, беренче эшне торф сазлыгыннан башларга туры киләчәк.

— Ни өчен сазлыктан?
— Станцадан төзелеш мәйданына дамба сузарга кирәк. Төзелешкә кирәкле барлык җиһаз шуннан киләчәк. Соңыннан тимер юл тармагы сузарбыз.
— Ә минем монда ни катнашым бар?
— Хикмәт шунда, иптәш Ардуанов, без, төзелеш җитәкчеләре, дамба салуны синең артельгә тапшырырга булдык. Дөресрәге, синең артельдән кулайрак артель булмас дип таптык.
— Ничек була инде бу? — диде Ардуанов. Чәчсез такыр башын сыпыргалап дәшми торды.— Без бит грузчик. Без бит торф чыгарып өйрәнмәгән.
Крутанов аның колач җитмәс киң җилкәсенә, зур мыегына, йөнтәс кара кашларына, кара-кучкыл түгәрәк битенә карап, беравык дәшми торды. Аннары татарларның эшкә батыр булуын, бер тотынса көн үтсенгә түгел, булсынга эшләвен ихлас күңелдән сөйләп китте. Пермьдә дә, Мәскәүдә дә татарлар белән бергә эшләргә туры килүен әйтеп, сөйләгән сүзенең хак икәнен раслап куйды.
— Ни өчен имынны без? — диде Мирсәет абзый, әртилчеләрнең үзен озатып калуларын искә төшереп.
Крутанов аның зур коңгырт күзләре хәйләсез каравын, сүзнең чынысын көтеп торганын аңлады. Шунлыктан әйтер сүзен ерактан уратмыйча, авызында әвәләмичә әйтеп бирүне кирәк тапты.
— Без, әлбәттә, башкаларны да куша алган булыр идек. Сине, иптәш Ардуанов, миңа партиядәш иптәшем тәкъдим итә.
— Кем ул?
— Нурисламов.
— Нәриманмы?
— Нәкъ үзе.
— Ә сез аны каян беләсез?
— Без аның белән Пермьдә заводта бергә эшләгән идек. Инде менә төзелешкә дә бергә килдек.
— Һмм... Менә бит ул... знакум,— диде Ардуанов, танышын очраткандай шатланып, ләкин артык җәелеп китүеннән янә уңайсызланып, сүзсез калды.
Крутановка форсатны ычкындырмаска кирәк иде.
— Менә шулай, иптәш Ардуанов. Минем партиядәш иптәшемә ышанмаска хакым юк. Аннары тагын шул ягы бар: синдә пролетар закалкасы.
— Ә сез каян беләсез?
— Анкетаңны карап чыктым. Патша төрмәсе дә таныш сиңа. Сугыш мәктәбен дә узгансың. Аннары мин бит үз күзем белән күреп торам: көн саен сине сорап килэләр, кстати, безгә килгәндә ничә кеше иде артелеңдә? Унбишме? Ә хәзер ничә?
— Бер йөз дә унҗиде.
— Менә бит! — дип яратып баш какты Крутанов һәм, җавап көтеп, Ардуановка төбәлде.
Мирсәет абзый уч төбенә йөткеренгәләп алды да аяк өсте басты.
— Булыр, иптәш Крутанов,— диде нык итеп.
Крутанов кинәт дулкынланып урыныннан кузгалды.
— Мәсьәләне аңлаганың өчен рәхмәт, иптәш Ардуанов. Мин шулай булыр дип ышанган да идем. Тик менә нәрсә: хәзергә спецовка юк. Итек тә бирә алмыйбыз.
— Чабата булырмы?
— Чабата кайтарттык. Өченче участоктан, складтан алырсыз. Бүген үк әйтермен.
— Инструмент?
— Хәзергә: көрәк, кәйлә, лом, тачка, носилка.

— Кайчан эш башлыйбыз?
— Иртәгә иртүк.
— Яхшы,— диде Ардуанов, баш селкеп. Саубуллашкан чакта Крутанов каты итеп аның кулын кысты:
— Эш авыр булачак, иптәш Ардуанов. Ике артель бу эштән баш тартты, егетләргә туп-туры әйтегез, төзелеш темпы эшне ничек башлауга, ягъни сезгә бәйләнгән.
— Аңлыйм,— диде Мирсәет абзый, ышанычлырак булсын өчен: «Дело будет!» — дип өстәүне кирәк тапты.
Ул, килгәндәге кебек үк, гөрселдәп агач ауган, һай-һулап ат куалаган тайга юлыннан кайтты. Чокыр-чакырлар, ауган төпләр аркылы тиз-тиз кайтты. Актарылып ташланган җир дә, ауган агачлар да, гөрселдәү тавышлары да хәзер аңа ничектер үз иде, якын иде, аның ул эшкә мөнәсәбәте бар иде инде. Эш башлауны тапшырганга аның күңеле кузгалган, яңа бер үзгәреш сизеп дәртләнгән иде. Менә син, хикмәти хода, бармаска, торф сазлыгында эшләмәскә дип күңеленә беркетеп килде, ә үзе каршы торып бер авыз сүз әйтмәде. Әртил алдында вәгъдәсез булды түгелме соң ул? Бигрәк кешечә сөйләште шул. Таш булып таш эрегән булыр иде...

## 4

Урал тайгасын сискәндереп мылтык атылды. Кулына ике көпшәле ау мылтыгы тоткан Никифор Крутанов көлтәсе белән чәчелгән утка, болыттай бөдрәләнеп, һавада эленеп калган аксыл төтенгә беравык карап торды да әмер көтеп тын калган эшчеләр әртиленә дәште:
— Башладык, иптәш Ардуанов!
Мирсәет абзый саллы зур көрәген ашыкмый гына җиргә батырды, каерып торып алган бер кантар балчыкны җилкә турысына ук күтәреп, сабан туенда сөлгедәшен селтәп аткан гайрәт белән уң тарафка ыргытып җибәрде. Бу минутта аның бөтен уе әртилчеләрендә иде, ул аларга ошарга, үрнәк булырга тели иде.
Әртил башлыгыннан биш адымнар читтәрәк басып торган Бәхтияр Гайнуллин — әртилдә Ардуановтан кала икенче өлкән кеше — уч төбенә төкереп һәм авыз эченнән нидер сөйләнеп, көрәгенә тотынды. Өченче бер урында Нәфүш-Сайрар кош уены-чыны белән: «Лә илаһы-иллаллаһы, ходаем, үзең мәдәт бир, Ардуан батырга сихәт бир, бар тапканымны, ашаган вә капканымны өйләнмәгән хатыным Зөлхәбирәгә, Гөлхәбирәгә, Миңлениса, Җимлениса, Бибисара җаныкайларыма багышладым»,— дип, торф сазлыгын дуамал бер көч белән актарырга тотынды.
Ун минут та узмагандыр, җир өсте көрәкләр ялтыравыннан, бер иелеп, бер тураеп торган җир казучылардан гыйбарәт иде инде.
Носилка белән балчык ташучылар әрле-бирле узып йөри башлады, зур бер полоса итеп агачы киселгән тайга төрле тавышлар белән тулды.
Прораб Борис Зуев юл башындагы кешеләргә татарча сүз кушып, эш тәртибен аңлатты. Ул күбесе киндер күлмәк-ыштанлы, чабаталы әртилчеләрдән аерылып тора, аның өстендә — каеш белән буган яшькелт гимнастерка, аягында — күн итек. Борис — Алабуга ягында үскән егет — русча да, татарча да бик әйбәт белә, шунлыктан аны татарлар белән башкортлардан җыелган өченче участокка куйганнар иде.
Мирсәет абзый, сулыш алырга дип туктаган арада, әртиленең басу киңлеге араны иңләп, баш күтәрми эшләвен күрде. Күңеле тынычлана төште. Тик әле җанында һаман бер борчу да сакланып тора иде: ахыргача шулай түзәрләрме?

Дамбаның торфлы балчыгын алып бетереп, суын агызу өчен ике ай вакыт кирәк, диделәр. Хәзер сентябрь, көннәр әле җылы тора, ләкин гел шулай тормас бит! Октябрь башларында суытачак, салкын сулы сазламыкта чабатадан, киндер күлмәк-ыштаннан ничек эшләрләр? Дымлы балчык хәзер үк инде чабаталарга ябышып хәлне ала, чолгаудан дым тартып, аякны әчеттерә.

Мирсәет абзый эшкә күн итектән дә чыга алган булыр иде, ләкин аның башкалардан аерылып торасы килмәде, кат-кат ыштыр урап чабата киде.

Менә алар янына төзелеш башлыгы Крутанов белән прораб Зуев килеп җиттеләр, алар инде өченче участокны әйләнеп чыкканнар иде.

— Эшләр барамы, иптәш Ардуанов? — дип, ягымлы итеп, шул ук вакытта бигүк төчеләнеп тә китмичә дәште Крутанов.— Синеңчә ничек, җир казучыларга оешкан рәвештә ял бирә барырга кирәк булмасмы?

Мирсәет абзый көрәген җиргә кадап:

— Ял бирү мәслихәт, Никифор Степанович. Егетләрнең беренче көнне үк гайрәтен чигерү ярап бетмәс,— диде.

— Ничегрәк ял иттерәбез?

— Учаклар ягып җибәрергә кирәк. Алмаш-тилмәш аяк-чуны киптерербез.

— Дөрес идея. Тагын?

Мирсәет абзый бу юлы төзелеш башлыгына түгел, шыпырт кына, татарчалап Зуевка әйтте:

— Прораб иптәш... безнең халык бит, үзең беләсең, чәйгә бик әвәс, әнә шул ял иткән чакта берәр кружка кайнар чәй эчертә алмабызмы?

Крутанов муенын сузып прорабка таба борылды.

— Әртил башлыгы нәрсә ди?

Зуев аңа Мирсәет абзыйның гозерен аңлатып бирде. Крутановның аксыл-саргылт кашлары язылып, күзләре яктырып китте.

— Ә нигә, учак ягуны бирәү дә тыймый,— диде төзелеш башлыгы.

— Учак ягу озак түгел анысы...

— Соң, шулай булгач?

— Чәй каян алырга?

Крутанов, прорабка карап, өзеп кенә әйтте:

— Чәй белән шикәрне ашханәдән китерт.

Бер җылы сүз кыш буе җылыта, диләр. Сүзе аяк астында калмаганга, Ардуановның җаны җылынып китте.

Прораб белән башлык китеп ярты сәгатьләр чамасы узды микән, алар янына җигүле ат арбасында бак китерделәр. Арбада олаучыдан тыш Зуев үзе дә бар иде. Ул арбадан җиңел генә сикереп төште дә баганага тимер чыбык белән элеп куйган рельс тимерен даң-доң кага башлады.

Җир казучылар, көрәкләрен дымлы җиргә батырып, ялга туктадылар.

Ардуанов, ярдәмчесе Исәнгол Юлдыбаевны чакырып, учак ягарга кушты. Башкортлар — далада ут ягып өйрәнгән халык — урманнан коры-сары җыеп алып чыгып, әллә ни арада өч-дүрт урында учак дөрләтеп җибәрделәр. Әртилчеләр, калай кружкалардан алмашлап кайнар чәй эчә-эчә, прорабны мактадылар, аяк-чуларын киптереп алдылар.

Бәхтияр абзый, ялдан һәм кайнар чәйдән күңеле күтәрелеп:

— Кул җилешенә әйбәт иттең, Мирсәет туган. Әллә, мәйтәм, икенче мәртәбә ялга туктаганда берәр чүлли дә килешеп куясыңмы? — диде.

Аның сүзен ишеткән башкорт егетләре дә авызларын ерып килеп җиттеләр.

— Кымыз һорарга кәрәк. Ә нәмә, һинең һүдең закун, әртилсе! Урыссаны ла һәйбәтрәк һукалайһың! — диештеләр.

— Анысы булмас,— диде Ардуанов.— Чуллиләр, кымызлар өмет итә торган булсагыз, башка әртил эзләгез. Кузгалдык, җәмәгать, без эшлисе эшне озын койрык сарбай килеп эшләмәс. Рельсыңны сук, булмаса, Борис.

Чаң суккач, дәррәү кузгалдылар.

— Әртил башлыгының талканы коры булырга ошай,— диде арттарак калып килгән Кинъябулат. Ул моны ачуланып түгел, елмаеп әйтте.

Тагын берничә минуттан көрәкләрдән авыр дымлы балчык оча, носилкалы егетләр йөгереп йөри, юл өчен калдырылган аралыкның ике ягына тау өелә башлады.

## 5

Ардуанов әртиле эшләгән урыннан өч чакрымнар читтә, Зырянка елгасының бөдрә таллар үскән тугаенда, өч кеше балык тотып утыра иде.

Кыршылган күн кепкалы, чаларган каты мыеклы, күңелгә шом сала торган каты тавышлы Сагайкин, юл кәҗәнен астына җәеп салып, җимле кармагын су өстенә ыргыткач, трубкасына тәмәке төеп ут кабызды:

— Татарва кузгалды, сиздегезме?

— Тайганы белмиләр әле алар...— диде гамьсез яшь чырайлы Шалага, җилкә аша төкереп.— Бер көн эшләрләр, ике көн, аннары — әллүр два креста!

— Яшь син, Петруся! Синең өчен дөнья — самогон да финка, чечетка да красотка! Татар — чыдам халык. Илле градуслы салкынга да, баш пешәрлек челләгә дә түзә! Башкалар спецовка таләп итеп эшкә чыкмады, алар чыкты.

— Нәтиҗә нинди?

— Син бит яшь кеше. Үзең нәтиҗә яса. Аңладыңмы?

— Аңламаслык нәрсәсе бар аның! Син, господин Сагайкин...

Сагайкин күз агын әйләндереп Шалагага карады:

— Ташла боргалануыңны! Ниткән господин булыйм мин сиңа? Постройком секретаре иптәш Сагайкин! Аңладыңмы?

Шалага яшьлеккә хас пошмас гамьсезлек белән үчекләп елмайды:

— Миңа барыбер: иптәш ни, господин ни! Икесе дә начальство. Тик мин, Ксенофонт Иванович, акылга сыйдыра алмыйм: нишләп син, иптәш постройком секретаре, ике сүзнең берендә, аңладыңмы, аңладыңмы, дип сорыйсың?

— Ә нәрсә дип сорарга боерасың?

— Аңлата алдыңмы? — дип сорарга кирәк.

— Нинди аермасы бар?

— Аңладыңмы дигәндә син үзеңне акыллы, мине дурак дип саныйсың. Аңлата алдыңмы дигәндә, киресенчә, син дурак, мин акыллы булып чыгам.

Сагайкин, трубкасын суырып, уйланып торгач, мыегын дерелдәтеп көлеп җибәрде.

— Беләсеңме, Шалага, теге заманда булса, начальство сине күп лыкылдатып тормас иде. Камчы белән бер генә орыр иде. Кемнең акыллы, кемнең дурак икәнен белер идең син! Аңлата алдыммы?

— Аһа,— диде Шалага, аңардан да сабыррак тавыш белән.— Заманасы ул түгел, Ксенофонт Иванович.

— Я, ярый, теш ыржайттык, җитәр...— диде Сагайкин.— Шаян сүзне килер көннәргә саклыйк.— Үзләреннән берәр адым читтә, әңгәмәгә

кушылмый балык калкавычына карап утырган киез эшләпәле, кәжәнле, тонык йөзле кешегә дәште:— Ә син ник дәшмисең, Шакир?

Эшләпәле селкенеп куйды, кармагын судан алып, яңа селәүчән кидертеп, яңадан салгач, ашыкмый гына әйтте:

— Сабыр итәм әле мин, Ксенофонт. Чуртан эләккәнне көтәм.



## 6

Төшке ашка кайтканда, бригаданы берьюлы ике яңалык көтә иде. Беренчесе — Строгановлар амбарына вакытлыча корган ашханәгә плакат элгәннәр: «Бөек төзелешне беренче булып башлаган ардуановчыларга сәлам!»

Плакатның ике телдә: русча һәм татарча булуы егетләрне сөендерде. Алар шаулашып сөйләшергә, тойгыларын уртаклашырга тотындылар. Балчык эшендә эт булып арысалар да, үзләренә булган шундый игътибар күңелләрен күтәреп җибәрде.

Яңалыкның икенчесе — Әдәми тауда Павел Громов әртиле бараклар салырга керешәчәк. Җир казуда кем дә кем кубикларны күбрәк бирә — шулар беренче булып землянкадан баракларга күченә.

Бу хәбәрне постройком секретаре Ксенофонт Иванович Сагайкин әйтте. Ардуановлар бригадасын ашханәдә ул үзе каршы алды, эшне коры тотып, өстәлләр янына урнаштырды, тәлинкәләргә аш бүлгәнне көткән арада кыска гына сүз сөйләде:

— Без Идел грузчигы Ардуановка исәп тотып ялгышмадык. Ардуанов артеле бөтен төзелешкә үрнәк күрсәтте. Юкны таптырып, саботажлык итәргә теләүчеләр авызларын күтәреп калдылар. Котлыйм, иптәшләр, уңыш телим. Кем дә кем ялкаулана, кем дә кем прогул ясый һәм шул сәбәпле социализм төзүгә аяк чала, аңар безнең арада урын булмаячак.

Сагайкин өстәл янында сабыр гына утырган Мирсәет абзыйның кулын кысты. Ардуанов постройком секретаренең кулы каты икәнен тоеп: «Моңардан уңарбыз, шаять»,— дип, күңеле булып уйлады.

Табынга җәелгән ак эскәтер, стенадагы Ворошилов портреты, көндәлек кысыр солы өйрәсе урынына бирелгән итле токмач әртилчеләрнең кәефләрен янә бер мәртәбә күтәреп җибәрде.

Бик җәелеп китмичә генә тамак туйдырып алгач, туп-туры эш урынына юнәлделәр. Төштән соң да темпны киметәселәре килмәде. Шулай да тук карынга эш әкренрәк барды, көрәкләр төшкә кадәрге тизлек белән җилләнеп очына алмады. Киндер бияләе булмаганнарның уч төбе кабарып чыкты. Яшьрәкләрнең биленә төште. Бирешергә ярамый иде: тешне кысып, билне нык буып эшләделәр. Көрәкләрне иңбашына салып өйгә кайтырга чыкканда, кояш Усолье урманнары артына баеп бара иде инде.

Кичке ашны ашагач, сазга баткан аяк-чу, тирләгән тән белән землянкаларга кайтасылары килмәде, әртилләре белән җыелып, Зырянка елгасына су керергә киттеләр.

Көннәр кояшлы торганлыктан, сентябрь башы булса да, су суык түгел иде әле. Шапыр-шопыр йөзделәр, чолгауларын, ыштырларын юып, үзләре сабынлап юынып алганчы, җир өстенә эңгер инде. Мирсәет абзый борчыла башлады, иртәгә иртүк эшкә чыгасы барын әйтте. Ләкин Исәнгол Юлдыбаев егетләре — Агыйделдә, Димдә су кереп үскән башкорт узаманнары — ашыгырга теләмәделәр. Беренче көннән үк егетләрнең иреген тыю уңайсыз иде, шуңа күрә Мирсәет абзый сабыр гына аларны көтте. Башкортлар судан чыккалаганчы, әртилнең бөтән егетләрен төркем-төркем итеп озата торды.

Үзе башкорт егетләре белән бергә кайтты.

Су кергәннән соң җиңеләеп калган эшчеләр, үзара гәрләшеп, аулак урман юлыннан кайталар, эшләр әйбәт башланды бит әле, болай барса, бигүк оттырмабыз, палучкыдан өс-баш рәтли алырбыз, дип хыялланалар иде.

Урманның иң куе урыныннан чыкканда, кош сайравына гаҗәпсенеп туктап калдылар. Сентябрьдә ниткән саташкан кош булыр бу, ә? Әллә берәрсе кошларны үчекләп йөриме?

— Калай матур һайрай, үзәктәремде өзеп ала,— дип, Кинъябулат һәммәсе өчен берьюлы хисен белдерде.— Дим буенда сагында алай апарук һайрамай ине бит ул. Әллә, булмаһа, бертиклем тыңлап алабызмы? Нәмә ашыгабыз әле без?..

Туктап, бер урынга өелделәр. Нәкъ шул мизгелдә егетләрнең баш өстеннән зур бер таш очып, нарат кәүсәсенә килеп бәрелде. Аннары кинәт барлык яктан таш, кирпеч, балчык кантарлары оча башлады. Кемдер башын тотып, ачыргаланып кычкырып җибәрде.

— Ятыгыз! — дип кычкырды Ардуанов.

Дәррәү яттылар. Кошчык әле һаман өздереп сайрый иде. Кай тарафтадыр байгышның уфылдап куйганы ишетелде.

«Безнең беренче булып эш башлавыбыз кемнеңдер эчен пошырган,— дип уйлады Ардуанов яткан җиреннән.— Әртилне бүлгәләп йөртмәскә, саграк булырга кирәк».

## 7

Төнлә булган хәлгә күңеленнән борчылса да, Мирсәет абзый аны төзелеш житәкчеләренә җиткермәде. «Гадәти хәл, спецовка белән уңайлы эш шартлары таләп итеп тә ниятләре барып чыкмаган бузатерлар бездән үч ала,— дип фикер йөртте.— Көнчелек нишләтмәс. Таш атып нәрсә кыралар, бер атарлар, ике атарлар да арыгач туктарлар».

Ялгыша иде Мирсәет абзый. Бер ай эшләгән арада төзелештә Ардуановларның дошманы күзгә күренеп артты. Кассага акча алырга килгәч, башка әртилләр аларга өнәмичә, дошман күз белән карыйлар, чөнки Ардуановлар получканы бер ярым мәртәбә артык ала, алар әртилендә прогул ясаучы, эш нормасын үтәми калучы юк иде. Җыелышка килгәч тә, алар адресына төртмәле сүзләр ишетелеп тора. Чөнки хезмәт дисциплинасы ягыннан аларны һәр вакыт үрнәк итеп сөйлиләр.

Каш астыннан карауларга, төртмәле сүзләргә дә түзәргә булыр иде, тагын бер атнадан Нәфүш-Сайрар кош белән Кинъябулатны Зырянкага балык тотарга барган җирләреннән авыз-борыннарын канатып кыйнап кайтардылар.

Мирсәет абзый көне буе күңелсез йөрде. Йөзе борчулы, кашлары җимерелгән, күңелендә төзелеш башлыкларына карата үпкә дә бар иде. Нәрсә карап йөриләр, ник тәртип урнаштырмыйлар? Әртил белән әртилнең сугышканын көтәләрме? Алайга китсә бит — Ардуаннныкыларны җиңәрлек әртил юк әле төзелештә. Болай ярамый, чарасын күрергә кирәк. Өч чакрым гына ары Веретья поселогы, поселокта патша заманыннан ук калган төрмә бар, стеналарын дегеткә буяп, нарат бүрәнәдән салганнар. Милиция постлары оештырырга, азу теше ярган хулиганнарны җыеп ябарга кирәк. Бер дә, ике дә җәзасыз калгач, узынырлар алар...

Берьюлы ике егетнең кара канга батырып кыйналуы әртилнең дә кәефен алган иде, ул көнне сүлпәнрәк эшләделәр. Көндезге аш вакытында Ардуанов әртилне Юлдыбаевка тапшырды да туп-туры конторга китте. Исәбе мәсьәләне «кабыргасы белән» кую иде. Ләкин ул анда

төзелеш башлыгы Крутановны да, партком секретаре Хангильдянны да, постройком председателе Мицкалевичны да очрата алмады. Төзелеш гаять зур мәйданда бара: Селин сазлыгын арчып, узкоколейка салырга җыеналар; станцага цемент, чуерташ, металл конструкцияләр төялгән эшелоннар килеп туктаган — аларны кабул итеп, комбинат булачак урынга китерергә кирәк. Үзәк дамбаның өлгереп җитмәве кулны тота. Шуңа күрә житәкчеләр, кырыкка ярылырдай булып, участоктан участокка чабалар иде.

Мирсәет абзый инде житәкчеләрне очрата алудан өмет өзеп, кайтырга чыккан иде, юлда аңа Сагайкин очрады.

Ксенофонт Иванович аны постройкомга алып керде. Янак сеңерләрен биетеп, тешен кысып тыңлады, кулларын артка куеп, ишекле-түрле йөреп тыңлады. Озаткан чакта әйтте:

— Борчылмагыз, иптәш Ардуанов, тәртип булыр! Социализм төзелешенә аяк чалучы бузатерларның тамырына балта чабарбыз.

Бер көн узды, ике көн узды, тәртип урнашмады. Ул арада бараклар салучы Громов әртилендә сугыш чыкты. Эш нормасыннан риза булмаган ике бузатер әртил башлыгы белән сүзгә килгәннәр.

Ниндидер Ардуанов безгә закон түгел, адым саен норма арттыруга без категорически каршы, дигәннәр.

Әртил кинәт икегә бүленгән, бер як Громовны яклый, бер як — бузатерларны, әлеге ике җәнҗалчы утка керосин сибеп тора. Дәгъвалаша торгач, сугышып киткәннәр. Йодрык белән, утын пүләне белән, кулга ни эләкте шуның белән. Канга баткан ике кешене больницага алып киткәннәр.

Балта осталары икенче көнне көне буе эшләмәде. Бу инде төзелешнең бер участогын туктату, димәк, шуңа бәйле рәвештә, җир казучы Ардуанов әртиленә дә йогынты ясау иде. Ник дисәң, суыклар инде башланырга тора, землянкаларда юеш, суык тиеп йөткереп йөрүчеләр күренә башлады.

Кирәк бит, өченче көнне, землянка янында учак яккан Исәнголга читтән килеп чыккан берәү, тәмәке сораган сылтау белән, бәйләнеп киткән. Юлдыбаевның кан бик кызу: оча-куна, бәйләнүче өстенә килә бу. Тавышка башкорт егетләре йөгереп чыга. Горур халык, кимсетергә юл куймый торган халык. Каннары кайнап, ярсынып, рәнжетүчене җир йөзеннән себереп ташларга итенәләр. Ардуанов, егетләрне үгетләпялынып, сугышны көч-хәл белән туктатып калды. Туктатуын туктатты, ләкин күңеле тынычланмады. Көн дә, көн дә үгетләп кенә котылып булмас бит, сугыш оештыручы, эшче халыкның күңелен бимазалаучы хулиганнарны авызлыкларга кирәк.

Ардуанов үтенече белән шул ук көнне кичкырын Крутанов җыелыш җыйды. Көндез ашханә, кичен клуб итеп җайлаштырылган тоз амбарына эшче халык килеп тулды. Төзелеш житәкчеләре барысы да килгән, өстәвенә, ышанычлы булсын дип, Веретьядән ике милиционер да чакырганнар иде. Житәкчеләр үзләре халыкка күренердәй урында, идәннән ярты гына метр биегрәк итеп эшләнгән сәхнә сыман урында утыралар, милиционерлар стена буена басканнар. Күгелҗем төстәге шинель, якага таккан кубиклар һәм бил каешын тартып торган авыр наганнар кайнар канлы егетләрнең эченә шом салырлык иде.

Җыелышны житди башлап җибәрделәр. Никифор Степанович Урал үзәгендә салыначак химия комбинатының әһәмияте, икмәккә туенмаган авылларга кирәкле ашлама турында сөйләде.

Аннары ул төзелешкә комачау итүче хулиган-бузатерларга каршы махсус комиссия төзелүен, аның житәкчесе итеп постройком секретаре Сагайкин иптәш билгеләнүен әйтте. Озакка сузып тормастан, сүзне аңа бирде.

Ялт итеп чистартылган биек кунычлы сары хром итектән, яхшы галифе чалбардан, пинжәк һәм галстуктан чабаталы-чикмәнле халык алдына, өстәл кырыена чыгып баскан Сагайкинны халык сагаебрак каршы алды. Аерма бик зур иде.

— Ил, күзен төбәп, безгә карый,— диде Сагайкин.— Азот-тук заводы — илнең беренче химия флагманы. Азот — капитализм белән кушылганда — җимерү, кыру, сугыш һәм үлем. Азот — социализм белән кушылганда — югары уңыш, хезмәт кешесенең тормышын бөтәйтү, ахыр килеп, азот — безнең шартларда культура. Шулай булгач, әйдәгез, киләчәк көнебезне матур итеп корыйк. Социализм иленең индустриясен нык итеп салыйк.

Амбарда дымсу, суык иде, йөзләгән халык сулавыннан ул җылынып китте. Сагайкин сүзләреннән соң халык кузгалышып, гөжләп алды.

— Ә хулиганнар? Нишләтәбез аларны?! — дип кычкырды карлыккан тавыш. Аны шундук икенчесе эләктереп алды:

— Вәйт имынны! Җитәкче булсаң, син безгә шунысын әйт!

Ксенофонт Иванович пөхтә итеп таккан галстугын рәтләп, тавыш басылганны көтеп торды.

— Мин бу сорауны көткән идем, иптәшләр. Безнең төзелеш көн саен сәләтле төзүчеләрне алгы планга чыгарып тора. Пермь грузчигы Ардуанов җитәкләгән артель ай буена эш нормасын бер йөз дә кырык процентка үтәп килде. Балта осталары артелен Павел Громов шулай ук беренче рәткә алып чыкты. Коммунист Николай Вотинов слесарьлары якын көннәрдә су кудыру станцасы монтажларга керешә. Алар башкарган эш меңнәргә үрнәк.

— Ә хулиганнарны нишләтәбез? — дип, баягы карлыккан тавыш тагын кычкырып җибәрде.

— Дөрес! Громов әртилен эштән туктаттылар.

— Бараклар житешмәячәк.

— Землянкада кыш чыгабызмыни?

Халык бердәм шаулый, амбарның төрле-төрле почмагыннан ачы итеп әйткән усал сүзләр яңгырап-яңгырап китә иде.

Крутанов халыкны кыңгырау шалтыратып тынычландырган арада уйлап алды: «Җыелышны ардыра. Халыкны үчекли... Эшчеләр бит матур сүз тыңларга түгел, конкрет фикер ишетергә килгән. Эх, комиссия председателе итеп Мицкалевичны куярга иде. Ул Мәскәүдә шул, ике айсыз кайтмый...»

— Я, ярый, сузмагыз,— диде ул Сагайкинга коры гына.

Сагайкин аңа карап баш иде дә тураеп басты.

— Төзүче иптәшләр, тынычланыйк. Аңсыз элементлар белән көрәш кискен куелачак. Безнең бурыч — иң әүвәл, төзүчеләргә уңайлы эш шартлары һәм культуралы ял оештыру. Икенчесе — социализм төзелешенә аяк чалучыларның тамырына балта чабу.

Мирсәет Ардуанов үзалдына җыерылып куйды. Сагайкинның соңгы сүзләре аңа үтә дә таныш иде. Ул бит аны теге чакта да шулай юатып чыгарды, ә үзе тәртип урнаштыру өчен кыл да кыймылдатмады.

Аның уйларын хуплагандай, халык тагын шаулаша, ризасызлык белдерә башлады.

— Нишләптер балтаң бик үтмәс күренә.

— Син балта кайраганчы әнә ничә эшчене имгәтеп ташладылар!

— Сүз боткасын туктатыгыз!

— Долой тел бистәләрен!!

Кемдер ишек төбендә ачы итеп сызгырып җибәрде. Милиционерлар шунда ташландылар, ләкин алар ду килгән халыкны ырып-ерып анда барып җиткәнче, сызгыручы чыгып тайган иде инде...

Җыелыштан соң төзелеш җитәкчеләре үзләре киңәшкә җыелдылар.

Партком секретаре Хангильдян җыелышта бер сүз дә дәшми тыңлап кына утырган иде, ул Сагайкинга төбәлеп:

— Син, Ксенофонт Иванович, ботка ясадың. Халыкны котырттың,— диде.

— Нигә, мин кирәкмәгән сүз сөйләдемме әллә?

— Һәр сүзнең урыны бар. Монда әле аңлы эшчеләр түгел, сезонниклар икәнен онытып җибәрдең. Бер елга соңрак сөйлисе сүзләрне сөйләдең. Бүген конкрет сорауга җавап бирергә кирәк иде. Әгәр алга таба да шулай кылансаң, постройкомнан китәргә туры килер сиңа.

— Гаебемне таныйм, иптәш партком секретаре.

— Тану аз, конкрет эш эшләргә кирәк. Милиция постларын көчәйтү, аңлы эшчеләр, бигрәк тә Гражданнар сугышы, Кызыл Армия мәктәбен узган партиецлар исәбенә тәртип сагына яңа кадрлар әзерләү синең өстә. Бүгенге гаебеңне син бары тик шуның белән генә аклый аласың.— Аннары ул Крутановка карап:— Җыелышны алдан әзерләмәвебез начар, иптәш Крутанов, беренче коймак төерле булды,— диде.— Мицкалевичның өйдә булмавы үзен нык сиздерә.



## 8

Октябрь ахырларында кар явып, Урал урманнарын актан киендерде. Сулыш алу иркен, дөнья ямьлерәк булып китте. Ләкин бер атна да узмады, кар эреп бетте. Җир кара, карагайлар кара, каен кәүсәләре генә ак. Күк йөзе тәбәнәк, соры, анда җил йөри бугай, болытлар ашыгып ага.

Ул да түгел, көзге бәйләнчек яңгырлар башланды. Әйләнә-тирә гел юеш, гел яңгыр, әртилчеләр бил тиңентен сазга батып кайталар, чабаталарга олавы белән балчык иярә, аякка су үтеп алҗыткач, чабата астына күн тегеп, сүс үреп киделәр. Алар гына да коткара алмый, хәзер инде җир казучылар түземсезлек белән Әдәми тауда бараклар-ның өлгереп җитүен көтәләр иде.

Әдәми тауның легендасы бар: абыйлы-сеңелле ике туган бер-берсенә гашыйк булганнар. Әтиләре аларны йорттан кугач, әлеге тауга килеп, куыш казыганнар, гомер буе шул куышта япа-ялгыз яшәп үлгәннәр, имеш. Шуннан тауның исеме Әдәми тау булып киткән, ди.

Ниһаять, бер көнне, иң беренче итеп, Ардуанов әртилен Әдәми таудагы баракка күчерделәр. Баракта, солдат казармаларындагы кебек, икешәр катлы нар-сәндерәләр ясалган, эченә коры салам тутырылган мендәр, матраслар куелган иде. Әртилчеләр аның тәрәзәләре биек һәм якты булуына, ягарга мичләре булуына сөенделәр. Дымлы юеш землянкалардан соң мондагы корылык, яктылык аларга бик зур рәхәтлек булып, җәннәт булып тоелды.

Урал тайгасына килгән гигант төзелешләр белән чагыштырганда, агач нар белән салам матрас — гел дә фәкыйрьлек бит инде. Әмма Урал урманнарында көне-төне ухылдаган, җир тетрәткән авазларны колаклары белән генә түгел, җаннары белән дә ишетеп, куәтле яңа дөнья килүен сизеп йөргән әртилчеләр артыгына дәгъва кылмыйлар иде. Көзге бәйләнчек яңгырлар да, ноябрь суыклары да аларны куркытмады, башланган эшне бер генә минутка да туктатмадылар.

Пар коперлары, чыгыр-лебедкалар, пошкырып-ухылдап, Кама буеның туң җиренә тимер-бетон субай суктылар; электр житәрдәй җиргә чыбыклар сузып, электр җитмәстәй җирдә учаклар ягып, кәйлә һәм көрәк, лом һәм кувалда белән коралланган меңнәрчә кешеләр, Әдәми тауны актарып, химкомбинат мәйданына Строганов солеварняларының

тозлы суы сеңә-сеңә кайракка, тимергә әйләнгән каты балчык ташыдылар.

Социализм иленең индустрия гиганты корылачак урында, юл өстендә комачаулап торган борынгы тоз амбарларының көлен күккә очырып, динамит шартлый; җимерелгән-тетелгән кирпечтән һавага соры-кызгылт төстәге тузан өермәләре күтәрелә; тузан таралган чакларда Әдәми тау белән Жданово кыры арасында ком һәм чуерташ ташучы Курган мужикларының атлы олаулары, кәрван-кәрван тезелеп, берәр чакрымга сузыла иде. Боларны көн дә саен күреп йөргән Мирсәет абзыйның күңелендә әле моңарчы татып карамаган яңа бер тойгы уянды: затлы нәсел Строгановлар өч гасыр буена Уралда хакимлек иткәннәр. Аларның явызлыгы халык бавырына тозлы таш булып утырган. Яңа заман әнә шул хатирәне җир өстеннән гүя бөтенләе белән себереп ташларга тели.

Ардуанов әртиле әле һаман да дамба төзелешендә эшли. Дамбаның соңгы эшләре борын төбенә килеп терәлде. Урамда утыз биш градуслы декабрь салкыны. Әртил туннель казырга тотынды. Төзелеш мәйданына килеп җиткән урында дамба гади дамба булып кына кала алмый, аның өстеннән әле поездлар җиһаз йөртсен өчен чуен юлы да узарга тиеш иде. Мирсәет абзый борчуга калды, әртил гадәттәгечә эшләсә, туннельне бер айдан бетерә алмый, җир тимер кебек каты, лом белән ваткан чакта туң җирдән очкыннар чәчри.

Контордан Ардуанов әртиленә өстәп тагын утыз кеше бирергә вәгъдә иттеләр. Ләкин әртилчеләр моның белән килешергә теләмәде. Туннельдән киләсе акчаны алар инде чама белән исәпләп куйганнар иде.

Мирсәет абзыйның солдат хезмәтендә, Гражданнар сугышында һәм Идел — Кама пристаньнарында җыйган тәҗрибәсе әйтеп тора: төзелешкә акча эшләп алырга җыелган сезонниклар түгел, аңлы эшчеләр кирәк. Шулай булмаганда, көне-төне лом белән, кәйлә һәм кувалда белән туң җирне вату, носилка һәм тачка белән балчык ташу, өстәвенә, гаиләңнән читтә ялгыз-ярым яшәү аларны бик тиз туйдырачак. Баштарак әле хулиганнар бәйләнү, тәртип бозулардан зарланалар иде, инде ул хәлләр дә ишетелми, ләкин кешеләр күңеленә шатлыкның да өстәлгәне юк бит. Әртилчеләр бер дә бер көнне һәммә нәрсәкәйдән туеп, арып, төрлесе төрле якка таралып китәчәкләр. Берәр төрле әмәлен табасы, шул хакта партком секретаре Хангильдян белән, яки аларны эшкә өндәгән Нәриман Нурисламов белән сөйләшеп карыйсы булыр. Хәзергә егетләрне кулда тотуның бердәнбер чарасы — як-якка карандырмый, аны-моны уйларга ирек бирми, дамбаны төзеп бетерү...

Мамык сырма өстеннән брезент кәҗән кигән, җылы бәрән бүрегенең колакчыннарын югары күтәреп бәйләгән Ардуанов, туң балчык төягән авыр тачканы ялгыш түнтәрмәс өчен, беләгендәге барлык җегәрен биреп, киң сайгак басма буйлап, карны каты шыгырдатып этеп килде дә балчыгын бушатып җибәрде. Кайтышлый янәшә юлдан юыртып узды, балчык төяүчеләр янына тачкасын җай гына куеп, үзе дә көрәккә тотынды:

— Ягез әле, балакайлар, тизрәк кыймылдыйк, бүген ике норма бирә алмабызмы?

— Мирсәет абзый, битең өшегән бит,— диде аңа Нурләхмәт.

Ардуанов зур тире бияләенең аркасы белән битен ипләп кенә ышкып торды; бите җылынып кызыша башлагач, бияләен салып, мыек чылгыена каткан бозны җебетеп алды, аннары терсәкләрен киереп тоткан хәлдә, авыр тачканы сайгак-юлдан төшермәскә тырышып янә китеп барды, аның артыннан башка тачкачылар иярде.

Туннельдә алар белән янәшә бетончылар әртиле эшли. Әртил илле кешелек. Эшне алып баручы осталар икәү: берсе — битен урман кебек

куе кара сакал баскан, мәһабәт гәүдәле, озын кайры тунлы, киез итекле Трапезников — төп оста; икенчесе — башына күн түбәле бүрек, өстенә кыска сары тун, аягына чүчинкә кигәне — Шакир Сираев; анысы көянтә-чиләк белән су ташучы кызларга командалык итә, ул — төп останың ярдәмчесе.

Трапезников эшне җае белән генә алып бара. Ыгы-зыгы тудырмас, шауламас, кулында көрәк булыр, чиләк булыр, бер минутын бушка үткәрмәс. Сираев исә, кулны артка куеп, әрле-бирле йөренә, көянтә-чиләк күтәргән хатын-кызларны, көтүче сарыкларын барлаган кебек, санап-барлап тора, шелтә сүзен, әрләүне даими кирәк дип саный. Шәл бөркәнгән бер хатын, түмгәккә абынып, ялгыш кына суын түккән иде, ул аңа карчыга кебек очып кунды. Тезелешеп су ташучы хатын-кызлар бөялеп калдылар, чиләктәге суга боз элпәсе утырудан куркып, Сираевны да, алдына карап йөрмәгән хатынны да тиргәргә керештеләр.

Трапезников килеп тиргәшүне туктатмаса, эшләре харап иде.

Бетончылар Ардуанов әртиле казыган туннельнең идәнен бетон белән катырып, стеналарын кирпеч белән тышлап, җир казучыларның үкчәсенә бастырып киләләр, шунлыктан теләсәң-теләмәсәң дә темпны арттырырга туры килә, ә бу хәл Ардуанов әртилен бер урында таптандырмый, гел ашыктыра, гел алга куалый иде.

Мирсәет абзыйны шатландырганы ул түгел иде әле.

Туннельне бетонлау эше үзе бик кызыклы булып чыкты. Су ташыла, ком ташыла, кирпеч тезелә, цемент капчыклары килә; гүәрдин-гүәрдин егетләр, көймә ишкәге төсле зур озын калаклар белән сыекчаны өзлексез болгатып торалар; суыкта аларның бите-башы кызарып чыккан, осталары Трапезниковның бетон парыннан, киңәшен-мазарын биргән чакта авызыннан бөркелгән будан сакал-мыегын ап-ак бәс сарган, һәм ул гел чыршы бәйрәмнәрендәге Кыш бабайга охшап калган иде. Мирсәет абзый сизеп алды, аның әртиле Сакалбайга сокланып карый, ара-тирә бетон болгатучыларга, кирпеч тезүчеләргә күз төшерә, йөгерә-йөгерә су ташучы хатын-кызлар аларны дулкынландыра. Бу хәл Мирсәет абзыйның күңелендә тонык кына өмет чаткысы кабызды: тукта, чү, сезонникларның һөнәргә омтылуы түгелме бу? Бетончы һөнәрен өйрәнеп алсалар, гомер буе эшле булдың диган сүз. Монда бит әле төзелешнең очы-кырые күренми. Ул хакта инде менә партком секретаре белән түгел, Никифор Степанович Крутановның үзе белән сөйләшәсе булыр. Ипле кеше, ярты сүздән ни әйтереңне аңлый белә, сүзне аяк астына салып таптамас, кирәк чакта Ардуанов та аны тыңлады бит.

Ул көнне Мирсәет абзый, әллә нинди бер шатлыгы бар сыман, кичкә кадәр дулкынланып йөрде. Смена бетәр алдыннан әртилчеләр янына Борис Зуев килде. Эшләгән эшне исәпләп карагач:

— Молодцы, ардуановцы, норманы 197 процентка үтәгәнсез! — диде.

— Их, тагын бераз гына тырышсак, ике йөз буласы икән,— диде Бәхтияр Гайнуллин.— Әллә ике йөз итеп язасыңмы, энем?

— Ысынлап та, өс проценттан бер нәмә лә булмай бит,— диде Юлдыбаев.

Башка егетләр дә Исәнголның сүзен күтәреп алдылар.

Мирсәет абзый аларның шаулашканын сабыр гына тыңлап торды да:

— Дөресен яз, Борис. Күз буяу Ардуановлар эше түгел,— диде.— Нәфеснең карыны зур, аны тутырып бетереп булмас.

«Ачның күзе икмәктә, тукның күзе хикмәттә»,— дип, борынгылар белми әйтмәгәннәр, күрәсең. Авыз адәм рәтле аш-суга тиенүгә егетләрнең буш вакытларын бушка үткәрәселәре килми башлады. Алар еракта, Агыйдел һәм Сөн буйларында калган гаиләләрен, гаиләсе булмаганнары сөйгән ярларын сагына башладылар. Барып күңел ачарга клуб әле өлгереп җитмәгән, күбесенең газета укырлык белемнәре дә юк, шунлыктан мәзәк сүзгә оста егетләр атаманлык итә башлады.

Ял сәгатьләрендә барактагы халык Нәфүш-Сайрар кош янына җыела. Нәфүш учын-учка шап иттереп китереп бәрер дә, баш бармагын мөгез кебек тырпайтып, кысык күзләрен ярык кына калдырып, сөйләп китәр.

— Пример өчен әйтәм, Шамук бүген чирле. Ягъни килеп, эштә түгел. Аның борыны шешкән.— Халык нар-сәндерәдә ыңгырашкалап яткан Шәмсетдин ягына борылып карый.— Ярый, хуш, борыны шешкән. Ә бит ул борын Шамукның үзенә генә кирәкле борын түгел. Ул борын, ныклабрак уйлап карасаң, безнең бөтен әртилгә кирәкле борын. Ә ул сантый-мантый Шәмсетдин шуны аңларга теләми и шулай ук әйткән сүзгә колак салмый.

— Нинди сүзгә, синең тиле сүзеңәме? — ди Шәмсетдин, нар-сәндерәдән башын сузып.

— Торып тор, торып тор, абзыкаем! Мин сиңа әйтмәдемме борыныңны тозлы су белән ю дип әйтеп? — Тыңлаучылар дәррәү көлеп җибәрделәр.— Ә нәмә көләсез? Аның нәмәсе көлке? Шулай Сарапулда Мирсәет абзый белән грузчик булып йөргән заманнарда борынга суык тидердем. Әдәм ише генә борынымы, бөтен битне баскан. Башта шеште бу, аннары килеп, Хөббенисаттәйнең иске читек балтыры кебек ләшпәрәеп калды. Шаштырт итеп тартып җибәрәм тегене, мин сиңа әйтим, тайга бүреләре куркып качарлык. Бер атна шулай йөрим, ике атна — бетми генә бит. Хәзер моның зәхмәте башка да суга башлады. Чигәдәге кан артиллериясе сулык-сулык итеп тора, аңа да түзәр иең, кузла белән аркага тоз капчыгы күтәреп алдыңмы, күз аллары әлҗе-мөлҗе килә, каршыда әкәмәт бөҗралар, аллы-гөлле тәңкәләр очып йөри башлый. Парахут басмасыннан очып төшеп китүеңне көт тә тор.

— Соң, шуннан, шуннан?

— Шуннан, нәрсәсе шуннан? Кеше-кара, грузчик агай-эне әйтә, син аны, Нәфүш-Сайрар кош, җылыга тотып кара, җылыга, ди. Бер көнне, алар сүзен тыңлап, борынны җылы мичкә терәп яткан ием, төннә мичне ягып җибәргәннәр дә, борын пешкән, болай да олы борын, мин сиңа әйтим, икенче көнне тукмак чаклы булып кызарып чыкты. И көлә халык — түзсәң түз, түзмәсәң — юк. Авылга кайтып китәр ием, өй тулы ач халык, ни хәл итим, ярман сугышы янвалиты кебек, борынны сөлге белән бәйләп куйдым да киттем тагын тоз капчыгы ташырга. Бәхетем бар икән алай да, әллә каян гына килеп чыга Мирсәет Ардуанов: теге дә бу, китә сорашу, борын шәрифләренә җитәбез; бар булган хәсрәтемне түкми-чәчми сөйләп бирәм тегеңәргә; менә шулай-шулай, мин әйтәм, Мирсәет абзыкаем, хур итте мине бу борын, хет кисеп ташла, хет умырып ат — үзәк бәгырькәйләремә үтте бит, мин әйтәм, син безнең арада бердәнбер акыллы кеше — берәр төрле әмәлен белмисеңме шуның, мин әйтәм. Әйттемме, Мирсәет абзый?

Ардуанов тыныч кына елмая:

— Әйткән иең шул.

— Миңа шуннан соң әйтә бу, син аны, ди, Нәбиулла туган, ди, тозлы су белән юып кара, ди. Көләме бу, мин әйтәм, чынлап әйтәме?

— Шуннан, шуннан? — дип сабырсызландылар тыңлаучылар. Ләкин

Нәфүш-Сайрар кошка көлкесен сөйләп бетерергә туры килмәде, барак яныннан малайлар кычкырышып уздылар:

— Нурлый хатынын үтерә! Нурлый хатынын үтерә!

— Каһәр генә суккан икән,— диде Мирсәет абзый, үзалдына сукранып.— Ниткән бетмәгән сугышу бу? — Ул ашыкмый гына урыныннан торды, кулына йомарлаган фуражкасын язып, такыр башына тартып киде, өстәл тирәсендәге халыкка:

— Ярар, тынычландырып килим инде,— диде.

— Бар, Мирсәет абзыкаем, тынычландырып кил, син бит начальник кеше, җавабын сиңа бирәсе,— дип мутланып калды Нәфүш-Сайрар кош. Ул моны көлдерергә исәп тотып әйткән иде, тик көлүче булмады. Нурләхмәтнең, әз генә «котырган сыер сөте» каптымы, хатынына бәйләнүен беләләр, һәм бу әртилне инде туйдырган, сызлап торган чуан кебек, үзәкләренә үткән иде.

«Менә дигән эшче. Кулына көрәк тотса, җир җимертеп эшли. Хәтирәсенең килмәгән бер генә җире дә юк, ни житми адәм баласына?» — дип, юл уңаенда көнелсез генә уйлап алды Ардуанов.

Ул шактый ук ямьсез күренешкә юлыкты. Ул кергәндә, Нурлый хатынын идәнгә егып салган да өстенә менеп атланган, ике кулын идәнгә җәеп, аңардан нидер таптыра иде. Нурлый чибәр хатынын пострөйкомдагы кара егеттән көнли диләр, бәлки шуны таптыруыдыр.

Хәтирәсе, ишектән кемдер керүен сизеп һәм сыдырылган күлмәгеннән уңайсызланып, тыпырчына-тартына башлады, ләкин Нурлый төп кебек берегеп утырган, алты потлы гәүдәсе белән ул хатынын идәнгә кузгала алмаслык итеп беркеткән иде. Хәтирә, мескен, Мирсәет абзый алдында шулай җәелеп ятуыннан гарьләнеп, күз яше белән елап җибәрде.

Ардуановның бәгырен күз яше өтеп алды. Үгет-нәсихәтнең файдасы тимәслеген шундук аңлап, Мирсәет абзый Нурлыйны култык астыннан кочаклап, хатыны өстеннән суырып алды.

— Ах, җир бит, җир бит,— дип кычкырмый гына сөйләнде әртилче.— Я инде, шушы да булдымы егетлек?!

Нурлый тыпырчынмакчы булып киерелгән иде, Ардуанов кулына эләгүен абайлап, юашланып калды.

Мирсәет абзый аны агач тапчанга утыртып куйды. Чөйдән үрелеп сөлге алды һәм «ә» дигәнче «батыр Галинең» кул-аягын бәйләп, тапчанга сузып салды.

Аңа хәзер чыгып китсә дә була иде, ләкин кул-аяклары бәйле хәлендә Нурләхмәтнең үзен генә калдырасы килмәде, тапчанның бер кырыена чүмәште дә көнелсез уйларына бирелде.

Үзсүзле, тешләк кеше иде Нурләхмәт. Тавыш-тынсыз бер сәгать ятты. Ардуанов та, ләм-мим сүз дәшмичә, бер сәгать утырды. Сабырлыкка көч сынашалар иде. Ахырда Нурләхмәтнең сабыры төкәнде.

— Җибәр инде, таз, алҗыдым бит инде,— диде.

— Хатын-кызга кул күтәргән ир ирмени ул! — диде Мирсәет абзый юаш кына.

Тагын ярты сәгатьләр яткач, Нурләхмәт гырлап йоклап китте. Ардуанов башта аның кулын, аннары аякларын чиште, сөлге буудан кызарган беләген җиңелчә ышкып торды да авыр гына көрсенеп чыгып китте.

## 10

Әртил башлыгы булганга күрә, егетләренең өс-башын кайгырту, акчаларын саклап тоту, гарьлекләренә тимичә генә, әкренләп үгет-нәсихәт бирү — һәммәсе Ардуановка йөкләнгән иде. Егетләре дә моны аңлый, кирәксә-кирәкмәсә, юктан-бардан тәртип бозмыйлар, ләкин

дөнья булгач төрлесе була, авызны авызга куеп, чөкердәшеп кенә торып булмый, бар яраштыра, юк талаштыра дигәндәй, әйбәт кенә йөргән җирдән тавыш чыгарып, ямьсезләнеп тә китәлиләр.

Балтач егете Шамук — үксез бозау булып кагылып-сугылып йөргәнгәме — шаярткәнны аңламый, ялгыш кына шул авырткан сөяленә бассалар, үлгәнен-калганын белми сугыша.

Ардуанов аны бер көнне бик озак үгетләде. «Шәмсетдин, нишләвең бу, улым, стройкадан кусалар, үзеңә кыен була бит. Сиңа бит әртил белән саубуллашырга туры киләчәк»,— диде.

Шамук әртил башлыгына ант итте:

— Бүтән беркайчан да тавыш чыгармыйм, Мирсәет абзый, кеше сөйләшкәнне күрсәм, бер чакрымнан әйләнеп узармын,— диде.

Шуннан соң тыныч кына ике көн эшләгән иде, өченче көнне Нәфүш-Сайрар кош белән сугышкан да киткән. Юктан гына бит, бөтенләй юктан.

Өйләнү, башлы-күзле булу турында хыялланганнар. Һәркем күңелендә йөрткәнен әйткән. Химкомбинатны салып бетерсәк, янәсе, бишьеллык ударниклары итеп «усубый» премия бирәселәр. Акчалата гына түгел, акчаны болай да ярыйсы гына эшлиләр, авылларына да почтадан салгалап торалар. Өс-баш киеме кирәк. Кияү егете, мин сиңа әйтим, кәләше янына алача ыштаннан кайтмас бит. Күн итек алып җибәрергә кирәк,— дегет белән майлый торганын, дагалысын; сатин күлмәк — изүдән билгә тикле ак сәдәф тезгәнне, кыек якалыны; аннан ары килеп, кәчтүн. Ниприминны постауны, караны, күз явыңны алырдайны. Хәлле хәленчә һәркем хыялланган була, Шамук әле сүзгә кушылмый.

— Син нигә дәшми торасың, әллә сиңа өйләндергеч такмаганнармы? — дип әйтеп салмасынмы Нәфүш-Сайрар кош.

Шул җитә кала ятим Шамукка.

— Нишләп син мине мыскыл итәсең? Нишләп син миннән көләсең?! — дип, җан ачуы белән кабынып, кабарынып килә дә, Нәфүшне якасыннан урап алып, күлмәген умырып та төшерә, ике күзенә ике фонарь утыртып та куя. Сөйләшеп-үгетләп тору артык. Аннары әртилче сүзе бер һәм берәгәйле булырга тиеш. Байтак кына икеләнгәннән соң Ардуанов участок милиционеры белән сөйләште, үз әртилендәге яшь эшче Шәмсетдин Сәләхиевне ике генә көнгә ябып, кайнарлыгын киметеп чыгаруларын үтенде. «Алып киткән чакта бөтен әртил алдында алып китәрсез, бүтәннәргә дә сабак булыр»,— диде.

Этлеккә бисмилла кирәкми дигәндәй, закон сакчыларының талканы Ардуанов көткәннән дә корырак булып чыкты, әртил эштән кайтып, бик әйбәт кәеф белән кичке ашка утырырга гына тора иде, бер рус, бер татар милиционеры баракка килеп керделәр дә:

— Ардуанов әртиле биредәме? — дип, гадәттәгедән катырак кычкырып сорадылар.

Мирсәет абзый алар янына килеп басты. Егетләр дә, сагаешып, берәм-берәм аларга кырын күз салдылар. Ни булган? Ни галәмәт? Әллә Шамукның сугышканын сизеп калганнармы?

— Шәмсетдин Сәләхиев! Җыеныгыз!

Төсе качкан Шамук, ярдәм эзләгәндәй, Мирсәет абзый янына елышты. Мирсәет абзый милиционерлардан ни өчен икәнне сорады, сугышкан өчен икәнен белгәч, бер юлга калдырып торуларын үтенде.

— Ниткән безобразие бу? Әртил башлыгы дисциплина бозучыларны безгә үзе тотып бирәсе урында, яклашып тора,— дип ябырылды татар милиционеры Ардуановка.

Ике төрле сөйләшергә урын калдырмадылар. Сәләхиевнең аркасына наган терәп, кичке ашын да ашатмаган килеш, алып та киттеләр.

Әртил тынып, нәүмизләнеп калды. Аннары барысы берьюлы Нәфүшкә ябырылдылар: син башладың, янәсе. Син телеңә баш булмадың. Үчекләсәң белеп үчеклә. Тигез ата-ана белән үскәннән бер түгел, ун тапкыр көл, мыек очын да селкетмәс. Ятим малайның күңеле эскрипкә кылы кебек бит аның: әз генә кагылдыңмы, шундук шыңгырдап китәргә тора. Шамукны кайтармасалар, нишлибез? Каргышы синә, Фәхриев.

Нәфүш-Сайрар кош, Мирсәет абзыйдан рөхсәт алып, шыпырт кына Шамук янына «передача» илтә барды.

Кайтуга Нәфүшне әртилчеләр сырып алды.

— Ничек анда?

— Күрдеңме Шамукны?

— Бик җылыймы?

— И-и-и, абзыкаем, күрмәгәнгә күрсәтмәсен, күргәнне тизрәк коткарсын. Анда бер эләккәч, тиз генә котылырмын димә икән. Анда, җаным, түгәрәгем-күбәләгем, сайрар кошым, сандугачым дип тормыйлар, шартлатып тимер богау белән бикләп куялар икән. Ике кеше биеклеге агач койма, койма өстендә ике рәт чәнечкеле тимер чыбык. Койма буена килеп, ярыкка күземне куюым булды, әллә каян, койма башыннан мылтыклы солдат:

— Стой, стрелять буду! — дип кычкырып җибәрде, алдыма-артыма карамый бер чакрым чаптым...

— И мескен, Шамукның кайтмаска китүе микәнни?

— Менә, малай, бер нермыңа баш булмасаң!

— Нәфүш гаепле, ул котыртты!

— Үзе дә фонарь алды бит.

— Фонарь ул бер кабыныр, бер сүнәр дигәндәй, менә Шамук нишләр? Себер җибәрмәсәләр ярый...

Ике көннән Шәмсетдинне кайтардылар. Исән-имин кайтып кергән Шамукны күреп, әртил тере тиен тоткан күк сөенде. Поездән артык кеше барысы да берьюлы аның хәлен белеште. Аңардан кат-кат сөйләттеләр, тел шартлаттылар, баш селкеп тордылар, кызгандылар.

Иң соңгы кеше булып хәл белешергә Ардуанов керде. Шәмсетдинне үзен генә урманга алып чыгып китеп озаклап сорашты. Азактан:

— Котларым калмады менә, улым, гомергә ябып куйдылар дип торам,— диде.— Икенче керергә язмасын инде...

— Син әйтәсеңме аны, абзый, үзем әйтимме? Исән-сау котылып чыксам, бер генә кешегә дә кул күтәрмәс идем, дип ант итеп чыктым.

— Чынмы?

— Җир упсын әгәр. Шушы кояшның чыраен күрмим.

## 11

— Малайлар, беренче дәресне башлыйбыз.

Баракта озын өстәл янына җыелып утырган әртилчеләр — егермеләп агай — шаркылдап көлеп җибәрде. «Малайлар» дигәннән көлделәр. Бу сакаллы сабыйларга ияреп укытучы үзе дә көлде.

Аңа унтугыз яшь. Кара бөдрә чәчләрен ике толым итеп үреп салган. Иркенләп, таралып үскән шомырт кара кашлар астыннан зур коңгырт күзләр карый, дөньяга туймаслык булып, тутырып карый бу күзләр. Килешле матур борын, янып торган алсу иреннәр, сөйләшкән чакта мәзәк булып күренеп калган ике теш арасы аны күңелгә якын, сөйкемле итә. Мирсәет абзый аны шундук таныды: теге көнне конторда каршы алган кыз бит бу.

Укытучы кыз инде ничәмә айлар туган-үскән якларыннан, хатыннарыннан аерым яшәп, дөнкәеп беткән каты бәгырьле кешеләрнең күңелен берьюлы ут салды.

Нәфүш-Сайрар кошны, Шамук белән Кинъябулатны әйткән дә юк инде, Мирсәет абзый үзе дә кызны беренче мәртәбә күргәндәге кебек дулкынлана башлады. Иске Кормашта калган Мәүгыйзәсе, балалары күз алдына килеп басты. Алып киләсе иде бит аларны, бергә-бергә яшисе иде...

Ыңгыраштырып җибәрер дәрәҗәдә рәхәт булып, өйгә килеп төшергән чаклары күңелендә яңарды.

Герман сугышы чыгар алдыннан иде. Шәйхелислам кызына — талдай зифа буйлы, зәңгәр күзле Мәүгыйзәгә күзе төште. Ул урамга гармун менми, ник дисәң, анда мәчет, анда хәзрәт яши, шунлыктан Мәүгыйзәнең чишмәгә суга чыкканын, яки Шәбез инеше буена кер бәләкләргә төшкәнен сагалап, ат эчерергә бара. Таза чагы Мирсәетнең, «дастуйн» чагы. Дуслары күп, егермешәр чакрымга сабан туена чакыралар. Бара, көрәшә, мәйдан тота, андый кешегә кайсы кызның күңеле алгысамас. Ләкин бер китек җире бар егетнең: Ардуанныкылар бай түгел. Шәйхелисламнар бай. Мәүгыйзәнең атасы Ардуан малаеннан яучылар кабул итмәс шул. Шуңа күрә Мирсәет эшне сеңелесе Гандәлиф аркылы йөртә... Гандәлиф хат илтә, хат алып кайта. Мирсәеттән Мәүгыйзәгә, Мәүгыйзәдән...

— Малайлар, менә бу — кара такта,— диде укытучы, Ардуановны сискәндереп.— Минем исемем — Зөлхәбирә. Кара тактага без акбур белән, сезнең күңелгә ак нур белән язарбыз.

— Син әле кияүгә чыктыңмы? — диде Нәфүш.

— Юк әле, чыкмадым,— диде укытучы.— Ә нигә?

— Тәк кенә. Беләсе килгән иде.

— Беләсе килү гаеп түгел.

— Тукта, торып тор, без сиңа ничек дип дәшик?

— Фамилиям минем Кадермәтова.

— Ә-ә-ә, Кадермәтова! Сиңа бер сүз әйтергә ярыймы, Кадермәтова?

— Тозсыз булса, әйтмә.

— Юк, бу тозлы. Әйтимме?

— Әйтеп кара.

— Безнең авылда бер җыру бар. «Күбәләгем-түгәрәгем»... дип башлана.— Әртилчеләр тынды, көлеп җибәрмәс өчен авызларын учлары белән капладылар. Нәфүш бик җитди чырай белән сүзен дәвам иттерде:— Сайрар кошым, сандугачым, Зөлхабирә җан кисәгем, иптәш Кадермәтова, әйтсәңче, миннән нинди писер чыксын, ди, менә бу куллар бит хәрендәш тотар өчен түгел, көрәк белән кәйлә тотар өчен генә яратылган. Җир казы, капчык күтәр дисәң — анысы минем эш. Бу бармакларга хәрендәш чыдыймыни?

Зөлхәбирә аңа якын ук килеп, аның бирчәйгән бармаклы зур кулын әйләндереп-әйләндереп карады да, сирәк тешләрен күрсәтеп, туйганчы бер көлде: карандашның сынуын күз алдына китерде бугай.

Суйды бу «Сайрар кошны», өнсез калдырды. Егетләр укытучының үткенлегенә сокланып, хәтта тел шартлатып куйдылар.

Вакытны ычкындырмаска кирәк иде.

Зөлхәбирә Кадермәтова, дәфтәрләрне икегә бүлеп, булачак укучыларына өләшеп чыкты. Аннары ике кешегә бер карандаш бирде, урталай бүләргә кушты, пәке белән очлатты һәм кәгазь битенә сызыклар сыздыра башлады.

Әнә шул көннән башлап ул сакаллы сабыйларга үз ихтыярын такты.

Беренче атналарны аның үзенә дә, «сакаллы сабыйларына» да кыен булды. Егетләр унар сәгать җир казыганнан соң эт булып арыйлар, бирчәйгән бармаклар карандаш тота алмый аптырый, олырак яшьтәгеләре кәгазь өстенә иелгән җирдән йоклап та киткәлиләр иде.

Адәм баласы нәрсәгә генә күнекми,— бер-ике айдан алар да күнектеләр, уку көннәрен, атнага бер мәртәбә түгел, ике мәртәбә үткәрүне сорадылар.

— А... ты — ат; А... ры... бы... а-арба,— дип, күз алдында биешкән кара хәрефләрдән көйләп сүз чыгара башлагач, алар сабый бала кебек куанышалар иде.

Яшьрәкләр тиз төшенә, ә менә өлкәннәрнең эше мөшкел. Үз гомерендә кулына китап тотып карамаган Бәхтияр Гайнуллин, зур кара бармагын хәрефләр янында йөртеп:

— Кы... а... ры... гы... а...— дип тезеп китә.

— Нәрсә булды? — дип сорый укытучы Зөлхәбирә.

— Белмим,— ди Бәхтияр абзый.

— Карга булды,— дип әйтеп җибәрә Нәфүш.

— Ә син үзең карга, авызыңны ачып кычкырып утырасың,— ди хәтере калган Бәхтияр абзый.

— Малайлар, уртәшү әйбәт эш түгел,— ди укытучы Зөлхәбирә.— Үртәшә торган булсагыз, мин сезне укытудан баш тартам. Надан көе яши бирегез.

Ул, алданрак өлгергәннәргә язу язарга кушып, берәр хәрефне акбур белән кара тактага язып күрсәтә, аннары Бәхтияр абзыйны бер читкәрәк утыртып, аңа гаять зур түземлек белән «карга»ның нинди хәрефләрдән җыелуын аңлата башлый.

Ниһаять, арый Бәхтияр абзый. Маңгаена бәреп чыккан тирне кулмәк җиңе белән сөртеп:

— Я, ярар, кызым, бүгенгә җитеп торыр. Югыйсә, синең миннән гомер буена гайрәтең чигүе бар,— дип уфтанып куя.

Егетләр әле таралырга теләмиләр, Бәхтияр абзый белән Мирсәет абзый кебек өлкәннәр һава сулап йөрүне сәбәп итеп, урамга чыгып киткәч, кичке уеннарын башлыйлар. Әхмәдишаның гармуны бар, ул йозак белән бикләп йөрткән фанер чемоданын ачып тальянканы ала, Нәфүшкә мутланып күз кыса һәм... өздереп уйнап җибәрә.

Агыйделләр киң булса да,
Парлап йөрми парахут,—

дип башлый Каентүбә егете жырчы Сибай.

Көй, айкап-айкап килгән бормалары белән, йөрәк төбенә хәтле төшеп җитә ала торган кодрәте белән сагыну-җирсү тойгыларын берьюлы кузгатып, татарын-башкортын берьюлы телгә китерә.

Йөзләрем тыныч булса да,
Эчләремдә яна ут,—

дип, ярсулы, көчле тавышлар бергәләп очлыйлар жырны. Икенче жырны Нәфүш башлый, аның тавыш Сибайныкыннан кайтышрак, әмма Иске Кормашлар Каентүбәләр алдында хур булып калырга теләми, иң моңлы жырчылары Зарифны алга чыгарып, аның тамагы белән жырга кодрәт өсти. Нәфүш-Сайрар кош алар арасында үзен инде ярыйсы ук булдыклы жырчы итеп сизә, ул жырга бөтен күңелен салып, башын артка ташлабрак, рәхәтлектән күзләрен йомып жырлый.

Һәм менә Урал төпкелендә жыр агыла. Аны күрше бараклар тыңлый. Көне буе эшләп арыганнар әллә кая китә, бирчәйгән күңелләр нечкәрә, күрше баракта кемдер балалайка чиртә башлый, кемдер тыпырдатып бии; иң аргы баракта Себер сукбае турындагы жырны дәррәү жырлап алып китәләр.

Ардуанныкылар инде кичәнең дәртлерәк өлешенә күчә.

Башта «Кул сугыш» уйныйлар. Зөлхәбирә — шәһәр кызы, Свердловскида туып үскән, аулак өй, кич утыру кебек нәрсәләрне белми. Егетләр уены ифрат кызык аңа.

Зөлхәбирә учына Нәфүшнең башын куйдыралар. Шау-гөр килеп Нәфүшне сырып алган егетләрнең берсе, Шамук, аның аркасына куйган кулына суга, берсе суга, унысы бармак тырпайтып тора. Нәфүш — ялт! — сикереп тора. Шамукның түгел, Сибайның бармагын тотып ала.

Өйне күтәреп китәрлек итеп көләләр. Зөлхәбиргә кызык, ул куллары чәбәкли-чәбәкли көлә:

— Белмәде, әлләл-ләә! Белмәде, әлләл-лә!

Нәфүш тагын Зөлхәбирәнең учларына йөзен яшерә, тагын сикереп тора, сукканны түгел, сукмаганны күрсәтә, тагын ята, тагын тора.

Бишме-алтымы тапкыр шулай эшләгәч, егетләр аның хәйләсенә төшенеп алалар. «Сайрар кош» юрамалый ялгыша, аңа Зөлхәбирә учына башын куеп тору рәхәт икән ләбаса!

Нәфүшне Зөлхәбирә учыннан суырып алалар да «Кул сугыш»ны туктатып, «Тәнкә салыш», «Утын кисеш» уеннарын уйныйлар.

Зөлхәбирә шуларның барысыннан кызык табып, егетләрне күзәтеп утыра, яшьлек җилкенүләре һәм ирешкән белеме югарылыгыннан ул эш кешесенең күңел матурлыгын тоя башлагандай була...

Кышкы төннәр караңгы, барак тәрәзәсе артында юлларга көрт өеп, җилләр йөри. Була шундый көннәр, Ардуанныкылар бер уен да уйнамый, бер җыру да җырламый, җил тавышына колак салып, тын гына утыра. Агыйдел һәм Сөн буйларында калган яшьлекләре искә төшә. Шунда берсе югары очка гармун уйнап меңүләрен сөйләп ала, икенчесе, Каентүбәдән килгән атлы егетләр кыз урларга кергәч, камыт бавын кисеп куюларын сагынып искә төшерә, өченче берсе йөрәк башына җыелган хәсрәтен уены-чыны белән әйтеп бирә:

— Минем карлыгач канатым көтмәс инде Кәбирен, китәр инде киртә башы Котдусларга.

— И-и, исең киткән! Хәзергесе заманда кызлар беткән диме.

— Бетүен бетмәгән дә...— ди «карлыгач канатын» сагынучы һәм үзе, сиздермәстән генә, күз кырые белән генә Зөлхәбирә ягына карап куя.

Зөлхәбирәгә күз төшерүче күп. Ләкин Зөлхәбирә үзе, башкорт егетләре әйтмешли, берсенә дә «егылып бармай».

Укытуын укыта, шаян сүзен әйтүен әйтә, әмма ләкин егетләрне үзеннән ерак тота.

Кичке укудан таралган чакта Зөлхәбирәне дәррәү җыйналып, әртилләре белән озатып куялар. Бу бәхеттән берәүнең дә мәхрүм каласы килми. Ләкин әртил соңгы вакытларда сизенеп йөри: Зөлхәбирә дәррәү озатуларын теләми, ул укытуын бетерүгә тиз-тиз генә җыена да, саубуллашып, китеп тә бара.

Ул китүгә, сылтау табып, Нәфүш кузгала. Әртилчеләр сагаеп кала: әллә, ходаем, тел бистәсе асыл кошның күңелен кузгата алганмы?

Ул да түгел, Зөлхәбирә көпә-көндез, ниндидер йомыш табып, Ардуановлар эшләгән туннельгә килеп чыга: Мирсәет абзый янында сөйләшеп тора, егетләргә баш өстендә кул болгап, сәлам бирә, Нәфүш-Сайрар кошка әйләнеп тә карамый, түмгәктән-түмгәккә тәкрарлектәй сикереп йөри-йөри дә китеп югала.

Менә син, хикмәти хода, ул килеп киткәннән соң, Нәфүш телсез кала, авыр тачкаларны йомычка кебек кенә селтәп йөртә, һәм егетләр моның тикмәгә түгеллеген төшенеп алалар.

Кичен, кайдадыр югалып йөреп кайткач, Нәфүш Мирсәет абзый янына килә, бер аягын алга куеп, башын кыңгыр салып, уены-чыны белән такмаклый:

— Күбәләгем, түгәрәгем, сайрар кошым, сандугачым, Мирсәет абзый, җан кисәгем, акча биреп торчәле.

Егетләр дәррәү көлеп җибәрсәләр дә, бирмә, Мирсәет абзый, бирмә, дип ирештереп торсалар да, Ардуанов акча бирә Нәфүшкә, егетнең рәхмәт хисе белән тулы бәхетле күзләренә карый: егетнең күңеле кузгалган, тикмәгә түгелдер...

Бер атна узгач, кичен, укытучы Кадерметова дәрескә керер сәгатьтә генә әртилчеләр Нәфүш өстендә кара «кәчтүн», кара чалбар, кыек якалы ак сатин күлмәк күреп алалар. Китә сорашу, китә тел шартлату!

— Каян алдың?

— Ничек алдың?

— Ну, малай, болай булгач...

Нәфүш-Сайрар кошка боларны тыңлавы рәхәт-рәхәт, авыз аның — колак артында. Ләкин әле ул дәшми, эре кылана. Иң соңгы кеше булып Мирсәет абзый белән Бәхтияр абзый киләләр. Бәхтияр абзый «кәчтүннең» материясен тотып-тотып карый. Мирсәет абзый Нәфүшне «зыр круглый» әйләндерә, шуннан соң гына үз итеп әйтә:

— Җылы тәнеңдә тузсын, Нәбиулла энем. Килер җирең киң итсен. Каян алдың бу хәтле затлы әйберне?

— И Мирсәет абзыкаем, син сорама, мин әйтмәем дигәндәй, бар булган акчамны, бар булган урысчамны бирдем!

Иа, дөньялар! Нәфүш Зөлхәбирә дәресенә кара «кәчтүн» киеп йөри. Теленә салышмый. Комсомолка Зөлхәбирә «Сайрар кошны» телсез калдырды.

Кемнең кемне телсез калдыруы — ул әле бәхәсле. Зөлхәбирә Нәбиулла Фәхриев дигән җир казучы егетне белемгә өйрәтергә, аның тупаслыгын әзрәк кенә булса да юнып төшерергә, аның ташып торган энергиясен әзрәк кенә булса да кирәкле юлга юнәлтергә дип кенә тотынган иде. Шәһәр кызы ирешә алганны авыл егетенә дә бирергә иде нияте. Әмма дә ләкин... тәрбия бирүче белән тәрбия алучы арасында педагоглык белән шәкертлек тойгысыннан тыш бүтән тойгы уянмас дип кем кистереп әйтә ала? Йомшак кына итеп әйткән тәрбия сүзләренең ярату сүзләре булып ишетелүе мөмкин түгелмени? Укучының укытучысын олылавы аның үзен, яшьлеген, матурлыгын олылауга әйләнеп китсә, ни диярсең?..

Зөлхәбирә әле һаман усал телле: кара костюм киеп алган, чәчләрен бер якка тарап куйган Нәфүшнең ул үзенә озаклап карап торуын, вакыт-вакыт күрсенеп куюларын көлкегә әйләндерә, беләгеннән тотарга дип сузган зур кытыршы кулын читкә кагып җибәрә, бер сүз белән әйткәндә, ул аны һаман укучы, үзен һаман укытучы итеп тотарга тели; әмма киң күңеле, шаян табигате, камил итеп яратылган матурлыгы белән Нәфүш-Сайрар кошны бу фани дөньяга кабат тудыруын, тирәндә, күңел түрендә яткан иң зур, иң изге тойгыларын уятып җибәрүен башына да китерми иде...

## 12

Тагын ярты елдан төзелештә әртилләр бетә, аңлы эшчеләрдән бригадалар оеша башлады. Акча артыннан куу көннән-көн кими, ликбездә Зөлхәбирә Кадерметовада укып хәреф танырга өйрәнгән эшчеләр «Социализм юлы» газетасына язылдылар. Моннан тыш алар үз баракларының бер почмагына аерым бүлмә итеп ясалган кызыл почмакка кереп китаплар да укыйлар иде.

Февраль урталарында Ардуанов бригадасын Урал төзүчеләренең Почет кенәгәсенә керттеләр. Мирсәет Ардуановка Мәскәүнең үзеннән кызыл тышлы, ап-ак көмеш язулы «Ударник» кенәгәсе кайтып төште. Баштарак ул моны бригадасына күрсәтми торырга булган иде.

Кенәгә алганга өч көн уздымы-юкмы, Нәфүш-Сайрар кош очынып-җилкенеп Мирсәет абзый янына килеп керде: кулында газета, янында иптәшләре шаулашалар, берсен-берсе бүлдереп кычкыралар, ни әйтергә теләгәннәрен дә белерлек түгел.

— Балакайларым, кычкырмагыз шул чаклы. Колагымны тондырып бетердегез бит инде. Берәм-берәм генә сөйләгез,— диде бригадир.

— Мирсәет абзыкаем,— дип, шатлыгына төелеп, Нәфүш сөйли башлаган иде, аны Шамук бүлдерде, Сайрар кошны җилкәсе белән каплап, үзе алга килеп чыкты.

— Гәзиткә язганнар. Валлаһи-билләһи, абзый, ышанмасаң менә укып кара,— дип, Нәфүш кулыннан газетаны йолкып ук алды.

Нәфүш аның сөенечне шулай кинәт бер сүз белән әйтеп ташлавына риза булмыйча:

— Үзем сөйләем, Мирсәет абзыкаем. Башта мин күрдем. Мин сөйләем. Егетләргә үзем әйттем.

— Яле, нәрсәне әйттең икән? — Ардуанов газетаны үз кулына алды.

Егетләр берьюлы тындылар.

Ардуанов газетаны ашыкмый гына ачты, тез өстенә бөтен бите белән җәеп салды.

— Кайда? Әһә, менә икән...

Укый башлады. Әкрен, сөенечсез итеп укыды.

Егетләр тагын ду килделәр. Шулай укырга ярыймыни? Кадере китә бит.

Ликбездә сабагын иң тырышып укыган, Зөлхәбирәгә гашыйк булу сәбәпле, бер ай эчендә гәзитне «су кебек эчәргә» өйрәнгән Нәфүш-Сайрар кош теле-телгә йокмый укый башлады:

«...Бригаданың акча өчен генә эшләве бетте, акча интересы арткы планга күчте...»

— Сиздегезме, арткы планга күчте, дигән.

— Укы син, укы,— диде Мирсәет абзый, мыек астыннан елмаеп.

«...Борынгы тоз заводлары агызган рассол еллар буе җиргә сеңеп, йомшак балчыкны чуер ташка әйләндергән. Ломнар кәкрәйде, кәйлә үтмәсләнде, тимер көрәкләрнең йөзе кайтарылды, Ардуановлар таш катылыгына беләкләр ныклыгын, аммоналның шартлау көчен, җиңүгә булган ихтыярларын китереп куйдылар һәм таш җиңелде. Фундаментлар салынды... Аларның батырлык үрнәге бүтәннәрне күтәрде, хәтта эштән борын чөйгән дезертирларны да каһарманлыкка әйдәде».

— Вәйт әйткән! Менә, ичмасам, әйтеп караган! Шулай бит, абзыкаем?

— Арттырганнар,— диде Мирсәет абзый, көлемсерәп.— Лом кәкрәер көннәр алда әле...

Егетләрнең сөенече берьюлы юкка чыкты, нәүмизләнеп калдылар. Аларны артык үсендерергә ярамаганын аңлый иде Ардуанов, ләкин нәүмиз хәлендә кайтарып җибәрү дә егетлек түгел.

— Шәмсетдин улым, чәй әзерлә әле,— диде.

Барысы бергә, өстәл янына түгәрәкләнеп утырып, чәй эчтеләр.

— Сез миңа рәнҗемәгез, егетләр. Сөенечкә сөенергә кирәк, анысы дөрес,— Ардуанов кайнар чәйдән тирләп киткән такыр башын тастымал белән озаклап сөртте. Аннары гына сүзен дәвам иттерде:— Безгә җир казучы гына булып калырга ярамый, балакайлар...

— Нигә, әллә начар эшлибезме?

— Сүзем юк, начар эшләмибез. Шулай да җир казучы булып кына калу мәртәбә түгел. Башлыклар әйтә, иптәш Ардуанов, ди, бригадаң маладис, карусыз эшли, прогул ясамый, сугышмый, ди.— Бригадир Шамук ягына карап күз кысты, тегесе әллә кайчан булган гөнаһысы өчен кызарып башын иде.— Вәйт, шулай булгачыннан, нишләргә кирәк?

Алдагысы көнне уйлап эшләргә кирәк, и янә дә килеп һөнәр алырга кирәк.

— Нинди һөнәр?

— Башлыклар әйтә, бетончы һөнәренә өйрәнергә кирәк, ди.

— Нәрсә, без гомер буе монда каласымыни?

— Сабыр ит, улым, олылар сүзен бүлдермә. Калу-калмау синең үз ихтыярыңда, бирәү дә сине көчләми, ә менә өстәмә бер һөнәр алу эчне тишмәс. Һөнәрле үлмәс, һөнәрсез көн күрмәс, ди бит халык.

Егетләр карашып алдылар: нишлибез, янәсе. Алар бригадирларыннан сер яшермиләр иде.

— И Мирсәет абзый, монда калып та ни бар? Ялгыз каз кебек, моңаеп кына йөрисең...— диде Шамук.

— Әйтеп бетер, Шәмсетдин,— диде Мирсәет абзый, аның нәрсә әйтергә теләвен сизенеп.

— Гомер узып бара бит, абзый... Авылда... йөргән кызым көтә мине... Камиләм көтә...— Беткән баш беткән дип, кызу-кызу сөйләп китте.— Мин бит туйлык акча эшлим дип кенә килдем. Ә ул мине көтә... Дүрт күз белән көтә!

— Шулай укмыни? — Ардуанов, башын кырын салып, Шамукның йөзенә карап торды: егетнең пешеп житкән чагы, эче тулы ут чагы. Кара ничек көйри күзләр, кашлар ничек тетрәнә.— Бик хуп, бик мәслихәт,— ә без Камилә сеңлебезне монда чакыртсак?

— Килмәс лә ул...— диде Шамук, икеләнеп.

— Менәтерәк! Нишләп килмәсен ди. Мин кыз булсаммы? Синең ише арыслан егет артыннан жир читенә китәргә риза булыр идем... Менә нәрсә, балакайлар... Башлыклар әйтә, буйдак булып йөрүегез житәр, ди. Хатыннарыгыз булса, хатыннарыгызны, кызларыгыз булса, кызларыгызны чакырыгыз, ди. Йортлар житкезәбез, һөнәр өйрәтәбез, ди.

— Булыр микән, абзый?

— Теләк булсамы? Һи, җүләр, теләк булса, булмаган бер генә нәрсәкәй дә юк. Менә тиздән Нәбиулланы башлы-күзле итәбез.

— Кемгә?! — диде Нәфүш, онытылып.

Мирсәет абзый кеткелдәп кенә көлеп куйды.

— Зөлхәбирә мөгаллимәгә.

— Әй, мине яратмый бит соң ул.

— Нишләп яратмасын. «Мәскәүгә барып, курсларда гына укып кайтыйм, Нәфүш-Сайрар кошка ябышып чыгам»,— ди.

— И көлмә инде, Мирсәет абзыкаем. Мине мыскыллаудан бүтәнне белми бит суң ул: юнылмаган утын бүкәне, ди. Телең булмаса, әллә кайчан карга күтәреп китәр иде, ди. Дөньяда булган барлык көлке сүз белән мыскыллый.

— Димәк, ярата. Яратмаган кешенә андый сүз әйтеп булмый,— диде Мирсәет абзый.— Башлыклар әйтә, Нәбиулла Фәхриев бетон һөнәренә өйрәнсә, ди, киләсе язга мөгаллимә Зөлхәбирә белән кызыл туйларын үткәрәбез, ди.

Нәфүш-Сайрар кош, сүзнең җимен чамалап алып, көлеп куйды:

— И дә хәйләкәр әдәм син, Мирсәет абзыкаем, башлыклар дигән була. Боларның барысын син үзең уйлап чыгардың бит.

Ардуанов урындык аркасына кайшалып, рәхәтләнеп бер көлде. Күзеннән яшьләр атылып чыкты.

— Сездән бер генә нәрсәне дә яшереп булмый шул. И балакайлар, балакайлар... Ярый, кузгалышыйк, кадер төне түгел. Иртүк эшкә.— Житдиләнеп әйтте:— Бетончы һөнәре мин уйлап чыгарган нәрсәкәй түгел. Нурисламов, кадрлар бүлеге башлыгы әйтте, киләм әле барагыгызга, рәхәтләнеп бер сөйләшәм әле, диде. Ярата ул безне.

— Ә нишләп килми соң?!

— Безне чакырып китерде дә хәлне дә белгәне юк! — дип ду килде егетләр.

Мирсәет абзый сүзен тыныч кына дәвам иттерде:

— Хатыннарны китертү дә мин уйлап тапкан нәрсә түгел. Крутанов иптәш, Никифор Степановичны әйтәм, мине үзенә чакырды. Акча эшлим дә качам дип йөрергә түгел, стройканың патриоты булырга вакыт. Сез ударниклар, Ардуанов. Унбиш мең кешенең күзе сезгә төбәлгән, ди. Мин инде Мәүгыйзә апагызга хат яздым, Мирзанур белән Кәшифәне алып, бер көн кичекми килеп җит, дидем.

Ул әле хат язмаган иде. Егетләр саубуллашып чыгып киткәч, сүзе ялган булмасын өчен, хат язарга утырды.

Озак язды хатны.

Сүзен таба алмый аптырады. Күңелдә җыелганны Мәүгыйзәсенә җылы итеп әйтәсе килде. Ләкин Мирсәет абзыйның кулы җанындагы җылыны язып өлгерерлек житез түгел иде. Шуңа күрә күңелдәгесе күңелдә калды, хатка гадәттәге, өйрәнелгән сүзләр язылды.

«Хат башы — яз каршы. Сезки гыйззәтлү вә хөрмәтлү булып торгучы хәләл җефетем Мәүгыйзәгә безки Биризнәктә җир казучы ирең Мирсәеттән күптин-күп сәламнәр. Дәхи дә килеп баш балам Мирзанур белән төпчегем Кәшифәгә сагынычлы сәләмнәр күндерәм. Туган-тумачага, күрше-күләнгә, мине сораганнарга үзең белеп сәлам әйтерсең. Сәләм шуның белән тәмам, бераз сүзләргә күчәм. Бу хатны язуымның сәбәбе шулдыр, син инде, Мәүгыйзә, бозауны сат, кырыкмышны берәрсенә асрамага биреп калдыр. Ник дип әйтсәң, мин быел кышка кайта алмам инде. Монда эшләр бик зурайды. Балаларны ал да төянеп үзең кил. Күршеләргә дә әйт, киләселәре килсә килсеннәр, ким-хур булабыз дип курыкмасыннар, эш хакы әйбәт төшә, рабучий кешенең пачуты артты, эштән курыкмаган кешегә эш муеннан. Бу хатны яздым фибралның унтугызынчы числасында. Хат көтеп калучы ирең Мирсәет дип белерсең».

## 13

Бетон эшенә өйрәнү дүрт ай вакытны алды. Айлап түгел, көнләп, сәгатьләп көтәрелгән гигант төзелеш өчен бу аз вакыт түгел иде; аның каравы, яңа һөнәр Ардуанов бригадасын төзелешнең урта бер җиренә китереп куйды һәм унбиш меңлек төзүчеләр армиясе белән турыдантуры бәйләнешкә кертте.

Элек, җир казучы булган чагында, алар әле беркем дә аяк басмаган яңа җиргә киләләр, җан-фәрманга тырышып канау казыйлар, котлован казыйлар, туннель тишәләр, балчыгын тачка белән, носилка белән йөгерә-чаптыра читкә чыгарып аударалар да, төзелешнең иң кызыклы эше — каркаслар кую, монтажлау, цементлау башлангач, китәләр дә баралар иде.

Чынлыкта алар башка бригадалардан аерылган хәлдә, үз уйлары белән япа-ялгыз яшиләр, төзелешнең бердәм механизмы аларны чыбыркылап тормый, үз казанында кайнатмый, һаман да читтәрәк йөртә иде.

Бетончы булу аларны слесарь-монтажниклар, балта осталары, электриклар белән бергә китереп тоташтырды, рус, украин, белорус егетләреннән җыелган бригадалар белән аралаштырды, бригаданың аңы үсү, житлегү, нәрсәнең нәрсәгә яраганын яки ярамаганын аңлауны тизләтте.

Бетончы булуның әйтеп бетергесез күп яңа мәшәкатьләре килеп чыкты. Бетончы һөнәре иң әүвәл бригадирдан тәүлегенә күпме измә ясауны гына түгел, ничек итеп ясауны, сызымнар белән эш итә белүне, Мирсәет абзый үз гомерендә дә ишетмәгән «опалобка» «заливка»,

«трамбовка» «конфигурация» дигән төшенчәләрне аңлауны таләп итте. Ягъни гомуми белемнән тыш техник яктан да грамоталы булу кирәк иде. Ардуанов хәзер үз егетләре белән бергә Зөлхәбирә Кадерматовадан укымый, прораб Борис Зуевтан укый. Бер ел эчендә тоташ грамоталы булырга дип йөкләмә алган Кызыл байраклы беренче баракта, кичләрен бригада җыелгач, баракның аргы башына ике кат фанер белән бүлеп ясалган Ардуанов фатирында да дәрес башлана. Борис Зуев — аксыл чырайлы, зәңгәр күзле Алабуга егете — килгән саен, ишек шакып, тартынып кына керә, озын буйлы, мәзәк сүзле, татарларда сирәк очрый торган җете зәңгәр күзле Мәүгыйзә түтигә (күчеп килүләренә әле ике атна да юк) бүрек салып баш кага, үсмер егет Мирзанур белән, тиң күреп, кул биреп күрешә, һәм алар Мирсәет абзый белән шундук эшкә керешәләр. Өстәл янына утырулары була, ишектән шаулап-кычкырып Катя-Кәшифә — ун яшьлек кыз бала кайтып керә. Ул урысча яңа сүз откан, шуны әтисе, кунак абыйсы белән уртаклашырга тели: ләкин тегеләр моның сүзен юньле-рәтле тыңламыйлар, тизрәк әнисе ягына чыгарып җибәрү ягын карыйлар.

Әтисе укыган чакта Мирзанур да колак салып утыра — аңа әйбер әйтмиләр, тавышланмаска, сорау биреп алҗытмаска гына кушалар.

Өстәлдә карта-сызым җәелеп ята. Борис аяк өсте баскан көйгә, иелә төшеп, карта буйлап бармагын йөртә-йөртә, җайлап кына сөйли, өлгеләрне кая куярга, фундаментны ничә ячейкага бүләргә, эшләгән эшнең күләмен ничек исәпләп чыгарырга икәнен аңлата. Туры почмаклы мәйданны тиз аңлый Ардуанов, аның үтә тере коңгырт күзләре, Борис әйткәнгә күнеп, елмайгандай итеп торалар. Ә менә гөмбәзле бинаны, өч почмаклы кыекның күләмен ничек итеп дөрес исәпләргә? Андый чакта Ардуанов моңаеп кала: күперенке дәү мыегы сәленеп төшә, күзләре уйчанлана. Ипле егет Борис, иренми, каударланмый, өр-яңадан аңлатырга тотына. Эшләнә торган эшнең һәр звеносын, аерым-аерым, берәм-берәм алып төшендерә, бу юлы да аңлата алмаса, һич нервыланмастан, өченче кат тотына; сабыр җанлы, һич кенә дә түземен җуймас бу рус егетенең аңлатуы барак ягында уен-көлке, гармун-җыр тавышлары ишетелә башлаганчы дәвам итә.

Уен-көлке башландымы, Борис аңлату сәләтен җуя. Аның ачуын кузгаткан нәрсә — гармун тавышы. Моның үзенә күрә сәбәбе дә бар. Өч ел буе яратып, өйләнәм дип йөргән кызы, аны ташлап, поп малаена кияүгә чыккан, туйда исерекләр төне буе гармун үкерткәннәр. Шуннан бирле Борис гармун уйнаганны күрәлми...

...Зур бер шүрәдән сүтелгән җеп төсле, ашыгып-ашыгып көннәр үтә; Кама ярында, Чуртан поселогында, Березникида берсеннән-берсе зуррак корылмалар үсеп чыга; төзелеш колачы арта барган саен синнән күбрәк нәрсә таләп итә, син төзелеш белән бергә үсәргә, бергә чыныгырга тиеш, юкса, ул сине кирәксез бер чүп итеп читкә ыргытып ташлаячак.

Әле күптән түгел, моннан бер ел элек кенә, синең егетләрең торф сазлыгын актарып салган дамба юлдан көне-төне, көне-төне олаулар агыла — химкомбинат төзелешенә җиһаз ташыйлар; дамбаның ике ягында дүртәр-бишәр катлы өч йорт үсеп чыкты,— берсендә мәктәп, берсендә балалар бакчасы, берсендә клуб ачып җибәрделәр; алар тирәсенә конторкалар, времянкалар, такта бараклар килеп сыенды; урамга, булачак химия шәһәренең беренче урамына «Пятилетка» дип исем куштылар. Халык телендә һаман бер сүз: пятилетка, бишьеллык!

Язын, әйләнә-тирә кардан арчылып, җир кипшергәч, төзелешкә ике машина кайтты. Искергән, буяулары уңган «Пирс» машиналарын шау-гөр килеп каршы алдылар.

Машиналар бишәр тонналы, тоташ резин тәгәрмәчле. Пермь шоферлары китерде аларны. Китерделәр дә китеп тә бардылар.

Инде менә унбиш мең эшче арасыннан машина йөртә белүче эзлиләр. Һай, заманалар диген! Крутанов бу эшкә үзе тотынды, биш якка биш ярдәмчесен чыгарып җибәрде, комсомолны эшкә кушты. Кадрлар бүлегендә Нурисламов, унбиш мең эшченең антекасын актарып, каустика цехы төзелешендә эшләүче Буранов фамилияле берәүне тапты. Аны төзелеш башлыгы кабинетына китерделәр.

— Утырыгыз, Роман Яковлевич,— диде Крутанов, слесарьга өмет белән карап.— Сез безгә бик тә кирәк кеше. Кадрлар бүлегендә сезнең Ленинградта автомәктәп бетергәнегезне белделәр. Дөресме шул хәл?

— Дөрес...— диде Буранов, теләр-теләмәс кенә.

— Димәк, сез машина ремонтлый аласыз.

— Алам...

— Мин сездә энтузиазм күрмим, иптәш Буранов.

Слесарь ирен чите белән генә елмайды.

— Мин бит, иптәш начальник, аларны япа-ялгызым ремонтлый алмыйм. Кимендә ике ярдәмче кирәк.

— Шул да булдымы сүз? Хет унны алыгыз, хет егермене!

— Миңа бит автоэшне белүче кирәк.

— Анысы булмый, Роман Яковлевич. Үзегезгә, әйе, әйе, үзегезгә әзерләргә кала.

— Булмастыр.

— Ничек булмас? Ничек инде ул булмас?! — Крутанов кинәт кызып китте.— Без дөньяда тиңе булмаган революция ясадык — булды. Ачлангач илдә химия гиганты салырга тотындык — була. Америка буржуйларыннан калган йолкыш бер утильны төзәтергә кеше булмасын, имеш. Куегыз, әдәм көлдермәгез! Мин сезгә, Роман Яковлевич, адрес бирәм. Балта остасы Громовка, слесарь Вотиновка, бетончы Ардуановка барыгыз. Удар бригадаларга. Һәркайсыннан берәр кеше бүлеп бирсеннәр. Һәм, мин ышанам, сез алардан бер атна эчендә менә дигән машина йөртүче әзерләрсез. Утырып, кызу-кызу, эре-эре хәрефләр белән, селтәнеп торып кәгазь язды, кул куйды, Бурановның кулына тоттырды да кире кага алмаслык итеп әйтте:

— Барыгыз, бүген үк эшкә тотыныгыз. Иртәгә иртүк, сәгать сигездә миңа, шакымый-нитми кереп, хәбәр итәрсез. Уныш телим!

Ардуанов бригадасыннан автомобиль эшенә Нәбиулла Фәхриевне бирделәр; «Сайрар кош» үзе теләп, ашкынып, йөрәксенеп тотынды. Һәм бу аның Зөлхәбирә белән булган күңел җепләре ныгуга да бик зур сәбәп булды. Көннең-көн буе, кайчагында уникешәр сәгать рәттән ватык машина янында кайнашканнан соң (аның түземлелегенә хәтта Бурановның да исе-акылы китте!) җен кебек каралып, машина маена батып кайтып керә дә, бил тиңентен чишенеп ташлап, шапыр-шопыр юына, «бар булган урысчасын биреп алган» костюмын киеп, Буранов биргән урысча китапны куенына кыстырып, Зөлхәбирә янына, кызлар барагына ашыга. Бергәләп өстәл янына утыралар. Зөлхәбирә Нәфүш аңламаган урысча сүзләрне татарчалатып әйтә, Нәфүш аңа машинаның йөрү системасын, кайда нинди механизмнары барлыгын сөйли, һәвәсләнеп, кабынып сөйли. Зөлхәбирә аңа зур кара күзләрен тутырып карап тора, Нәфүш кызарынып, күзләрен читкә алгач кына, егетне оялтуын аңлап, китап өстенә иелә; вакыт-вакыт, китап өстенә иелгән чакта, Зөлхәбирәнең чәч бөдрәләре Нәфүшнең муенына кагылып, рәхәт кытыклый, егет зыңлап торган тәненә кайнар ут йөгерүен тоя, башына шаулап кан йөгерә, битләре уттай кызыша һәм Зөлхәбирәнең яңгыравыклы тигез тавышы үз янында түгел, кайдадыр еракта, тайга урманнары эчендә ишетелә башлый...

*Ахыры бар*

## Рөстәм Мингалимов

•

Җитди итеп әйтәм,
Һич сөйләмим көлеп:
Миңа Татарстан —
Җир үзәге кебек...
Йөрим кайчак чыгып,
Шәһәрләрем күреп.
Казан — шәһәрләрнең
Иң гүзәле кебек.
Сорасалар әгәр,
Бирә алмам бүлеп —
Мәскәү — Татарстан
Шәһәредер кебек.

Кул сузсалар әгәр
Җиде ятлар килеп,
Я җиңәрмен яшәп,
Я җиңәрмен үлеп.
Мин дөньяны сөйдем,
Дөнья торсын белеп!
Ул Татарстанның
Бер өлеше кебек.
Ялгышасың диеп,
Әйтсә кемдер көлеп —
Шул кешегә мәңге
Үпкәләрмен кебек.

### Суыкларга кердек исә...

Кышкы суыкларга кердек исә,
Хәтеремә төшә үткәннәр...
Аякта нык хәзер, өстә калын,
Онытылсын иде ул көннәр:
Тәрәзләргә салкын урман чикте,
Ә ягарга утын юк иде...
Шәһәрләр ач иде, авыллар ач —
Сугыш кына ул чак тук иде.
Су буенда безнең ач әнкәйләр
Су җылыта иде малларга.
Башлары боз иде, өсләре боз —
Боз хатыннар кебек аналар!
Кулларында һаман бозлы чиләк,
Юлларына калын боз сарган.
Елгасы боз аның, дөньясы боз —
Таймас өчен ныграк басарга!
Итәкләрен тарта боз чуклары,
Бөкләгәндә җиңнәр сыналар.
Өйгә кайтып безне җылытырга
Ничек җылы тапкан соң алар?
Бик өшетеп хәтеремә төшә,
Йөрәгемә төшә ул көннәр.
Күшегеп тора иде, бөгәрләнеп
Морҗалардан чыккан төтеннәр.

## Күк барында...

Акчам бетсә — «бәхетсезлек!» дисәм мин,
Ярым китсә — «бәхетсезлек!» дисәм мин,
Яшьлек үтсә — «бәхетсезлек!» дисәм мин —
Оятыннан бәхетем йөзе кызарыр.
Җиңел генә «Мин бәхетсез!» димәм мин,
Күк барында башым түбән имәм мин.
Торалмасам гына шушы сүземдә —
Горур бәхетем янымнан китеп барыр.

## Бар да барып җитәрләр

Ашыгып үтте җәяүле,
Үтте атлы дөбердәп...
Машиналы үтеп китте,
Самолет үтте гөрләп.
Максатлары бардыр алда,
Бар да барып җитәрләр.

Максатын югалтканнар бар,
Шулар ни хәл итәрләр?!

## Олыгайгач

Яз Иделне эретерлек итеп
Күккә учак яга.
«Бозлар китә, бозлар китә!» — диеп,
Йөгерә бала-чага.
«Бозлар китә, бозлар китә!» — диеп,
Йөгерер идем мин дә —
Мәңге китми торган
бозлар бар шул
күңелем иделендә.

## Ерактагы зәңгәр офыгым бул

Син каршымда горур кыя булма,
Булма нәни чишмә яктысы...
Ерактагы зәңгәр офыгым бул,
Тормыш таңым синдә яктырсын.

Юлларымда көзге чәчәк булма,
Булма язгы ярсу ташкын син...
Ерактагы зәңгәр офыгым бул,
Йөрәгем гел сиңа ашкынсын.

Кәккүк булып кырда кычкырсам да,
Әйтмә, җүйды бу, дип, оясын...
Ерактагы зәңгәр офыгым бул,
Сиңа төшсен гомер кояшым.

Тыныч төн бу, җәйге төн бу авылда.
Кое тора урам уты алдында.
Җанга ничек тынгы килсен ди хәзер,
Җанга ничек тынгы килсен ди хәзер?!
Буйга җиткән ак күлмәкле кыз бала
шыңгыр-шыңгыр,
шыңгыр-шыңгыр
су ала.

Күкрәгемдә тау ватарлык көчем бар.
Таңда торып юл чыгасы эшем бар.
Ялгыз китү җиңел түгел бит инде,
Ялгыз китү җиңел түгел бит инде?!
Үсеп җиткән ак күлмәкле кыз бала
шыңгыр-шыңгыр,
шыңгыр-шыңгыр
су ала.

Тыныч төн бу, җәйге төн бу авылда.
Болай соңлап ник инде су алырга...
Алган суы күңел утын сүндермәс,
Дәрьялар да күңел утын сүндермәс?!
Ак күлмәкле, кара кашлы кыз бала
шыңгыр-шыңгыр,
шыңгыр-шыңгыр
су ала...

## Госман Садə

### Тимерче

Койдым келə, койдым йозак,
Койдым богау тимердəн.
Кемгə хəсрəт, кемгə елау,
Кемгə əрнү китергəн —
Койдым кайгы тимердəн.
Шул ук тимер... Кыздырдым да
Ишеккə тотка койдым.
Кешелəрдə шатлык күргəч,
Үземне күктə тойдым.
...Нибары тотка койдым.

●

Яшел үлəн. Ямьле чагың,
Болын, болын.
Эңгер төшə. Болынлыкта
Нəни колын.

Чыга болыт. Кала тынып
Бар тирə-юнь.
Яшьни яшен. Бер мизгелгə
Яктыра төн.

Караңгыга төрə җирне
Янə кемдер.
Күктəн арба уза кебек
Дөбер-дөбер.

Шул тавыштан җир-күк кинəт
Дер селкенə.
Курка колын. Сыена ул
Әнисенə.

...Таң яктыра. Нурга чума
Чыклы болын.
Таң нурларын юрган итеп,
Йоклый колын.

●

Аңлау кыен таулар җанын,
Алар сирəк телгə килə.
Гасырга бер, онытылып,
Каһкаһалап таулар көлə:
А-һа-һа-а!

Үзəннəрдəн уза күкрəү,
Кайтавазлар кайта кабат.
Таш кыяда оя корган
Чал бөркетлəр кага канат.

Кунып бөркет канатына,
Илдəн-илгə күкрəү бара.
Күкрəү чыккан күкрəклəрдə
Җөй, җəрəхəт — күпме яра.

...Гасырларны сискəндереп,
Каһкаһалап таулар көлə:
А-һа-һа-а!
Аңлар өчен таулар җанын
Яңа буын җиргə килə.

# РАФАИЛ ТӨХФӘТУЛЛИНГА 50 ЯШЬ

**Кадерле дустыбыз Рафаил! Сине, күренекле каләм иясен, алтын юбилееӊ белән ихлас күӊелдән тәбрик итәбез.**

**Туган туфракта шытып, шунда тамыр җибәргән, яшьтән үк тормыш җиленә йөзен куйган тынгысыз талантларныӊ берсе син. Трактор руленә утырып, иген кырларын гөрләткәнсеӊ, күмер шахталарына төшеп, илгә якты, җылы табышкансыӊ. Ә хәвефле, дәһшәтле көннәр башлангач, кулыӊа мылтык алып, Ватан иркен якларга киткәнсеӊ, халкыӊа тугрылыклы икәнлегеӊне кан белән раслагансыӊ.**

**Туплар авазы тынуга, мылтыгыӊны син каләмгә алыштырдыӊ, «Таныш гөрелте»ӊ белән киӊ әдәбият мәйданына килеп кердеӊ. Кабатланмас гаҗәеп бу авазларга меӊләгән укучыларыӊ сокланып колак салды.**

**Син бәхетле йолдыз астында туган, авыр иҗат юлында үз йолдызыӊны табу бәхетенә ирешкән нәфис сүз осталарыныӊ берсе. «Авылдашым Нәби», «Йолдызым», «Тамчылар ни сөйли», «Агымсу» шикелле гүзәл повестьларыӊны, шигъри хикәяләреӊне, нефть ягы кешеләрен данлаган сугышчан очеркларыӊны татар һәм рус укучылары бердәй яратып кабул иттеләр. Алар республикабызда гына түгел, Мәскәү нәшриятларында, үзәк журналларда һәм газеталарда әледән-әле басылып киләләр. Синеӊ исемеӊ күп милләтле Совет халкына яхшы таныш. Геройларыӊ тормыш эченнән күтәрелгән һәм әсәрләреӊдә дә тормыш сулышыныӊ кайнарлыгы бөркелеп тора.**

**Яшьлегеӊ синеӊ пионер быргылары астында, комсомол сафларында шаулап узган, канлы ут эчендә чыныккан. Алга табан да иҗатыӊда яшьлек дәрте бөркелеп торсын.**

**Сиӊа, Рафаил дустыбыз, корычтай сәламәтлек, озын гомер һәм иҗатта яӊа биеклекләр телибез.**

**Туар көннәреӊ һәр вакыт аяз, саф һәм ашкынулы булсын!**

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ИДАРӘСЕ.
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫӉ ӘЛМӘТ ОЕШМАСЫ.
«КАЗАН УТЛАРЫ» ЖУРНАЛЫ.

## Рафаил Төхфәтуллин

# АКБҮЗ АТ

ПОВЕСТЬ

### 1

Хәзер Әсгать этисеннән нәкъ ун яшькә олы. Колхозның баш механигы ул, авылда хөрмәтле кеше, ике малай белән бер кыз үстерә. Әтисе сугышка китеп, икеме-өчме ай үткәч туды Әсгать. Ә олы улы яшендә... юк, уртанчы кызы яшьләрендәдер, Галимҗанның кара матәм кәгазен алганнар. Бу хәбәр миңа хат аша сугышта чакта ук, Пруссия җирендә килеп җитте.



Озакламый без, җәһәннәм утларыннан исән чыгучылар, әйләнеп кайттык. Хәер, бу «озакламый» дигәнем алай бик тиз генә булмады. Без яшь солдатларны сугыш бетүгә үк кайтарып җибәрмәделәр. Үзебез сугышып үткән ил-җирләрдә ике елдан артык туп-ядрә шартлатмыйча гына да хезмәт итәргә туры килде.

Мин авылга кайтканда, Әсгать, әнә, үзенең олы малае яшьләрендә иде.

Бик хәтердә ул көннәр.

Менә хәзер уйласам оялып та куям, кайткан көнне үк алар янына кереп чыга да алмадым. Дус-иш егетләр, туган-тумача белән солдат тузаннарын кагып-юып йөри-йөри, икеме, өчме көн үтеп тә киткән.

...Әкълимә белән күрешкәндә мин каушап калдым. Янып торган алсу йөзле, көлә башласа көлеп туймый торган кыз, аннары шундый ук шукчая, гаҗәп җиңел-житез яшь килен — хәтеремә шулай сеңеп калган иде ул. Һәм менә каршымда... бик өлкән бер хатын басып тора. Авыз кырыйларыннан ияккә таба тирән генә җыерчыклар салынып төшкән, маңгаен да җыерчыклар сырлаган һәм нигәдер тагын шул бик күзгә ташланды: борыны калынаеп, зураеп киткән...

Мин кайткач ук керә алмавыма гафу сорап мыгырдандым.

— Бушый алмаганыңны күреп йөрдем. Ничәмә еллар утлар-сулар кичеп кайт та алай гына бер типтереп тә алма! — диде Әкълимә һәм тын гына гөрләп көлеп куйды.

Ә көлүе... бигрәк тә, әнә, тезелеп киткән ап-ак тешләре шул ук икән. Әйе, нәкъ элеккечә. Бу энҗе тешләрдән бөтен йөзенә якты-шук нурлар сибелә кебек, әнә, бу нурлар аның бар йөз җыерчыкларын күмеп таш-

лады, энә, жыерчыклар бөтенләй юкка чыкты. Һәм менә, бу нурлар яктысы минем йөзгә дә килеп кунды түгелме?

— Утыз көн уразаның бер бәйрәме дә була диләр бит...

— Шулай булмый ни. Сез түгел, менә без дә... Дөньясын онытып бер бәйрәм итәсе килә кайчак.

Кинәт буыла-буыла йөткергән тавыш ишетелде. Түрдәге агач караватта йодрык кадәр генә башын тезләренә бәрә-бәрә тетрәп-чайкалып утырган карчыкны шунда гына күреп алдым. Иа алла, Галимҗанның әнисе ич бу. Заманында, сугышка чаклы ук әле, ирләрдән уздырып печәнен чапкан, кибәнен куйган авылда бер хатын...

— Исәнме-саумы, Майҗамал апа! Әллә авырып киттеңме? — дип, аның белән килеп күрештем.

Карчык, шиңгән күк җиләктәй күзләрен карават башына текәгән килеш, нидер мыгырданды.

Мин, авыруны куандырмакчы булып, үземнең күчтәнәчләремне — ул елларда шактый тансык булган бер такта чәй, конфет-мазарны аның алдына куйдым. Майҗамал апа аларга үрелде, әмма күзләрен карават башыннан алмады.

— Әнкәй, Харис бу. Галимҗанның дусты. Солдаттан кайтты, — диде Әкълимә. — Сугышта Галимҗан белән бергә булганнар.

— Шулаймы?.. Әйбәт, әйбәт...— дигән сүзләрне бу юлы аера алдым.

— Какшабрак китте шул әнкәй соңгы вакытта, — диде Әкълимә. — Җир селкетеп йөргән җиреннән бигрәк кинәт сыгылды да төште. Врач дарулары да нигәдер килешеп кенә китми... Тәмам аптырагач, өшкертеп тә карадым...

Майҗамал апа юрганын башына ук тартып, стенага таба борылып ятты.

— Кая соң, нишләп торам әле мин. Самавар да куеп җибәрмичә...— дип сөйләнә-сөйләнә, Әкълимә, ике якны бер итеп, идәннәрне зыр селкетеп йөри башлады.

Шул чак Әсгать тә кайтып керде. Атылып килеп керүгә, мине күреп, туктап калды. Һич оныта алмыйм, зур ачылган күзләре ташырга торган шатлыктан балкый иде аның, шул ук вакытта ниндидер шүрләүме, әллә шөбһәме чагыла иде карашында. Юк, күзләре генә түгел, бөтен торыш-килбәте шулай иде: шатлыклы да, шөбһәле дә. Әйтерсең малайга күзгә күренмәс канатлар үскән дә, ул, чиксез шатланып, менә-менә очып китәргә тора, әмма бу очудан бераз шүрли дә...

Аннары шул: малай һич тә «суйган да каплаган әтисе» түгел, юк, бөтенләй охшамаган ул әтисенә. Җирән үк булмаса да, чәче-кашы куе саргылт иде Галимҗанның, борын-иреннәр шактый мулдан иде. Әсгать исә әнисенә тартым кара малай, хәтта әнисеннән дә карарак бугай — йөзләре үк сөйкемле кара тутлы.

— Улым, күреш Харис абыең белән, — диде Әкълимә.

Әсгатьнең башы түбән иелде. Шулай башын түбән игән килеш кенә миңа кулын сузды. Мин, мондый вакытларда әйтелә торган: «Я, үсеп буламы, егет?.. Исемең ничек әле?» кебек сораулар тездем. Әсгать ләммим җавап бирмәде.

— Слуши, син шахмат уйный беләсеңме? Белмәсәң, әйдә, өйрәтәм. Кил безгә,— дип, үземчә әлеге тапталган сораулардан уздырмак та булдым. Малайның теле ачылмады.

Килеп кергәндәге очынулы-утлы карашлары кая китте соң әле аның?

Икенче яктан, бу аңлашылмас үҗәтлеге белән әтисен хәтерләтә иде Әсгать. Галимҗанның да бар иде шундыйрак сәер гадәте. Бу турыда мин Әкълимәгә дә әйттем.

— Үзем дә шулай дим,— диде Әкълимә, энже тешләрен балкытып. Әчке бер куаныч, горурлык белән әйтте ул бу сүзләрне.

Алтындай ялтырап торган җиз самавар өстәлдә иде инде. Табын янында сүз үзеннән-үзе Галимҗан турында куерды.

Галимҗан класстан-класска гел иң арткы партада утырыр иде. Гадәттәге «Камчатка малайлары» кебек, алдагыларга чәйнәлгән кәгазь пулялар атып, чышын-пышын кыбырсып утыручылардан түгел иде ул үзе. Киресенчә, класста иң тәртипле, юаш малайлардан иде. Хәер, «юаш» сүзе Галимҗанга бик батмый да. Класста чыпчыклар арасындагы карга сыман йөрүче Сәетгәрәй бар иде — әллә берәр ел укымый үткәргән, әллә кайсыдыр партада икешәр ел ыштан төбе шомарткан, ачык кына хәтерләмим дә. Әнә шул сугыш чукмарын искә алмаганда, Галимҗанга бармак белән дә чиертүче булмады. Юк, алай дисәм тагын бик үк дөрес булмас. Кызлардан бик эләгә иде үзенә. Тәнәфесләрдә коридор почмагында бу кызлар нигә шулай өелешеп чыр-чу киләләр дисәң, Галимҗанны тукмыйлар икән. Бишмәт төймәләре ни арада коелып беткән моның дисәң, кызлар уздырыштан чүпләгән. «Борының, битең нигә шәмәхә, Галимҗан?» «Кызлар шулай бизәде...» Ә үзе бу чая халыкка кул күтәрү түгел, кычкырыбрак та сүз әйтмәс иде, бахыр.

Галимҗан болай начар укымый иде, әмма... Менә укытучы аңа сорау бирә. Галимҗан солдатларча төп-төз торып баса, ә башы кинәт күкрәгенә үк салынып төшә. Зур колак яфраклары күзгә күренеп кызара бара. Шушы кызыллыктан җирәнгә тартым чәчләренә дә дөрләп ут кабына кебек. «Я, я, Гатауллин?» ди укытучы. Галимҗан дәшми. Укытучы сорауны үтемлерәк, аңлаешлырак итеп кабатлый, менә ярты җавапны инде үзе әйтеп бетерә язды... Юк, Галимҗан авызыннан эһ иткән аваз чыкмый. Ник сәгать буе басып тормый — шул ук хәл.

Гомумән, Галимҗанның мәктәптә укытучыларга авыз ачып бер кәлимә сүз әйткәне булды микән?

Галимҗан дәресләрдә балык кебек телсез булса да, класстан класска әйбәт кенә күчеп барды. Ник дигәндә, язма эшләрдән шәп алдыра иде ул. Язуын гына күрсәң иде син аның! Гәрәбә күк хәрефләре типтигез тәгәрәшеп торыр, дәфтәр битләрендә ник бер тап-кер әсәре булсын!

Уку елы ахырына таба Галимҗанның дәресләрдә дә теле ачыла башлаган иде башлавын. Ләкин аңа алтынчыдан ары укырга туры килмәде. Әтисе үлеп китте дә, Галимҗан өч сеңлесе белән бер әнисе кулында калды.

Карт иде инде аның әтисе, бабай иде. Олылардан ишетә торган идек: ул карт үз гомерендә әллә биш, әллә алты мәртәбә өйләнгән булган, ләкин, ни хикмәттер, хатыннары аның белән озак тормаганнар. Ә соңгы яшь хатыны белән, ягъни Галимҗанның әнисе белән бик әйбәт яшәп киткәннәр алар, күзгә-күз карашып кына гомер иткәннәр.

Тиздән Галимҗан авылыбызның хат ташучысы булып китте. Почта бүлекчәсе бездән дүрт чакрымдагы Ташкичү авылында иде ул чакта. Галимҗан һәр бирмеш көнне, зур кара сумкасын асып, шуннан хат ташый, газета-журнал ташый, җилкәсенә посылкалар да аса. Посылкаларны бүлекчәдән алып кайту аның вазифасына керми дә иде бугай — кәгазен алып кайтып бирсә, шул җитә — ләкин Галимҗан күчтәнәч хуҗаларын тизрәк үзе шатландырмакчы.

Мәктәптә бергә укыганда без Галимҗан белән алай якын дуслар түгел идек. Урамдашлар, сабакташлар — шуннан артмый иде. Безнең дуслык Галимҗан хат ташып йөри башлагач ныгып китте. Галимҗан-

ның әнә шул зур кара сумкасы дуслаштырды безне. Ул серле сумканы без гел икәүләшеп актара торган булдык.

Менә җан тиргә баткан Галимҗан күтәренеп кайтып килә. Вакытын чамалап, еш кына ярты юлга кадәр мин дә аның каршына барам. Кайтып җитүгә, әтисе кайчандыр тәрәзә рамнары ясап яткан верстаклы лапас почмагы үзенә күрә бер уку залына әверелә. Майҗамал апа, кырдан кайтышлый көлтәләп ташый-ташый, бер якка хуш исле печән чүмәләсе өеп куйган. Шунда сузылып ятабыз да, китә авылда әле берәү дә кулына алмаган өр-яңа газета, журналлар уку, китапханәгә килә торган китап, брошюралар, плакатлар актару...

Һай, шул чаклар! Күкрәк тулы чәчәкле печән исе, верстакка тәмам сеңгән нарат сагызы исе. Тирәбездә тавыклар җырлап йөри, чырыйк-чырыйк килеп кара карлыгач лапас түбәсендәге оясына гел нидер ташый, печән эчендә тын гына әллә нiләр кыштырдый. Боларны да ишетәбез, сизәбез, ә үзебез әллә кайларда... Мадрид баррикадаларында сугышабыз, Берлин диварларына шыпырт кына листовкалар ябыштырып йөрибез, япон чигендә шпионнар тотабыз...

Шулай хыялланабыз-хыялланабыз да, бермәл күңелле генә көлешә башлыйбыз.

— Акбүз атка атланып, име?

Икебез дә бик ярата идек без ул Акбүз ат турындагы әкиятне. Галимҗанга бу әкиятне күптән, авырып яткан чагында, карт әтисе сөйләгән булган.

— Шул әкиятне тыңлап кына терелдем дә мин, — дияр иде Галимҗан.

Галимҗанның бик укырга яратканын, никадәр күп әкиятләр белгәнен мәктәптә чакта мин абайламый да идем. Аннары, Галимҗанның «сөйләшми» дигән даны киткән иде бит. Ә хәзер без сөйләшә-серләшә башласак, көннәр, төннәр, атналар буе да иге-чигенә чыгарлык түгел.

...Күпмедер вакыттан соң, Галимҗанга икенче бер эш йөкләделәр. МТСтан килгән өй чаклы зур сугу машинасының мотористы итеп билгеләделәр аны. Мәктәптә укыганда ук Галимҗанны «механек» дип йөртәләр иде. Кемнең сәгате йөрми, кемнең тегү машинасы көйсезләнә — Галимҗанны чакыралар. Мыш-мыш килеп көнозын маташса маташа Галимҗан, әмма эшен эш итми туктамый. Инде менә нигәдер бик еш ватылып тора торган сугу машинасы движогын да аңа ышанып тапшырдылар. Электән дә гел шул тирәдә юкка чуалмаган икән, көйсез движокның да телен-җаен тиз тапты ул — әвен ягыннан тигез гөрелдәү көн-төн бер туктамый ишетелеп тора хәзер. Ә хат ташу вазифасын Галимҗан, чиратлаштырып, өч сеңлесенә йөкләде. Ләкин шундый шарт: Ташкичүдән кайткан серле кара сумка иң башта Галимҗан кулына тапшырылырга тиеш.

Шулай итеп, безнең «уку залы»ның урыны үзгәрде. Әвендә, салам эскерте төбендә хәзер. Без туйганчы актаргач, укып туйгач кына, кара сумка сеңелкәшләрнең берсенең иңенә менә.

Айлар, ничәдер еллар шулай дәвам итте. Әмма һәрнәрсәнең чиге бар бит...

Бервакыт кинодан кайтып киләм. Ундүртенче көне бугай айның — клуб өстендә көмеш табак кебек балкый. Җирдән энә эзләп табарлык якты. Язгы салкынча һаваны сулаулары тәмле каймак эчкәннән ким түгел. Урамнар тын. Тик арырак берәү җырлый. Егетләр тавышы, шактый моңлы яңгырый. Каршыга килә бугай, инде җырның сүзләрен дә аермачык ишетәм.

Сикереп мендем, бил бирмәде,
Егылып төштем Акбүздән.
Җан бирсәң дә, яр бирмәгез —
Васыять булсын бу бездән.

Шактый өлкән ир-егеттәр инде бу, яр бирмәү турында васыятьләр әйтеп моңлана бит. Ә акбүз дигәне безнең әлеге әкияттәге аргамактыр әле! Әкияте булгач, нигә җыры да булмасын?

Җырчы якынлашты. Әбәү! Галимҗан ич бу. Көлеп җибәрдем.

— Син нәрсә, Галимҗан? Әллә нинди сәер җырлар җырлыйсың...

— Бер дә сәер түгел. Бик мәгънәле җыру бу, малай.— Галимҗан кесәсеннән папирос алып капты, әллә ничә шырпы бетереп, кабызды. Үзе тарта, үзе буыла-буыла йөткерә.

— Карале, Харис, синең кызлар кочаклаганың бармы? — диде кинәт кенә.

Мин битләремә кызыллык йөгергәнен сиздем.

Чыннан да, бигрәк сәер иде бүген Галимҗан. Җыры да, соравы да сәер. Папирос кабызуы да килешсез. Тәмәкече малай түгел иде бит ул моңарчы.

— Әй, мала-ай!.. Дөньяның оҗмахы кызлар куенында икән ул. Белерсең әле менәтерә!

Галимҗан авырттырып ук иңбашыма сугып куйды.

— Бу дөньяда егылып төшмәскә кирәк ул Акбүздән. Әнә, әкияттәге малай егылып төшми бит. Ялына ябышып булса да, сөйрәлеп бара, әмма егылмый. Шуңа күрә ахырдан ниләр генә кылмый!

Галимҗан акрын гына мөгрәп җырының ахырын кабатлады.

— Ә бу җырдагы егет, әнә, егылган Акбүздән, бичара. Шуңа васыять әйтеп калдырган. Я, ярар, хәзергә!

Тагы бер кат иңбашыма җилле генә берне чәпәде дә Галимҗаным китеп тә барды. Тагын җыр сузды, тик сүзләрен аерып булмый — әкрен генә көйли иде.

Ул кичне бик озак йоклый алмый яттым. Күземне йомдым исә, алдыма елмаеп торган кызлар килә дә баса. Таныш кызлар да түгел үзе, әмма бигрәк чибәрләр, шаяннар. «Белерсең әле менә...» Ә Галимҗан үзе белә инде, күрәсең...

Ул арада ак ефәктәй ялларын тузгытып акбүз ат күз алдымнан юыртып үтә, бераздан тагын алып-биреп чабып килеп чыга, ә өстенә бер дә әкияттәге малай түгел, Галимҗан менеп атланган. Акбүз арт аякларына үрә басып та, артын сикертеп тә Галимҗанны өстеннән алып ыргытмакчы итә...

Шушы кичтән соң Галимҗан гел сагышлы гына, моңсу гына көйләпмөгрәп йөри торган булып китте. Әмма шунысы бик истә. Тавышы моңсу, җыры сагышлы булса да, күзләре әйтеп бетергесез әчке бер нур белән балкый иде аның бу көннәрдә.

Шулай бер аймы, ике аймы вакыт үткәч, бер иртәне өр-яңа хәбәр ишеттек: Галимҗан өйләнгән. Кемгә диген? Бар классташ малайлар һәм... яшерен-батырын түгел, мин үзем дә әчтән генә гашыйк булып йөргән кыйгач каш Әкълимәне алган.

Яшьтән өйләнешкәнгәме, бу пар турында авылда ул көннәрдә сүз күп булды.

Кибет алдында Сәетгәрәйнең дә сөйләнеп торганын хәтерлим.

— Галимҗанның кичке биләмгә чыгарга чалбар төбе тишек иде аның. Ә чыгасы килә мескеннең... И шуңа тоткан да өйләнгән. Ничек авыз ачып, кызга: «Миңа кияүгә чык»,— дия алды икән ул балык? Ха-ха...

Өйләнде дә... үзгәрде Галимҗаным. Кара сумканы минем белән түгел, шунда, әвендә үк, эшләүче Әкълимә белән актара ул хәзер, үзләре пышын-пышын сөйләшәләр, тын гына көлешәләр, чәп иттереп бер-берсенә суккалап алган булалар. Бер кырыйда нәүмизләнеп кенә журнал битенә төртелгән сыбызгы борын, — ягъни мин, — әллә бар алар өчен бу дөньяда, әллә юк.

Һәм минем әвен ягына эзләрем акрынлап суынды.

Ә аннары... 1941 елның дәһшәтле таңы. Сугыш башлануга ук китмәсә дә, көзгә Галимҗанга да чират җитте. Сәетгәрәй белән бер үк арбага утырып киттеләр алар.

Әкълимә Майҗамал апага мине «Галимҗан белән сугышта бергә булганнар» дип, болай гына әйтүе булгандыр, без алардан соң тагын елга якын үткәч кенә киттек әле. Хәер, сугыш җирендә Галимҗан белән бер очраштык.

Бу очрашу турында мин Әкълимәгә дә сөйләдем.

Күңелем түрендә Галимҗан турында тагын бер бик кадерле-газаплы сугыш хатирәсе саклана да...

Анысын мин Әкълимәгә сөйләмәдем. Сөйли алмадым...

Мин инде, саубуллашып, чыгып китәргә дә кузгалган идем. Шунда ук һич көтелмәгән бер хәл булып алды.

— Галимҗанга рәхмәтләремне ирештерә күр, улым, — диде Майҗамал апа кинәт бөтенләй ачык, көр тавыш белән. Ул арада торып утырды, менә караватыннан төшеп аягүрә басты... башта сак кына, аннары нык-нык атлап китте... Безгә таба килә, кулына күчтәнәч такта чәйне тоткан.

— Белә шул ул балакаем минем чәй яратканны... Әнә, үзегез дә сөйләшеп утырдыгыз ич... Пуштыда эшләп алган беренче акчасына да шушылай такта чәй алып кайткан иде балакаем. Ирештерә күр рәхмәтләремне.

Әкълимә дә, Әсгать тә аңа карап катып калдылар. Икесенең дә йөзләрендә чиксез гаҗәпләнү, гадәттән тыш могҗиза алдында калгандагыдай шаккату чагыла иде.

— Һай, әнкәй җаным!.. Сихәткә генә була күрсен. Тазарасың, терeләсең, болай булгач, әнкәй бәгырем, — диде Әкълимә, бераздан гына телгә килеп. Миңа карап өстәде: — Инде өченче елын урыныннан да кузгалганы юк иде бит аның. Һай, хәерлегә генә була күрсен!..

Өч көннән соң Майҗамал әбине җирләдек.

Зират каеннары гел шулай шомлы-моңсу шаулашып калдылар.

Әкълимә янәшәмдә, тыелып кына сулкылдый-сулкылдый, яулык чите белән күзләрен сөрткәләп бара. Алдарак, ачы җилдән ышыкланган тату күгәрченнәрдәй, бер-беренә сыенышып кына өч кыз атлый. Өчесе дә гәүдәгә бер чамалар, өчесе дә бик зифалар. Мәрхүмәнең кызлары, Галимҗанның сеңелләре.

Мыштым гына борын тарткан тавышка икебез дә артыбызга борылып карадык. Әсгать икән.

— Һай, балам җаным, син нигә монда әле? — дип, Әкълимә улын күтәреп алды.

— Мин... әбине җиргә күмгәннәрен карадым.

— И бала... — диде дә Әкълимә, улын күкрәгенә кысып, дымлы керфекләрен чытырдатып йомды.— Кем алып килде соң сине монда?

— Берәү дә алып килмәде. Мин үзем. Агачка менеп карап тордым.

— Һай сине!..— Әкълимә тагын улын кочагында назлый башлаган иде. Әсгать тыпырчынып җиргә төште.

— Әни!.. Әби анда... җир астында, әти белән очрашалармыни? Рәмис шулай ди. Бабайсы әйткән аңа.

— Белмим шул, улым... Мин белмим. Бәлки очрашырлардыр. Кая, улым, изүеңне төймәлик. Салкынча бит.

— Мин үзем.

— Үзең инде син. Гел үзең.

— Әнә, Рәмис вилсәпиден алып чыккан. Әтисе сугыштан алып кайткан вилсәпид ул.— Әсгать чатыр чабып китеп тә барды.

— И бала!.. Мин аны, сабый күңеле киселмәсен, хәтерендә ямьсез калмасын дип, әнкәй өзелгәч үк күршеләргә кертеп куйдым. Ә ул, әнә... Сизми диген син аларны. — Әкълимә тагын яулык читен чылатып алды. — Әбисе генә аякка бастырды шул аны.

Сүзсез генә атлыйбыз. Капка башларындагы оялары тирәсендә сыерчыклар очыналар, карлыкканрак тавыш белән өзек-өзек сайрашып алалар. Бик кызу чаклары шул аларның — кошчыккайларына тизрәк канат кактырасылары бар.

— Рәхмәт инде сиңа, Харис, әнкәйнең соңгы көннәрен ямьләндердең, — диде Әкълимә, тавышы инде шактый тыныч яңгырый иде. — Дөньядан көр күңел, якты йөз белән дигәндәй китте бичара.

— Аңлап ук бетерә алмыйм.

— Син кереп чыкканнан бирле көннәр буе аяк өстендә булды әнкәй. Өйне җыештыргандай итә, көнгә ике-өч тапкыр өс-башын алмаша. «Кайта, болай булгач, Галимҗан улым кайта. Күчтәнәче артыннан үзе дә озакламас», ди... Әйтәм ич, өченче елын урын өстеннән торган кеше түгел иде ул. Сугышның иң авыр елларында да нинди нык йөрде үзе. Галимҗанның кара кәгазе килгәч тә бирешмәде. Гел мине юатты, мине көйләде ул көннәрдә. Аннары бигрәк кинәт кенә ауды да төште...

— Гаҗәп!..

— Шундый бер гаҗәп кеше иде инде ул мәрхүмә. Дөресен генә әйткәндә, без шул әнкәй аркасында бөтен сугыш буе әллә ни ачлык та күрмәдек. Ә бит өйдә кашыклар саны җитәрлек иде, әнә, өч кызының да мәктәпкә йөргән чаклары. Эшләтә дә белде ул аларны, бер көн сабактан да калдырмады. Шыгырдый башласалар, өстәлгә шык-шык бармак кына сугып куяр иде, тегеләр шунда ук каз бәбкәләредәй тезелешеп чыгып китәләр... Җәй буе кызлары белән печән хәзерләп, сыер белән сарыкларны бетермәде. Язларын бәрәңге бакчасын берүзе казып утыртыр иде. Мәктәптә язгы имтиханнар чагы булганга, «сабагыгызны карагыз» дип, кызларына көрәк тоттырмады ул көннәрдә.

Әкълимә мәктәп рәшәткәсе буйлап үтешли, үрелеп кенә бер тәлгәш канәфер чәчәге өзеп алды.

— Әнкәй әллә нинди үләннәрдән шундый тәмле ашлар пешерер иде. Кешенең алабута-кычыткан ашын авызга алгысыз була, ә әнкәй әллә кайлардан әллә нинди тәмле үләннәр таба, ашларын, әйтәм ич, ашап туйгысыз була иде. Авыр туфрагы җиңел булсын бәгырькәемнең, йортны да тота белде, Әсгатькә дә җил-яңгыр тидермәде, кызларын да кеше итте, ичмасам. Әнә, Әлфия белән Гөлфиясе укытучылар хәзер, кечесе Фәния район больнисында медсестра...

Әкълимә, тавышын акрынайта төшеп, кызу-кызу әйтеп куйды:

— Инде менә бу сугыш аларга дигән кияүләрне генә харап итеп куймагандырмы...

Алдагы өч кыз, әллә инде үзләре турында сүз чыгуын сизенеп, берәмберәм ялт кына безнең якка карашып алдылар.

— Минем дә рәхмәттән бүтән бер сүзем юк мәрхүмәгә. Андый кайнананың килене булу, белмим, сирәк бәхеттер ул. Әйтәм ич, бөтен йорт эше башы-аягы белән аның кулында булды, ә мин, нәрсә, көне-төне колхоз эшендә. «Бар, килен, бар, кеше арасында бул, ил белән бергә бул», — дип кенә торыр иде.

Алар капкасы төбенә кайтып та җиткәнбез икән. Әкълимә, кулындагы канәфер чәчәгенә текәлеп, сүздән калды. Аннары кинәт башын күтәрде.

— Әгәр оҗмах дигәннәре чыннан да булса, урыны шунда гына була күрсен әнкәйнең. Әсгать әйтмешли, Галимҗан белән дә очрашсыннар иде.

Шунда мин әллә нишләп киттем. Юк, оҗмах турындагы сүзләрдән түгел. Минем алдымда, сизелер-сизелмәс кенә елмаеп, бөтенләй яшь Әкълимә басып тора иде. Теге көнне озак күрми торганга күрә генә йөзе шулай картаеп киткәндәй күренде микәнни?... Көче-дәрте ташып торган, чын ныгып җиткән күркәмлек белән чибәр хатын икән ич ул!

## II

Шул елларда, дөресрәге, ике ел чамасы вакыт үткәч, Әсгать белән тагын бер очрашу бик хәтердә.

Минем авыл хуҗалыгы мәктәбендә укып йөргән еллар бу. Ялга кайткан идем. Урамнан үтеп барышлый, каршыма әллә кайдан гына Әсгать тәгәрәп килеп чыкты.

— Абый!.. — диде дә аяк очларына текәлеп катты. Үтә күренмәле сыман колак яфраклары яран гөледәй алсуланды. Мин: «Кара, нинди дәү егет булгансың... Мәктәптә укыйсыңдыр инде?» — дигәләп, үземчә тизрәк малайның тел ачкычын табарга маташа башлаган идем, Әсгать кинәт башын күтәрде дә, кыю гына чат-чат әйтеп салды:

— Абый, теге әкиятне сөйләче! Акбүз ат турында...

— Ах, менә нәрсә!.. Сөйлибез аны, энем. Әйдәле, әнә шунда утырыйк. Юк, иң дөресе, әнә, бакчага кереп утырабыз.

Клуб артындагы тын бакчада карт өрәнге төбенә җайлашып утырдык.

Акбүз ат әкияте... Галимҗан белән икебезнең уртак бала чак әкиятебез. Сөйләп бирә алырмынмы мин аны? Барысы, барысы бик истә дә кебек... сихри йомгак очы инде шактый чуалган да бугай. Чуалтмыйсы иде ул йомгакны! Уртак әкиятебез дисәм дә, ул, иң беренче, Галимҗанныкы. Галимҗанны, ихтимал, авыр сырхаудан йолып алган, сәламәтләндергән әкият.

Башта, әлбәттә, этисеннән ишеткән бу әкиятне Галимҗан сөйләде. Аннары без аны икәүләшеп бер-беребезгә сөйли торган булдык. «Әүвәләүвәл заманда, кәҗә команда»ларны бик озын итеп тезеп, әкиятне Галимҗан башлап җибәрә дә, иң кызык урынга җиткәч, «Әйдә, Харис, калганын инде син сөйлә» дип, печәнгә сузылып ята. Күзләрен йома, кулларын җәйләп кына баш астына куя, йөзендә әйтеп бетергесез бер илһамлы-рәхәт елмаю... Аның бу кадәр дә рәхәт кичереп әкият тыңлавына мин көнләшә үк башлыйм һәм «калганын син сөйлә» дип, янына барып ятам. Менә Галимҗанның үзенә генә хас моңлы-мөгрәүле тавышы салмак кына агыла. Тавыклар җырлашуы, печән эчендә ниләрдер кыштырдавы, карлыгачлар чыркылдавы бу моңны тагы да көчәйтә. Әлапас өрлегенә оя корган ул карлыгачлар, ифрат тынгысыз шул карлыгачлар, хыялларыбызны кыйгач канатларына элеп, әллә кайларга алып китә...

Әйе, әйе... Тавыклар җыры, бөҗәкләр кыштырдавы, тынгысыз карлыгачлар... Әнә хәзер дә койма артында бер тавык җырлап җибәрде. Яшел үлән эчендә ниләрдер кыштырдый. Һәм менә... Колак төбемдә Галимҗанның көйле тавышы тигез генә агыла башлады сыман. «Борынборын заманда...»

— Булды бу, Әсгать. Хәтеремә төште. Онытырга ярамый ул әкиятне. Их, печән өстенә сузылып ятып сөйләсәң икән аны! Без шулай итә идек.

— Әле печән чаба башламадылар бит.

— Башламасалар да... Зыян юк. Әсгать, аның каравы, әнә, тавыклар җырлый. Ишетәсеңме?

Әсгать сәерсенеп кенә «әһе» дип баш селкеп куйды.

— Әнә, үлән эчендә тәти коңгызлар ниндер пышылдый, бал кортлары без-безз көйли. Аларын да ишетәсеңме?.. Ишетсәң, менә шуларга ку-

шып, экиятне дә тыңла. Син, әйдә, рәхәтләнеп сузылып ятып тыңла. Әкиятне шулай тыңласаң әйбәт була ул.

— Кызык син, абый.

— Ярый, башладык... Борын-борын заманда, кәҗә команда, саескан сотник, төлке шутник, үрдәк үрәтник, песнәк писер, бака плотник булып йөргән заманнар булган ди... моңлы-зарлы, язылмас билле, сөялле куллы, айдай йөзле, кыйгач кашлы бер тол хатын. Аның булган ди өч улы. Һава белән капланган, җилләр белән мүкләнгән, ай-йолдызлар белән бизәлгән, җиде катлы, туксан тугыз бүлмәле пулатта яшәгәннәр ди болар, иңе җиде чабата, буе тугыз чабата җирдә иген игеп көн күргәннәр. Менә бер заман шул басуларында куйган кибәннәре бер-бер артлы югала башлый боларның. Иртән киләләр — бер кибән юк. Икенче көнне киләләр, тагын бер кибәннән җилләр искән. «Болай булмый, оланнар, кибәннәрне сакларга кирәк», ди әниләре. Башта басуга олы малайны җибәргән. Малай барган да, аны-моны уйлап тормастан, бер кибән төбенә яткан да йоклаган. Таң аткач торып бакса, тагын бер кибән ычкынган. Чират хәзер уртанчы малайга. Монысы да, йокы симертеп ятып, бер кибәннән колак кагып кайткан.

Өченче көнне кече малай китә. Теләсә ни кыланып, теленә ни килсә шуны сөйләшеп йөргәнгә, Тиле дип кенә йөртәләр икән бу малайны. Тиле басуга барган да кибәннең очына ук менеп утырган. Күз кабаклары никадәр салынса да, йокламаган Тиле, түзгән. Шулай да таң алдыннан йокыга куерган. Менә бер заман ят тавышка сискәнеп уянган. Караса, галәмәт зур бер акбүз ат кибәнне астан кырт-кырт кимереп-күшәп тора ди. Бер кабуда бер көлтәне йотып кына бара ди бу. Үзе гәүдәгә чамадан тыш дәү булса да, карап туйгысыз матур икән. Яңа яуган кар кебек ап-ак ди, көмештәй елык-елык ялтырый ди, ял-койрыклары алтынсу ефәктәй дулкын-дулкын җилдерди икән. Башта Тиленең эченә шөр йөгергән — ай-һай, зур хайван бит, бигрәк гайрәтледер. Аннары, күп уйлап тормастан, тота да кибән башыннан атның өстенә сикерә Тиле. Биленә менеп атлана алмаса да, атның ялыннан эләктереп ала бу. Шуннан соң Акбүз и китә чабып, и китә. Дөньяны тузан болыты каплый, җир дер селкенә, тояк асларыннан яшеннәр яшьнәп кала. Шулай бер җиргә орып, бер тауга бәреп, бер болытларда айкап, Тилене ялыннан селкеп төшермәкче була Акбүз, әмма булдыра алмый, малай бик нык ябышкан. Ахырда ат, телгә килеп, әйтә:

— Җитәр, инде батыр егет икәнеңне белдем. Мин хәзер синеке, теләсәң кая илт, — ди...

Мин ашыкмый гына тәмәке төреп кабыздым. Әкиятнең хәтердә яңаруы белән рухланып, тәмләп кенә суырам. Әсгать, түземсезләнеп, терсәгемә кулын тидереп алды.

— Хәзер, Әсгать. Бер генә суырам да... Ләкин беләсеңме нәрсә?

— Нәрсә?

— Бәйрәм ашы кара-каршы диләр бит.

— Ничек?

— Мин сөйләп бетергәч, син дә сөйләрсеңме соң? Әкиятләр беләсеңдер ич?

— Беләм дә... Мин сөйли белмим шул.

— Сөйли белмим дип... Тел сөйләп ачыла ул. Без әтиең белән гел бер-беребезгә сөйли идек. Инде синең белән дә шулай итик. Килештекме?

Әсгать ризалашып ияк какты.

Мин әкиятемне дәвам иттердем.

Акбүз белән Тиле бик тә дуслашып китәләр, бу акыллы ат бик күп изгелек-яхшылыклар эшли егеткә. Акбүз ярдәмендә Тиле бихисап батырлыклар күрсәтә. Әкиятнең дәвамы Тиленең әнә шул искиткеч батырлыклары, гаҗәеп маҗаралары турында. Ургып-ургып ут чәчеп торган

тауларны кичә Тиле, җиде диңгезне йөзеп чыга, җиде кат җир астына төшеп китә. Уникe башлы диюне җиңә. Дию сараендагы йөз дә бер кол кызны азат итә, патшаның дөньяда бер гүзәл кызын кырык үлемнән йолып кала. Энеләренең җиңү-уңышларыннан үлә язып көнләшкән ике агасы Тилегә әллә нинди астыртын явызлыклар эшлиләр.

Берсеннән-берсе кызык-мавыктыргыч бу мажаралар, гүзәл челтәр, оста нәкыш кебек бик нечкә үрелгән-чигелгән алар. Ләкин... Ни генә әйтмә, бу ифрат шигърият энҗеләр челтәренең шактый гына матур бизәкләрен хәтер дигәнең югалтып та өлгергән, күрәсең. Галимҗанның әтисе бу әкиятне өч-дүрт кич буе авыру улы изрәп йокыга киткәнче сөйли торган булган. Галимҗан белән без икәүләп сөйли башласак... Кояш офыкка авышкач башлыйбыз, лапас түбәсе тишекләреннән йолдызлар күз кысыша башлагач кына очына чыгабыз. Ә хәзер минем Әсгатькә сөйли башлавыма ярты сәгать үтеп вакыт үттеме-юкмы, йомгагым сүтелеп бетеп тә килә... Батыр энекәшләренә карата гел мәкер-явызлык юлында йөргән ике аганы, ниһаять, Акбүз ат гадел хөкемгә тарта. Менә дөньяларны шаулатып, җирне-күкне балкытып, туй тантанасы башлана — патшаның гүзәл кызы Тилегә кияүгә чыга. «Ул туйда мин дә булдым, бал-ширбәт эчтек, сыра чүмердек, мыек чыланды, телгә йокмады»...

— Бетте дәмени, абый?

— Хәзергә бетте шул. Тиленең кызык-кызык мажаралары тагын бик күп иде дә... Онытылыбрак киткән бит, шайтан алгыры...

— Син, абый, күзеңне йом. Шулай итсәң, хәзер хәтерлисең.

Тын гына ятабыз. Чуалыбрак киткән җеп очларын хәтер берәм-берәм ялгый да башлады шикелле... Юк, кайсыдыр очын һич кенә дә табып булмый.

Шул чак бик кинәт кенә Галимҗанның җыры колак төбемдә генә яңгырап киткәндәй булды.

Сикереп мендем, бил бирмәде,
Егылып төштем Акбүздән...

Әйе, җыры да бар бит әле ул әкиятнең. Анысы да Галимҗанныкы. «Егылып төшмәскә кирәк ул Акбүздән» дигән иде бит дустым. «Бик мәгънәле җыру бу» дигән иде.

Бәлки Әсгатькә хәзер нәкъ менә шушы турыда сөйләп бирергә кирәктер?

Ул арада Әсгать яткан җиреннән җәһәт кенә сикереп торды.

— Беләсеңме, абый, кичә мин дә сугыштым. Рәмкә миннән үзе зуррак та... Булса да, кирәген бирдем.

— Нәрсәдән чыкты соң ул сугыш?

— Һе! Мактанмасын!

— Нәрсә дип мактана инде ул... Рәмкә дисеңме әле?

— Ну, Рәмис. Без аны Рәмкә дип йөртәбез. Минем әти герой, әллә ничә ордены, медале бар, ди. Ә бүтәннәрнең әтисе, аныңча... әйбәт сугышмаган.

— Шуннан? Син нәрсә дидең?

— Минем әти геройларча үлгән, килгән язуында да шулай әйтелгән дидем.

— Ә Рәмис ни дигән була?

— Фи, бөтен кешегә шулай язалар, ди. Геройларча үлсә, өегезгә ордены кайтыр иде, әнә, Фәрит әтисенең ордены кайтты ич, ди.

Зиһеннәрем үк чуалып китте. «Мәгънәле җыру» турында башларга җыенган әңгәмәм бик тә катлаулана бит әле, болай булгач... Сугыш җирендә кыска гына очрашуда мин Галимҗанның күкрәгендә ике сары тасма — ике тапкыр каты яралану билгесе күрдем. Ә сугыш мәхшәре арасында яраланып ерак госпитальгә китүчеләр... еш кына онытыла, орден-медальләр, андыйларга караганда, ут эченнән исән-имин чыгучылар

күкрәгенә күбрәк кадала. Гомумән, солдат батырлыгын медальләр саны белән генә бәяләү шактый шартлы бәрабәр бит ул...

Ә Галимҗан турында бу аеруча... Дустымның нинди солдат булганлыгын бик яхшы беләм мин. Алай, Акбүздән егылып төшүче егет түгел иде ул. Юк!

Бәлки Әкълимәдән дә яшереп күңелем түрендә саклаган Галимҗан турындагы изге-газаплы сугыш хатирәсен Әсгатькә сөйләп бирергәдер? Ир заты бит, бәлки аңлаша алырбыз?

Ләкин бик нечкә осталык, үтә сизгер саклык кирәк аны сөйләр өчен. Юктыр, бүген генә булдыра алмамдыр мин моны.

— Беләсеңме, Әсгать, әйдә, иртәгә тагын шушында очрашабыз. Синең Рәмис белән бәхәсең турында да иркенләп сөйләшербез. Әкиятнең дә онытылган җирләре хәтеремә төшәр. Бүген, ни... вакытым юк. Ләкин син шуны бел, Әсгать, медале булмаса да, бик батыр солдат иде синең әтиең.

Ләкин иртәгесен мин бу очрашуга килә алмадым.

Нигә килмәдем икән? Сәбәбен хәзер инде хәтерләмим дә. Әй, дөнья! Алай хәтердә калырлык булмагач, һич тә кичектергесез сәбәп булмагандыр инде ул...

## III

Әсгать белән без тагын биш-алты ел үткәч кенә очраштык.

Авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлагач, мине эшкә башка районга җибәрделәр. Ялга кайткалаганда, Әкълимә белән урамда, я колхоз идарәсендә очрашып, озак-озак сөйләшеп торабыз, ә Әсгатьне күрергә туры килмәде. Үзен күрмәсәм дә, кайткан саен аның турында сүзләр ишетә торган идем. Бик әйбәт сүзләр түгел иде бу. Мәктәптә шуклык катнаш тәртипсезлеге, урамда күп малайларга йодрыклап «сабак укытырга» яратуы белән телгә кергән иде Әсгать.

— Әтисез үскәч, нихәл итәсең... Әниләрне тыңлыймыни ул ир малайлар, — дия иде Әкълимә, авыр көрсенеп. — Аннары менә, Фәния апасы да бик узындырамы дим баланы. Әлфия белән Гөлфия, үз тормышлары булгач, алай бик исләре китеп тормый. Ә Фәния бит... Һаман ялгыз. Шуңадыр, чат ябышты энесенә. Ничәмә велосипед кына алып бирде инде...

Ә бер кайтуымда көтелмәгән хәл: Әсгать югалган. Бөтен авыл белән тирә-юньне бетереп эзләгәннәр, Ашыт елгасын да айкап-сөзеп чыкканнар — малай юк.

Һичничек ярдәм итеп булмастай бәла-кайгыга тарган кеше белән очрашу-сөйләшүдән дә авыр нәрсә юктыр. Хәер, андыйларны тәмле-матур теле белән юата белүчеләр дә була. Миндә андый сәләтнең әсәре дә юк. Шунлыктан, Әкълимә белән очрашудан котым чыгып йөрде. Шул ук вакытта очрашасым, күрешәсем дә бик килә иде... Сагынып кайткан идем үзен.

Бер көнне урам башында зәңгәр-кызыл бизәкле таныш яулыкны күргәч, тез буыннарым ук йомшарып китте. Ул! Каршыма килә.

— Кайтканыңны ишеткән идем, күзгә-башка гына күренмисең — диде Әкълимә, кул биреп күрешкәч. Күз кабаклары ялкынсынып китсә дә, энҗе тешләре нәкъ элеккечә балкып алды.

— Әә... шулай инде. Ниме... Әсгатьнең берәр хәбәре юкмы?

— Бар, хәбәре, бар. Станцадан хат язып салган балакаем.

— Ә? Исән-саумы ул?

— Исән-аман, балакаем. Беләсеңме, кая сәфәр чыгып киткән малай?

— Кая?

— Әтисенең каберенә зиярәт кылырга киткән, балакай... Һай, үзем гаепле. «Әйдә, әтием каберенә барып кайтыйк» дип, кайчаннан бирле и

сорады, и сорады. Гел-гел суза килдем. Эш тә эш дигән булып... Бетәсе бармы ул дөнья мәшәкатенең.

— Шулай инде... Бергәләп барып кайтырга иде.

Ә үземнең эчтә чәнчеп алды. Акыл саткан буласың... Үзеңнең барып кайтканың бармы соң дустың каберенә?!

— Ничекләр барып җитәр инде балакай. Бигрәк ерак юл бит, Белоруссия чигендә үк. Җитмәсә, бер тиен акчасыз чыгып киткән. Апаларыннан, күрше-күләннән дә сорашып бетердем, берәүдән дә акча-мазар сорамаган.

— Бәлки әнисеннән яшереп кенә акча җыйгандыр. Була ул шулай, үземнән беләм.

— Шулай итсә генә инде. И балакай... Карачы, нигә урам уртасында басып торабыз әле без? Бусаганы бурсык яламаган безнең, нечәме-ничә еллар инде бер керепь тә чыкканың юк. Әйдәче, сөйләшеп бер чәй эчәр идек.

Без алар өеннән ерак түгел генә басып тора идек. Борылып китсәм, килешмәс шикелле тоелды.

Өйләре яктырып, киңәеп киткән кебек. Ялтравыклы никель карават, зур көзге-трюмо, тәрәзәләрдә ак челтәр пәрдәләр... Теге керүдә боларның берсе дә юк иде һәм хәзер әнә шулар яктырта иде бугай өйне.

Әкълимә ап-ак алъяпкычын ябып алып, ни арада өстәл тутырып тегесен-монысын тезде, җыйнак кына ялтыр ак самавар да өстәлгә тиз килеп басты. (Теге вакыттагы күпне күргән җиз самавар отставкага чыккан, күрәсең.)

— Аңлыйм мин Әсгатьне... Әйтәм ич, аның болай чыгып китүенә күбрәк үзем гаепле... — Әкълимә кара бизәкле ак эскәтерне җайлап кына сыпыра-сыпыра тынып калды.

— Син Сәетгәрәйне хәтерлисеңдер бит? — дип сорап куйды кинәт кенә.

— Әйе-йе. Кабан Сәлти.

— Кабан дип... Ул ямьсез теше урынына алтын теш жылык-жылык ялтырый хәзер Сәетгәрәеңнең.

— Кайда соң ул хәзер?

— Читтә йөри. Сахалинга, дөнья читенә үк китеп барган... Кая, тагын бер чынаяк ясыйм әле. Безнең ул уймак белән биш-алтыны эчмичә авыз да чыланмый. Ашамадың да шунда. Яратсаң, менә, чәкчәге...

Әкълимә шулай мине кыстый-кыстый, тагын өстәл башын сыйпаштырырга тотынды.

— Нишләпләр генә йөридер инде балакай. Исән-аман әйләнеп кайтырга гына язсын иде.

— Кайты-ыр! Алай югалып кала торганнардан түгел малай.

— Борчыла шул ана күңеле...— Әкълимә, борчуларын селтәп атарга теләгәндәй, кискен генә башын чайкап куйды, яулыгын рәтләде. — Синең, солдаттан кайтканнан бирле, Сәетгәрәйне очратканың да юкмы әллә? — диде гадәти генә.

— Элегрәк елларны очрашкалап, сөйләшкәләп йөри идек. Хәзер, әнә, дөнья читенә үк киткән дисең бит.

— Анда китканенә бик күптән түгел әле аның. Китүе дә шул... Ирнең җилкәсен — нужа, башын — хатын ашый, диләр бит. Бер дә гаилә бәхете булмады ул мескеннең.

Сәетгәрәй берәр җиргә килеп өч көн торса, өйләнеп тә өлгерә, дип колагыма кергән иде.

— Һай, кешегә авыз ерырга гына булсын. Төптән уйлаганда, бер дә мәзәк түгел ул Сәетгәрәйнең тормышы.

Мин чопыр-чопыр чәй чүмерергә тотындым.

Самавар тиздән тагын күңелле көйләп утыра башлады, тик Әкълимә генә тагын сүзсез калды.

— Сизеп торам инде... Сәетгәрәйне өнәп бетермисең син. Элекке Сәетгәрәй түгел бит ул хәзер.

— Кешене, аралашмагач, кайдан беләсең?

— Шул шул менә... Сугыштан бик үзгәреп кайтты Сәетгәрәй. Башкалар кебек, тишек шинель белән кайтмады ул. Өстендә яхшы пальто, аягында хром итек иде. Әлеге ямьсез теше урынына корыч теш тә куйдырып җибәргәч, бөтенләй чибәрләнеп киткән егет. «Калкыбрак торгангадыр, беренче атакага барганда ук немецлар сугып сындырдылар ул тешне», дия иде. Әллә шаярта, әллә чынын сөйли. Госпитальдән чыккач та, туры өенә кайтмаган, берәр ай заводта эшләгән, өс-башын шулай караган икән. Анысы, яфрак селкенми тормый, төрле сүзләр дә булды. Янәсе, бер бик бай хатынга йортка кереп торган. Телнең сөяге юк, ниләр сөйләмәс.

Кайтканда сыңар култык таягы белән бик авыр йөри иде әле. Шул килештән дә, олыны олы, кечене кече итеп, өй борынча бөтен авыл белән исәнләшеп йөрде. Карчык-коры, бала-чагага, мулдан булмаса да, күчтәнәчләр дә өләшкән. Кеше күңелен бер тутәрәм күтәреп җибәрергә күп кирәкме...

Кайтуына колхоз хисапчысы итеп утырттылар үзен. Ул чакта ирләр заты санаулы. Бераз хәл алып, җиңелрәк йөри башлавына, моның җилкәсенә тагын тау чаклы эшләр йөкләп бетерделәр. Авылда ит, сөт налогы да җыя, мәктәптә военрук булып та эшли. Барысына да өлгерер, барысына җитешер, титак-титак гел йөгерер иде, бичара.

Озакламый Галимҗанның кара язуы килде. Һай, ул көннәр!.. Болай да көннәрем кара төн, төннәрем утлы җәһәннәм, өстәвенә... Бер килсә, килә бит кеше башына, нәкъ шул көннәрдә өйнең әнә шул матчасы сынды да өебез җимерелде төште. Бәхеткә каршы, гомеребез булган, кем әйтмешли, ходай саклаган, беребез дә өйдә юк чак иде. «Бик беткән инде бу өй, яңасын салырбыз» дип, Галимҗан да хәстәрен күреп йөри башлаган иде инде, өлгерә генә алмады, бичара. Инде, менә, ни хәсрәтле көнебездә, күк түбә астында утырдык та калдык. Шунда иң беренче ярдәм кулын сузучы кем булды диген? Сәетгәрәй булды, рәхмәтләр яугыры. Җылы-тәмле сүзләре белән генә түгел, кайгыбызны җилкәсе белән дә күтәреште. Әллә кайлардан бүрәнәсен, тактасын юнәтеп, ярдәмгә картларны көйләп-җайлап, өч көн дигәндә өйне күтәрде дә куйды, игелекле җан. Менә бит, хәзер дә рәхәтләнеп торырлык әле бу өй... Син алай сүз белән сыйлаганга карама, капкалап утыр әле...

Әкълимә җәһәт кенә почмак якка чыгып керде.

— Ашым да өлгерә. Ялга кайткан кеше, әллә кая ашыгасың юктыр әле.

Ашыгыр җирем юк иде, әлбәттә. Ләкин... Әкълимәнең нәкъ менә Сәетгәрәй турында сөйләвен бер дә тыңлап утырасым килми иде. Нигә аның турында башлады соң ул сүзне? Сөйләшер сүзләр беткәнме безнең?

— Мин ул вакытта ук тракторда эшли идем. Галимҗан да бит сугыш алдыннан трактористлыкка укырга ниятләп йөри иде. Шуңамы, районнан килеп әйтүләре булды, авылда хатын-кыздан иң беренче үзем язылдым механизатор курсына. Укып чыккач, яшь бала булганга, эшкә үз авылыбызга кайтардылар. Әмма, МТС кешесе саналсам да, колхозда кеше җитмәгәчтен, теләсә нинди эшкә йөртәләр иде. Ә трактордан бушаган чаклар күп була иде. Искереп беткән, ничәмә еллар җүнләп ремонт күрмәгән «НАТИ» ватыла да тора. Аңа карап, кояшта арка кыздырып ятар чакларммыни, фермада сыер да савам, үгез җигеп салам ташыйм, язгы былчыракларда чана тартып симинәгә дә күп йөрдем. Сәетгәрәй гел әйтә иде. «Ташла син, Әкълимә, болай кара эштә йөрүеңне. Җиде класс белемең белән сугыш чорында болай йөрү, беләсең килсә, җинаять ул, синең урының җитәкче эштә хәзер», дияр иде. Ә минем һич

кенә дә күңелем тартмый андыйга. Кеше кушып, кеше өстеннән йөргәнче, җиң сызганып үзем эшлим мин, шуны артыграк күрәм. Элегрәк елда бригадирлыкка куеп та карадылар, әнә Гатият абзый кулын өздереп сугыштан кайтуга, бригадирлыкны аңа тапшырып, андый эштән бер котылган идем инде.

Ә Сәетгәрәй тәки үзенекен итте. Ул вакытта председательләр календарь бите урынына алмашып торган чаклар. Әнә шулай тагын яңа председатель сайларга дип килгән район кешесенә әйтеп, җыелышта да сөйләп, тәки мине председательлеккә үк куйдыртты бит, әй.

Башта котым чыкса да, тора-бара эшләп киттем тагы. Хәер, эшләвем дә инде... Бары Сәетгәрәй аркасында гына. Акыллы киңәшләре белән дә бик ярдәм итәр иде, аннары, ир-аттан булсын, телчәнрәк хатыннармы бик тавышларын күтәрә башласалар, «әнә, хисапчы белән сөйләшегез» дип, җәтрәк аңа җибәрә идем үзләрен.

Бер тәртә арасына җигелгәч, председатель белән хисапчы күзгә-күз генә дә каласың. Сүз, әлбәттә, күбрәк эш турында. Әмма Сәетгәрәй бик еш әйтә башлады... Синнән яшереп маташыр хәлем юк, Харис... «Күңелемнән һич алып ташлый алмыйм мин сине, Әкълимә», ди бу. Аннары турыдан-туры әйтә башлады. «Әйдә, чәчләрне чәчкә бергә бәйлик», ди. Ие, синнән яшерен-батырын түгел инде... Әле кыз чакларымда ук сүз салгалый иде ул... Күңеле миңа тартканын сүзе белән дә, тотышы-кыланышы белән дә дигәндәй, һаман сиздерә килде, сиздерә килде... Инде менә, Галимҗанның кара кәгазе килүгә елы да тулгач, өзми-куймый әйтә башлады.

Тәмам аптырадым-йөдәдем. Ашым аш, йокым йокы булмый башлады. Уйладым-уйладым да, бу турыда әнкәй белән киңәшеп карарга булдым. Ул ни әйтсә, шул булыр дим. Бигрәк акыллы, бик туры сүзле иде бит ул, мәрхүмә. Әйтерсең гаделлек дигәннәре, аның кыяфәтенә кереп, арабызда йөри...

Оялып-тарсынып торудан узган булганмын инде, күрәсең. Әнкәйгә берни яшерми-нитми бәйнә-бәйнә сөйләдем дә бирдем. Әнкәй беркавым дәшми генә тып-тын утырды. «Биатаңның мин ничәнче хатыны икәнне беләсеңме?» дип сорады аннары. Ишеткәнем бар иде, әткәй, әнкәйгә кадәр, алтымы, әллә җидемме хатын аерган. «Юк, арттыралар, диде әнкәй, миңа кадәр дүрт хатын белән торып караган биатаң. Әмма берсе белән дә яшәп китә алмаган. Ә без, яшь аермасы шактый булса да, гомер буе кичә генә кавышкан парлар шикелле яшәдек. Кичләрен яткач бер сөйләшеп китсәк, таңнар атканчы сүзебез бетмәс иде. Бер-беребезне аз гына ымнан да аңлап алыр идек. Нигә шулай? Әллә миңа кадәре биатаңның күңеле бик азгын булган, шуңа дүрт хатын аерган дисеңме? Юк инде. Берәүләр үз бәхетләрен яшьтән үк табышалар, икенче берәүләр мәхәббәтләрен тапкан кебек кенә булалар да, аннары этле-мәчеле дигәндәй яшиләр. Беришеләр бер-беренә ияләшеп тә китәләр тагы. Әмма ләкин барыбер чын бәхетле булмыйлар. Биатаң исә алай яшәргә теләмәгән, дүрт хатын аерса аерган, чын үз бәхетен тапмый туктамаган. Шуннан менә үзең уйлап кара. Чын бәхетеңме ул Сәетгәрәй? Уйла, үз күңелеңнән кат-кат сора. Әгәренки энә очы кадәре генә яратмаган, өнәмәгән җире, берәр гадәте бар икән, тәвәккәлли күрмә, ди. Шул энә очы кадәр генә яратмау да тора-бара дөя кадәрегә әверелә... Минем сиңа сүзем менә шул, фатихасы-ние бергә, ди. Син әле бик яшь, сугыш афәте килде дип, гомер буе мендәр чылатып яшәргә димәгән. Әсгатьне дә якын итә кебек ул Сәетгәрәй, аны да уйла», ди.

Тәмам уйлар коесының төбенә үк салды мине әнкәй. Энә очы кадәре генә дә яратмаган төше, өнәмәгән гадәте калмасын ди бит. Уйлыйм-уйлыйм да, Сәетгәрәйнең бар да кебек, юк та кебек андый җире. Ә үзенең әйтмәгән көне юк: бергә булыйк та бергә булыйк. Мин һаман сузам...

Ахыр чиктә инде тәвәккәлләргә дә исәп тотып бетергән идем... Кая соң, анда ашым ташып утырмасын тагын...

Әкълимә почмак якта шактый озак торды. Бу якка чыкканда күз кабаклары тагы да кызарып киткән иде.

— Һай, ул көннәр... Әнкәй: «Сәетгәрәй Әсгатьне дә якын итә шикелле» диде дә диюен... Анысы, дөрес, бик ягымлы, бик үз итеп дәшә иде балага Сәетгәрәй. Конфет-прәннеген, уенчыкларын, ул вакытта юк җирләрдән табып, күпме ташыды. Әмма һич кенә дә ияләнеп китә алмады аңа Әсгать. Өч яше тулып кына узган бала бит әле үзе... Тәрәзәдән Сәетгәрәй күренсә, «әнә, тәти абый килә» дияр иде дә, үзенең коты чыгып, караватт астына кереп качар иде, бәгырькәем. Туганнан бирле өйдә ир заты күреп үскән бала түгел, шуңадыр дип, үз-үземне юатып та карыйм, әмма күңелдә шом, бик ачы шом...

Ә Сәетгәрәй өзми-куймый әйтә килә. «Бәхетем синдә генә минем, Әкълимә, сине дә бәхетле итәр өчен тау-ташлар актарырга риза», ди. Мин һаман кистереп кенә сүземне әйтә генә алмыйм. Шулай икеле-шайлы йөргәндә, Сәетгәрәй бер сөйләшүдә әйтеп салмасынмы! «Шул сантый баш Галимҗаныңны оныта алмыйсың син, ул иләс-миләс белән, исән-сау кайтса да, барыбер бәхетле була алмас идең син», ди бит. Үтерде, җан бәгырьләремне телгәләп актарды ул шушы сүзләре белән. «Җитте, моннан ары әйтмә дә, йөрмә дә!» дип бер генә кычкырдым.

Шул чакларда күпме күз яшь түккәннәремне берүзем генә беләм. «Җырлаганда ят та ярый, җылаганда үз кирәк», дияр иде минем әни. Шунда түбәнә кадәр төшенеп беттем мин бу сүзләрне. Әни дә, мескен, яшьләй тол калган безнең.

Инде аралар өзелдеме дигән идем. Юк бит, бер түбә астында эшләгәч, көн саен очрашасың. Җае чыккан саен әйтә Сәетгәрәй: «Мин барыбер синсез яши алмыйм, Әкълимә, башкайларым элмәккә керсә, син генә гаепле, шуны бел», ди бит.

Беркөнне шулай кичен соң гына идарәдә ялгызым утыра идем, Сәетгәрәй килеп керде. Бераз гына салмыш. «Бәхил бул инде, Әкълимә, ди, синсез дөньяның бер яме юк миңа. Хуш, яман итеп искә алма». Шулай диде дә чыгып та китте. Мин аны кызмача баштан гына шулай сөйләнәме дисәм... Иртәгесен бөтен авыл шау итә. Сәетгәрәй асылынган, диләр. Әллә үкереп җыладым, әллә тораташ кук тик катып утырдым — менә хәзер хәтерләремне җепселләп актарсам да әйтә алмыйм.

Әкълимә өстәлдәге тәлинкә-савытларны җайлаштыргалап кузгатарәтли, беразга сүздән калды.

— Алай асылынгач, нигә исән соң ул? — дип сорап куйдым. Хәзер инде Әкълимәнең хикәяте миңа алай ук кызыксыз түгел иде.

— Шулай, кичен бернечә ир салып утырганнар. Утыра торгач, Сәетгәрәй: «Мин чыгып керәм, кермәсәм, бәхил булыгыз», дип чыгып киткән. Тегеләр көткәннәр-көткәннәр дә моны, әлеге «бәхил булыгыз» дигән сүзе дә шом салгандыр, чыгып эзли башлаганнар. Шулай итеп, лапас өрлегендә асылынып торган килеш табып алганнар, шунда ук элмәкне кискәннәр... Җыясы ризыгы бетмәгән инде бичараның, ике-өч көннән аякка да басты. Аякка басты, әмма күп тә үтмәде, авылдан юкка чыкты Сәетгәрәебез. Районга барып кайтам дип өеннән чыгып киткән дә шуннан юк. Арчада поездга утырганын гына күреп калучылар булган.

Әкълимә тагын почмак якка чыгып китте. Шактый озак торып, куллары белән күзләрен угалый-угалый килеп чыкты.

— Күзгә суган керде, — диде дә өстәл читенә капланды. Иңбашлары сизелер-сизелмәс дерелди иде.

Нәфислек тә, көч-ныклык та бөркелеп торган бу иңнәрне назлап кына сыпыйсым, аңа иң җылы берәр сүз әйтәсем килә иде минем... Юк, шыпырт кына урынымнан тордым да китап шкафы янына килеп бастым.

— Син кузгалма әле, — диде Әкълимә, башын күтәреп. — Өлгергән ашны ташлап китәме кеше. Ошамаганны!

— Ризыктан өстен булыр хәлем юк, Әкълимә.

— Шулай булмый ни! Минем дә буш көнем бүген. Тракторым көйсезләнеп тора. Механикка әйткән идем, «югалып тор күз алдымнан, кеше карап торганда эшли алмыйм мин» дип куды да җибәрде үземне. Әйдә, утыр, аш бүләм.

— Менә хәзер сөйләүләре генә җиңел, — дип, бераздан Әкълимә бөтенләй акрын тавыш белән башлап китте. — И ул чакта күргәннәрем!.. Хисапчылыкка махсус укыган кеше түгел бит Сәетгәрәй, әллә исәп-хисапны бутап бетергән, әллә инде... Килеп тикшергәч, бик зур тулмаучылыгы чыкты монын. Үзе әллә кая китте дә югалды, бөтен авырлык минем өскә төште... Күтәрсен генә иңнәрең! НКВДга чакыралар да допрослыйлар, чакыралар да допрослыйлар. «Сез Гайсин белән якын мөнәсәбәттә булгансыз, колхоз байлыгын бергәләп үзләштергәнсез. Гайсинның кая киткәнен дә белергә тиеш син, барысын да әйтеп бир», диләр генә бит. Сүзгә генә ышанмауларыдыр инде, килеп, өйне дә тентеп киттеләр. Каян белгәннәрдер, «Гайсин, үлсәм син генә гаепле, дип әйткән, нигә алай әйтте ул?» — дип тә таптыралар. Көн аралаш, кайчак көн саен чакыралар, төн уртасында килеп алып киткәннәре дә булды... Болай интектергәнче, утыртып куйсыннар иде, ичмасам, дип тә теләп бетердем. Нигә, гаебем дә юк түгел ич. Мин председатель кеше, хисапчының эшен тикшереп торырга тиеш идем, андый буталчыклыкка юл куярга хакым юк иде бит!

Ләкин утыртмадылар. Анысы, утырткан да булырлар иде... Соңыннан гына белдем, Гафият абзый, тагын берничә авыл коммунисты мине бик яклаганнар, рәхмәт яугырлары. Ул чакта райком секретаре Батыршин иде, комсомолдан күтәрелеп, яңа эшли башлаган еллары. Ул да минем яклы булган.

Аннары, шул да ярдәм иткәндер, Сәетгәрәйне әллә Актүбәдә, әллә Алма-Атада барыбер табып алганнар.

Шуннан соң председательлектән очырдылар үземне. Монысына мин сөендем генә. Кулыңнан килмәстәйне нигә көчәнергә... Тик менә алдагы сезонда МТСта трактор да ышанып тапшырмадылар. Монысына инде җаным бик әрнеде, бик кимсендем. МТСлар бетеп, бөтен механизация үз кулыбызга күчкәч кенә, яңадан тракторга утырдым... Кая, ашың суынып та беткәндер инде синең, кайнарын өстим әле.

— Рәхмәт, Әкълимә, бигрәк тәмле ашың.

— Шулай дигән бул әйдә. Сиңа, буйдак кешегә, җүнлерәк аш-су бик эләгеп тә тормыйдыр әле.

Әкълимә гөрләп кенә көлеп куйды да шунда ук җитдиләнде.

— Бу афәтләргә дә түзәр идем, әмма нәкъ шул көннәрдә икенчесе... Әйтәм ич... бер килсә ябырыла гына бирә кеше башына... Шул көннәрдә ифрат ямьсез сүзләр ишеттем. Янәсе, Галимҗан, иләс-миләс бер сантый, сугышта җүнләп мылтык төзи дә белмәгән. Янәсе, үлеме дә... шул иләс-миләслеге белән тиктомалга ут эченә барып кергән... Тагын әллә ниләр... Ялган, чеп-чи ялган! Кеше белеп тә бетермәскә мөмкин, ә мин үземә караганда да ныграк ышанам Галимҗанга!

Урынымнан сикереп торганымны сизми дә калганмын.

— Мин дә ышанам Галимҗанга, Әкълимә. Аның турында аз гына да кыек сүз әйтергә берәүнең дә хакы юк!

— Мин дә шулай дим... Кайдан чыга шундый әшәке сүзләр? Әнкәй мәрхүмә әйтте әйтүен... «Сәетгәрәй таратып киткән бу сүзләрне, мәлгунь, ди. Мин уйлаганча булып чыкмады ул адәм, ди. Өй җимерелгәч күрсәткән игелеге, бүтән ярдәм-мазары күземне томалаган икән. Теге, бүлнистан чыккач, йортка кереп торуы да хактыр. Ташкичүдә дә сөйрәлгән нәрсәсе бар дип сөйлиләр. Әмма ләкин биатаң кебек, үзенең чын

бәхетен эзләп болай кылануы түгел анын. Юк, биатаң ише түгел ул адәм. Кара аны, моннан ары аң бул!» Әнкәй мәрхүмә шулай диде дә диюен... Белмим шул, белмим... Башыма сыймый... Карачы, сүзгә мавыгып, онытканмын да, керәнем дә бар иде ич минем. Кичә генә уып куйдым. Ит манып ашарга зрә шәп нәрсә бит ул.

Әкълимә, керән савыты капкачын ачып, иснәп карады. «Ай-яй, зәһәр булган бу» дип, бик озак пышык-пышык күзләрен каплап утырды.

— Яман сүз күзге ачы җил белән бер бит ул. Күпме генә тынып торган күк була да тагын килеп-килеп исә: Әсгатькә дә ишетелмәгән дисеңмени син андый сүзләрне? Сизеп торам: шуңа чыгып киткән дә инде ул балакай. Галимҗанның кабере Бураки дигән авыл янында. «Әни, ул авылда этинең ничек-ничек сугышып үлгәнен күрүче-белүче юкмы икән?» дип әйткәне дә бар иде. Әнә шуны белергә дип чыгып киткән дә инде ул, җанкисәгем. Әй, дөнья! Кырык эшен кырык якка ташлап, әллә кайчан баланы ияртеп барып кына кайтасы иде кана... Үзем дә инде, бигрәк... Сүз Сәетгәрәйнең дөнья читенә китеп баруыннан чыккан иде бит безнең. Шул тулмаучылыгы белән утырып та чыкты ул. Амнистиягә эләгеп, тиз котылган тагын. Горурлык диген үзендә! Чыккач, бу юлы да туры авылга кайтмаган. Берәр ел каядыр эшләгән. Менә бер заман, өс-башын бер дигән итеп ясап, госпитальдә куйдырган теге корыч тешен алтыннан балкытып, кайтып төште бу. Анысы, илдә дус бар, дошман бар дигәндәй... Авыз чайкаучылар да булмады түгел. Имеш, бер дә эшләп тапкан малы түгел, колхозны талап киткән акчага киенгән...

Кайткач, авылда күп тормады. Арчага китеп, станцада кемдер булып шунда эшли башлады. Өйләнде. Менә дигән өй салып керделәр. Тормышлары бик бөтен, бик житешле иде инде анын, юкса. Алай-болай гаугалашып-нитеп йөргәннәре дә ишетелми иде. Менә кинәт... Тоткан да, бөтен тормышын ташлап, ике баласын калдырып, әнә, Сахалинга ук чыккан да киткән бит. Әй, бу кеше күңеле... чисти бер урман-чытырман, валлаһи...

Әкълимә, беразга тагын шул өстәл башын сыйпаштыргалап утыргач, кинәт кенә урыныннан сикереп торды.

— Карале, Харис, башыма бер уй төште бит әле. Әсгать киткән авылга телеграмма суксам, нишләр икән? Исән-сау килеп житкәненне хәбәр ит дип. Тапшырылыр ич?

— Әйе-йе... Ике телеграмма сугарга кирәк. Берсен Әсгать исеменә булса, икенчесен авыл Советына. Балага игътибар да итәрләр, ярдәм дә кирәк булырдыр. Әйдә, сүзләрен бергәләп язабыз.

...Без капкадан бергә чыктык.

— Алай онытып бетермә инде син безне, Харис. Кайтсаң, шулай кергәләп утыр... Кая, телеграмма суккач, мастерскойга сугылыйм әле мин. Нишләтәләр икән анда минем Акбүз аткаемны? — Әкълимә кызарган күз кабакларын гадәттәгечә нурга күмеп, гөрләп кенә көлеп куйды. — Әсгатьтән откан сүз монысы. Шулай Акбүз ат дип кенә йөртә ул минем тракторны. Бала диген! Ир канаты ат булыр дигәндәй, дүрт аяклысының почеты калмагач, корыч йөрәклесенә омтыла хәзерге малайлар...

Ул көнне без ничегрәк аерылып киттек соң әле?

Почтага бергә бардык бугай. Мастерской юлы буйлап та бергә атладык шикелле. Ниләр сөйләштек? Юньләп хәтеремдә калмаган. Шунысы гына истә: күбрәк мин сөйләдем, мин такылдадым.

Аннары шул... Ындыр артлары, тын тыкрыклар буйлап ялгызым гына да күп тәпиләдем. Шулай тәпили торгач... Капка төпләрендә сабакташ малай мотоциклын кабызып маташа иде. Йөгереп тә килдем, рульгә чат ябыштым. «Бер генә әйләнеп килим» дим. Әллә ризалыгын алдым

монын, әллә юк, уч буе иярга атландым да басу ягына элдерттем. Көпчәкләрем җиргә тиеп-тиеп кенә ала, җил чәчләремне йолкып калырдай дулап-тузынып бара... Аның саен куам.

Акбүз! Әй, Акбүз...



## IV

Әсгать, атна чамасы үткәч бугай, әйләнеп кайтты. Бу хәбәрне ишетүгә, өйләренә ашыктым. Күрергә кирәк иде миңа аны, сөйләшергә кирәк иде. Күңелем шулай куша, вөҗданым боера, Әсгать алдында үземне күпмедер дәрәҗәдә гаепле дә сизә идем...

Әсгать өйдә ялгызы иде. Минә каршымда, үзем буе булыр, сузылып үсеп киткән, чуендай тут йөзле бер малай басып тора. Керүемә, каш астыннан гына бик усал карап куйды, аннары, таныды булса кирәк, калын иреннәрен тыйнак кына җәеп елмайды. Ирләрчә нык итеп кул кысыштык.

— Я, ничек йөреп кайттың? Уңдымы сәфәрләр?

— Әйбә-әт... Күптән барасы калган! Белмәдем болай барып буласын.

Һәм Әсгать, һич кыстатып тормастан, үзенең юл мажараларын сөйләп китте. Ул, чыннан да, кесәсендә тиенләп кенә акча белән юлга чыгып киткән. Поезддагы юлдашлары, олысы-кечесе дигәндәй, аның кая, нигә барганын белеп алгач, контролер-фәлән күзеннән бик ныклап саклап барганнар. Әсгать әтисенең матәм кәгазен дә үзе белән алган булган икән, шунын да тылсымы булган, күрәсең. Юлдашлары кайсы нәрсә белән бик сыйламакчы да булганнар икән дә, Әсгать монысын теләмәгән. «Үземнең капчык тулы ризык иде, малайлар төяп җибәрделәр», — ди. Кайтыр юлы әллә ни мажарасыз гына үткән, Буракидан кулына билетын тоттырып, әйбәтләп озатканнар.

— Барысына да Акбүз атым ярдәм итте, — диде ул, бик җитди итеп.

Күңелгә рәхәт бер җылылык йөгерде. Корычка төренсәң дә, барыбер тере икәнсең, җанлы икәнсең әле син, Акбүз!

— Беләсеңме, Әсгать, ул Акбүз турында тагын әле җыр да бар бит. Галимҗан аны да бик яратып җырлый иде.

— Нинди җыр ул? Әйтегезче?

— Әйтермен. Син башта әтиең кабере турында сөйлә әле. Ничек, әйбәт саклана мы?

— Әйбәт.

— Болай... Ялгыз кабер генә түгелдер инде ул? Туганнар кабередер?

— Әһе...

— Һәйкәле дә бармы?

— Әһе... Бар.

Мин бер уңайдан инде икенче папиросымны суырам. Нәрсә булды соң әле малайга? Юл мажараларын ни рухланып сөйләде дә, кабер турында сүз чыккач, саранланды да калды. Ихтимал, менә болай түгелме икән... Әсгать әнисенә әйткән бит: «Ул авылда әтинең ничек-ничек сугышып үлгәнен күрүче-белүче юкмы икән?» дигән. Әсгать, баргач, сорашып-белешеп карагандыр да... Меңләгән солдаттан йөзләгән үлемнең берәрсен күреп-хәтерләп калучыны табу, ай-һай, хәзер инде эскерт эченнән энә эзләү шикеллерәк бит ул. Малайның шуңа бик кәефе китеп, күңеле кителеп кайтты микәнни?

Мин тышта тәмәке тартып, өйгә әйләнеп кергәндә, Әсгать тез өстенә песи утырткан да бик бирелеп китап укып утыра иде.

— Карале, Әсгать, әгәр вакытың булса, әтиең кабере турында әйбәтләбрәк сөйләсәң иде син. Үзең беләсең, бик дуслар идек без әтиең белән. Беләсем килә минем.

— Нәрсәсен сөйлисең инде аның... — Әсгать китабыннан башын күтәрсә дә, күзләре читкә төбәлгән иде.
— Шулай да... Авылдан еракмы?
— Юк. Авыл башында.
— Һәйкәле ничегрәк? Таштанмы, әллә мәрмәрме?
— Таштан. Андый каберләр күп анда. Авыл саен, юл чаты саен... — Әсгать дорфа гына итеп тезеннән песине төртеп төшерде.
— Да-а... Отпускы алсам, үзем дә һичнигә карамый барып кайтам инде быел.
— Барып та йөрмә лутчы, — дип, Әсгать үзалдына гына мыгырданып куйды.
— Менә сиңа кирәк булса! Нигә алай дисең?
Әсгать дәшмәде, китабына кадалды да катты.
Каядыр сәгать текелди, әллә Әсгатьнең, әллә үземнең борын көйләп-көйләп сызгыра иде.
— Әсгать, чыннан да... Нигә алай дисең әле син?
Әсгать кисәк кенә башын күтәреп, күзләремә туп-туры карады. Бу караш миңа нигәдер аның белән беренче очрашуны шундый да ачык итеп күз алдыма китерде дә бастырды. Юк, охшаш карашлар да түгел бу... Ул вакытта ишектән песнәк-коштай атылып кергән туп малайның күзләре ташырга торган шатлык-куаныч белән балкый, шул ук вакытта ниндидер шүрләү-шөбһә дә чагыла иде. Хәзергә Әсгать исә миңа шундый да усал итеп, эчке бер ярсу белән карый...
— Син минем этине батыр солдат иде ул, дидең. Нигә, алайса, һәйкәлдә аның исеме язылмаган?
— Ничек язылмаган? Нәрсә... Шулай исемсез генә һәйкәлмени?
— Исемсез түгел. Сигез фамилия язылган да, ахырдан «и др.» диелгән. Һәм башкалар, янәсе.
— Ничек инде?.. Галимҗанның шул матәм кәгазендә әйтелгән каберме инде ул? Тәгаенме?
— Тәгаен. Без андагы малайлар белән шул тирәдәге бар һәйкәлләрне дә йөреп чыктык. Юк этинең исеме. «И др.»лар бар...
— Сәер...
— Сәердер шул!.. Мин хәтерлим әле. Теге вакытта әни белән сөйләшеп утырдыгыз. Шунда син әйттең... «Сәеррәк егет иде Галимҗан», дидең. Гел шуларны сөйләштегез.
— Их, Әсгать. Бик яратып әйтелгән сүз генә бит ул. Булмаса, мин тагын берне көйрәтеп керим. Сөйләшәбез әле без синең белән.
Сәер... Юк, менә шушы хәл генә түгел. Барыбыз да сәеррәк без. Арабыздан киткән иптәшебез-дустыбызны искә ала башладыкмы, аның эш-хезмәте янсә батырлыгыннан бигрәк, тотабыз да мәрхүмнең сәеррәк гадәтләре, аңа бәйле мәзәгрәк вакыйгаларны сөйләшеп китәбез.
Ни гаҗәп булмасын, монысы шулай инде аның. Күрәсең, кешелекнең табигате шулайдыр. Әмма монда... Әтисен бер генә тапкыр да күрмәгән сабый күңеле... Никадәр гүзәл, батыр сурәт-сыйфатлар белән бизәлеп тугандыр ул эти кеше бала хыялында. Ә без... Әтисенең бала чак дусты, яшьлек иптәше, сугыш җирендә аның белән очрашып кайткан егет килә дә ул кадерле образның сәер-сәер гадәтләрен сөйләп утыра... Аннары, әнә, кайсыдыр адәм актыгы тараткан бик әшәке сүзләр. Ана күңеле сизенми калмас, ул корымлы сүзләр, ихтимал, Әсгатькә дә килеп ирешкәндер.
...Бу керүемдә мине Әсгать идән уртасында басып торган килеш каршылады. Күзләре инде алай усал карамый, ниндидер ялварулы өмет тулы иде карашында.
— Әсгать, хәтерлисең микән? Моннан ничәдер еллар элек без синең белән очрашырга сөйләшкән идек.
— Мин килдем. Көттем, көттем дә...

— Ә мин килә алмадым шул. Килеп булмады... Гафу итсәң икән? Шул вакытта ук мин сиңа әтиең белән сугыш жирендә ничек очрашканымны сөйләмәкче идем. Бер очрашу турында әниеңә сөйләгәнем бар, ә икенчесе турында... Тыңлыйсыңмы, Әсгать, баштан ук сөйлимме?

— Тыңлыйм, абый, бик тыңлыйм. Сөйлә генә!



## V

Брянск юнәлешендәге бер сугышта, мина кыйпылчыгы тиеп, кулым яраланды. Ярам алай әллә ни дә түгел иде, ләкин кесәмдәге бинт кисәге белән генә канын туктатып булмады. Саркый да тама, саркый да ага бирә.

— Бар, йөгер санротага! Әйбәтләп бәйләтеп кил. Живо! — дип, комдив куып жибәрде.

Санротада канны тиз туктаттылар, аннары «бераз ял ит» диделәр. Яралылар белән шыгрым тулы кысан өйдә бер почмакка чүгәләүгә, изрәп йокыга да киткәнмен. Март урталары иде бу. Сугышлар ул кадәр үк каты бармаса да, көн-төн дәвам итә иде. Әле һөҗүм итәбез, ул арада, бераз кире чигенәбез. Ниндидер тактик маневр булгандыр инде ул, үзара шуңа юрый идек. Ә солдатка бу бик кыен. Ал-ял юк, юньлерәк траншея, блиндаж казырга вакыт тимәгәнлектән, бер тамчы жылы әсәре күргән юк. Полк кухнясының кайдалыгын еш кына белмибез, таба алмыйбыз да, авызга жылы ризык эләкмәгән көннәр күп. Кар казып кына төшкән окопларда ятабыз. Көндезен март кояшы елмаеп жибәрә дә, окопларыбыз кар суы белән тула. Муеннан су эчендә ята бирәсең. Ятмый хәлең юк, баш өстеңнән жәйге черки урынына пуля очып тора. Ул арада пушка, минометлар гөрселдәшеп «сөйләшә» башлыйлар. Безнекеләр дә ата, немецлар да. Ул да булмый, команда:

— Атакага хәзерләнергә!

Һәм тиздән, лачма су сеңгән авыр шинельләрне сөйрәп, һөҗүмгә күтәреләбез... Көчәйгәннән-көчәя барган пулемет-миномет уты бераздан безне кар өстенә ятарга мәжбүр итә. Тагын шул кар окоплар, әлеге юллары әмәлләргә тотынабыз. Көндезләрен март кояшы елмайса да, төннәрен чатнама суык. Безнең ул лачма шинельләр, тоташ боз булып, броняга әверелә хәзер. Иелер хәл дә юк, бөгелер хәл дә. Атналар буе шушы хәлдә. Суык жилекләргә кадәр үк сеңгән, күзләр саташулы-уяулы, керфеккә-керфек кенә тигәләп ала. Әнә шуңа күрә дә, арт як аз гына коры идәнгә тиюгә, шундук йокыга изрәп төшкәнмен дә инде мин. Жылы иде бу кысан өйдә, шул кадәр рәхәт иде, жәннәт ләззәтләрең бер якта торсын.

Күпме йоклаганмындыр, иңбашымнан селеккәләп уяттылар.

— Әйдә, сержант, подвода килде. Санбатка киттек, — диләр.

Йокы белән аңкы-тиңке килеш: «Нигә санбатка? Миңа комдив тизрәк әйләнеп килергә кушты, кайтасым бар», — дип карышып маташуымны санга да сукмадылар. «Ярар, комдивың белән туйда үбешерсез», дип, үрәчәле чанага, тагы кемнәрдер өстенә тәртеп аудардылар да, кар туздыра-очыра, чыжлатып китеп тә бардык. Санбатта ярамны тагын карап бәйләүгә, бу юлы инде машинага төяп, тагы озаттылар. Шулай итеп, туймас йокымнан һаман да юньләп айнымаган көйгә, жылы-йомшак госпиталь койкасына ук илтеп салдылар.

Айдан артык ярамны дәвалап, аннары, бер запас полкта ни пычагымадыр тагын айт-двага атлатып, яңадан передовойга әйләнеп килгәнче, жәйләр житте. Эшелоннан төшеп, күпмедер тәпиләгәч, кап-кара мичләре генә тырпаеп утырган бер белорус авылына туктадык. Монда инде туп гөрселдәүләре, пулемет-автомат тыкылдаулары аермачык ишетелеп тора, ара-тирә якында гына да снарядлар төшеп ярыла иде. Шунысы

кызык, ут эчендә инде бер булып чыккан солдатны мондый гөрселдәүшартлаулар аз гына да өркетми, киресенчә, күңелне генә җилкендереп җибәрә. Яраң сызламаганда госпитальдә аунау, бигрәк тә запас-резервларда талкыну андый солдатларга мең мәртәбә кыенрак.

Шулай, бервдә безне «Кем танкист, бер адым алга», «Артиллеристлар бармы?» «Связистлар кайсыгыз?» дип, төрле частьларга яучылап алып китә башладылар. Мин дә үз хәрби һөнәрем буенча, артиллеристлар сафына чыгып бастым.

Минә каршыбыздан гына бер төркем үтеп бара. Саф алдыннан япьяшь кенә лейтенант белән муенына автомат аскан бер сугышчы атлый. Бернигә исе китмәгәндәй җайлап кына, эре-эре атлап баруларыннан ук сизелеп тора — дарыны инде җитәрлек иснәгән солдат бу. Өстендәге ап-ак булып уңган гимнастеркасы да шуны раслый бугай. Әллә үзенә карап торуымны сиздеме шунда бу солдат, ялт итеп кенә миңа таба борылып карап куйды. Каравы булды, «Галимҗан!» дип, стройдан атылып чыктым. Галимҗан да каршыма очты. Кочаклашып, бермәлгә һични сүз дәшешә алмый тордык.

Болай командирдан рөхсәтсез-нисез стройдан чыгып йөгерү уставның бер генә хәрефенә дә сыя торган нәрсә түгел ул үзе. Ләкин фронтовикларның, уставтан тыш, һич кая язылмаган үз законнары да була. Шундыйларның берсе — якташлар очрашканда аларга комачау итмәү, киресенчә, кулдан килгәнчә ярдәмләшү.

— Кайсы частька эләктең, әй? — Галимҗанның беренче соравы шул булды. Мин әйттем.

— Их, малай! Нигә биш кенә минут алданрак очрашмадык икән? Безгә дә бик кирәк иде бит артиллеристлар. Сорокапятистлар кирәк безгә. Менә болай кирәк. Син, анысы, зуррак калибрга күнеккәнсеңдер дә бит... Аның каравы, бергә булыр идек, малай. Әйдәле лейтенант янына. Ул сөйләшеп караса, үзебезгә алып булмас микән сине?

Без бер читтәрәк көлемсерәп кенә тәмәке көйрәтеп торган лейтенант каршына килеп бастык. Галимҗан ашыга-ашыга үтенечебезне сөйләп бирде.

— Ах, шайтан! Эләккәнсең икән үзең дә,— диде лейтенант бик җитдиләнеп. — Полковник Гладышевтан берәр солдат сорап алу кышын бер уч кар теләнеп алудан кыенрак бит ул.

Лейтенант, бәбкә йонсдай җилфердек мыегын сыпыргалап, чак кына уйланып торды.

— Зыян юк, егетләр, — диде, — без болай итәрбез. Мин, кайтуга, үзебезнең комполкка мөрәҗәгать итәрмен. Безнең Назарян белән Гладышев күптәнге ут-су әшнәләре, карт бүреләр, үзара килешми калмаслар. Ә аңарчы, вакытын-җаен табып кына, бер-беребезгә кунакка килгәләрбез. Аралар ерак түгел.

Шуннан соң гына без хәл-әхвәл сорашуга күчтек. Мин Галимҗаннан соң елга якын авылда яшәгән, аннан да бигрәк, менә сине, Әсгать, идәндә мүкәләп йөргәнеңне күреп киткән егет бит, шунлыктан ул сорауларын гына яудыра, мин сөйлим. Син инде, Әсгать, җиткән егет, дөрес аңларсың дип уйлыйм... Галимҗанга синең турыда сөйләгәндә... күпме ут-су кичкән, үлемнең күзенә ничәмә генә мәртәбәләр туп-туры караган солдатның, улын бер тапкыр да күрү бәхетенә ирешә алмаган эти кешенең күзләреннән мөлдерәп-мөлдерәп яшь акты...

Ут-су кичкән, үлем белән күзгә-күз очрашкан солдат дип, Галимҗан турында матур сүз өчен генә әйтүем түгел, Әсгать. Һич юк! Сөйләшеп киткәч, шул да ачыкланды: Брянск юнәлешендәге әлеге мин сөйләгән сугышларда Галимҗан да булган икән! Күршеләр генә булганбыз, очрашу бәхете генә эләкмәгән. Әйткәнемчә, мин җиңел яраланып, җылы госпиталь койкасына эләктем. Ә Галимҗаннар миннән соң да әле күпме көннәр буе шундый тактик сугышларны дәвам иттергәннәр. Аннары

зур һөҗүм, немецның башына ныклап торып тондыра торган һөҗүм башланган. Инде килеп, мин авылда җир сөреп йөргән чакларда ук Галимҗан үткән, кичергән сугышларны саный башласаң?!

Әмма боларны тулырак сөйләшеп торырга вакытыбыз сыйдырмады. «Гатауллин, кузгалмыйк микән?» дип, яшь лейтенант та сабыр гына әйткәли башлады, миңа да ничәмә кат инде дәштеләр.

— Бик ашыктырмаслар иде дә... Шундыйрак чак, малай, — диде Галимҗан. Аннары пышылдап кына өстәде: — Тиздән урак өсте башланыр шикелле. Шулай сизелә... Ярый, хәзергә! Очрашырбыз да, бергә дә булырбыз дип уйлыйм мин. Сүзендә тора торган егет ул безнең лейтенант, душа малай. Менә үзең дә ишетерсең әле, «лейтенант удалой Дубовой» дип, аны бөтен фронт буйлап беләләр. Связное мин аның, бик тату яшибез. Ну, малай, күрешкәнгә кадәр! — Галимҗан, әлекке гадәтенчә, иңкәеп китәрдәй каты итеп иңбашыма сугып куйды.

Менә шушындый очрашу булды безнең синең әтиең белән, Әсгать энем.

— Рәхмәт, абый. Әнигә син моны бик кыска гына сөйләгән идең... Рәхмәт.

— Әйе, Әсгать... Вакытлар үткән саен, фронт истәлекләренең һәрбер вагы-төяге ничектер зурая бара, тагы да ачыграк, мәгънәлерәк булып, хәтердә яңара бара...

— Шуннан соң ничек булды, абый? Тагын очрашмадыгызмы әти белән? Сүз куешкансыз бит...

— Әйе, очраштык дияргә була. Тик бу очрашу... Ничек дип әйтергә?.. Ерактан гына булды бу очрашу. Монысын мин әниеңә сөйләмәдем. Ник дигәндә... Ирләрчә сөйләшү кирәк монда. Ир белән ир булып.

Мин кесәмнән папирос кабы чыгарып, урынымнан кузгалдым.

— Абый, өйдә генә тартсаң да була, тәрәзәне ачарбыз.

— Юк, тартмыйм әле. Син, булмаса, бер стакан су китер миңа... Их!.. Хәзер инде тыңла. Син белергә тиеш моны.

— Әйе, безнең Галимҗан белән бергә, бер частьта булуыбыз бик мөмкин, бик ихтимал хәл иде. Шулай ук, лейтенант Дубовой әйтмешли, бер-беребезгә кунакка килгәләргә булыр иде. Әйткәнемчә, фронтовиклар якташларның очрашуына, бергә булуларына ярдәм итешергә генә торалар. Ләкин, Әсгать энем, сугыш сугыш инде ул. Галимҗан әйтте дидем бит, тиздән урак өсте башланыр шикелле, диде. «Урак өсте» дигәнне аңлыйсыңдыр инде. Төнме-көнме икәне дә, алы-ялы да онытыла торган зур һөҗүм сугышларын шулай атый идек. Ә солдат күңеле андыйга бик сизгер ул.

Әнә шулай «уракка төшәр көннәр» көтелгәнгәдер, Галимҗан янына барып килергә рөхсәт сорасам, «бүген генә булмас, җаен табарбыз» дип, көннән-көнгә суза килделәр. Хәер, алай кунакка йөрешер чаклар түгеллеген үзем дә күреп тора идем. Алгы сызыкта дежур частьлар гына калдырып, безне тылга таба эчкәрәк алып киттеләр дә, берәр елга буенда тактик өйрәнүләр башлана. Белоруссиянең эреле-ваклы бик күп елгалары бормаланып агып яткан, баткаклы-сазлыклы җирләре бу. Алдыбызда гына, нейтраль зона буйлап та шундый бер елга ага иде. Исеме дә бик хәтердә — Суходровка. Кызык исем, әйеме? Үзе елга, үзе «коры утын»... Без әнә шундый елгаларны бик тиз кичү әмәлләрен өйрәнәбез. Үзебез генә түгел, пушкаларыбызны, тагын дөнья хәтле сугыш дирбияләрен дә бик тиз алып чыга белергә кирәк. Пушкабызны әһ дигәнче ботлап-чатлап сүтеп ташлыйбыз да, кайсыбыз кайсы кисәген күтәреп, елга кичәбез, сазлыклар үтәбез. Пөзеп тә үтәбез елганы, билдән-муеннан су ерып та. Камыштан, чыбык-чабыктан саллар әмәлләп тә кичәбез. Чыгуга, тагы да җитезрәк, тагы да өлгеррәк пушкабызны ут чәчәр хәлгә китерергә кирәк. Көннәребез дә, төннәребез дә шушындый

өйрәнүләр белән үтә. Анысы, дөрес, Суворов та әйткән, өйрәнгәндә кыен булса, сугышта җиңел, дигән. Ләкин бик туйдык без бу өйрәнүләрдән. Үзара сукранабыз, тизрәк урак өсте башлансын иде, дип теләкләр телибез.

Ниһаять, башланды шикелле.

Бер төнне күрше часть Суходровканы кичеп чыккан да аргы якта немецны якалый да башлаган. Безнең дивизионга сугышчан бурыч куелды — аларга артиллерия уты белән ярдәм итәргә. Элемтә әйбәт булса, пехотага мондый ярдәм күрсәтү артиллеристларга үзе бер шатлык. Әйтелгән ориентирларга утлы күчтәнәчләрне яудыра бирәсең.

Башта элемтә әйбәт кенә барды.

Сизеп торабыз, аргы якта сугышлар бик каты. Утны әле якынгарак кына, ул арада шактый эчкәре дә сорыйлар.

Кичкә таба элемтә өзелде.

Без элемтәчеләрне эттән-эткә салып сүгәбез. Нәрсә карап яталар, эшлексез җаннар, нигә көйләмиләр?

Тан алдыннан телефоныбыз тагын телгә килде. Безнең пушкаларга да җан керде.

Күп тә үтмәде, элемтә тагын юк.

Бу юлы инде элемтәчеләрне генә түгел, бөтен югары командованиенең тетмәсен тетәбез. Ни карап яталар анда, нигә ярдәм җибәрмиләр ул якка? Күрәләтә безнең братны һәлак итәләр бит!.. Юкса, күреп торабыз, бу якта безнең көчнең исәбе-хисабы юк. Нинди куак бу? дип чүгәләсәң, ул маскировкаланган танкмы, пушкамы булып чыга. Күзгә бик күренеп йөрмәсәләр дә, солдатларның да сансыз-чутсыз икәнен сизеп йөрибез. Нигә дип тикмәгә ипи ашатып яткыралар аларга?

Ләкин һич тә тикмәгә булмаган икән.

Алдагы таңда иң көчле зилзиләдән дә болайрак җир тетрәтеп, җир белән күкне тоташтан ут-сөремгә урап, безнең артподготовка башланды. Һавада кыр казларыдай тезелешеп безнең самолетлар күренде.

Дошман өстенә шушы кадәр дәһшәтле көч белән ябырылган утялкын ташкыны күпме дәвам иткәндер, хәтерләмим дә. Немецлар да җавапсыз ятмый, әлбәттә, алар да ата. Ләкин без инде моны сизмибез, безнең нәрсәдер сизәргә, нәрсәдер уйларга вакыт та юк, снаряд артыннан снаряд яудырасыбыз бар, шул ук вакытта баш миенең кайсыдыр сыры туктаусыз тукып тора: тиздән атака, тиздән елганы кичәбез... Әзер бул!

Шулай булды да... Үз тавышың үзеңә ишетелмәслек тоташ шартлау-гөрселдәү белән тетрәп торган бөтен җир-күк бер генә мизгел тып-тын булып калды. Аннары меңләгән-меңләгән көчле «ура» яңгырады.

Башланды!..

Ләкин без көткән, өченче көн күрше часть кичеп чыккан урыннан түгел, елганы бөтенләй башка урыннан, уң һәм сул фланглардан кичтек.

Әнә бит никадәр куәтле хорның җыр башлаучылары булган икән ул часть сугышчылары!

Бөек Ватан сугышы тарихында «Белоруссия операциясе» дип, данлы җиңүләр исемлегендә күренекле урында торган зур һөҗүм сугышлары әнә шулай башланды. Дошманның үзләре җиңелмәс-җимерелмәс дип санаган «Фатерланд» оборона линиясен ватып-сытып, сугышасугыша, көнгә ун-унбиш километрлап алга ыргылдык. Тиздән Белоруссия җирләре ахыргача азат ителде.

Әсгать, бик кызыклы сугыш киносы карагандай, урынында сикергәләп куя, күзләре ялтырый, ярым ачылган авызы менә-менә «ура» кычкырып җибәрер төсле иде.

— Абый! Минем əти дə шунда сугышты инде, име? Күрдеңме син аны? Очраштыгызмы?

— Əйе-йе... Хəзер шул турыда. Көн саен алга барабыз, көн саен диярлек елгалар кичəбез. Шул кечү-переправаларда күп частьлар бергə очрашасың. Мин гел эзлəнəм, сорашам. Полковник Назарян частеннан берəрсен очратсам, Галимҗанның эзенə төшəр идем кебек. Лəкин язмыш андый очрашуны тиз генə насыйп итмəде.

Тагы да соңрак, инде Пруссия жирендə, Галимҗаннар частеннан бер старшинаны очраттым. Шуннан сорашып белдек... Суходровканы беренче кичкəн əлеге часть полковник Назарян егетлəре булганнар икəн. Бик олы җиңүнең, əлеге дə баягы, нинди куəтле «хор»ның җыр башлаучылары Галимҗаннар булган бит!

Мин очраткан старшина Галимҗанның үзен күреп белми иде. Аның каравы, лейтенант Дубовойны яхшы белə иде ул. Шул сугышлардагы зур батырлыклары өчен Дубовойга, үлгəннəн соң, Советлар Союзы Герое исеме бирелгəн. Ə Галимҗанның язмышын старшина, əйткəнемчə, белми иде. Лəкин мин ышанам, иманым камил... Синең, Əсгать, «Чапаев» киносын күргəнең бардыр инде?

— Бар.

Галимҗан энə шундагы Петя кебек булгандыр дим мин. Тамчы да шигем юк моңа! Андый батыр командир үзенə связной итеп ни җитте генə солдатны алмый ул. Юк, Галимҗанны юкка гына сайлап алмаган Дубовой... Əлеге старшинадан тагын шуны белдек. Сугышлар бик каты булган ул Суходровка плацдармында. Монысы бик аңлашыла, моны без үзебез дə сизеп тордык. Менə шунда... Дубовой егетлəре дошманның беренче линия траншеяларына бəреп кергəч, тегелəр саранча өередəй ябырылганнар аларга. Көчлəр тигез түгел. Дубовой бездəн артиллерия ярдəме сорый. Ə без күрсəтелгəн координатлар буенча ут яудырабыз. Һəм менə... Дубовой моны əйтеп тормаган, без дə старшина сөйлəгəч кенə аңладык... Үз өслəренə, дошман өере белəн бугазга-бугаз килгəн урынга сораган ул ут яудыруны... Үз кулларыбыз белəн менə кая ут чəчкəнбез без. Аңлыйсыңмы, Əсгать?!

Тавышым белəн йөрəк сыкравымны басарга телəпме, бик каты, артык каты кычкырып əйттем бугай мин бу сүзлəрне. Идəндə җəелеп яткан песи кинəт сикереп торды да, сыртын кабартып, читкə атылды.

Шулай да никадəр кычкырсам да, сыкрау ишетелде. Əсгатьтəн чыктымы бу аваз, əллə үземнəнме?.. Белмим.

— Аңлыйм мин, абый,— диде Əсгать, баягыча ярым пышылдап. Малайның озын керфеклəре тетри, алар менə-менə яшькə чыланыр кебек иде... Чыланмады.

— Менə бит никадəр коточкыч, явыз, адəм актыгы нəрсə ул сугыш! Менə ни өчен мин əниенə бу турыда шушы көнгə кадəр сөйли алганым юк... Сөйли алмыйм. Ə без, Əсгать, ир кешелəр, бер-беребезне аңларбыз дип уйлыйм.

Əсгать ишетелер-ишетелмəс кенə «əһе» дип баш селекте.

— Инде менə, шул батырлар һəйкəленə Галимҗанның исеме «һəм башкалар»га гына кереп калган икəн, бу һич тə дөрес түгел. Бу — хаксызлык!

Кулымдагы стаканнан муеныма су чəчрəп китте дə, бераз суынгандай булдым.

— Бер уйлаганда, моңа кемнедер гаеплəп тə булмый шикелле. Каты һөҗүм сугышлары бара... Кемнең кем икəнлеген, ничек сугышканлыгын, ничек һəлак булганлыгын тикшереп торырга һич вакыт юк. Вакытлыча дип, агачтан гына ясалган йолдызлы һəйкəлгə берничə генə фамилия язалар да, калганнары, янəсе, соңыннан ачыкланыр, язылыр. Ə вакыт дигəн нəрсə бик рəхимсез ул. Калган эшкə кар ява башлый.

— Яуган шул инде менə...

# VI

Хәзер инде Әсгать этисеннән нәкъ ун яшькә олы.

И гомерләр... Үтә диләр яшь гомерне, үткәнен күрсәң иде, үткән чакта тотып алып...

Әй, юк! Бер дә егылып төшәр исәпләр юк әле синнән, Акбүз!

Ә уйлап баксаң... «Мена кайтам... Бу отпускыда һичнигә карамый кайтам» дип йөри-йөри, туган туфракка аяк басмаган еллар саны дистәләп үк үтеп киткән.

Элегрәк туган нигез җылысы ничек тә тартып кайтара иде. Сугыштан соң озакламый эти үлеп китте. Өч революция давылы кичергән, ничәмә еллар мәдрәсә сасысы иснәп, унҗиде яшеннән күпме мәктәп тузаны эчкән өлкән укытучының сәламәтлеге болай да чамалы иде. Күзлек киеп, тын кысуларын яшьләргә сиздермәскә тырышып йөгерәчаба, бу сугыштан эти бөтенләй какшап кайтты.

Әтине җирләгәч, апа белән ике энекәш арасында кызу гына бәхәс булып алды. Без, ир малайлар, әлбәттә, әнине үз яныбызга алдыруны даулыйбыз. Апа безнең күзебезне дә ачырмый.

— Нинди феодаллар сез? Әниләр уллары янында гына яшәр заманнар үтте инде ул! Гомер буе иңкәеп су ташый-ташый, кочаклап чи усак ягып, исеннән исереп, таң тишегеннән көтүгә кәҗә куып яшәде әни. Инде сез аны тагын үзегезнең сала тормышыгызда интектермәкчеме? Юк инде, картлык көнендә шәһәрдә дә яшәп карасын әле! Сез, феодаллар, малай чакта ук икегез бер яклы булып, өйдә бердәнбер кыз баланы гел кыерсыта идегез. Инде тагын шуны кумакчы икәнсез...

Бу дәлилләрен апа әлеге «кыерсытылып яшәгән» заманнарда түгелеп бетми калган кайнар күз яшьләре белән дә юешләп ныгыткач, без җиңелдек. Әни авылдагы бер якка кыйшая башлаган өен, өй янындагы шау алма бакчасын калдырып, киявенең ванналы-газлы Казан квартирына күчеп китте.

Тормыш елгасы безне, үзенең тирәнрәк-сайрак чоңгылларында бөтергәли-чайкый, туктаусыз агыза бирде.

Туган җирнең җылысы суынганнан-суына барды.

Казанга эш-йомыш төшми тормый. Килгән саен әни авылның яңадан-яңа хәл-әхвәлләрен сөйли — алардан бик хәбәрдар яши ул. Тыңлап утырасың да, күңел кузгала. Туктачы, бер уңайдан нигә авылга да сугылмаска? Ул арада, сыртың сынардай итеп төяп килгән эш-йомышларың артыннан куа торгач, командировкаңның срогы үтеп тә киткән, җилкәңә кайтуга һич кичекми эшләнергә тиешле тагы дөнья чаклы вазифа өстәлгән. Арча поезды синсез генә китеп бара, ә син, маңгаеңнан шабыр тир агыза-агыза, Бөгелмә самолетына йөгерәсең.

Казан еш кына якташлар белән дә очраштыра.

Бик хәтердә, бер вакыт Әкълимә белән дә очраштык.

Әкълимәнең әлеге, шул, нәкъ Әкълимәчә генә итеп тын гына гөрләп көлүе очраштырды безне.

Аэровокзал, гадәттәгечә, колхоз базарыдай гүләп, кайнап тора, радиодан, гадәттәгечә, «фәлән самолетның очуы фәлән вакытка кичектерелә» дип хәбәр салып торалар иде.

Мин, гадәттәгечә, бер телмә чәчне юеш маңгайга ябыштырып, күтәренеп килеп кердем дә, очар рейсыма әле талон да өләшенмәгәнен белгәч, лачма кулъяулыгым белән җилләнеп торам.

Зал тулы шау-гү эченнән бик тә таныш гөрләп көлү яңгырап китте. Күзләрем белән эзләнәм, сагынылган аваз хуҗасы үзе күренми.

Әкълимәчә итеп көлү тагын яңгырап алды. Чемоданнар, иңбашлары, кайнар сулышлар арасыннан ерып, эзләнеп йөри башладым. Һәм таптым!

Ниләр сөйләшүебез сүзгә-сүз диярлек хәтердә.

— Бер дә картая белмисең син, Әкълимә. Яшәргәннән-яшәрә генә барасың. Тьфү-тьфү, минем телем түгел, Әйшә-батман теле.

— Шулай дигән бул. Без дә яшәрмәгәч тагы!

Ләкин минем һич тә «дигән булуым» гына түгел иде бу. Армиядән кайткач, аның белән беренче очрашуны күз алдыма китерәм дә гаҗәпләнгәннән-гаҗәпләнә барам. Ул очрашуда хәтеремдәге ябь-яшь Әкълимәнең ничәмә генә еллар аша өп-өлкән хатын булып килеп басуы мине сискәндереп җибәргән иде. Шуннан бирле Әкълимә яшәргәннән-яшәрә генә бара кебек. Юк, миңа гына шулай тоелуы түгелдер... Табигать, гүя тормыш дәрте ташып торган бу хатынны ашыгыбрак өлкәнәйтүенә үкенгәндәй, инде ялгышын төзәтә шикелле.

— Һаман да трактордамы?

— Якалап кына сөйрәп ыргытмасалар, төшә алмамдыр, ахры, мин аннан.

— Акбүз ияреннәнме?

— Акбүз дигәннән, Әсгатькә дә бик иртә кагылды ул машина җене.

— Әйе-йе... Ни хәлләре бар ул малайның?

— Шулай Акбүз атым дип, бик кечкенәдән гел машина тирәсендә чуалып үскәнгәдер, унны бетергәч, тагы укырга ниятләп-нитеп тә тормады, үз янымда эшли башлады. Күпме генә үткәндер, өр-яңа «Беларусь»ны ышанып тапшырдылар үзенә.

— Алай җаны тарткач, начар эшләмидер?

— Начар эшләмәде. Тик председателебез Батыршин... Син аны хәтерлисендер, райком секретаре иде... Шул Батыршин абый һич тынычлык бирмәде үзенә. Гел укырга китәргә кыстады. Ахырдан, идарә утырышына куеп, тәки күндерделәр малайны. Инде әнә, уч тулы колхоз стипендиясе каерып, сельхозинститутта укып йөри.

— Алай... Кайсы факультетта?

— Шул, механизация буенча... Үзеңнең ни хәлләрең бар? Өйләнгәнеңне ишеткән идек.

— Әйе, керде муен камытка... Ничек соң, Әсгать әйбәт укыймы?

— Начар бармый. Менә, озатырга төшә алмавына бик әчен уып калды. Экзамен бирәсе көне икән... Син Әлмәт ягында бит хәзер, ниме... Сәетгәрәйне очратканың юкмы? Ул да бит шул якта.

— Һе! Әллә нефтьче булып киттеме?

— Нефть чыгаруда ук түгел бугай. Нефтьчеләргә тегесен-монысын кайтарту эшендә йөри диделәр. Очратканың юк, алайса?

— Мин Әлмәттә сирәк булам шул. Карале, Әкълимә, мин бит Әсгатькә... сезгә хат язып белешергә, тагын әллә кайларга язарга җыенып йөри-йөри... Төннәрен исемә төшсә, әллә нишләп китәм... Бу укып йөрүләр дә аяк-кулны бик бәйли. Мәскәүгә, Тимирязев академиясенә барып кергән идем. Заочно. Ничек соң?.. Син беләсеңдер инде, Галимҗанның һәйкәленә исемен язу турында... Хәл ителде микән ул мәсьәлә?

— Хәл ителер төсле. Әсгатьнең ул турыда язган хатлары-җаваплары белән бер чемодан тула инде. Быел менә икәүләшеп Буракига барып кайтабыз. Җитте. Сузсаң, сары май да сузыла.

— Сузыла шул менә... Синең болай нинди сәфәр соң әле? Барышмы, кайтышмы?

— Мәскәүләргә үк очарга тора бит апаң. Күргәзмәгә барабыз. Райоңнан җиде кешене Хәбибуллин, безнең яңа секретарь, үзе җыеп алып бара. Әнә шулай кулыңнан сөйрәп торгызгач, кузгаласың икән ул.

Нәкъ шул чакта радио Мәскәү самолетына утырту башлануын хәбәр итте.

— Һай, бигрәк вакытын чамалап әйтә белүен генә күр! Иртәдән бирле зар-интизар көттерде дә... Карале, Харис, әйтеп калыйм... Сәетгәрәй дип шуңа сүз чыгаруым иде... Әсгать башлы-күзле булырга йөри бит әле безнең.

— Изге теләкләрем ирешсен.

— Ирештерермен. Кемне ала дип сора син миңа. Язмыш дигәнең Сәетгәрәй кызы белән кавыштырырга тора бит улымны. Теге, Сәетгәрәйнең Арчадагы аерган хатыны кызы. Зөлфия исемле.

— Чыннан да... Кызыграк язмыш.

— Зөлфия дә Казанда, пединститутта укый икән. Шунда танышканнар... Әнә, безнекеләр кузгалды. Артларыннан калмыйсы иде.

— Әйе-йе. Киттек. Озатып куйыйм.

— Шуны әйтеп калыйм дим, Әсгать үзләренең туйларына, Харис, сине дә чакырырга бик исәпләп тора. Анысы, чакыру хатын үзе язар әле. Минем әйтүем шушы булсын. Килерсең бит?

— Килергә тырышырмын. Туйларын кайда, авылдамы, Казандамы үткәрәләр?

— Авылда булмыйни!.. Ярар, Харис, тагы да иминлектә-шатлыкта очрашырга язсын.

— Хәерле юллар, Әкълимә!

## VII

Ләкин мин Әсгатьнең туена кайта алмадым. Сәбәпләрен уйлый-саный башласаң, бар инде алар. Шактый җитди, хәтта кичектергесез дә кебек сәбәпләр...

Узган көз, ниһаять, кузгалып-кубып чыгып киттем.

...Якты түбәләр өстендә кораб мачталарыдай калыккан телевизор антенналары, шәһәрдәгедән һич ким булмаган клуб, мәктәп, идарә биналары, читтәрәк берәр завод-фабриканы хәтерләткән озын-төзек ферма каралтылары... Бүгенге авылның мондый күренеше берәүгә дә шаккатардай нәрсә түгел, юкса. Миңа бигрәк тә. Эшләгән якларымда да күзгә сеңеп беткәннәр алар.

Әмма мин, автобустан төшүгә, туган авылымның бу яңа күренеше алдында каккан казыктай басып калдым. Яшерен-батырын түгел, керфек төпләрем кызыша ук башлады. Көзге кояш алтынсу-кызыл агачларга җайлап кына төренеп утырган клуб артына тәгәрәп төшеп бара, шул якта (кирәк бит!) бигрәк татарча итеп «Истә, һаман да истә»не сыздыралар, янымнан гына, моңсу бәәлдәп, бөдрә бәти йөгереп узды.. Шулай рәхәт исереп басып калуыма болары да, әлбәттә, тәэсир итми калмагандыр...

...Бала чагыннан соң озаграк күрми торып, инде үсеп-ныгып җиткән ир-егетне очраткач, гадәттә, «урамда кыйнап китсә дә, танымассың», диләр. Әсгатьне мин кайдадыр очраклы гына очратсам, алай төсмерли алмый тормас идемдер.

Шул ук кара тутлы йөз, тик алай чуендай ук түгел хәзер, яктыра төшкән. Карашлары җитди чакта шулай ук усал-кырыс, инде бераз юкара төшкән иреннәрен җәеп җибәрсә, һаман да сабыйларча саф. Ә менә буйга мин аны озынрак итеп күз алдыма китерә идем. Буйга алай сузылмаган бу, бөтен көч-куәтне җилкә-күкрәккә җыйганы әллә кайдан сизелеп тора. Аннары, менә, чәчләре... Малай чагында кырып-алдырып йөргәч, каян беләсең, чәч тә бар икән үзендә. Кара бөдрәләре дулкын-дулкын күпереп тора, бу алкалар болай чуалып төшсә дә, тегеләй чуалып китсә дә, йөзенә яңа күркәмлек кенә өсти.

Әсгать өйдә ялгызы иде. Күрешү, хәл-әхвәл сорашу шау-шуыннан соң, егетем мин килеп кергәч тә салып аткан чуар алъяпкычын һич тартынмый-нитми яңадан бәйләп алды да, сөйләнә-сөйләнә, баллонлы газ плитәсе өстендәге кастрюль, табаларны шакы-шокы китерә башлады.

— Кем алдан кайта, шул повар безнең өйдә. Син, Харис абый, үз өеңдәге кебек бул инде. Әнә, теге якка чыгып, газета-китап караштыра-

сынмы шунда. Юлдан соң ятып алсаң да бик шәп булыр. Әллә ваннада, я душта юынып чыгасыңмы? Алары, шәһәрдәге кебек, өйдә үк түгел түгелен, мунчада. Ләкин ике атлап бер генә сикерәсе. Иске өй агачларыннан үзем эмәлләгән идем. Заманча итеп. Ваннасы, душы, ял-хәл бүлмәсе — һәммәсе бар. Әйдә, булмаса, Харис абый, берәм-берәм кайткалый башлаганчы, кереп чыгасыңмы әллә?

Мин инде, «заманча мунча»ны бер күреп чыгарга булса да кызыгып, урынымнан кузгалган идем, ишекне бик олы ачып килеп кергән малайны күреп тукталып калдым.

Тукталып калдым һәм нидер әйтергә ачылган авызым да шул килеш калды бугай.

Минем алда нәни Галимҗан басып тора иде.

Иа хода! Охшаса да охшар икән... Шул ук җирәнгә тартым чәч-каш, шактый эредән уелган йөз чалымнары. Нәрсәгәдер үпкәләгән сыман турсаеп кына карап торулары ук Галимҗанныкы.

Мәнә син, табигать, Галимҗан дустымның бар төс-кыяфәтен кайчанга саклагансың икән!

Нәни Галимҗан минем белән бик кыю исәнләште, учларны шапылдатып сугып кул кысыштык. Исеме Сәлимҗан икән, беренче класста укый, инде җиде «бишле»се бар, тик мәнә язудан гына «өчле» дә әләккәли, монысына каләм гаепле икән, нигәдер чүп иярә дә чүп иярә, чурт... Шуларны сөйләшеп торганда тагын ишек ачылды.

Ишек ачылды да тиз генә ябылмады. Иң алдан бик олы сары портфель күренде, аның артыннан җете кара күзле малай пәйда булды. Шунда ук, бу олы портфельне һәм җете күзне бик житез генә әйләнеп узып, зәп-зәңгәр күзле, бөдрә сары чәчле кыз бала алга чәчрәп чыкты. «Тьфү, тьфү, күз тимәсен, мондый миләүшәдәй зәңгәр күз, бөдрә сары чәч авылыбызда булганы да юк иде бугай әле». Шулай «өшкеренгәләп», югарырак карасам, бусага бушаганын көлемсерәп сабыр гына көтеп торган тагы да зәңгәррәк күзлесе белән очраштым.

— Сезмени инде ул... Харис абый? — диде Зөлфия, йомшак жылы кулын учыма тидереп кенә алып.

Зөлфиянең мәктәптән кайтышлый бакчадагы нәниләрен дә ияртеп алып кайтуы икән.

Әсгать чуар алъяпкычны салып, аңа тоттырды.

— Тантаналы төстә кабул итеп ал, әнисе. Миссиягә кызыллык төшмәде шикелле. Әйдә, Харис абый, кухня исен мин иснәттем, инде ашын королева үзе китерсен.

Түр якка уздык. Шактый иркен, биек. Яхшы мебель. Иң күзгә ташланганы — китаплар. Төрлечәрәк биеклектәге китап шкафлары бер як стенаны тоташтан тутырып тезелеп киткән.

Әсгать сәгатенә карап алды.

— Әни озаклады әле безнең нигәдер.

— Кырда түгелдер инде? Мастерской тирәсендәме?

— Кырда шул менә.

— Нишли бу вакытта?

— Туңга сөрә, — диде Әсгать, турсаеп кына.

— Озаклагансыз... Без инде амбар юлларына кадәр әллә кайчан сөреп ыргыттык, — дип, мин мактанып алдым.

Әсгать минем алга чип-чиста көл савыты китереп куйды.

— Син, Харис абый, тартырга чыгып йөгерми тор әле. Гадәтең истә. Хәзер әйтеп бирәм бездә туңга сөрүнең нигә сузылганын. Сезнең халык... Ягъни безнең баш агроном Халитов гаепле монда.

— Кызык! Агроном суза туңга сөрүне, бер дә механизаторлар түгел?..

— Кызык шул менә. Рәмис Шәехович шулай үзе атланган ботакка үзе балта чабарга да ярата безнең... Бала чактан бергә үстек, институтта да бер чордарак укыдык без аның белән. Бик дус чаклар да булды, чәкәләшеп тә алгалый идек. Менә хәзер дә...

Сак кына атлап, бүлмәгә Зөлфия килеп керде.

— Сүзегезне бүлдем, ахры, — дип, серванттан нидер алуга шунда ук чыгып та китте. Чыгышлый, ир белән хатын бер-берсенә карашып алдылар. Нindидер үпкәме, шелтәме чагыла иде кебек Зөлфиянең карашында.

Әсгать уңайсызланып кына елмаеп куйды.

— Менә хәзер дә кайчак, бала чактагы кебек, Рәмкә дип җибәрәсе килә үзенә. Тик менә...— Әсгать күзе белән генә кухня якка ымлады,— кайберәүләр бер дә алай әйткәнне күтәрә алмый.

— Ә мин хәтерлим бугай ул егетне.

— Хәтерегез яхшы, алайса. Малай чакта бер чәкәләшүне сөйләгән идем шул. Алай начар агроном чыкмады аннан. Уңыш алу буенча районда алдынгылардан йөрибез. Тик менә, әйтәм ич, үзе утырган ботакка үзе балта чабып та куйгалый... Сез салам турагычлы комбайннар белән урдыгызмы?

— Көйләдек ул нәрсәне.

— Без дә көйләгән идек тә... Яңа нәрсә бит, комбайнчылар тиз генә күнегеп китә алмады аңа. Я пычаклары тыгыла, ул арада бушаткыч арбалары каядыр тоткарлана. Рәмис кашларын җимереп карап йөри моңа. Шуннан бервакыт мин РТСка киткән идем, комбайнчыларны пыр туздырган бу. «Алып ташлагыз бу нәмәрсәләрегезне, яңалык дигән булып, уракны кара көзгә кадәр сузарга йөрмәгез»,— ди икән.

— Әйбәт яңалык бит ул. Басулар берьюлы саламнан арына бара, күпме әзер терлек азыгы була.

— Соң инде! Хәзер Рәмис үзе дә терсәген тешләрдәй булып йөри. Бер комбайнда салам турагычны чынлап торып көйләп тә күрсәттем үзенә. Юк, һаман да үз туксанын тукыды ул чакта. Аңа, понимаешь, уракны районда беренче булып тәгәлләү кирәк булган. Беренче булмаса, икенче булып тәгәлләр идек уракны, аның каравы, шушы көнгә кадәр тунга сөреп йөрми идек. Басудан салам ташып гомер уза хәзер. Юкса, үзенең үк әйткәне бар Рәмиснең: «Зәбең шәп — күнелең шат, амбарыңа тагын бер йөк — шалт!» дип, үзенчә мәкаль чыгарган.

— Дөрес сүзләр.

— Дөрес сүзне шулай авыз чайкар өчен генә тотабыз кайчак. Тагын бервакыт шулай...

Ләкин тагын бервакыт ни булганын ишетергә туры килмәде. Зыңгылдап пыяла ишек ачылды да, бүлмәгә язгы ташкындай гөр-гөр көлү, бала-чага чыр-чуы ыргылып килеп керде. Әкълимәнең бер оныгы җилкәсенә асылынган, икенчесе кулына, ә кечесе муенына ук менеп атланган иде. Әкълимә үзе исә һич тә эштән кайткан кешегә охшамаган, өстендә аның эре бизәкле әйбәт киңчә күлмәк, бөтен йөзе, күлмәгенең һәр чәчәге, дымлы толымнары, энҗе тешләре — табигать шулай мәңге ак һәм какшамас итеп биргән тешләре — барысы көлә, нурланып, балкып көлә иде. Һаман да шулай яшь үзе, тик... еллар үзенекен дә итми калмаган, кара толымнары инде көлсуланган, гәүдәгә калыная төшкән...

— Кая соң, ыланнар... Абый белән күрешик инде. Сагындык дигәч тә сез... Ничек килә белдең, Харис, ничек килә белдең... Исәнлек-саулык, тынычлык-иминлекме? Һай, бик рәхмәт инде...

Шушы мәлдән башлап, бүлмәне тутырган бу күңелле шау-шу, гөрләү, чыр-чу аз гына да туктап тормады. Китте олысы-кечесе бергәләп өстәлгә сый-нигъмәтләр ташу, олы сабый белән кече сабый көлешә-көлешә куышып алу, кызык-мәзәк сүзләр әйтешү, аннары тәлинкә-

кашык шалтыраулары, кыстаулар, уймак кадәр генә рюмкаларның кыңгыраудай зыңлап алулары...

Бу нәни сабан туе күпме дәвам иткәндер, анысы сизелмәде дә һәм шулай сизелмәстән генә бүлмә эче тып-тын булып калды.

Балалар көйсезләнми-әйттерми генә кайсы кая тәгәрәште, Әсгать, «мин озакламам» дип, кичке нарядка чыгып китте, Зөлфия кухня якта китап-дәфтәрләр кыштырдатып, дәрескә хәзерләнеп утыра.

— Менә шулай яшәп ятабыз инде... Иртә-кич бер ду кубышып алабыз да көндезләрен бер-беребезне күргән дә юк.

— Бик матур яшисез, Әкълимә. Күңелле яшисез.

— Зарланыр җиребез юк, шөкер,— диде Әкълимә һәм, әллә мина гына шулай тоелдымы, тыелып кына тирән бер көрсенеп куйды. Үзе җайлап кына өстәл башын сыпыра иде — һаман да шул гадәте икән.

Күпмегәдер тынлык. Була бит шундый минутлар... Ике әңгәмәдәш беразга сүздән кала, ләкин сүзсез утыруларын алар үзләре дә сизмиләр, күңелләре моңсу гына сызыла... кинәт искә төшкән әллә кайчангы хатирәләр, уй-хисләр дулкынында тын гына чайкалып утыра бирәсең.

— Кая соң... Тәмам оеп утырам,— диде Әкълимә һәм җәһәт сикереп торып, өстәл өстен тәртипкә кертеп алды.— Ашамадың да инде син. Безнең Әсгать кунак сыйлый беләмени ул. Кая соң...— Әкълимә өстәлдәге бармак иңле дә кимемәгән коньяк шешәсен кулына алды.— Булмаса, менә үзем сыйлыйм әле. Зөлфия, әйдә, син дә кил. Хуҗа югында рәхәтләнеп бер чәкештерә-чәкештерә салабыз, әйдә.

— Әйе шул, иртәгә дәрескә җырлый-җырлый барып керим әле,— диде Зөлфия, бит очларында тагын шулай бер генә мизгел ялкын кабызып алды, уймак рюмкага иренен тидереп куйды һәм «әнкәй, иртәгә минем теге алты дәресле көнем. Гафу итегез, Харис абый» дип, кухня якка чыгып китте.

— Әсгать бу нәрсә белән алай дус түгел, ахры? — дидем мин шешәгә ымлап.

— Шөкер, чуалмый аның белән, бик шөкер... Син, алай дигән белән дә, тарсынып утырма тагын. Үзең хуҗа бул монда. Чит кеше түгелсең, әйдә.

— Рәхмәт. Барысы да алда.

— Дөресен генә әйткәндә, Әсгатьнең бер гөнаһысы булды ул яктан.

— Яшьлек тилелегедер.

— Нәрсә дияргә дә белмәдем. Бер уйлаганда, аңлашыла да кебек... Шулай, җиңүнең егерме еллыгына сугышта үлгәннәргә авылда һәйкәл ачтылар. Килгәндә күргәнсеңдер бәлки, клуб каршында. Галимҗанның да исеме бар анда.

— Әйе-йе. Озак басып тордым.

— Аннан элек кенә Буракида булып кайткан идек. Теге, Әсгать әйтмешли, «и др.»лар беткән андагы һәйкәлдә хәзер. Галимҗанның исемен дә алтын белән язып куйганнар. Әсгать бит ул турыда әллә кайларга язып бетерде, шуның да файдасы тими калмагандыр. Бик хөрмәтләп, олы кунак күк каршыладылар үзебезне, күңелле итеп озатып калдылар. Кайтып, күпме генә вакыт узгандыр, үзебездә әлеге һәйкәл ачылды. Менә шул көнне күрсәтте инде Әсгать татар тамашасын. Һәйкәл ачылган кичне этиләре сугышта үлгән егетләр җыелып, әйбәт кенә салганнар болар. Ярар, монысына бер сүзем булмады. Ир заты булсам, үзем дә бер төшерми түзә алмас идем кебек ул көнне. Әмма ләкин... иртәгесен малай тагын исерек. «Улым, мин әйтәм, укуына зыян килә күрмәсен, бер генә көнгә сорап кайткан кеше бит син», дим. Кул гына селти. Баксаң, монысы әле тамашаның кечесе генә булган, мичтә калган икән олысы... Өченче көнне, Батыршин абый кабинетына чакырып алып сөйләп биргәч, чәчләрем үрә торды. Шулай, салган баш белән председатель бүлмәсенә килеп кергән дә олы тавыш кубарган малай... Кая соң, ишек-

не дә яба белмәгәнмен, минем лыбыр-лыбырны ишетеп утыру эш кешесенә бик күңелле түгелдер.
Әкълимә кухня ишеген тавышсыз гына ябып килде.
— Син безнең иске идарә йортын беләсең инде. Хәзер аны агролаборатория иттеләр. Шул өйгә бәйләнә икән Әсгать. «Алыгыз андагы бөтен әйберләрегезне, мин ул өйне ут төртеп яндырам!» — ди икән. Ни ачуы булгандыр инде ул өйдә? Әллә инде минем анда председатель булып утырып, әлеге күңелсез хәлләргә таруыма җене котырганмы?..
— Кем белә, бәлки...
— И бала... Тавыш кубарып кына калса, тагын бер хәл. Шул төнне килеп, ул өйнең бөтен тәрәзәләрен ватып бетергән, кулына шырпы тоткан килеш, дружин егетләре бәйләп салганнар үзен.
— Менә син, ә!
— Әйтәм ич, чәчләрем үрә торды. Ичмасам, җылый да алмыйм. Ә Батыршин мәсьәләне бик каты куя. «Судка бирми булмый бу эшне, без аңа ышанып колхоз стипендиясе түләп ятабыз, ул яшьләргә әнә нинди үрнәк күрсәтә», — ди. Нишлисең, дөрес сүзгә җавап юк. «Куегыз судка, алсын тиешле җәзасын», — дидем дә чыгып киттем.
— Да-а...
— Өйгә ничек кайтып ауганмындыр, хәтерләмим дә. Тәмам миңгерәүләндем. Көтәм, Әсгать кайтмый. Төне буе да кайтмады. Ярар, мин әйтәм, утыртып та куйганнар икән малайны. Чисти акылдан шашаммы дип торам ул төнне. Өйдә япа-ялгызым бер үкереп җылыйм, ул арада, каршымда Әсгать басып торгандай, эт итеп орыша-сугә башлыйм үзен. Ә бит малай тәмам акылга утырды дип шатланып бетә алмый йөргән көннәр... Элегрәк, мәктәптә укыганда, күрсәткәләгәне булды. Югары классларга киткәч, үзен кулга алган иде. Колхозда ни әйбәт эшләде. Институтта да алдынгы булып бара иде. Юк икән, мин әйтәм, үзәге нык булмаган икән малайның... Иртәгесен кайтып керде бу. Бер тамчы капмаган. Өсте-башы чип-чиста. Эчтә янар таулар актарылса да, сер бирмәдем. «Әле син төрмәдә түгелмени?» — дим. «Күпме бирсәләр, шул кадәр утырырмын, кулым эшләгәнне җилкәм белән күтәрә дә белермен. Патша төрмәсе дә, фашист төрмәсе дә түгел, бер дә кайгырма, әни»,— ди бу, исе дә китми. «Ни дип кылануларың соң инде бу? Ичмасам, сәбәбен генә белеп калыйм»,— дим. Дәшмичә генә турсаеп утырды-утырды да ярсый-ярсый җылап җибәрмәсенме, балакаем. Малай чакта да бер тамчы күз яше күрсәтмәгәнне... «Әни, — ди, — нигә элегрәк салмадылар бу һәйкәлне? Нигә этинең исемен каберенә ничәмә еллар үткәч кенә яздылар? Нигә?» — дип өзгәләнә җанашым. «Менә безнең, сугыш ятимнәренең, үсеп беткәннәрен көттеләр микәнни? Нигә алай итәләр, әни? Без малай чакта бигрәк тә кирәк иде ул һәйкәлләр. Бик тә кирәк иде...» — дип ачыргалана. Нәрсә дим? Никадәр нык торырга маташсам да булдыра алмадым. Балакаемны кочакладым да үзем дә үкси башладым. Аналы-уллы икәүләшеп җылашабыз...
— Аңлыйм, Әкълимә. Бик аңлыйм.
— Кичкә таба, инде бераз тынычлангач, тагын сорадым: «Шулай да, улым, ул иске идарә йортында ни үчең бар иде соң? Нигә алай кыланасың?» — дим. Күпме төпченсәм дә, анысына җавап ала алмадым.
— Сәеррәк шул... Ә болай, ничек, хөкем итмәделәрме үзен?
— Судка ук китмәде эше. Һаман да шул Батыршинның изгелеге инде, рәхмәтләр яугыры. Бигрәк кеше өчен генә туган адәм инде ул Батыршин абый. Инде менә пенсиягә чыкканына да ничәмә еллар, һаман да шул кемнәр турындадыр кайгыртып чабып йөргән көне. Теге вакытта ул эшне зурдан кубарса, малайны да утыртмый калмаслар иде. Алай итмәде. Әмма малай бөтенләй үк җәзасыз да калмады. Иң әүвәл, авылда ук, колхоз комсомол җыелышында бик әйбәтләп пешергәннәр. Институтта да шәп эләккән бугай үзенә. Аннары килеп, бер ел буена

колхоз стипендия түләмәде. Батыршин миңа да бик каты кисәтеп куйды. «Кара аны, бер тиен акча җибәрәсе булма улыңа, бераз Лаеш шулпасы чүмерсен», — ди. Алай дигән белән дә, ана күңеле түзәмени! Ай үтте микән, күпмедер акча салдым. Өч-дүрт көннән акчам кире әйләнеп тә кайтты. Тагын җибәрәм, тагын кире кайта. Аптырагач, район үзәгенә барып, шуннан җибәреп бактым. Янәсе, моннан салганына Батыршинның кулы уйнамый микән? Юк, барыбер кире кайтты.

Ә Фәния апасы, бичаракай, түзмәгән, малай янына үзе киткән. «Алма апам, кадерлем, сабый чакта изгелекләреңне күп күрдем, инде дә сакаллы сабыйга санамасаң икән энеңне», дип, сумкасына дөнья күчтәнәчләр төяп, озатып җибәргән апасын.

Соңыннан гына белдек, ял саен пристаньда йөк бушатуда эшләп, ел буе үз көнен үзе күреп укыган. Студент кенәгәсен дә күрсәтте, укуы да бик әйбәт барган... Менә шуннан бирле, әйтмәгәнем булсын, авызына да алганы юк бу нәрсәне. Кунак-төшем килсә дә, форма өчен рюмкага авызын тидереп кенә куя. Үзең күрдең ич.

Әкълимә кухня як ишеккә күз төшереп алды.

— Аннары, әйтмәгәнем булсын, килен дә бик акыллы, ул да бик нык тота бугай үзен. Шул җәһәттән сорыйм әле... Ничек соң, синең һаман да Сәетгәрәйне очратканың юкмы?

— Бер дә очраганы юк шул...

Һәм мин гомеремдә беренче мәртәбә Әкълимәгә ялган сүз әйттем. Бар иде минем Сәетгәрәйне очратканым.

Әлмәткә нindидер эш белән килгәч, «Нефтяник» ресторанына ашарга кердем. Сәетгәрәй белән шунда очраштык. Бик яктырып килеп күреште. Яныма күчеп утырды. Таза, чибәр. Өс-баш бик затлыдан. Гадәттәгечә, хәл-әхвәл сорашу китте, сабакташларны искә алдык. Әкълимә турында сүз чыккач, Сәетгәрәйнең алтын тешләре ялтырамый башлады.

— Карале, сабакташ, алыйк әле берәр йөз грамм. Гомер эчендә бер очрашып та... Хак тәгалә үзе үк гафу итмәс моны,— дип, Сәетгәрәй урыныннан кузгалды.

Мин кирәсе җирләрем барын әйттем. Сәетгәрәй чәнечке сабы белән өстәлгә тиз-тиз сызгалагандай итте.

— Алайса, сабакташ, болай итәбез. Бүген кич безгә кайтабыз. Куныш китәрсең. Гел-гел генә эш артыннан куарга димәгән, эшнең аның үзе сине куганы да бик җиткән. Иркенләп бер сөйләшеп утырырбыз.

— Рәхмәт. Теләсәм-теләмәсәм дә керми булмас әле. Гостиницада урын юк, диделәр.

— Шәп, алайса! Болай сөйләштек. Нәкъ сәгать алтыга нәкъ шушы ишек төбендә сине машина көтәр. На всякий пожарный случай, адресны да язып ал.

Сәетгәрәйнең чәнечкесе тагын өстәлгә бормалар-сырмалар сызгалый башлады.

— Их, сабакташ... Сөенечләренә караганда, көенечләре күбрәк минем тормышның. Түйганчы бер эчләремне бушатасым килә. Ләкин кемгә? Юк минем андый җан дустым-сердәшем. Дөресен әйтергә кирәк, юк! Аңласаң, менә син ничек тә аңлар идең мине...

Сәетгәрәй үзе сөйли, ә куллары, инде чәнечкене ташлап, өстәлдәге салфетка кәгазьләреннән ни арада әле нәни көймә, әле матур гына чәчәк, әле очар кошчык ясап куя башлады.

— Тегендә өйрәнгән һөнәрләр болар,— диде ул, бер як авыз чите белән генә елмаеп һәм кисәк үзенең бөтен «һөнәрләрен» берьюлы зур учына йомарлап алып, көл савытына ташлады. — Әй, малай!.. Җырда да бар бит, «җан бирсәң дә, яр бирмәгез» диелгән. Шуның шикелле... Булмады инде миннән.

Кинәт эчемдә әллә нинди җеннәрем котыра башлады. Ни хакы бар аның Галимҗан җырына кагылырга?!. Бармы хакы? Җырның бит аның актан пакь үз җаны бар... үз иясе бар.

— Юк, Сәетгәрәй килә алмыйм мин бүген сиңа. Онытканмын, ашыгыч эшләрем бар, кайтам, — дидем дә урынымнан кузгалдым.

— Шуннан әйтүем аны...— диде Әкълимә, тагын ишеккә таба карап алды.— Килен бик акыллы, бик уңган, сүз дә юк. Тик минә... этисенә бигрәк рәхим-шәфкатьсез инде. Кешегә әйтсәң, кеше ышанмас. Шулай кайвакыт Сәетгәрәйдән хат килгәли. Ә кызы укыса укый этисе хатын, укымаса юк, ерта да мичкә ата. Аннары минә... Кешегә әйтеп, кеше ышанмас. Туйларына да чакырмадылар Сәетгәрәйне. Анысы килер идеме-юкмы, күңел өчен генә булса да хәбәр итсәләр, ни була соң... Нихәл итәсең, бигрәк сыны-бәгыре каткандыр инде этисенә. Юкса, кызы институт бетергәнче алиментын җибәреп торган Сәетгәрәй. Зөлфия үзе үк әйтеп тора. Яхшымы-яманмы, эти кешегә болай ук таш бәгырьле булмаслар. Һай, бу тормыш... Кая соң, нигәдер озаклады бу Әсгать?

Без инде, сөйләшә-сөйләшә, икенче самаварны сыгабыз. Әсгать һаман кайтмый.

— Берәр утырыш-мазарлары чыкты микәнни соң боларның? — дип, Әкълимә еш-еш тагын ишеккә карангалый башлады. Ишектә, зәңгәр плащын кыштырдатып, Зөлфия күренде.

— Әнкәй, мин бер әйләним әле.

Мин дә, җилләнеп керәм дип, ишегалдына чыгып киттем.

Мин әйләнеп кергәндә, Әкълимә диванда башын нарасыйларча кырын салып, мыш-мыш йоклап утыра иде.

— Кайттылар мәллә? — дип, урыныннан сикереп торды.

Шунда капка тавышы ишетелде, минә ишектә Әсгать белән Зөлфия күренде. Икесенең дә йөзләре, яңа кавышкан пардай, балкып тора, Зөлфия ипле генә итеп иренең беләгеннән эләктереп алган, Әсгать кулына кәгазь төргәк тоткан иде.

— Инде йоклап туйганнардыр болар дисәм... Сөйләшеп кенә сүзләре бетәсе түгел, ахры, бу сабакташларның,— диде Әсгать, кулындагы төргәген нииндидер әчке бер тантана белән өстәлгә куйды, актарып ташлады. Өстәлдә металлдан коеп ясалган зифа ат сыны пәйда булды. Озын-спай аякларының ашкынулы бөгелешләренә, ял-койрыгының җилдә җилфердәгәндәй дугай-дугай күпереп торуларына караганда, аргамак минә-минә өстәл буйлап, бүлмә буйлап очып кына чабып китәр төсле иде.

— Акбүз ат бу, әни. Харис абыйга истәлегем, — диде Әсгать, илһамлы елмаеп. — Күптән койган идем дә, игәләп-шомарткалап «җан кертергә» һаман кул тими ятты. Калган эшкә кар яуды. Бүген инде бетерми кайтмыйм дип тотындым. Моннан ары бер генә эшебезгә дә кар яумасын, Харис абый. Юкса... юкса, Акбүздән егылып төшүебез дә бик ихтимал!

— И, кара инде! Бигрәк чын ич бу, — дип, Акбүз сынын беренче Әкълимә кулына алды.— Әйтәм аны, шул Акбүз әкиятен сөйли башласаң, өч-дүрт кич буе балаларны авызыңа каратасың... Рәхмәт инде, олыларны олы итә белүеңә бик рәхмәт.

Зөлфия дә кайнанасы кулындагы Акбүз сынын тере нәрсәдәй назлап кына сыйпап куйды.

Алар өчесе дә елмаялар иде.
Мин дә елмаерга тырышам, ләкин...
Бер дә егылыр исәпләр юк та бит Акбүздән...
Күп эшләремә кар ява шул, кар ява...

## Саҗидә Сөләйманова

●

Эңгер төшеп килгән кышкы көннең
аклыгына күзләр чагыла.
Сырлап-бизәп язган эзләр укып,
Зәй өстеннән киләм чаңгыда.

Елга аша поши-болан үткән,
кош-корт аулап, төлке шуышкан.
Мавыктыргыч әкият батырлары —
куян белән бүре куышкан.

Куркаклык та, хәйлә, явызлык та —
әкият түгел — чыннар, дәресләр.
Яфраклы җәй, яңгырлы көз булса,
ачык ятмас иде бу эзләр.

Яңа гына җиргә яуганнар да,
көн пакьлеге булып, ак карлар
таң калганнар яхшы-яманына:
— Күрегезче, илдә ниләр бар!

Куян алай җитез чапмас иде,
үкчәсенә бүре басмаса.
Кош канатсыз, кыш таләпсез булса,
төлке яшәр иде башкача.

Ярый әле, күз кабаксыз түгел,
күрмәсен дә кайсын, сизмәсен, —
су буйлатып кына ике болан
йөри бирсен эзгә-эз басып.

Зәй буйларын урап, кайтып киләм.
Нур-бизәкләр,
эзләр — ак карда.
Бу дөньяда кара таплар күренә
ак өстендә ярылып ятканга.

## Себердән

Күңеле илереп тә,
сөрелеп тә —
кыю ирләр сәфәр кылган ил.
Кырлары — күз, урманнары — аваз, —
юлын-телен белсәң —
— туган ил.

Ишетелә, очрый таныш сүзләр,
даулы еллар исем биргәннәр:
«Үткәрмә» дә «Урай», «Яулы-Тора»,
урман-елга корган кирмәннәр.

Себер көен җырдан алып атсаң,
тулы булмас илнең аһәңе.
Аттан төшкәч атны онытуны,
юк, мактамый халык мәкале.

Ничә буын монда, күпме милләт
үз җылысын салган, гомерен —
җылытырга җирне, яшәртергә,
яктыртырга сөрген Себерен.

Көнбатышка инде нур сузарга
«кара алтын» таба якташлар.
Таныш йөзләр —
җир сандыгын ачкан,
Татарстан данын яклашкан.

«Дуслык юлы» булып кайта бүген
кайнар елга
салкын Себердән.
Күзгә — дала,
җырга — кара урман
юл ачышкан гомер-гомердән.

## Тиз генә онытмале

Түбәдә яңгыр шыбырдый,
куана җиңүенә:
капладым күген Себернең,
китмәле җиңел генә.

Урамда зонтлар-чатырлар, —
күчкәндәй Күчем явы...
Әйтерсең төнге төшләрнең
ишетелә пышылдавы.

Чатырлар чолганышына
чыгамын ялан башым.
Тамчылар аяк очымда
биеләр тупылдашып.

Алдылар мине әсиргә,
аһ, Себер болытлары!
Күп серләр сеңгән бу җирдә —
истәсе, онытканы...

Агыла, йөзә болытлар,
ачыла соры пәрдә.
Һәм нәни кара чатырлар
юк була шушы мәлдә.

Карашлар хәвеф-хәтәрсез,
күк төсе — зәңгәр күзләр.
Төн сере — кыйгач күзләрдә.
Яңгырлар юган эзләр...

Гасырлар юган барын да —
кем каны кем канында.
Яралган җаннар —
яралы
бер тарих карынында.

Дау белән давыл куптарып,
ач җилләр көчләп искән.
Яу килгән — башлар киселгән,
яу тынган — урман үскән.

Каннарны кушып, кайнатып,
шул Себер киңлекләре
үстерде үз күңленә тиң
пәһлеван егетләрне —

ялкынга салып сынап та,
салкында чыныктырып...
Богаулар кысса ирекне —
Кем әүвәл алды йолып?!

Чылбырлар чыңын ишеткән
дәрьялар сискәндерер...
Ят күрү, дусны бәһаләү —
табигатеңдә, Себер.

Үткәннең чоңгылларыннан
калкынып, болытлары
чолгады мине: китмәле,
тиз генә онытмале!..

## Җисми дөнья...

Җисми икән дөнья.
Искән җилләр
сәлам түгел сөйгән ярлардан.
Сандугач та җәйнең уртасында
туктый диләр өзелеп сайраудан.

Хыялыйның каурый канатында
оя кора чуар мәшәкать...

Ләкин —
кемнәр өчен йолдыз атыла,
кемне сагынып сызыла бу шәфәкъ?!

Исеме табылмаган нинди көчләр
туфрак-җирдән йолкып, кешене
алып менә хыял үрләренә? —
Төреп бирә идеал серләренә
яшәешнең гади җисемен.

Юк, ышанмыйм! —
әгәр җисми җирсү
өстен булса изге хисләрдән —
нигә
һаман елый Ярославна?
Дастан туа Таһир-Зөһрәдән!

Бирәү өчен бирәү канын бирә.
Җаны фида —
сатмый иманын.
Илаһилык җиңә —
үтә алса
яшәешнең җисми сынавын.

●

Сыкылы-бәсле кыш иде.
Чатнама салкын кич иде.
Ак бәллүр тәрәзә — ак рәшә.
Бик таныш ят аһәң — янәшә.

Өстәлдә шәрабле тустаган,
күчтәнәч якыннар-дуслардан.
Йолдызлы ак кар — бар җир,
ә бездә кояш, «Алжир».

И кызды дуслыкка имтихан, —
шигырьдә кем хаким, кем туфан...
Бәхәстән иреннәр чатнады.
Бу кичтә күп нәрсә хакланды:

Хак сүзнең саксызы, саклысы,
хаклының һәркайда пакь йөзе,
Тарихта кем халык, кем тиран...
Алтынга сатылмый ихтирам...

Чын бәллүр чынбарлык — һәр яһәт,
Янәшә бик тә үз бер аһәң, —
бөдрәләр зәңгәр — төтеннән.
Әллә мин гашыйк бу төндә?

Сүзләрдә чакматаш очкыны.
Кулымда иркә-наз уч тулы...
Мин аны чәчмәдем, түкмәдем,
күкрәккә кысып йокладым...

Чатнады җандагы бозлавык,
уятып, сызлатып, кузгалды...

Сыкылы тынлык,
хуш инде!
Чатнама суык кыш иде...

●

Сулар ага, күлләр күккә бага,
кояш карый дөнья күзеннән.
Яз килсә дә җиргә, боз яуса да —
күкрәп уза кеше күңленнән.

Карурманнар ава, юллар чаба,
шәһәр калка таулар ташыннан.
Таш ярса да заман, төш ярса да —
ярчыклары — адәм башында.

Йөрәгендә кайнап ал таң ата,
кояш бата шул ук төбәктә, —
бәндә ничек гел фәрештә булсын,
оҗмах, тәмуг — бер үк йөрәктә.

●

Бер юлыңны илдә яңгыратырга
еллар буе йөрим тәкатьсез, —
шигърият, мин сиңа хыянәтсез,
ә кемгәдер шундый шәфкатьсез.

Бер сүзеңне таңда сайратырга,
читлекләрне ватып, җимереп,
күңелемнең изге минутларын
кош теленә салам җим итеп.

Гөнаһлары төннең кунмый аңа,
таң аттыра былбыл тирәктә.
Ай былбылым, җаным, янып бетәм,
тирәгеңә көлем кирәксә.

●

Син әле яшь тал сыман зифа, сылу,
Белмисең, ни әле ул сыну, сулу.
Яшьлегең — сызылып киткән язгы яшен.
Күңелең — җәйге урман — шаулы, яшел.

Чәчләрең кара төтен кебек бөдрә,
һәр бөдрә балдагында — тыелган дәрт,
кагылырга кем кулы итәр җөрьәт? —
сикереп төшәргә тора көнче кодрәт.

Син әле яшь тай сыман гамьсез, чибәр,
Ә тормыш шундый чуар, шундый чуар...
Дөньяга өстәлмәсен бер җилкуар,
гөлләрдән дә җан-күбәләк бер туяр...

Күзләрең асыл ташлы чишмәдәй саф,
затлыга һәвәсләргә — ирек форсат;
күбәер һәвәскәрләр, кибәр ярың, —
мин сакчы булып күңелеңдә калыйм.

## Фәния Чанышева

### Бер төенчек идең...

— Әни, — дисең, — нәни чакта
Мин соң ничек идем?
— Күкрәгемә кысып тоткан
Бер төенчек идең.

Кайгы-хәсрәтләрең белән
Сыя идең шунда.
Минем белән идең гелән:
Өйдә, тышта, юлда...

Үсә төшкәч, шакмаклардан
Өйләр өя идең.
Үткер-тапкыр сүзләр әйтеп,
Кинәндерә идең.

Баш очымда тоймый идем
Каралыгын көннең,
Көннәремне ак челтәрдәй
Хыялларга төрдең.

Күкрәгемә кысып тоткан
Төргәк сыман идең:
Кайгы-хәсрәтләрең белән
Шуңа сыйган идең.

Гел яз иде, гел наз иде
Ул чак йөрәгемдә,
Авырлыгың булган икән
Беләгемдә генә,
беләгемдә генә...

## Нур Хәмиди

# ФӘҮЗИЯ КИЯҮГӘ ЧЫГА

хикәя



Минем Салават ни хәлләрдәрәк соң, Фәүзия Исламовна? Бик азынмыймы? Иптәшләре белән ызгышмыймы? — дип сорады улын алырга килгән ана.

— Моны Салаватның үзеннән сорарга кирәк, — диде тәрбияче.

Шомырт кара күзле, түгәрәк йөзле, бөтерчектәй хәрәкәтчән малай сүз эзләп тә куршегә кере торганнардан түгел иде, тәтелдәргә җай чыкканга сөенеп:

— Хәзер бер дә шаярмыйм, әйе бит, Фәүзия апа? — диде. — Иптәшләрем белән дә ызгышмыйм. Әйе бит, Фәүзия апа?..

— Әйе, Салават, яхшы малай син. Рәсемнәрне матур ясыйсың. Җыр күп беләсең...

Сабыйның түбәсе күккә тиде. Авызы ерылды. Әнә бит, әниләр, әбиләр алдында аны тәрбияче апасы мактап тора!

Бераздан балалар бакчасы тынып калды. Тәрбиячеләр дә, саубуллашып, кайтырга кузгалдылар. Гадәттә «Иртәгәгә кадәр!» дип кенә аерылышалар иде, бүген Фәүзия белән алар бөтен шартын китереп саубуллаштылар. Чөнки Фәүзия чираттагы ялына чыга.

— Әйбәт ял итегез инде, Фәүзия Исламовна!

— Берәр җиргә сәфәргә җыенасызмы? — дип сораштылар коллегалары.

Фәүзия, гадәтенчә елмаеп, сабыр гына җавап кайтарды.

— Сәфәр дип, кая барыйм? Ял өчен безнең яклардан да кулай җирне каян табасың? Өйдә булам. Кунакка килеп чыгыгыз...

Кайткач, хезмәттәшләренә әйткән сүзләрен тагын бер кат фикер бизмәненә салып карады. «Безнең яклар...» диде ич. Кара диңгез буен, Абхазияне әйтте, болай дирое белән район үзәге булган Гагра шәһәрен күз алдында тотуы иде. Югыйсә, монда туып-үскән кеше түгел ул Фәүзия. Казан кешесе. Язмыш аны монда китереп чыгарды. Инде менә сигезенче елын шунда яши, шунда эшли. Табигатенә килеп урнашкан тәүге көннән гашыйк булды. Яшел манарадай чайкалып утырган сылу кипарислар, без дөньяга җәелеп яшәргә килдек дигәндәй үсүче купшы

пальмалар, күгелҗем томан эчендә утырган таулар, исләре белән исертә торган чәчәкләр, көннең нинди булуына карап әллә ничә төрле төскә керә торган диңгез киңлеге аның күңелен яулап алды. Дөрес, Идел буе тугайлары, Ослан таулары, алтын комлы Казан пляжлары да хәтереннән тиз генә чыкмады аның. Монда, диңгез буенда, беренче елын яшәгәндә, төшләрендә ул гел генә Татарстанны күрә иде. Әле Аккош күле, әле Казанка буйлары. Болак буендагы үзе укыган институт керә торды аның төшләренә. Вакыт — дәва, диләр. Акрынлап кешеләренә дә күнекте Фәүзия, аралашып яши башлады. Тик монда килеп ел тулар-тулмаста ук күңеле кителде аның. Күрәсең, гомерлеккә кителүе булгандыр. Ул менә инде ни гомердән бирле китек күңел белән яши. Яратып кияүгә чыккан кешесе белән юллары аерылды аларның.

«Гаеп кемдә?» — дип сорау куелса, белмим, Фәүзия кырт кисеп кенә җавап бирә алыр идеме икән? Атта да, тәртәдә дә булгандыр, күрәсең. Кияүгә аны берәү дә көчләп, димләп бирмәде. Гамил аңа байтактан таныш һәм белеш иде. Тугызынчы-унынчы класста укыган елларыннан бирле. Тел-теш тидерердәй егет түгел дип белә килде аны Фәүзия. Дөрес, менә хәзер дә, еллар үткәч тә, хәтердән китми торган кайбер гадәтләренә бераз сәерсенә иде ул аның. Тик яшьлектә анлык кына чатаклап алулар буладыр, дип тә уйлый иде кыз.

Унынчыны бетерәсе елның язында, аттестатка имтихан тапшыра башларга бер ай чамасы вакыт калгач, Фәүзия әнисеннән — шәһәрнең мактаулы педагогларыннан берсе Зөләйха ханым Мөхәммәтьяровадан — акча сораган иде.

— Әнием, миңа өч сум акча кирәк,— дигән иде Фәүзия гадәтенчә гозерләнеп.

— Менә, рәхим ит. Нәрсәгә кирәге чыкты соң, кызым? — Педагоглык канына сеңгән Зөләйха апа, сумнар түгел, тиеннәр бирсә дә, нигә икәнен сорамый калмый иде.

— Иделдә боз киткәнен карарга барган көнне Гамил безне фотога төшергән иде. Шуның өчен түлисем бар. Фотолары бик әйбәт чыккан. Менә... — диде Фәүзия.

Зөләйха апа, сурәтләрне карагач, кызының фикере белән дә килеште, тик күңелендә ризасызлык туды.

— Ай, кызым, иптәшләрең, дусларың кесәсеннән суырып акча эшләргә калгач, актык эш инде ул. Бүләк итеп кенә бирсә начар булыр идемени? — диде күпне күргән педагог. — Аның бу эшендә син бернинди дә начарлык күрмисеңме?

— Юк, әнием, күрмим. Әтисе инвалид, әнисенең хезмәт хакы күпме генәдер. Мәсрура апа гади тегүче генә бит...

— Менә монысын дөрес әйтмәдең, кызым. Тормышның ачысын-төчесен күргән гаиләдә, киресенчә, комсызлык кимрәк була. Ә Гамил мондый фокусларын бер генә ясап карамагандыр. Хәзер аның тешен акча кыздыра. Шулай булмаса, дусларын каезларга алгысып тормас иде...

— Шулай да әллә ни зур гаеп ташламыйк әле, әнием, Гамил өстенә. Карточкаларны ясар өчен кәгазе дә, пленкасы, химикатлары да кирәк ич. Аларны аңа елмайган өчен бирмиләр лә...

— Барыбер әйбәт итми Гамил. Нәфсенә булыша.

Шушы әңгәмәдән соң, Фәүзия Гамил исемен сирәгрәк телгә алучан булып китте. Һәрхәлдә, моңа кадәр булганча итеп, ул егет турында әнисенә чишелеп сөйләмәскә әйләнде.

Өлгергәнлек аттестаты алгач, Фәүзия классташ кызы Сөмбелә белән бергә педагогия институтына укырга керде, ә Гамил хәрби училищега китте. Медаль алмаса да, егетнең аттестатында бер генә «өчле» дә юк иде. Дәрт итсә, теләсә, аның югары уку йортына һичбер артык авыр-

лыксыз керәсенә бирәү дә шикләнмәде. Әмма Гамил хәрбиләр юлын сайлады. «Кемдер ил сагында торырга тиештер бит», — диде ул.

Училище тәмамлап, лейтенант булып чыккач, аны Грузиягә эшкә җибәрделәр. Шулай ул кечерәк бер шәһәрдә хезмәт итә башлады.

Фәүзия дәүләт имтиханының соңгысын тапшырган көннәрдә лейтенант егет чираттагы ялга кайтты. Сагынып, сабырсызланып, түземе текәнеп кайтканга охшый иде. Беренче очрашуында ук Фәүзиягә күңелен ачып, бөтен серен, ниятен, планнарын сөйләп ташлады.

— Сине алырга, өйләнергә кайттым, — диде.

Турысын әйткәндә, Фәүзия өчен көтелмәгәнрәк хәбәр булмады бу. Институт тәмам. Кулында рус теле һәм әдәбияты укытучысының дипломы. Югары белемле педагог. Иртәме, соңмы, парлы тормыш корырга, үз ояңны үрергә кирәк. Яратуның югары ноктасы семья кору булырга тиеш ич инде.

Гамилнең тәкъдимен Фәүзия иртәгесен үк әнисенә әйтте. Баласының бәхетле булуын кайсы ана теләми! Бәхетле дигәне олы эш эшләп яшәү, үзенне кешеләргә кирәкле итеп тою, илгә-көнгә зурмы, кечкенәме файда китерү. Зөләйха апа бераз икеләнде, шулай да ризалык бирде кызына.

Гамилнең әти-әнисе улларының Фәүзиягә өйләнүенә дүрт куллап риза иделәр. Шәһәрнең бер районында, бер урамында бергә яши торган абруйлы укытучы кызы, яман аты-гайбәте чыккан бала түгел, күз өстендә каш диярлек бит Фәүзия!

Җир җимертеп булмаса да, тел-теш тидермәслек матур итеп туй уздырдылар, аннары Гамилнең хезмәт урынына китәргә җыендылар. Фәүзиянең бар шикләнгәне яңа җирдә белгечлеге буенча эш табу мәсьәләсе иде. Ләкин, Гамил әйткәндәй, диңгез җиле аңа уңай исте. Эшче яшьләрнең кичке дип тә, сменалы дип тә йөртелә торган мәктәбендә рус теле укытучысы кирәк икән. Сәгатьләре күп түгел иде, әмма яшь педагогка һәм яшь киленгә шуннан артыгы кирәкми дә иде. Бердән, аның тәҗрибә туплыйсы бар, икенчедән, тынгысыз хәрби хезмәттәге ирен тәрбия итәсе бар иде.

Парлы тормыш үз эзенә төшеп, җай гына акканда, Гамил үзен Германия Демократик Республикасындагы Совет гаскәрләре группасына күчерүләрен әйтте. Мондый хәлнең буласын ул отпускага кайтканчы ук белгән булган, тик төрле уйларга салмас өчен, Фәүзиягә әйтмәгән икән. Тик әйтми уза торган эш түгел бит, бер көнне сүз шул хакта купты.

Чәй янында шул хәбәрне ишеткәч, Фәүзиябез коелып инде, авызына капкан ризыгын чәйнәп йота алмый торды. Зур зәңгәр күзләрен яшь пәрдәсе каплады. Аны ирен кайдадыр күчерү факты үзе түгел, бәлки Гамилнең «Мин моны байтактан белә идем, ләкин син кәҗәләнә башларсың дип әйтми тордым» дип, үз хәйләсенә куанып сөйләве аптыраштa калдырды.

— Шулай аяусыз шаярырга ярыймы соң, Гамил?! Бу бит күршеләргә кунакка кереп чыгу түгел. Минем эшем бар. Әнкәйнең саулыгы чамалы. Бер көн исән, өч көн сырхау. Шушыларның барсы белән дә хисаплашмый булдыра алмыйм ич мин. Син мине аңларга тиеш идең. Ирләрчә, офицерларча һәммәсен туп-туры, төп-төгәл һәм ап-ачык әйтергә тиеш идең,— дип, Фәүзия нык рәнҗеде. Ә Гамил иркәләп-назлап кына әйтә куйды.

— Барсын берьюлы сөйләп ташласам, миңа кияүгә чыкмаска дигән карар кабул итәрсең дип шикләндем, Фәүзия. «Мин сине көтәрмен, туган илгә әйләнеп кайткач өйләнешербез» — диярга дә күп алмас идең.

Сүз шунда өзелде. Иртәгесен эштән кайткач, әңгәмәне тагын Гамил яңартты.

— Я инде, Фәүзия, сабый бала булма. Сөйләшик, аңлашыйк. Кияүгә хәрби кешегә чыкканыңны белеп чыктың. Ә безнең тормыш күчеп йөрүләр белән дә, аерым торулар белән дә тулы ул. Ике-өч ел чик аръягында яшәп кайту педагог кеше өчен үзе бер яңа дөнья булачак...

— Аннан кайтканда минем педагоглыгымнан җилләр искән булачак инде, бик беләсең килсә,— диде Фәүзия. Еламаска тырышса да, күзләреннән тәгәрәшкән кайнар яшь тамчыларын тыя алмый иде инде ул.— Дипломым коры каты кәгазьгә әйләнеп калачак. Мин әти-әнием юлыннан китеп, гомеремне яраткан эшемә багышлармын дип хыялланган идем, ир саклап өйдә утырырмын дип башыма да китергәнем булмады... Сүнгән лампа булып яшисем килми минем.

Яшьлек дуамаллыгы, тормыш кытыршылыкларының иң бәләкәен дә Алып тау итеп күрү, сүзләрне уйламыйчарак, иң катгый төсендә әйтеп ташлау шулай була торгандыр инде. Ул көннәрдә алар бер-берсен каты рәнҗеттеләр. Әчегә төче чыкмый. Сүз куера торды, аш-суның тәме, кояшлы көннәрнең яме китте.

— Хәерле булсын, чәчләрнең чәчкә бәйләнүе шул чама гына булгандыр, мин Казанга кайтып китәм! — диде Фәүзия.— Әле соң түгел. Бер-беребезгә гомерлек йөк булганчы, икебезнең ике тарафка олагуы бәлки яхшырак та булыр... Белә идем, Гамил, үзең турында күбрәк уйлаганыңны, белә торып синең янәшәңнән атлап киттем.

Фәүзия хәлне телефоннан Казанга, әнисенә хәбәр итте.

Көтелмәгән бу хәбәрдән миңгерәп калган Зөләйха апа ике-өч көн эчендә болар янына килеп төште. Кызын да үгетләмәкче, кияве белән дә иплән киңәшмәкче иде. Яшь килен белән яшь кияүләрнең кайберләре буйдаклык рәхәтен җуйган беренче көннәрендә үзгәреп, аптырап киткәнне күргәне дә бар, ишеткәне дә бар Зөләйха апаның. Егет белән кыз чакта ни! Таң сызылганда гына аерылып киткән булсаң да, кич җитүен көтеп зарыгып бетәсең. Кабат очрашкач, инде мең дә беренче мәртәбәгә сөйләнсә дә, һәр икәвеңнең дә сүзе дөрес тә, матур да, күңелгә ятышлы да була. Бер-береңнән күз алмыйсың, бер-береңә һичкемгә алыштыргысыз чибәр һәм сөйкемле күренәсең. Нигә шулай дип аптырыйсы да юк: кыз егетенә, егет кызына тәмсез сүз әйтеп гайрәт чигермәгән, хәтер калдырмаган, үпкә тудырмаган...

Гомер дигәнең агымсу төсле, көннәр үтә тора, һәр тумыш иртә үзенең шөгылен, мәшәкатен, таләбен, уйланырга мәҗбүр иткән соравын кочаклап килә. Алай гына да түгел, шатлыгы янына хафасын, җан әрнүен, күз яшен төяп килә. Яши торгач, гомер буена бер-берсен назлап кына яшәрдәй кешеләрнең дә йөзенә кырыслык куна, көлү авазлары да кими, сүзне үлчәп сөйләргә кирәклеге аңлашыла, ә беравыктан тулган ай һәм чәчкәле болын, матур җыр һәм легендар мәхәббәт фәлсәфәсенә алмашка ипи дигән, бәрәңге һәм ит-сөт дип аталган прозаик әйберләр турындагы уйлар, йорт-җир, җиһаз, кием-салым, бала тәрбияләү, ата-анага, кече туганнарга булышу, ялгызлыкта сыкрау, сагыну һәм ямансулау авырлыклары дигән нәрсәләр хакында фикерләр килә. Ни хәл итмәк кирәк, яшәү — көрәш ул.

Самолет белән Адлерга очканда да, аэропорттан рейс автобусына утырып кызы һәм кияве яши торган район үзәгенә килгәндә дә Зөләйха апа шулай уйланды. Секунды-минуты белән үзгәреп, куерып, төрле төсләргә манылып барды аның уйлары. Шулай булса да, күңелсез, эчпошыргыч уйларны читкә куарга тырышты ул, кара буяуга манылганнарын бөтенләй якын да китермәскә теләде. Ә чынбарлык аңардан көлгәндәй булды.

Зөләйха апа кызы яши торган квартира ишеген ачканда, Гамилнең бүтән өйгә, ниндидер буйдак бер белешенә китеп яши башлавына атна була иде инде. Фәүзиядән һәммәсен кат-кат, бәйнә-бәйнә сөйләткәч, ни булса да булыр дип, ана киявен күрергә дигән карарга килде. Ләкин әби белән кияү арасында дипломатик сөйләшүләр барып чыкмады.

Гамилне квартирасында туры китерә алмагач, Зөләйха апа аңа язу язып калдырган иде. Язуында, мәгълүм инде, күрешеп сөйләшергә, аңлашырга теләвен әйткән иде. Гамил дә әбисенә ике-өч юл язу белән генә җавап бирде. Дөресрәге, мине янә сорап килүче булса, шушы язу кисәген тоттырырсыз дип, квартира хуҗасыннан үтенде.

«Очрашып тәмсезләнүне һич кирәкле тапмыйм. Фәүзия белән минем ара өзек. Аның сәбәпләре кояшлы көн кебек ачык. Кызыгыз аларны бик яхшы белә. Мин тиз арада бүтән кешегә өйләнәм, яңа урынга шул кеше белән китәчәкмен. Гамил»,— дип язылган кәгазьне кулына алып карагач, Зөләйха апаның күз аллары караңгыланып киткәндәй булды. Кулында гүя утлы күмер иде. Ул кәгазьне төшереп җибәрде һәм күтәреп ала алмыйча азапланды.

Язуны укып Фәүзия бик озак елады. Зөләйха апа аны юатмады, еласын, күңеле җиңеләер, дип уй йөртте. Ләкин кызының хәле алай ансат кына җиңеләерлек түгел иде. Ул Гамилне бөтенләйгә югалтуын бар тирәнлеге белән аңлады. Күпме гомер генә яшәп калды булып чыкты Фәүзия ир белән?! Ире исән-сау дөньяда яшәгәне хәлендә, тол иде инде ул. Тол хатын! Абау да шыксыз сүз! Ирсез хатынга караш ук бүтән бит. Ир-ат затының байтагы ире йөз чөергән хатыннарны, күп сөйләшеп тормастан, бер кап шырпы алгандай, кулда тотып карарга, яндырырга, аннан соң вөҗдан газабы кичерми генә, ыргытып калдырырга мөмкин дип исәплиләр.

— Юк! — дип, җан ачыргалануы белән кычкырган иде ул, елап арыгач. — Юк, мин берәүгә дә алай итәргә юл куймам...

Зөләйха апа берни дә аңламый аптырап торган иде шул минутта. «Акылына зыян киләме әллә бу баланың?» — дип коты алынган иде аның. Әмма Фәүзия әнисен утта көйдерергә ярамаганын, ничек кенә булмасын, аны тынычландырырга кирәген тиз абайлап алган иде. Үзүзен дә сабырлыка өндәп, күндергән иде.

Кыска гына итеп әйтсәң, Фәүзия тормышындагы бәгырьгә яра салган хәл — әнә шул. Ул инде хәзер үзен тыныч хис итә, үкенүнең мәгънәсезлеген белә. Әнисе үлеп киткәннән соң, үз эченә тагын да ныграк бикләнде. Шулай йомык килеш яши бирә... Күңеленә беркеткән уе бар: гаилә корып яшим дисә, кеше гаилә бәхетен һәр көн, һәр даим уяу сакларга, бер-берсенә булган хисләрен һәр тумыш көнне үстерә, дәрләтә барырга тиеш. Шунсыз күңелгә тормыш вак-төякләренең юшкыны утыра, тормыш юлдашының җанлы сурәте тоныклана бара. Ә бит кеше җиз самавар түгел, кирпеч комы белән ышкып ялтыратып, нурландырып булмый аны. Сабырлык ирләр өчен генә түгел, хатын-кызларга да бик-бик тансык, үтә зарур сыйфат икән!

Ирләрне кеше иткән, яңа ачышларга, хезмәт батырлыкларына, изге, олы адымнарга рухландырган кеше дә хатын-кыз, юлдан яздырган, хыялын йолкыш хәлгә төшергән, яшәүне ачы газапка әйләндергән җан иясе дә хатын-кыз. Борынгыларның «Чын хатын — җаның өчен хатын» дигәннәре рас бит ул, билләһи! Рас!

...Тәрәзәдән күреп торган икән, Фәүзияне күрше квартирада яшәүче Дуся каршылады.

— Сөенечгә нң бирәсең, Фая? — Дуся кулларын артка куйган иде.

— Бүгеннән ялда мин, Дусенька, отпускага чыктым. Юл уңаенда

магазинга кагыла кайттым. «Абхазия букеты» белән сыйлыйм үзеңне, әйт, нәрсә бар?

Дуся, канәгатьсезлек күрсәткәндәй кыланып, иренен турсайтты һәм бер читкә карап:

— Шәрабмени ул «Абхазия букеты»? — дигән булды. — Быел сигезенчене бетереп чыккан күбәләк кызчыклар сые ич ул! Исеме матур, җисеме такыр. Сыйлыйм дигәнең сыек нәрсә буласы булач, «кристалл» белән диген, я булмаса «столичный»ны әйт! Иртәгә минем дә ял көне лә... — Аннары түзмәде, көлеп җибәрде. — Карасана бу эчкече хатынны! — дип тиргәргә җыендың бугай, Фая, әйеме? Кирәкми, җаным, бер сыең да... Сыйның менә дигәне үземдә бар, күрше кайтсын дип кенә, сине көтеп, сабыр канатларымны сындырмый тордым... Мә!

Күрше хатыны, Фәүзия шикелле үк ялгызак тол хатын Дуся, башта заказной хат, аннары телеграмма сузды.

— Казаннан! Сашадан! Кире адресы да бар. Салих Габбасов дигән. Ә телеграммасын келәйләп китергәннәр, ачмадым...

Телеграмма дигәне Фәүзияне сискәндерә язып калды. Укыгач кына аның йөзенә елмаю чыкты.

— Сашалар килә, Дусенька! Малаен алып килә, хатынының әнисен дә алып килә. Иртәгә көндезге бердә Адлерда булабыз, дигән. Төш авышуга кайтып җитәрләр...

— Акыллы кеше кебек ләбаса ул Саша-Салих! Кара дингез буена әбисен сөйрәп йөрмәсә. Малае ярый инде! — дип ычкындырды.— Хатыны үлгәнгә ике ел димәсәң, контроль карчык өстерәп йөри...

— Алай димә, Дуся. Сөмбеләсенең истәлегенә бик туры ул Салих. Шуңа күрә улын да бик ярата, хатынының әнкәсен дә үз күрә.— Фәүзия моны бик җитди итеп әйтте һәм Дусяга кырыс караш ташлады.

Фәүзия квартира ишеген ачты һәм конверт читен ерта-ерта бусагадан атлады. Дуся аңа ияреп керде. Каршы күршеләр мондый хәлгә күптән күнегеп беткәннәр инде, ике арадагы коридор идәненә тузан төшермиләр, берсе янына икенчесе керә-чыга йөриләр.

Фәүзия хат укырга утырды. Салих хәрефләрне энҗе тезгәндәй итеп яза, укуы җиңел генә түгел, үзенә бер төрле күңелле дә була ул язганны.

«Якташ Фәүзия!

Идел ярыннан, Казан каласыннан күп сәлам Сезләргә! Исәнлек, бәхет, уңыш телим.

Башка таш булып төшкән хәлләрдән соң, ялга бару хакында беренче тапкыр авыз ачуым. Былтыр бу мәсьәләдә уема ялгышып кына да китермәгән идем. Әгәр, теге елгы кебек, Сөмбелә исән чактагыча дигәнем, Сез безне кабул итә алсагыз, тормыш җаегыз үзгәреп китмәгән булса, мөмкинлек тапсагыз диюем, без быел да Сездә тукталыр идек.

Мансур инде бишенче яше белән бара, бакчага йөри. Аңа да диңгез күрсәтим дим. Теге елны бит ул бер нәрсә дә хәтерләмәслек сабый гына иде. Шунсын да әйтим, әнине (Сөмбеләнең әнисен), Сезгә бик яхшы таныш Гөлҗамал апагызны да алып барырга булдым.

Бару кадәресе төгәл хәл кылынган. Шунлыктан Сездән җавап көтеп тормыйча ук кузгалабыз. Өстәмә рәвештә телеграмма бирермен. Әгәр Сездә тукталу андый-мондый сәбәп аркасында мөмкин булмый икән (дөнья хәлен белеп булмый!), икенче бер адрес та ала барабыз.

Һәрхәлдә, күрешербез дип уйлыйм.

Сәлам һәм ихтирам белән, алдан үтенеп куючы Салих».

— Хатында да шул ук хәбәр, — диде Фәүзия, үз уйларына бирелеп тын калган Дусяга. — Димәк, иртәгә кунаклар каршылыйбыз, күрше-

кәем. Ярый, бик әйбәт! Изге тамырым сизенгәндәй, отпускам да каян туры килде!

— Изге тамыр сизүдән ни мәгънә! — диде Дуся, уенын-чынын бергә кушып. — Конвой белән килә икән бит, конвой белән... Теге елны ук колагымнан чумып гашыйк булган идем шул чибәр чукынчыкка! Хатыныннан салкын су сибеп тә аерып булмаслык иде. Инде тол килеш үзен-үзе зинданга яба, җүләр!

Фәүзия Дусяга томырылып карады, тик ачуланмады. Беркатлы бәндә бит ул Дуся! Эчендәге тышында. Тамырларында каны кайный, яшерә алмый...

— Нигә шулай кадалып карыйсың, Фая?

— Болай гына.

— Беләм мин болай гына түгелен, беләм. Хәйләләп маташма. Менә бит исәр хатын, дисең син, ирләргә зарыкканын яшереп тә тормый димәкче буласың. Синнән ник яшерим, я әйт, ник? Иремне командировкага озатып, ике-өч көнгә генә япа-ялгызым калган кешеме мин? Ирем юк, көнләшер кешем юк. Итәгемә ябышкан балам юк. Әгәр шул Сашаны үземә тарта алсам, начар булыр идеме? Бөтенләйгә дип хыялланмыйм. Анысы — тузга язмаган эш... Ял иткән чорына гына дим. Заяга үткән айларның, җилгә очкан елларның әҗере булыр иде, ичмаса... Сал әле, ичмасам, шул «Абхаз букеты»н бераз! Тол хатынның дөрләп янган йөрәге басылмасмы?! — Аннары Дуся дуамаллыгыннан үзе рәхәтләнеп көлде.

— Хәзер өстәл әзерлим, Дусенька. Сабыр ит,— диде Фәүзия.

Күрешкәндә күңел хуш, диләр. Ай-һай, гел шулай булыр микән? Улы, хатынының әнисе белән Салих килеп төшкәч тә, күңелле минутлар күп булмады. Гөлҗамал апа Фәүзия белән килеп күрешүгә балавыз сыгарга кереште. Аны ничегрәк юатырга, ни әмәлләр табып тынычландырырга белмәделәр.

— Сөмбеләм ял иткән җирләрне күреп китим дип килдем, Фәүзия кызым. Бер генә дә онытылмый балакаем. Шул тикле дә иртә гүр иясе булды шул! Менә бит ул йөрәк дигәнең. Берәүдән дә сорап тормый. Туктый да куя икән. Мин әле дә булса йөрим, аның кара җир астына керүенә инде ике ел була...

— Алай үз гомереңне үзең күпсенмә инде син, Гөлҗамал апа. Кеше гомере кешегә түгел, ни хәл итмәк кирәк... — Шуннан гайре Фәүзия юатыр сүз таба алмады. Белә ич инде ул ана йөрәгенең ни тикле өзгәләнгәнен.

Шулай да Кавказ табигате, җәйге айлардагы рәхәтлек Гөлҗамал апаны да үзенә суырып алды булса кирәк, беренче көнге булган сөмсер коелуын ул бүтән күрсәтмәде. Яр буендагы ярым шәрә бихисап халык арасына атлыгып йөрмәсә дә, Фәүзия белән, Дуся белән аулаграк урынга китеп, рәхәтләнеп су керүчән булып китте, диңгез суының тәнгә сихәтләре турында өзми-куймый сөйли башлады. Килүләренә атна-ун көн узгач шикелле, шәһәр экскурсия бюросы оештырган сәяхәткә чыгып, Рица күленә барып кайттылар. Тау юлларының кабатланмас матурлыгын, елгаларының шаулап агуын, тау битләренә үскән урманнарының гүзәллеген мактап туя алмады Гөлҗамал апа. Кыскасы, ял аның күңеленә ята иде.

Салихка килгәндә, ул Мансур арып-талып китмәслек дәрәҗәдә гел генә диңгез буенда булды. Үзе дә рәхәтләнеп су коенды һәм кызынды, улын да йөзәргә өйрәтте. Өлкәннәр Мансурдан:

— Гел менә чуен китеге булдың бит син! — дип көлә башладылар.

Ялда гына түгел, эштә дә шулай: тормыш бер үзәннән ага башладымы, көн үткәне сизелми дә.

Бу йортта да шундый бер хәл булды.

Иртәнге чәйне эчкәч, Салих белән Мансур, гадәттәгечә, диңгез буена киттеләр. Коенырга-кызынырга дип кенә дә түгел, теплоходта Пицундага барып кайтырга, андагы курортларны, атаклы наратлыкны карап кайтмак булдылар. Гөлҗамал апа исә диңгездә имин-аман баруына шикләнде һәм бу сәфәрдән баш тартты. Хикмәт дулкын тирбәтүеннән күңел болганыр дип шүрләүдә түгел иде, әлбәттә.

Аулакта калып, диңгез җиле җиләслегендә утырганда, Гөлҗамал апа сүз башлады.

— Иреңнең кайдалыгын, ни хәлләрдә икәнен беләсеңме, Фәүзия кызым? — диде ул, сак кына, тавышына җан җылысы өстәп кенә.

— Ишетә беләм, Гөлҗамал апа. Майор инде ул хәзер. Әле быел гына биргәннәр майорлыкны. Уралда хезмәт итә. Ике балалары бар. Аның хатыны шушы шәһәрнеке бит, абхаз кызы. Бик әйбәт торалар дип сөйлиләр...

— Гамилнең сиңа хат язганы юктыр бит?

— Юк, Гөлҗамал апа, юк. Мондый акылсызлыкның нигә кирәге бар, гомумән? Кискән икмәкнең кире ябышмаганын белә торган кеше ул. Ваклана торган гадәте дә юк.

— Үзең ничегрәк яшәргә исәплисең, кызым? Гел ялгызың гына тормассыңдыр бит инде? Сугыш чагы түгел, үз ишең табылыр иде...

— Бер дә өзеп кенә уйлаганым юк шул, Гөлҗамал апа. Бер авызың пешкәч, өреп кабасың дилэр бит... Кичке мәктәптә укытканда, хатын аерган берәү сүз кузгаткан иде дә, беренче авыз ачуыннан ук кырт кистем. Уку елы беткәнче чак түздем. Җәен балалар бакчасына күчтем эшкә дә. Шуннан ул да тынып калды...

— Алай, алай... — Гөлҗамал апа шактый вакыт сүзсез утырды. Аннары гына: — Сиңа бик олы бер киңәшем бар бит әле минем, Фәүзия кызым. Зур сүзем бар,— диде.— Син зинһар үпкәләмә, аптырап та калма. Үземнең кара акылым җиткәнчә, хәл-хәленчә дигәндәй, аз уйланмадым инде мин. Кулымнан килгән микъдарда аркылыга да, буйга да үлчәп карадым. Тиктомалдан тот томыр дигән сүз түгел... — Ул туктап калды. Дулкынлана идеме, кыенсынамы, кирәк сүзе теленә килмиме. Ләкин күзгә-күз карашып, тел тешләп утырыр хәл дә юк бит инде!

— Салихның, кияүне әйтәм, сиңа ул-бу сүз әйткәне булмадымы? — дип сорады ул, ниһаять.

Фәүзияне яшен бәрдемени! Ул агарып китте. Тыны кысылды. Тез буыннарын калтырау алды.

— Юк, Гөлҗамал апа, кешедән читтә сыңар сүз әйткәне дә юк. Әллә берәр шигегез бармы? Ачык итеп сөйләгез,— диде. Тавышына да ниндидер калтырау төшкән иде.

Гөлҗамал апа аны тынычландырырга ашыкты.

— Аңлап бетермәдең син мине, Фәүзия кызым. Дөресрәге, мин аңлатып сөйли алмыймдыр. Начар уйның башыма да килгәне юк. Салихны мин биш бармагым кебек беләм. Дөнья бәясе кеше ул. Миңа карашын да күреп торасың булыр. Улына мәхәббәтен әйтмим дә... Турысын гына әйткәндә, кияүнең дә, үземнең дә бар яшәгәнебез шул сабый дип, Мансур дип... Бигрәк Сөмбелә балама охшаган бит... Менә шул баланың бәхете булсын дип, заманча тәрбиясе булсын дип, Салихның да тормышы сыңар канат булып заяга узмасын дип, синең белән сөйләшмәкче идем мин...

Инде, Гөлҗамал апаның тел төбен аңлап алгач, Фәүзия уңайсызлануы хисенең икенче төрлесен кичерде. Кызарды, тирләп чыкты. Нидер әйтергә дип авыз ачкан иде, Гөлҗамал апа алданрак өлгерде.

— Тагын аптырашта калдың, ахры.— диде ул.— Шундый-шундый карарга килерлек дәрәҗәдә уртак тел тапкан булгач, нигә бу турыда Салих үзе сүз кушмаган, дип сәерсенәсең инде син... Сәерсенмә, Фәүзия кызым, минем белән дә бәйле булгач, эндәшми йөрде ул. Мин үзем сүз катып карармын, дип ышандырдым аны... Авыз ачарга курка торган булдыксыз бәндә түгел ул. Кулыннан эш килә торган, абруйлы кеше. Бик гадел, кешелекле... Әгәр син менә күңелең бүтәннәрдән азат булып, безнең якка ризалык бирердәй булсаң, ул сине рәнҗетмәс дип беләм... Миңа да кызым төсле кеше инде син. Бала чагыңнан беләм. Без уйладык, син менә ныгытып исәпләп кара әле, Фәүзия балам...

Ишек шакыдылар. Дуся икән. Коридордан ук сөйләнә-сөйләнә керде.

— Кунакларың кайларда, Фая?

Фәүзия аның нәкъ менә шушы минутта бәреп керүеннән үтә канәгатьсез булса да, сер сынатмаска теләп, аңа каршы чыкты.

— Кунакларның иң олысы менә түрдә утыра, күрше. Уртанчысы белән кечесе кайтып җитмәгәннәр әле. Диңгезгә прогулкага киткәннәр иде, — дип җавап кайтарды.

— Минем бүген туган көнем бит, күршеләр. Картаеп бару юлында бер станса — егерме өч яшь тулды! Кичен миңа чәй эчәргә рәхим итегез! — диде Дуся.

— Рәхмәт, күрше. Котлыйбыз.

— Киләчәк көннәреңне бәхет-тәүфыйк белән яшәргә насыйп булсын, — диде Гөлҗамал апа. — Егерме өчтә картая башласаң, Дуся балам, җитмеш өчтә нишләрсең икән?

Гөлҗамал апа да, Фәүзия дә күрше хатын белән җай саклап, күңел күреп кенә сөйләшәләр иде. Телләрендә Дусяга әйтәсе сүзләр, ә күңелләрендә бөтен эчке дөньяларын айкаган уйлар, фикерләр иде.

## Гамил Афзал

### Салават батыр

Хәлләреңне шималь яктан килгән
Үзәк өзгеч җилләр сөйләсен.
Биек тауда,
Акбүз атка менгән
Илче булып төшкә керәсең...

Шәфәкъ яна,
Офык кан төсендә.
Козгын оча мәет сагалап.
Текә ярда,
Ярсу ат өстендә
Кулын изәп тора Салават.
— Әйдәгез, — ди, — данлы юллар ярып,
Йөзгә бәреп, җилләр, исегез!
Язмыш язганына каршы барып,
Ир-егетләр, Идел кичегез!
Мәрмәр сарайларда ришвәт көтеп,
Зина кылган исерек түрәләр
Халыкларны хаксыз коллар итеп,
Батырларга элмәк үрәләр.
Үлгәннәргә генә дөнья тыныч,
Үзе хуҗа соңгы йортына.
Кыюларга бирәм алмаз кылыч,
Куркакларның — камчы сыртына!
Елан кебек шуышып килә дошман,
Төрле яктан аны әйләгез!
Пугач патша безгә шулай кушкан:
Түрәләрне тотып бәйләгез!
Әйдәгез!

Ай карап йөргән алан бу,
Җил тарап йөргән алан.
Гөл-чәчәкләрен таптатып,
Михельсон килгән заман.

Башкортлар атка менгәннәр,
Дөньяны ялкын алган,
Яланны иңләп килгәннәр,
Салават килгән алдан.
Үләннәр иелеп калганнар,
Чыклары түгелеп калган.
Исәннәр алга барганнар,
Үлгәннәр үлеп калган.
Тояклар дөп-дөп килгәндә,
Йөрәкләр дөп-дөп типкән.
Утлы-төтенле җилләрдә
Алышлар авыр икән.
Ярсып йөрәкләр янганнар,
Тимер беләкләр талган.
Батырлар җиргә ауганнар,
Каннары илгә тамган.
Аланнар уелып калганнар,
Сөңгеләр сыгылып калган.
Козгыннар җыелып калганнар,
Кызарып шәфәкъ янган.
Ай карап йөргән алан бу,
Җил тарап йөргән алан.
Кылычтан алган ярадан
Егылып калган балаң...

Азаматлар яу кырында үлгән,
Башын түбән игән исәннәр.
Ил намусын, ир намусын белгән
Чәчәннәрнең телен кискәннәр.

Урал тугайлары үзән-үзән,
Үзәннәрдән ага Юризән.
Киң сулышлар чыга ялкын булып
Янып кына көеп йөрүдән.
Урал кыялары киртләч-киртләч,
Карлыгачлар кайта яз җиткәч,
Киткән кошлар кайта язлар җиткәч,
Каторжаннар кайтмый бер киткәч.
Утлы кылыч кебек нәҗәгайлар
Басу түрләрендә йөргәндә,
Ятим картлар кебек карагайлар
Шомлы гөжли кара төннәрдә.
Тол киленнәр кебек ак каеннар
Яшел чуклы яулык болгыйлар.
Караучысыз калган чал аналар
Чал чәчләрен йолкып елыйлар.

Таулар түбәсенә ай төшә,
Салаватның кылычы кебек.
Яшел сахраларда җил исә,
Салаватның сулышы кебек.
Җәяләр тарттың да ук аттың,
Сызгырып очты угың.
Бахырым-баламны югалттым,
Кайда син, кадерле улым?

Шаулама син үкереп, кара урман,
Күзгә төннең салкын җилендә;
Салаватлар сугышып узган юлдан
Моңлы җырлар кайта иленә.
Шаулама син үкереп, кара урман,
Кәккүкләр кычкырган таңнарда;
Башкортларның яклаучысы булган
Арслан егетләр кайларда?
Шаулама син үкереп, кара урман,
Шом таратып Урал кичендә;
Үзәннәрдә йөзгән күксел томан
Гаскәр булып керә төшемә...

Карт имәннәр утыра колач-колач,
Карт тирәкләр белән янәшә.
Башын игән халык өнсез булгач,
Урман белән урман сөйләшә.
Шаула инде үкереп, кара урман,
Син шаула, ичмаса!
Килмешәккә тәслим булып торган
Йөрәкне моң баса.

Балтик дулкыннары кургаш-кургаш,
Ишкәкләре авыр беләккә.
Аяк-кулда тимер богау булгач,
Кургаш кебек уйлар йөрәктә.
Алыслардан ачык күрә икән
Каравыллар безнең көймәне.
Алтын сараенда сөенә микән
Ак патшаның кара йөрәге!

Өзәңгегә басып, кылыч алдым,
Каршы гына бардым яуларга.
Үзәннәрдә үкереп сөрән салдым,
Тавышым ла китте тауларга:
— А-а-а, а-а-а, а-а-а!..

Урал түбәсендә, әллә кайда,
Күк күкрәгән шомлы төннәрдә,
Дөлдөл атлар оча таудан-тауга
Ялларын ла чөеп җилләргә,
— Ә-ә-ә, ә-ә-ә, ә-ә-ә...

Карурманнар тын торуны белми,
Елгаларның очы күренми;
Батырларның каны җиргә сеңми,
Кыюларның рухы сүрелми.
Гүя
көчен кушып ил көченә,
Заман җилен бора Салават.
Текә ярда, чуен ат өстендә
Горур карап тора Салават.

# Бер көн

*Колхоз рәисе Әхәт Батталовка*

1

Ай сүрелә, таң тарала, көн ярала, ил яктыра.
Ил төзүче, гөл сибүче бәхетлеләр таңнан тора.
Әле кояш чыга гына, күңелле һәм тантаналы,
Халык битен юа гына, берни дә борчымый аны.
Әле күңел иләс-миләс, әле керми үзгәрешләр,
Һәр кешенең тел төбендә таң алдыннан күргән төшләр.
Бар күңелләр ап-ак әле, теләк изге бу чакларда,
Әле берни эшләнмәгән: саваплар да, гөнаһлар да.
Чәчәкләрдә кыз сафлыгы, бәллүр кебек чыклы иртә,
Мөлдерәтеп яфракларын тал-тирәкләр рәхмәт көтә.
Әле мәкер-ачу кушмый саф йөрәктән көләләсез,
Әле көннең сабый чагы, әле күңел күләгәсез.
Әле бер кыл өзелмәгән, әле бер кыл ялганмаган,
Әле сулар болганмаган, әле бер җан алданмаган.

2

Менә үтә, менә китә хуш күңелле ваемсызлык,
План тотып килеп җитә аяусыз дөньяви чынлык.
Көләч күзләр кырыслана, кырыс күзләр очкын чәчә,
Иркәләнү истә дә юк, коры сүзләр кискенләшә.
Ансы кирәк, монсы кирәк, телефоннан тона колак,
Бик ягымлы Гамилов та каш җыера тирән сулап.
Йөкләмәләр үтәлмәгән, анда доклад, монда доклад,
Өлгер әйдә, элдер әйдә, анда лап-лап, монда лап-лап!
Кыш уртасы салам бетсә, күршеләргә бурычка бар,
Пыр тузынып партком куа: китап укы, курыска бар!
Печән чери, яңгыр коя — бөтен юлны харап иткән,
Чукынгыры Шәрәфетдин эш өстендә шәраб эчкән.
Арыш җитә, бодай җитә — барысын да карап йөр син,
Бирәү килә, бирәү китә — барысына җавап бир син.
Ансы сорый, монсы сорый, аны тыңла, моны тыңла,
Штрафы, прокуроры — бары да исәптә монда.
Кичен кайтып егыласың, кыл өзәрлек хәлең калмый,
Безне гүпчем оныттың дип, халат кигән хатын шаулый.

3

Урамнарны уйландырып төшә эңгер, йөзә эңгер.
Шул минутта елый-елый туа кемдер, үлә кемдер.
Чәй янында уйланасың үз эчеңә бикләнеп бер:
Үз турыңда, эш турында ышанып бер, шикләнеп бер.
Рәхәт вакыт, серле вакыт — җәйге кичләр, айлы кичләр,
Песи булып эчне тырный пошыну һәм үкенечләр.
Печән җитми, сенаж җитми, мал азыгы сорасы бар,
Яңгыр коя, яңгыр коя, арыш җиткән, урасы бар!
Шул вакытта тышка карап, махра төреп бергә-бергә,
Булсын иде алла бабай өстәл сугып сөйләшергә!
Төшеңә дә бәхет булып салам керә, көлтә керә,
Балкып торган медаль түгел, шелтә керә, шелтә керә...

●

Давыллар кичеп, дәверләр буйлап
Үтелгән юллар чамасыз.
Әй, еллар, еллар, елларны болгап,
Чабасыз алга, чабасыз...

Көйде бәгырьләр, янды офыклар
Корычлар сынган дәвердә.
Ә без сынмадык, көләч оныклар,
Чәчәк салыгыз кабергә!

●

Дөнья шаулый, дөнья матур гөрли,
Каян килә микән ямьсезлек;
Җитәкләшеп ике тинтәк йөри:
Әдәпсезлек белән Гамьсезлек.

●

Бу дөньяга мин дә елап тудым,
Яшь аралаш көлдем үземнән,
Сатирик та үтә гомер юлын,
Йөреп үтә пычак йөзеннән.
Бу дөньяга мин дә елап тудым...

●

Исләр, төсләр шаен шәйләп үтәм,
Заманнарга нинди төс керми!
Кояш нуры гына уңмый икән,
Кояш нуры гына искерми.

## Үзбәк Саттаров

# КЫЗЫМ ХИКӘЯЛӘРЕ

## Тормыш тәҗрибәсе

Балаларга беркөн керпе алып кайттым. Шатлануларының чиге булмады. Нәрсә генә кыландырмадылар аны! Песи дә, курчаклары да, башка уенчыклары да — барсы да онытылды. Керпе белән генә уйнадылар. Керпесе дә бит «аңлы» булып чыкты: янына өлкәннәр килү белән туп кебек йомарлана, ә балалар белән генә калса, бернигә исе китми йөри бирә.

Гөлнара бәләкәй әле, тәпи йөрсә дә, сөйләшә белми. Керпене ул да ошатты, ләкин беренче көнне янына килергә шикләнде. Икенче көнне, карап торам, ул да батырайды: акрын гына килде дә керпенең янына ук чүгәләп утырды. Кулын бер суза, бер ала — мәчене сыпырган кебек керпенең аркасын сыпырырга уйлый. Менә ул керпене сыртыннан сыпырып та җибәрде, чәнечкеле энәләр баланың кулын чәнчеп тә алдылар. Гөлнара кулын тартып алды да сикереп торды һәм керпегә тибеп тә җибәрде. Янәсе, мә, кирәгеңне ал кулны чәнечкән өчен! Керпенең чәнечкеләре бу юлы аяк бармакларына кадалып ук керделәр. Шул хәлдән соң тавыш та, яшь тә күп булды. Әмма тормыш белән танышу тәҗрибәсе аннан зуррак иде.

## «Мин—этием кызы»

Гүзәлне туган көненнән үк «этисе кызы» дип сөябез. Мин үзем дә бала янына килгәндә:

— Этисенең кызы ни хәлдә? — дип киләм. Әнисе дә, әбисе дә сүзләрен:

— Этисенең кызы ни эшли анда? — дип башлыйлар иде.

Кызымның теле дә «эти» белән ачылды.

Сөйләшә башлагач Гүзәлдән:

— Син кем кызы? — дип сорасалар, — мин — эти кызы, — дип җавап бирә башлады.

Көннәрнең берендә безгә Хәерниса апа килде.

Гүзәл йөгереп барып апасын каршы алды.

Уйный башладылар. Хәерниса апа әллә ничек сүз арасында:

— Син — әниең кызы бит! — дип куйды.

Гүзәлгә бу ошамады, үпкәләп, Хәерниса апасы яныннан китеп үк барды:

— Ник мин әни кызы булыйм, мин — эти кызы ич! — диде дә елый да башлады.

## «Дөньяда иң кирәк нәрсә»...

Беркөн шулай балаларны каршы алырга бакчага бардым. Көн эссе булды, кичкырын булса да, шактый бөркү. Гадәтләре буенча чәңгелдәшеп, күргән-белгәннәрен, бакчада булган бүгенге яңалыкларны сөйләп кайталар.

Гөлнарасы кинәт сүзне икенчегә бора башлады:

— Мин беләм: дөньяда иң кирәк кеше — әти!

Болай башланган сүз, гадәттә, ни булса да сатып алуны сорап бетә: тик белмим әле шоколадмы, әллә мороженое алуны сорармы.

— Әтидән соң дөньяда иң кирәк нәрсә — мороженое!

Мәсьәлә ачыкланып бетте: урамны аркылы чыгабыз, чөнки мороженоены урамның теге ягында гына саталар.

— Әниең дөньяда иң кирәк кеше түгелмени? — дим Гөлнарага.

Ул үзен бераз гаепле сыман сизеп:

— Безне каршы алырга бакчага бүген әни килмәде, син килдең бит! — ди.

## Алма биргәч ни диярга?

Кызларымны ияртеп Хәйрулла абзыйларга кунакка килдек. Алма өлгергән чак иде. Хуҗа безне бакчада каршы алды:

— Килегез әле, бакчага керегез, быел алма менә ничек уңды,— дип, безгә, ботакларын көчкә күтәреп торган алмагачларын күрсәтә башлады. Үзе кып-кызыл ике зур алма өзеп кызларым янына килде:

— Ашагыз, кызлар, — диде ул, икесенә дә берәр алма сузып.

Кызлар ялындырып тормадылар, алманы алдылар да, рәхмәт тә әйтмичә, ашый да башладылар.

Әниләре кызларының әдәпсезлеген күрсәтәсе килмәде, ахры:

— Алма биргәч нәрсә дип әйтергә кирәк? — диде.

Балалар оялып, бераз дәшми тордылар. Бераздан соң Гөлнара:

— «Нигә берне генә бирдең?» диярга кирәк, — диде.

## «Әти, мин монда бит!»

Эштән кайтып керүемә кызым каршыма килде:

— Әти, әйдә уйныйбыз,— диде ул.

Мин риза булдым. Ләкин өсне дә салып өлгермәдем, ул инде:

— Әти, хәзер качышлы уйныйбыз. Мин качам, син мине эзлә! — дип, күрше бүлмәгә йөгереп кереп тә китте.

Эзләп, артыннан күрше бүлмәгә уздым. Ул шкаф артына качкан. Башы шкаф артында булса да, арты гәүдәсе күренеп тора.

— Кая икән минем кызым? Әллә әбиләренә китте инде? — дип сөйләнеп, мин аны эзләгән булып йөри башладым. Бала түзмәде:

— Әти, мин монда бит! — дип, елмаеп, шкаф артыннан килеп чыкты. Бераз уйнаганнан соң ул юрган астына качты, аннан чыкмады.

Бу юлы инде мин эзләп тапканчы ятты.

— Менә икән минем кызым, — дип, барып юрган аша аны тотуым булды, ул өстен ачып җибәрде дә:

— Әти, син мине ничек күрдең, юрган астында бик караңгы иде бит, — диде.

## «Әти, без дә үсәбезме?»

Җәйнең эссе көннәре. Күптән яңгыр яуганы юк инде. Бакчага су сибәргә килдек. Җылынгач кичкә каршы сибәрбез дип, әнисе белән мичкәләргә су ташыйбыз. Балалар да булыша.

— Яңгыр яусын иде, яшелчәләр күкрәп үсеп китәрләр иде, — диде әнисе.

Чыннан да бераздан соң яңгыр явып китте һәм артыннан ук елмаеп кояш чыкты. Һава шундый саф, көн шундый матур. Карлыган, чия куаклары чистарып, матураеп киткәннәр, яфрак очларында, карлыган тәлгәшләрендә, чия сабакларында җемелдәп яңгыр тамчылары асылынып тора.

Йөгерешеп яныма кызларым килде: икесе дә манма су булганнар, чәч очларыннан тамчы тамып тора. Йөзләре шат, үзләре көлешәләр.

— Нигә шулай чыландыгыз? — дип, бераз шелтәләргә теләгән идем үзләрен.

— Без яңгыр астында тордык. Безнең дә үсәсебез килә,— диделәр алар.

Ни эшлисең: дөрес сүзгә җавап юк.

## «Әйдә тизрәк авылга барыйк!»

Машинага утырып авылга барабыз. Әмма балалар табигатьнең сокланып туймаслык матурлыгын, кырларның киңлеген тыныч кына карамыйлар, бертуктаусыз сорау биреп баралар.

— Әти, авыл еракмы?

— Ерак, кызым, ерак әле,— димен, аларның йөз дә беренче соравына җавап итеп. Ләкин алар шунда ук йөз дә икенчесен әзерләп куялар:

— Ераклыкны каян беләләр соң аны?

— Километр баганасыннан.

— Нәрсә ул километр баганасы?

Моны сөйләп аңлатуга караганда, күрсәтүе җиңелрәк иде. Километр баганасы очрауга машинаны туктаттым.

— Менә ул — километр баганасы, — дим кызларга.

Гүзәле шунда ук кычкырып җибәрде:

— Мондый багана әбиләрнең дә өе каршында бар бит, — ди.

— Әйе, кызым, әбиләрнең өе каршында да бар ул километр баганасы.

— Ә баганага нәрсә язган? — ди Гөлнара.

— Әбиләрең өе янындагы баганадан монда кадәр ничә багана икәнен язган. Бара торган юлда ничә километр баганасы булса, юлның озынлыгы шул кадәр километр була, — дим.

Бик яхшы аңлаган кыяфәт керде кызыма. Бу турыда сорашулары шуның белән туктады.

Бу хәлдән соң берничә көн узгач, әбиләренә төштек. Балалар тышта уйный, без өйдә утырабыз. Бервакыт дәррәү икесе дә йөгерешеп өйгә керделәр:

— Әти, әйдә тизрәк авылга барыйк! — ди Гүзәле.

— Ник синә кинәттән авылга бару кирәк булды әле? — дим мин аңа.

— Якын чакта барып калыйк, әбиләр каршындагы километр баганасын аудардылар, — ди Гүзәл.

## «Шушы буламыни инде культурасыз абзый?»

Балаларны әдәпкә өйрәтәбез: исәнләшергә, саубуллашырга, тышта йөргән аяк киеме белән эчке бүлмәгә кереп китмәскә, өйдә баш киеме киеп утырмаска һәм башка шундый гадәтләргә.

Аларның күбесенә кызлар тиз төшенде, әмма өйдә баш киеме салуның кирәклеген тиз генә аңларга теләмәделәр.

— Өй эчендә баш киеме белән утырган кешеләр культурасыз булалар, — дидем бер көнне бик аптырагач,

— Ә культурасыз кеше нинди була ул? — диләр кызларым.

Бу сорауга:

— Культурасыз кешеләр өй эчендә баш киеме белән утыралар, — дип, төпчечүләрен туктатмакчы булдым.

Әмма озак та үтмәде, мондый ашыгуым йөз кызыллыгына әйләнде. Шул ук көнне кич безгә Хәйрулла абзый килде. Ашыгыч йомышын сөйли-сөйли, ул аягыннан итеген, башыннан эшләпәсен дә салмыйча түргә узып, урындыкка утырды. Без аның белән гәпләшеп утырганда арага Гөлнара килеп кысылды:

— Әти дим, әти! Шушы буламыни инде культурасыз абзый? — диде.

— ?..

— Башыннан эшләпәсен дә, аягыннан итеген дә салмаган, ә үзе түрдә утыра!

## «Фил бит синнән зур!»

Казанга килгәч, җыйнаулашып зоопаркка кердек. Шатлану, соклануга чик юк! Һәр җирдә кызык, һәр хайванны туйганчы карыйсы килә, ә карар әйбер күп. Гөлнараны иң кызыксындырганы фил булды, ә Гүзәлнең маймыллар янына барасы килде. Ул безне маймыллар янына әйдәде, ә Гөлнара:

— Әти, фил яныннан бер кая да китмибез әле, фил бик кызык! — диде, җиңемә асылынып.

Фил, кымшанмыйча, бер урында басып тик торды: күзен йомгалап ала да койрыгын гына селкетә, колакларын каккалый.

— Фил яныннан китми торабыз әле! — дидем дә, кызларымның икесен ике кулыма җитәкләп, филне карап тора башладым.

Озак та үтмәде, фил бик кинәт кузгалып китте һәм борыны белән җирдән тузан алып өстенә сибә башлады. Ул да булмады, Гөлнара кулымнан ычкынып, йөгерә дә башлады.

Көч-хәл белән куып җиттем аны.

— Янында әтиең кулыннан җитәкләп тора, шулай булгач, ник курkасың ул филдән? — дидем.

Гөлнара һаман тынычлана алмыйча:

— Куркам шул, фил синнән зур бит ул, — диде.

## «Дуңгыз баласы»

Гүзәл авторучкасына үзе «ремонт ясаган», рәтләвен рәтләмәгән, әмма кулларын-битләрен, күлмәкләрен һәм өстәл өстен буяп бетергән. Карар җире калмаган, зәп-зәңгәр булган. Бу эше өчен бераз ачуланып алыйм, башка вакытта авторучканы актарырлык булмасын дидем үземчә:

— Кара син аны, дуңгыз баласы...

Сүзне дәвам итә алмадым, кызым бүлдерде. Ул шатланып:

— Әйе шул, мин дуңгыз баласы! — дип кычкырып та җибәрде.

Мина шик төште, ник ачуланганга шатлана әле бу дип уйладым.

— Әти, мин синең балаң бит, әйеме? — дип көлде Гүзәл.

Ачуны бераз басып:

— Әйе шул, син минем балам, — дидем, сүзнең кая барганын аңламыйча.

— Шулай булгач, син дуңгыз буласың бит, ә мин — дуңгызның баласы, — диде ул шаркылдап.

## «Хәзер синкалыйбыз»...

Тик тора белмәгәнгәме, әллә кызык итепме — кызларым әниләренә булышырга яраталар, ул нәрсә эшләсә шуңа барып тыгылалар да комачаулыйлар.

Бераздан әниләре кер юа башлады, алар инде хәзер кер юарга сорыйлар.

— Идән юдыгыз бит инде, шул җиткән. Барыгыз хәзер курчакларыгыз белән уйнагыз, — дип, әниләре аларны янынннан җибәрде.

Бераз вакыт балаларның тавыш-тыннары чыкмый торды. Күңелгә шик төште. Алар тынып калса, бер хикмәт чыгуын көт тә тор.

Кухняга барсам күзләремә ышанмыйм: балалар икесе дә баштанаяк зәңгәр карага буялганнар, ә кечкенә тазда курчакларының киемнәре һәм әниләренең кофталары ята. Кызлар мине елмаеп каршыладылар, Гөлнарасы мактанып:

— Без кер юдык. Хәзер синкалыйбыз! — диде.

## «Нинди зур кастрюльләр алар?»

Нефть чыга торган җирдә торганга, кызлар аның ни икәнен яхшы беләләр. Ә менә нефть җиһазлары белән танышу «акрын» бара, чөнки аларны сирәк күрәләр. Качалканы гына яхшы беләләр, аны, күренгәч тә:

— Скважина, скважина!.. — дип кычкырыша башлыйлар.

Бер көн шулай машинада авылга барабыз. Еракта акка буялган нефть резервуарлары күренеп тора. Балалар да аларны күрделәр.

Гүзәле бармагы белән төртеп күрсәтте дә:

— Әти, нинди зур кастрюльләр алар? Нигә анда тезеп куйганнар? — дип сорады.

## «Дүрт күз»...

Гөлнара күзлек киеп йөри башлады. Күзлек киеп барган беренче көнне бакчадан кайтып керде дә:

— Әти, сана әле, минем ничә күзем бар? — дип сорады.

Аптырап киттем:

— Ник алай дисең, кызым, синең ике күзең бар.
— Нигә соң алай булгач бакчада миңа «дүрт күз» дип әйттеләр?— диде Гөлнара.

## «Җыелыш монда да була бит!»

Минем өйдән чыгып китүне балалар бер дә яратмыйлар. Киенә башлау белән:

— Әти, кая барасың? — дип йөгереп киләләр дә, мең сәбәп табып, киенергә комачаулый башлыйлар. Әшкә, җыелышка һәм командировкага бару гына алар өчен җитди сәбәп була. Бервакыт Казанга барырга җыенып чемоданга тотынган идем, икесе дә йөгерешеп килеп җиттеләр:

— Әти, кая барасың?

— Казанга барам.

— Анда ник барасың?

— Җыелышка барам.

Бу сүзне әйткәч кенә хата җибәргәнемне аңладым, командировкага барам дияргә иде дә бит, соң инде.

Гөлнарасы:

— Җыелыш монда да була бит. Шулай булгач, Казанга барма! — дип өлгерде, ә Гүзәле чемоданны күтәрде дә балалар бүлмәсенә алып кереп тә китте.

## «Бәлеш баласы»

Гүзәл дә, Гөлнара да һәркемнең, һәрбер нәрсәнең баласы булырга тиеш дип уйлыйлар. Беркөнне шулай бәлеш ашап утыра идек, кызларыбыз:

— Бәлешнең баласы кайда? — дип, «бәлеш баласы» таптыра башладылар.

— Менә шимбә көнне тагы бәлеш салганда баласы да булыр! — дип, әнисе котылу чарасын тапты.

Шуның белән балалар тынычланды.

Шимбә көнгә кадәр бу турыда сүз чыкмады, шулай да кызлар онытмаганнар. Иртән тору белән:

— Әйдә, әни, бәлеш тә салабыз, бәлеш балалары да салабыз,— дип, әниләрен кухняга әйдәп алып киттеләр. Чыннан да ул көнне бәлеш тә, ике «бәлеш баласы» да салынган иде. «Бәлеш балаларының» мичтән чыгуын кызлар түземсезлек белән көттеләр, ә ул пешеп өлгергәч, авызларын пешерә-пешерә кабаланып ашап та бетерделәр. Шушы көннән алып «вак бәлеш» дигән тәмле ашны безнең семьяда «бәлеш баласы» дип йөртә башладык.

Шулай, көннәрнең берендә, вак бәлешне мичкә куеп кайнашкан чакта гына, Хәйрулла абзый килеп керде. Бераз гәпләшеп утырганнан соң ул китәргә җыенып урыныннан торды. Мин аның юлына каршы төштем:

— Утырыгыз әле, Хәйрулла абзый, хатын әнә вак бәлеш салды, хәзер өлгерә, ашап-эчеп китәрсез! — дидем.

Сүзгә ашыга-ашыга Гүзәл кысылды:

— Әти, син белмисеңмени, мичтә «бәлеш баласы» пешә бит, — диде.

Нәзифә Кәримова

# ДУСЛАРЫМ-ИПТӘШЛӘРЕМ

ПАРЧАЛАР

## Сөенче



Безнең әти күп сөйләшми. Ә менә бүген төшке ашны ашаганда:

— Кыр башындагы бодайны суктырдык. Без төшке ашка кайтканда Габделбәр сарыкларны Бурсык елгасына төшергән иде инде...— диде.

Габделбәр безнең авылның көтүчесе ул. Әллә ничә ел көтә инде ул сарык көтүен. Аның шундый озын чыбыркысы бар. Бер башы авылның бер башында булса, икенче башы икенче башында кала. Әйтәм бит бик озын дип. Ул аны көн дә озынайта әле. Көтүдән кайта да тотына чыбыркысын озынайтырга! Карале, мин бит әти әйткән сүзне сөйли башлаган идем. Каян килеп керде әле бу чыбыркы?! Менәтерә шул, Габделбәр абый әтигә, Әминә җиңгинең сарыгы бәрәнләде, килеп алсыннар әле, дип әйтергә кушкан.

— Әнисе, кызларның берсе әйтеп кайтсын,— диде әти. Берсе тагы, Әлфия бара аламы соң анда. Билгеле, мин барам инде. Әти шулай дип торганда минме соң карулаша торган кеше. Чәемне дә эчеп тормадым, шикәрне авызга каптым да — ялт өстәл артыннан! Әлфия тагы миңа иярә инде. Каламы соң ул миннән. Кычыткан беләнме? Тиеп кара син аңа, бөтен авылыңны җыяр.

Өйдән чыгып та йөгердек, арттан капка ябылып беткәнче, без инде ярты юлны үткән идек. Аннары инде җитәкләшеп йөгердек. Әминә җиңгиләр турына җитәрәк ял иттек тә капкаларына атладык. Аларның этләре дә юк, әле безнең ишеләргә дип капка келәләренә бау да асып куйганнар. Баудан тартасың да капканы этәсең. Арттан капка әкрен генә үзе ябылып кала. Ә чыкканда барыбер ачып чыгаручы кирәк шул.

Без кергәндә Әминә җиңги өйалды күләгәсендә май язырга дип чүлмәктә каймак туглап утыра иде.

— Исәнме, Әминә җиңги? Әти әйткән иде, барып алсыннар дип. Әти әйткән иде алып кайтсыннар дип.

— Нәрсәне алып кайтсыннар дип әйткәние әтиең?

— Сарыгыгыз бәрәнләгән. Габделбәр абый көтүче әйткән, безнең әтигә әйткән...

Әминә җиңги эшен ташлап безне тыңлады да, әй, кара син аны, кысыр дип йөргән идем, менә син рәхмәт яугыры, дип сөйләнә-сөйләнә, чоланга кереп китте.

Эшне беткәнгә санап, чыгып китәбез дип Әлфиянең кулыннан тотуга, ул чүлмәк ягына ымлады. Анда сары күзле кап-кара мәче, безне искә дә алмыйча, Әминә җиңгине юкка санап, чүлмәктәге каймакны ялый иде. Шул минутта чоланнан Әминә җиңги килеп чыкты. Мәчесенең тәртибен яхшы белгәнгәдер инде, аның күзе иң беренче безгә түгел, каймак чүлмәгенә төште.

— Кара син гадәтсезне, просс!

Мәче китәргә уйлап та карамады. Муенын гына җыерды да, чүлмәкнең икенче ягына чыгып, үз эшенә керешТе.

Җиңги безнең икебезгә дә берәр күкәй тоттырды да, елмаеп:

— Мәгез, балакайларым, сөенчесе сезгә. Рәхмәт төшсен, кул-аякларыгыз сызлаусыз булсын...— диде. Без рәхмәт әйтеп, күкәйләрне алдык та капкага таба йөгердек. Җиңги безнең арттан, вата күрмәгез, пешмәгән алар, дип кычкырып калды.

— Үскәнем, ялгыш төшереп ватарсың, китер үзем генә тотып кайтам.

Алырсың Әлфиядән әйбер. Саран да соң инде. Барыбер вата ул аны, менә күреп торыр әле, дип уйлап бетерүем булды, кулыма тоткан күкәй җиргә төште дә китте. Сеңелем алдында миңа оят булды. Күкәйнең кабыгы икегә бүленеп ике якта ятса да, ышанмадым, кап-кара җирдә яткан күкәй сарысын кулыма алырга тырыштым. Юк шул, бер ватылгач, җыярсың күкәйне, бар. Әлфиягә ачуым килде. Әниләргә кайтып сөйләсә, миннән көләләр дә көләләр инде. Ләкин сеңелем әкрен генә минем янга килде дә:

— Елама инде, беркемгә дә әйтмәбез, минекен дә ватарбыз,— диде.

## Яңалык

Безнең авылда көн дә бер яңалык булып тора. Бүген тагы бер яңалык булды. Диләрәләргә читтән кунак кызы кайтты. Бездә әле аннан шәбрәк яңалыклар да бар ул. Әле кичә генә әти җигеп йөри торган ат колынлады. Аның матурлыкларын күрсәгез инде менә!

Диләрә әйтә, бөтен яңа хәбәр дә яңалык була ул, ди. Нишләп алай булсын инде ул? Яңа хәбәрләрнең бит сөенечлесе дә, көенечлесе дә була. Кайгылы хәбәр яңалыкка кермәсен. Кайгы алып килә торган булгач, нинди яңалык була инде ул аннары. Кирмән очында ике ел буенча яңа күпер салып бетерә алмыйлар. Салынып беткәч тә яңалык була алмый инде ул. Бар кеше дә белеп бетергәч, шул да булдымы яңалык!

Әле бүген авылда иң шәп яңалык булды. Илсурның чик буенда хезмәт итүче абыйсы кунакка кайтты. Менә, ичмасам, яңалык! Бер кеше дә көтмәгәндә кайтты да килде. Илсурның абыйсы кайткан

дигәч, бөтен кеше дә, кара син аны, яңалык: Мөхәммәтша малае кунакка кайткан, диләр.

Рәхәт тә соң авылда яңалык булгач.

Иң шәп яңалыкларны кибет, клуб яныннан ишетәсең. Кибеткә әйбер кайтканын иң беренче кем ишетә? Без, билгеле! Яңалыкны кем тарата? Тагы без инде — вак кызлар. Авылда безне шулай дип йөртәләр.

Менә кибеткә кеше килә башлый, кеше килә башлый... Кибетче генә җитешеп өлгерсен. Хәер, анысы кибетчегә сүз әйтеп булмый. Шалт-шолт гер сала, ялт-йолт башкасын. Кулы кулга йокмый, ничек чүтлап өлгерә диген син аны. Безнең авылда иң башлы кешедер ул. Әле үзе барысын да сөендерә, барысының да күңелен күрә. Инде озак та үтми, алып кайткан әйберләр дә бетә, кибет тә бушый. Тик соңга калган апалар гына ашыга-ашыга кибеткә керәләр дә:

— Су чиләкләрең булган икән, Садретдин, калдырмадыңмы? — дип сорыйлар.

— Әй, түти,— ди Садретдин абый, әле һаман китмичә, нидер көткән апайларга күз кысып,— чыгам да карыйм, чыгам да карыйм. Ник килмиләр болар, мин әйтәм: яңалык бит, кибеткә су чиләкләре кайтты.

— Әй шушы Садрины! Һаман шаяртуы булыр. Кара аны, кабат алып кайтсаң калдыр,— дип көлми генә чыгып китәләр.

Менә шундый яңалыклар безнең авылда. Әле мин үзем дә яңалык булырга торам бит. Быел беренче класска укырга керәм. Башка урам кешеләре генә түгел, безнең урамнар да шаккатар әле, сумка күтәреп мәктәпкә барганны күргәч.

— И бу вакытның үтүләре! Сиңа да җиде яшь тулдымыни, үскәнем? Менә сиңа яңалык! — диярләр.



## Беренче кар

Минем апам бик зур шәһәрдә яши. Әни әйтә, анда өйләр шундый зур, кемнәр яшәгәнен дә белеп бетереп булмый, ди. Кызык та соң, өйе бит. Ничек инде ул, үзең яшәгән өйдә кем торганын белмисең! Әгәр моны Диләрәгә сөйләсәң, ышанмый инде ул, әйеме? Тагы ялганчы булып калам инде. Каян белсен инде Диләрә, аның апасы да бик бәләкәй шул әле.

Чынлап та, менә безнең өйдә, кыр куянын, песине чутламаганда, әни, әти, абый, мин, сеңелем Әлфия. Әле мин безнең өйдәге кешене генә түгел, безнең урамның барлык-барлык кешесен беләм. Зурларны да беләм, кечкенәләрне дә. Исемнәрен дә беләм, кушаматларын да. Безнең авылда бит Наилләр генә җидәү. Каян белеп бетерерсең, кушаматын белмәсәң.

Кемдер кереп килә, ахрысы, капка тавышы ишетелүгә урынымнан торып тәрәзәгә карасам... Урам тулган кар белән.

— Әни, әни, кар ява икән бит, нишләп әйтмичә торасың? — дип, чөйдә эленеп торган бишмәтем янына атылдым.

Беренче кар! Беренче кар! Ур-ра!

Әллә кайчаннан бирле мине көтеп яткан чанамны әләктердем дә Диләрәләргә йөгердем.

— Диләрә, чык, кар ява! Диләрә, чык, кар ява!

Диләрә чыкты.

— Нәрсә шул хәтле кычкырасың?

— Кар яуганны күрми каласың бит.

— Нәрсә дисең?

— Һи шушының бер! Мактанчык! — дидем мин, аның янына ук килеп.— Харап икән, яңа чаналы булган икән. Ишетмәгән булып кылана! Бик беләсең килсә, былтыр минем чанам да яңа иде, шуашуа искерде.

— Ә минеке өр-яңа!..

— Булсаный!

— Ә минем буявы да уңмаган! — диде Диләрә. чанасын бавыннан күтәреп.

— Ярар, алайса, карап тор шул яңа чанаңа! — дидем дә иске чанамны тартып тау ягына йөгердем.

— Тукта инде, мин дә барам бит,— дип мышный-мышный, Диләрә дә минем арттан йөгерде.

Без килүгә абыйлар зур итеп кыш бабай ясаганнар, борынына кызыл кишер, күзләренә кара күмер куйганнар иде.

— Әйдә, без дә үзебезнең кыш бабайны ясыйбыз!

Кулның туңуларын да онытып, зур кыш бабай янына кечкенә кыш бабайлар ясап куйдык. Алар шул хәтле кечкенә булып чыктылар, без аларга кыш малайлар дип исем куштык.

Ә абыйлар һаман тәгәрәтәләр дә тәгәрәтәләр карны. Артларыннан җир чыгып кала, карлары да кап-кара булып беткән инде. Күп яуса да, беренче кар шул әле бүген.

— Малайлар, әйдәгез, безнең коега кар тутырабыз. Ну, яңгырап та төшә инде ул кое төбенә,— диде Мансур. Алар тагы кар тәгәрәтергә тотындылар. Безгә кызык. Карның кое төбенә яңгырап төшкәнен карыйсы килә. Алар безне коега якын да җибәрмиләр. Аларның коелары бик тирән, тирән булса да, бер тамчы да суы юк. Буш кое ул. Җәй көне олы кешеләр күмәргә дигән иде, тагы калды шул көе.

Өч малай карны зур итеп тәгәрәтеп килделәр дә кое авызына китереп капладылар. Кар кысылды да калды. Төшми дә төшми.

— Менә яңгырады сиңа,— диде Рифгат.— Әйттем мин сезгә зур итмәгез дип.

— Һәй, куркаклар! — диде дә Мансур кое авызындагы кар өстенә менеп тә басты.— Күрдегезме абзагызны! — дип, кое кырыендагы баганага тотынып тыпырдап та алды.

— Баганага тотынма син, тотынгач кем дә сикерә аны! — диде Илсур.

— Әйе, әйе, тотынмыйча сикер бик батыр булсаң,— диештеләр малайлар.

— Тотынмыйчамы? Һи! Әллә сикермәс дип беләсезме? Бер, ике, өч...

Өч дигән тавыш инде кое эченнән килде. Кары-ние белән Мансур кое төбенә очты.

Күзләребезгә ышанырга белмичә, бермәл карашып торганнан соң, без бөтен көчебезгә акырышып өйгә йөгердек. Малайлар кое авызына капланып калдылар.

Мансурның әнисе бау алып килде.

— Кар коймагыз,— диде Мансур кое эченнән тонык кына тавыш белән.

— Әй, яшьти,— диде Рифгат,— нәрсәләр бар анда, кое төбендә?

— Монда әйбер күп. Нурсамат абыйның югалган мотоциклы да монда икән, малайлар!

Мансурның коега төшү хәбәре бик тиз таралып өлгерде, күрәсең, кое янына халык җыелып та өлгерде. Ул арада Мансурны бау белән тартып та чыгардылар. Менә, бәхете булгач, бер генә җире дә сыдырылмаган, ичмасам!

Шул көннән башлап Мансурга «Кое Мансур» дигән кушамат тагылды да куйды. Үзе гаепле. Мактанмасын иде.



## Җәнлекләр кайта

— Кайталар, кайталар! Иң беренче мин күрдем,— диде Диләрә ашыга-ашыга,— куян баласы булса, миңа!

— Әйе, сиңа ди, көтеп тор менә. Син бит башта төлке баласы кирәк дигән идең. Әле бүген, үскәнем, Илсур чираты,— дидем мин.

Менә ничә көн инде урман эшендә эшләүчеләрне көтеп алабыз. Ни өчен дисезме? Барыбызның да өйдә нинди дә булса җәнлек булдырасы килә. Ә урманда эшләүчеләргә гел очрап тора бит ул. Тотасы да алып кайтасы.

Беркөнне мин, Диләрә, Сәвия, Фәния, тагы берничә малай, безнең очлар инде, җыелышып, урманда эшләүче Газизҗан абыйларга керергә булдык.

Шакыраеп каткан киез итекләребезне шакылдатмаска тырышып, кердек тә ишек төбендә җыелып калдык.

— Барыгыз да кереп беттеме, я, ишекне ябыгыз инде,— дигән тавыш ишетелде.— Я, ни йомыш, балалар?

Урамда бик батыраеп сөйләшсәк тә, өйгә кергәч, син әйт инде, мин әйт дип, бер-беребезне кыстый башладык.

Көн дә саен урманга эшкә киткәндә, безгә куян баласы алып кайтыгыз әле, дип кычкырып калганга, безнең ни өчен кергәнне Газизҗан абый бик тиз аңлап алды.

— Ә-ә, җәнлекләр кирәк инде сезгә, алайса,— диде ул сузып.— Кемгә нәрсә алып кайтыйм соң, ә?

Барыбыз да шаулаша башлагач, ул безне туктатты да берәм-берәм сорый башлады:

— Борһан кызы, мин сиңа нәрсә алып кайтыйм?

— Миңа куян баласы.

— Ә сиңа, Галимулла кызы?

— Миңа төлке булса да ярый,— диде Диләрә.

— Төлке булса да ярыймы? Бик әйбәт. Гел очрап кына тора ул безгә. Кара, язып куй Хисаметдин,— диде ул, пырхылдап көлеп җибәргән малаена карап.

Ә минем күптәнге хыялым кечкенә генә тиен баласы булдыру иде. Экиятләрдә дә бик матур итеп язалар бит ул тиен турында.

— Яз әле, улым, тиен баласы дип.

Язды ди шул Хисам. Гомердә дә язмый ул аны.

— Ярар,— диде Газизҗан абый,— язмаса аңа ялынып тормабыз, болай да истә калыр әле.

Шушы көннән башлап, көн кичке якка авыштымы, без Тазнарат тавыннан төшеп килүчеләрне көтә башлыйбыз. Менә бүген дә «кайталар» дип кычкыруга, юлны бар дип тә белмичә, кар ерып, мәтәлә-кадала, алар каршысына йөгердек.

Безне күргәч, арган йөзләре ачылып китте боларның. Газизҗан абый белән бергә кайтучы Равил абый белән Мәүләви абый да туктап калдылар.

— Бүген кем чираты иде әле? — диде Газизҗан абый, барыбызны да күзе белән барлап чыкканнан соң. Ә без, тыннарыбыз кысылып, барыбыз да аның сумкасына текәлдек.

— Тотканнармы?

— Алып кайтканнармы?

— Минем чират,— дип кычкыра-кычкыра, артта калган Илсур да килеп җитте. Ә инде иң артта калган Мансур, бер нәрсә дә күрмәсә дә, ишетмәсә дә:

— Куян, куян баласы тотканнар! Әй, бүре бугай! — дип кычкырып җибәрде.

— Минем чират,— диде тыны кысылган Илсур.— Миңа төлке баласы кирәк иде.

— Ә менә бит әле нәрсә,— диде Газизҗан абый, бүреген артка җибәреп, сакал үскән битен сыпырып алганнан соң,— бүген төлке булмады шул. Бүре оясын күрдек. Әнә, миңа ышанмасагыз, абыйларыгыздан сорагыз дип, читтән генә көлеп безгә карап торган Равил абый белән Мәүләви абыйга күрсәтте.

— Аннары, сезнең чират бит, егетләр, чират... Аны бозып булмый инде...

— Әй,— диделәр малайлар, үпкәләргә җыенып.

— Юк, егетләр,— диде Газизҗан абый, сез үпкәләмәгез әле. Иртәгә кем чираты? Менә Сәвиягә куян алып кайтырбыз. Барысы да берьюлы булмый бит ул.

Көн артыннан көн үтте, кыш та үтеп китте, ләкин Газизҗан абый әле беребезгә дә җәнлек алып кайтканы юк. Булмаса булмас инде, аның каравы, ул безгә көн дә ничек куян артыннан йөгергәнен, баласын алам дигәндә генә ана бүренең ничек алар артыннан куганын сөйләп, көлдереп бетерә.

Хәзер инде без аны шушы хикәяләре өчен көтеп алабыз.

# КамАЗ ЕЛЪЯЗМАСЫ

*Камадагы автогигант төзелеше турында илебез матбугаты*

**ЯНВАРЬ, 1973 ел.**

«Һәр буынның үз Магниткасы бар. Бүгенге көн яшьләре өчен КамАЗ — Бөтенсоюз удар комсомол төзелеше — хезмәт энтузиазмы символы булып әверелде.

Камадагы автомобиль гигантын һәм яңа Чаллы шәһәрен комсомол җибәргән егетләр-кызлар — илебездәге барлык республикаларның вәкилләре — сала. Алар вакыттан узып эшлиләр, 1973 ел — бишьеллыкның хәлиткеч елы — вакыттан элек тәмамлансын өчен барысын да эшләргә омтылалар».

**«Молодая гвардия»**, Мәскәү.

«Өч ел дәвамындагы төзелеш эшләренә йомгак ясап, һәркемгә мәгълүм хакыйкатьне кабатлыйсы килә: гомуми максатка омтылган, фидакарь хезмәт белән рухланган кешеләр тиз вакыт эчендә бердәм коллектив булып әвереләләр...

Төзелешкә катнашучы эшчеләр, инженер-техник хезмәткәрләр, КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре Л. И. Брежневның СССР төзелүгә 50 ел тулуга багышланган тантаналы утырышта ясаган докладында үз хезмәтләренә биргән югары бәя белән рухланып, тугызынчы бишьеллыкның өченче, хәлиткеч елы планнарын вакытыннан элек үтәү өчен көчләрен кызганмыйлар».

СССР энергетика һәм электрификация министры урынбасары, «КамГЭС энергострой» идарәсе начальнигы, Социалистик Хезмәт Герое **Н. Иванцов** мәкаләсеннән. **«Социалистик индустрия»** газетасы, Мәскәү.

**«Труд»** газетасында камАЗчылар турында кыска очерклар басылып чыккан. Төзүчеләр үзләре һәм эшләре турында менә нәрсә сөйлиләр.

«Башта Магнитогорск шәһәрендә домна миче, аннан «2500» номерлы уникаль проект станын салуга катнаштым. Иргә чыктым. Ирем Владимир да төзүче-механизатор, тиктормас кеше. Аннан Оренбург өлкәсенә күчеп киттек. Зур металлургия комбинаты төзедек. КамАЗга Башкортстаннан килдек, анда, Салават шәһәрендә, нефтехимия комбинаты төзегән идек...»

Кранчы **Александра Ивановнаның** хезмәт биографиясе әнә шундый. Ул КамАЗда эре блокларны җыю конвейеры өчен махсус эшләнгән, заводтан беренче номерлы булып чыккан зур күтәрү кранында эшли.

Ә **Виктор Козин** — РИЗда комсомол-яшьләр бригадасын җитәкли.

— Мин Амур буендагы Комсомольск шәһәрендә үстем,— ди ул.— Мөгаен, шуңа күрәдер, бирегә килдем. Безнең шәһәр беренче бишьеллыклар комсомолларының батырлыгы хатирәсен изге итеп саклый. Алар Комсомольск шәһәрен һәм Магниткаaны төзеделәр. Без бу эстафетаны дәвам итәбез — КамАЗ төзибез... Икенче ел инде бик дус коллективта эшлибез...

**Владимир Кумичев:**

— Без эстакада блокларын җыябыз. Ә Казанцев һәм аның егетләре аларны монтажлый. Мин үз гомеремдә инде икенче төзелешкә катнашам. Түбән Тагил шәһәреннән килдем. Анда химзавод монтажлаган идек. Төзелеп беткәч, автозаводта эшләргә калырга уйлыйм. Шәһәр миңа ошый. Ә эстакаданы вакытында тапшырырбыз дип уйлыйм. Әгәр Казанцев егетләре тоткарламаса.

**Иван Казанцев:**

— Ә безнең кайчан тоткарлаганыбыз бар? Тик безгә блокларны үз вакытында әзерләп бирсеннәр. Бездән эш калмас. Эстакада үз вакытында һичшиксез тапшырылыр.

«Автозаводны ходка җибәрергә ике ел вакыт калды. Әмма бүген үк инде кадрлар әзерләү мәсьәләсе — иң мөһим бурычларның берсе.

Безнең шәһәр ерак Татарстан вәкилләрен якты чырай белән каршы ала. Алар өчен барлык уңайлыклары булдырылган ике тулай торак әзерләнде. Андагы уңай

квартираларда кичләрен төрле телләрдә сөйләшкәнне ишетергә мөмкин. Татарлар, чувашлар, казакълар, үзбәкләр, мордвалылар — уннарча миллэт вәкилләре бердәм дус семья булып яшиләр, үзләре сайлаган һөнәрләргә тырышып өйрәнәләр».

**«Вечерний Минск».**

«Бүген сигез йөзгә якын комсомол-яшьләр коллективларының бригадирлары һәм комсорглары штабның төп көче, төп терәге булып тора... Кыен участокларда без бригадирлар советлары җыябыз. Коллектив фикер производстводагы кыенлыкларны җиңәргә ярдәм итә. Мәсәлән, шул совет утырышларының берсендә туган эреләндерелгән комплексы бригадалар оештыру фикере монолит нигезләрне бетонлау эшен тизләтергә мөмкинлек бирде.»

Кама автомобиль заводы һәм шәһәр Бөтенсоюз удар комсомол төзелеше штабы начальнигы **Ю. Петрушин** мәкаләсеннән. **«Комсомольская правда»**, Мәскәү.

«Яңа ел алдыннан Кама автомобиль заводының беренче участогы җиһазлар монтажлау өчен әзерләнеп бетте. Производство управляющие Г. М. Чернов, автозавод промУКСы начальнигы урынбасары С. Е. Воеводин, «Автозаводстрой» идарәсенең СМУ-5 начальнигы А. А. Кича 3700 квадрат метр мәйданда ремонт-инструменталь завод цехының беренче участогының әзерлеге турындагы актка кул куйдылар. Инженер З. Гайфуллин җитәкчелегендәге РИЗ коллективы биредә төрле станоклар урнаштырырга керешт.

Чуен кою корпусы стеналары панельләрен монтажлау башланды. Бу эшне «Металлургстрой» идарәсенең яңа төзелгән монтаж участогы башкара.

...Кама автомобиль комплексының кою заводында эшләүче Социалистик Хезмәт Герое Алексей Новоладский бригадасы 1972 елда социалистик ярыш нәтиҗәләренә йомгак ясады. Бригада Алексей Стаханов, Мария Виноградова һәм беренче бишьеллыкларның башка геройларына җавап итеп күтәренке йөкләмәләр алган иде. Йөкләмәләр үтәлеп кенә калмады, бетон эшләрендә бригада хезмәт җитештерүчәнлеге буенча рекорд куйды. Алексей Новоладский һәм аның иптәшләре 1972 елда һәр айда 2120 кубометр бетон койдылар. Арматура монтажлау заданиесе дә ике мәртәбәгә артык башкарылды.

Бригада җыелышында иң яхшы эшчеләрдән егерме кеше «Коммунистик хезмәт ударнигы» дигән мактаулы исемгә тәкъдим ителде. Алар арасында Резеда Мөбәрәкшина, Юрий Бондаренко, Василий Дмитращук, Михаил Новиков, Иван Шихов һ. б. лар бар. Кама төзелешенең почетлы шефы Алексей Стаханов исеменә бригада хезмәт рапорты әзерләде.

Яшьләр тулай торагында (30/08 йорт) «Эврика» клубы ачылды... Клубның беренче утырышында юристлар хезмәт законнары, гаиләдәге мөнәсәбәтләр буенча сорауларга җавап бирделәр».

**«Социалистическая индустрия» на строительстве КамАЗа» газетасы.**

«Бары тик алга, бары тик җиңүгә! — олимпиячеләр өчен бу төп закон. Һәм совет спорты гвардиячеләре бертавыштан шундый карарга килделәр: төзүчеләр белән бергә удар производство вахтасына басарга, гомуми хезмәт янчыгына үз өлешләрен кертергә!..

Анатолий Рощин бетон җәя. Эмма Гапченко бригадир белән бергә арматура монтажлый. Аның җитез кулларына җәядән төз атылган ук кына түгел, каты металл да буйсына икән. Кою заводында монтажчы Д. Загребальный бригадасында олимпия чемпионнары Л. Турищева һәм З. Воронинaлар да ударникларча эшлиләр.

Олимпиячеләр тормышында бу көн истәлекле булды. Саппоро һәм Мюнхен геройлары илебезнең удар төзелешендә хезмәт вахтасында булдылар.»

**«Советский спорт»**, Мәскәү.

«...Чаллыда узган елның башында махсус «Соцкультбытстрой» тресты булдырылган иде. Ул составында 56 төзү бригадасы булган зур подряд оешмасы... Төзүчеләр җәмәгатьчелек биналарының экстерьерларын һәм интерьерларын зәвыклы итеп бизиләр. Мәктәп, кинотеатр, кибет, мәктәпкәчә балалар учреждениеләрен бизәгәндә витражларны һәм мозаиканы киң кулланганнар».

**«Архитектура»** журналы, Мәскәү.

«Социалистическая индустрия» на строительстве Камского автозавода» газетасы. КамАЗ белән чит ил, беренче чиратта, Франция автомобиль фирмаларының бәйләнеше турында яза. Парижда автобус белән кырык минутлык юлда «Оффис» фирмасы бар. Анда «Автоимпорт» һәм «КамАЗ» вәкилләре эшли. Бу шәхси фирма тарафыннан күптән түгел генә салынган унбиш катлы бинаның алтынчы каты Советлар Союзыннан килгән белгечләр карамагында.

Совет белгечләренең эше сөйләшүләр алып бару, Франциядәге техниканы өйрәнү, андагы яңалыклар белән танышудан гыйбарәт.

Бүлмәләрдә иртәдән кичкә кадәр Франция һәм башка ил вәкилләре белән сөйләшүләр бара. КамАЗның тимерчелек производствосы управляющие урынбасары Валентин Михайлович Мельниченко әйтүенчә, безнең белгечләрнең андагы эше җиңел түгел. Алардан белем һәм тәҗрибәдән тыш, сәүдә, коммерция законнарын да белү таләп ителә. Һәм Советлар Союзыннан килгән вәкилләр чын-чынлап техник яңалык булган әйберләрне танырга өйрәнделәр. Франциягә барыр алдыннан алар техника буенча әдәбиятны җентекләп өйрәнделәр, төрле фирмаларның продукцияләрен бер-берләре белән чагыштырдылар. Хәзер инде алар практика, тормыш сынавын үткән, прогрессив җиһазларны гына сайлыйлар. Белгечләрнең күбесе чит ил фирмалары белән бәйләнешкә керү буенча шактый тәҗрибә тупладылар инде. Шул ук Валентин Михайлович Мельниченко соңгы елларда гына төрле илләрдә үз профиле буенча егермеләп заводта булды. Ул производствода кулланыла торган фәнни-техник яңалыкларның иң яхшыларын үз күзләре белән күрде. Франциядәге безнең белгечләр барысы да аның кебек үк төрле илләргә командировкаларда булдылар.

Сатып алу группасында нигездә — цех, производство җитәкчеләре һәм Кама автогигантын проектлау, төзү эшләренә катнашучы белгечләр.

КамАЗда фәнни-техник прогресс үрнәгеп, бирелә илебез һәм дөнья практикасында сыналган иң яхшы сыйфатларны туплау — совет белгечләренең омтылышы шул. Авыр кул эшләренә юл калдырмый торган җиһазлар гына сайлана. Шул күзлектән карап, совет белгечләре чит ил фирмаларына күп кенә тәкъдимнәр әйтәләр. Ә алар бу тәкъдимнәрне үтиләр. Көнбатыш Германия фирмаларының берсе төп эш процесслары бары тик 20 процент кына автоматлаштырылган горизонталь-чүкү машинасы тәкъдим итте. Безнең белгечләр күп кенә тәкъдимнәрен әйттеләр, Һәм фирма аларны искә алды. Агрегатта эш процесслары тулысы белән автоматлаштырылды.

Пресс-рам производствосы управляющие Валерий Николаевич Соколов болай ди: «Күп кенә фирмалар КамАЗның үзләре өчен реклама булуын да аңладылар. Хәзер инде алар совет автомобиль төзүчеләренең таләпләрен тулысынча канәгатьләндерерлек җиһазлар гына тәкъдим итәләр».

Сөйләшүләр инде төгәлләнү алдында тора — кайбер җиһазлар буенча контрактлар инде төзелде.

Быел ук инде беренче автомат линияләр Чаллыга килеп җитәчәк.

Безнең белгечләрнең чит илләрдәге эшләре турында тагы нәрсә әйтергә мөмкин. Җиһазлар сайлау һәм сатып алу вакытында Кама автогигантының башта эшләнгән проектларына төзәтмәләр дә кертелә. Һәм бу бик табигый. Чөнки проектлар булган җиһазлар күздә тотылып төзелгән иде, ә чит ил фирмалары белән сөйләшүләр һәм якыннан бәйләнеш вакытында прогрессиврак мөмкинлекләр барлыгы беленде. Хәлбуки, кайбер үзгәрешләр кертү котылгысыз һәм техник прогресста күп кенә экономик файда бирәчәкләр.

Безнең белгечләрнең барлык эшчәнлеге КамАЗда барлык нәрсәне хәзерге заман техник фикерләүнең эталоны булуы өчен юнәлдерелгән.

КамАЗда, ремонт-инструменталь заводында Мәскәү «Красный пролетарий» заводында ясалган автомат-технологик җиһазлар монтажлау башланды.

**«Труд»**, Мәскәү.

Чаллы шәһәренең яңа районы, Кама елгасы буенча яңа кварталлар корган Мәскәү төзүчеләре хәтердә озак сакланыр. Бигрәк тә нигезгә беренче таш салучылар — «Главмосстрой»ның 190 нчы номерлы төзү идарәсеннән Николай Зрелов җитәкчелегендәге комплекслы комсомол-яшьләр бригадасы коллективы. Яңа шәһәрнең беренче йорты — 4/10 номерлы йорт — алар көче белән салынды. Шул көннән бирле бригада социалистик ярышта беренчелекне бирми. Ул инде 40 мең квадрат метрдан артык торак мәйдан җитештерде. Узган ел гына да Н. Зрелов бригадасы 29 мең квадрат метр күләмендә торак мәйдан тапшырды.

Анда интернационализм темасына багышланган «Огонек» бик күңелле үтте. Ул «Ровесник» кафесында уздырылды. Кафе паннолар, фотокүргәзмәләр, плакатлар белән бизәлгән иде. Төрле союздаш республикалардан килгән вәкилләр якташларының эше һәм тормышы турында сөйләде.

КамАЗ яшьләре Казан дәүләт консерваториясе студентларын һәм укытучыларын көчле кул чабулар белән каршыладылар. Булачак музыкантлар һәм аларның остазлары кызыклы концерт бирде.

Болар турында **«Социалистическая индустрия» на строительстве Камского автозавода»** газетасы сөйли.

«...КамАЗга килгән һәркем кайда укырга теләве, нинди һөнәр сайлавы турында махсус анкета тутыра. Партия шәһәр комитеты, комсомол комитетлары янында, бу анкеталарны өйрәнеп, яңа килүчеләр теләгән эшкә урнаштыруда ярдәм итүче комиссияләр эшли. Бу комиссияләр тәкъдиме буенча иң яхшы производство алдынгыларын төзелеш вузларга һәм техникумнарга укырга җибәрә».

**«Комсомольская правда»**, Мәскәү.

ooooooooooooooo

## Диас Вәлиев

# ҖАМАЛИЕВЛАР ДИНАСТИЯСЕ

I



Тирә-якта кызу эш кайный, моңарчы бу тирәләрдә һичкайчан күрелмәгән зур төзелеш бара. Яңа корпуслар җитештерү өчен кирәкле кирпеч, такта һәм башка төзү материалларын бер урыннан икенче урынга күчерүче озын сыйраклы краннар туктаусыз хәрәкәтләнә.

Йөзгә җепшек кар бәрә. Аяклар сыек ләмгә бата, машиналар узып киткән саен чалбар балакларына пычрак чәчри. Ә якында гына тупыйк борынлы бульдозерлар үкерә-үкерә җир актаралар. Алар яныннан авыр йөк төягән МАЗлар уза.

Күкне караңгы чырайлы калын болытлар каплаган. Шулай да җиргә, табигатькә җылы сулыш өргән язның бердәм уянуын тоясың. Су ергалап бетергән юллар, ботакларын як-якка җәеп, башларын күккә сузган чал наратлар, хезмәт шавы көннән-көн көчлерәк яңгыраган цехлар — барысы да инде күптәннән таныш та, шул ук вакытта таныш түгел дә шикелле. Әйе, завод биредәгеләрнең күз алдында акрынлап төзелде. Монда озак еллар буена эшләгән кешеләр дә көн саен, сәгать саен туып торган яңалык — үзгәрешләргә тиз генә күнегеп, ияләшеп, җайлашып җитәргә өлгерә алмыйлар. Аларның күңелен сүз белән аңлатып бирә алмаслык рәхәтлек белән бергә ниндидер сагыш-моңсулык били.

Нуриәхмәт Җамалиев ирен кырыйлары белән генә елмаеп куйды. Үзенең шундый халәттә булуы аңа ничектер кызык тоелды. Ярый, завод төзелсен дә, ди. Я шуннан нәрсә булган? Ул, әлбәттә, төзелергә һәм үсәргә тиеш — тормыш үзе шуны таләп итә. Уйланып бара-бара, Нуриәхмәт үзенең үткән гомерен, башыннан узган төрле хәлләрне күңеленнән кичерде. Әйе, күпме еллар сизелмичә узып киткән. Завод та шундый ук сизелмәс тизлек белән үскән, күрәсең. Нуриәхмәтнең бала чагы һәм яшьлеге дә завод белән аерылгысыз бәйләнгән. Хәзер дә ул шушы заводта эшләргә, үз иңенә салынган йөкне зарланмыйча күтәреп барырга тиеш. Тормышның ямен, яшәүнең тәмен ул бары тик шунда гына бөтен йөрәге белән тоячак. Ә инде тормыш белән бер адымга атлап бару өчен дистәләрчә эре һәм вак-төяк эшләр башкарырга, дистәләрчә проблемалар чишәргә туры килә.

Вакыйгалар өстеннән хакимлек итүнең кыенлыгын ул башкалардан ишетеп түгел, үз тәҗрибәсендә ап-ачык белә. Кайвакытта вакыйгалар кеше белән үзләре идарә итә башлыйлар. Аларның үзагымына, үзсүзлегенә каршы тору өчен һәр сәгать, һәр минут әзер булырга кирәк. Тормыш ул һәр каршылык белән бергә-бер торып, пычакка пычак килеп тартышуны сорый. Җитмәсә әле, эштә туган кыенлыкларга йорт мәшәкатьләре килеп өстәлә.

Әнә шулар хакында уйлана-уйлана, башын гадәтенчә бераз алга ия төшеп, Нуриәхмәт яңа төзелеп яткан автоматик регенерацияләү корпусына таба атлады. Аның күзе әле күптән түгел генә кайтарылган һәм кирәкмәгән нәрсәләр шикелле кайсы кайда аунап яткан җиһазларга — станокларга, аппарат һәм чаннарга төште. Шул вакыт түгәрәк чан артыннан җитен чәчле мастер Севостьянов килеп чыкты.

— Ишкәнсең син монда ишәк чумарын,— дип исәнләште аның белән Нуриәхмәт, чыраен сытып.

— Нәрсәгә шул кадәр чәпчисең? Синең бу келтрифуннарыңны кая куярга икәнлеген мин каян белим,— дип ярсыды мастер.— Мин бит сиңа технолог түгел.

Нуриәхмәт тә авыз йомып торуны кирәк санамады. Күңелендә аңа карата әллә ни ачу сакламаса да, Севостьяновка саллы гына сүзләр белән җавап кайтарды. Шулай итеп, көннең икенче яртысын ул өстенә акбурга буялган телогрейка, башына иске кепка кигән хәлдә, яңа корпус буйлап әрле-бирле йөреп үткәрде.

Электр җиһазларын җыю эшләрен махсус монтажлау идарәсеннән килгән егетләр башкара. Эшләвен алар болай начар эшләмиләр. Ләкин сигез группалы пунктлар урынына һәр җирдә диярлек бишәр группалыны гына куйганнар, үткәргечләр исә торбалар аша уздырылмаган, ә бит монтажлаганнан һәм барлык электр хуҗалыгын эшкә җиккәннән соң бу корпусны ул — Нуриәхмәт Җамалиев кабул итәчәк. Аны файдалануга тапшыргач, ул-бу килеп чыга калса, бөтен җаваплылык Нуриәхмәт өстенә төшәчәк.

— Син ничек тә проект буенча эшләргә тырыш инде,— диде ул тәкәббер мастерга һәм аңа туп-туры карап тагын бер тапкыр елмайгандай итте. Әмма бу караш салкын һәм кирәгеннән артык игътибарлы иде. Мастер, өлкәннәр соравына җавап кайтарырга сүз таба алмаган малай шикелле, баскан урынында таптанып калды. Нуриәхмәт кайчандыр үзе дә нәкъ әнә шундый тәҗрибәсез бер малай иде. Шуңа күрә дә мастер белән сөйләшкәндә ул үзен заводка беренче тапкыр килгән көннәрендәгечә хис итте.

## II

Хуҗи картның больницага керүенә бер ай чамасы булган иде инде. Өлкән улы Нуриәхмәт белән кече улы Вәлиәхмәт — әтиләре кебек үк кечкенә, әмма авыр гәүдәле ирләр — аның хәлен белергә килделәр. Хуҗи карт, кулларын тез өстенә куеп, янәшәсендә утырган улларына карап алганнан соң кипшенгән иреннәрен чалышайтып, сизелер-сизелмәс кенә елмаеп куйды:

— Култык таякларының әйбәтрәген табарга тырышыгыз... Озакламый аягымның тышавын салдырачаклар, ә гипсын — соңыннан... Врач әйтте, аягың ялганачак, диде... Миңа култык таяклары кирәк... Җиңел дә, чыдам да булсыннар...

— Табарбыз, әти,— диде Нуриәхмәт.— Таба алмаслык нәрсә түгел.

— Кирәгеннән артык юанаеп киттең әле син, Вәлиәхмәт,— дип, карт сүзне икенчегә борды.

— Юанаймадым, олыгайдым,— дип җавап кайтарды Вәлиәхмәт, үпкәләгән кешедәй иреннәрен бүлтәйтеп.— Вакыты да җитеп килә бит, әти, озакламый кырык яшь тула.

— Шулай укмыни инде?.. Ә менә мин хәзер үземнең кайчан кырык яшьтә булганымны да тәгаен генә әйтә алмам шикелле,— дип уйга чумды Хуҗи карт.— Кешегә үлем килми калмый. Мин үләрмен, синең оныкларың, Нуриәхмәтнең оныклары үләр. Без бу җиргә беребез дә мәңгелеккә килмәгән. Әмма безнең намусыбыз мәңгелек! Менә шуңа күрә дә тормышта кешеләрчә яшәргә, аны үз кулларың белән төзешергә, әйбәт якка үзгәртергә кирәк... Ярый, бу әле болай гына, тел очына эленеп торган сүз генә... Ә сез, тагын бер тапкыр әйтәм, култык таякларын алып килергә онытмагыз. Яңа квартирага үз аякларым белән күчәсем килә.

Бу сөйләшү дүшәмбе көнне кичкырын булды. Ә иртәгесен таң алдыннан агалы-энеле Җамалиевлар яшәгән тәбәнәк баракның тәрәзәсен кактылар. Нуриәхмәт йокысыннан уянып, күзләрен уа-уа, ишеккә таба юнәлде. Тыштагы сыек караңгылык эчендә, папиросын авызына кабып, янәшә баракта яшәүче күршесе басып тора иде.

— Больницага син минем телефон номерын калдырган булгансың икән. Әле менә шуннан шалтыраттылар... Бүген төндә әтиегез дөнья куйган,— диде ул, Нуриәхмәтнең күзләренә туры карамаска тырышып.— Үпкәсе җилсенүеннән...

Нуриәхмәт барак стенасы буендагы салкын туфрак өеменә барып утырды, Вәлиәхмәттән тартырга сорап алды.

— Яшәргә дә яшәргә иде әле аңа.

Бераз тынып торганнан соң сүзен түгәрәкләде:

— Хәзер инде менә култык таякларының да кирәге юк...

## III

Иске баракның болай да кысан бүлмәләре, кешеләр кереп тулгач, тагын да кечерәеп, тараеп калгандай булды. Монда Нуриәхмәтнең дә, Вәлиәхмәтнең дә бөтен гаиләсе җыелды. Нуриәхмәтнең хатыны ӘкъЛимә, балалары Дамир, Әмир, Дилә үзара шыпырт кына сөйләшәләр. Вәлиәхмәтнең хатыны Зөләйха мәктәпкә барырга әзерләнгән кызлары Зөбәрҗәт, Розалия һәм Рәмзия тирәсендә кайнаша.

Маһруй карчык карават читендә, ире Хуҗиның аяк очында утыра һәм аның белән гомер кичергән елларын бер-бер артлы күңеленнән уздыра. Моннан берничә ел элек ул үзе дә бик каты авырып урын өстендә ятты. Ләкин үзен бик начар хис иткәндә дә үлемнән курыкмады ул, бары тик Хуҗиның япа-ялгыз торып калачагын уйлап борчылды. Алар бит йорт-җирләрен бергәләп үзләре эшләделәр. Җәйге чиллә көннәр булсын, кышкы салкыннар булсын, аларның кулларыннан беркайчан да эш төшмәде. Шулай да башта әллә ни мантып китә алмадылар: әле янгын чыкты, әле сугыш. Еллар тынычлана төшкәч кенә бераз аякка бастылар. Әмма нинди генә авырлыклар кичерергә туры килмәсен, балаларына әйбәт тәрбия бирергә, аларны кеше итәргә тырыштылар. Улларыннан башка әле тагын Кәшифә, Рәисә, Зәйнәп исемле кызлары бала-чага үстереп, җир җимертеп яшәп яталар. Әйе, тормыш үз агымы белән ага бирә. Монда искитәрлек бернәрсә дә юк. Аның Хуҗиәхмәте һәр вакыт шулай дия торган иде. Соңгы сулышына кадәр тормышка, җиргә гашыйк әнә шул кеше хәзер күзләрен йомып, мәңгегә тынып калган.

Бу минутта Маһруй карчык бик күп нәрсәне хәтереннән үткәрде. Акрынлап аның уйлары туып-үскән авылына барып тоташты. Матур, бик матур иде аларның авылы. Чирмешән елгасы буена урнашкан

иде. Хуҗи ул вакытта яшь, сәламәт, көчле иде. Беренче өйләрен җиткергәндә аның оста кулларында ут уйнады, күлмәге аша кайнар тир бәреп чыкты. Маһруй аңа әледән-әле салкын су китереп бирде, ә ул, ап-ак тешләрен күрсәтеп, һаман елмаюында булды.

Маһруй үзе дә тирә-якта менә дигән бер кыз иде. Хуҗи аны төнлә урлап алып кайтты. Алар артыннан кызның бирнәләре, кияүгә һәм аның туганнарына дигән бүләкләр төялгән олаулар килмәде. Ә бит Маһруйга дип бөтен өй эче белән ничә еллар буе әзерләнгән бирнәләрнең чуты-чамасы юк иде. Ләкин ата-анасы, туганнары алдан ярәшмичә кияү йортына аяк баскан кызга бернәрсә дә бирергә теләмәделәр. Кияү белән кызны берничә ел хәтта кунакка да чакырмадылар. Ә шулай да соңыннан җайланды. Алар тату һәм матур гомер иттеләр... Йортка ямь-нур өстәп беренче кызлары Кәшифә дөньяга килде. Күп тә үтмәде, Хуҗины хәрби хезмәткә чакырдылар. Ул Петербургның үзендә, лейб-гвардия полкында хезмәт итте, кемнәрдәндер патшаны саклады. Ул чагында әле Хуҗи күп нәрсәне аңлап җитә алмый иде. Ә инде дөнья хәлләренә бераз төшенә башлагач, кулындагы мылтыгын үзе саклаган шул ук патшага каршы борды...

Карт ананың уйларын бүлдермәскә тырышкандай, Нуриәхмәтнең өлкән улы Дамир аяк очларына гына басып, карават янына килде һәм әбисенә сыенды. Йортлары янганнан соң Хуҗи белән Казанга, төзелешкә килгәндә аларның уллары Нуриәхмәт үзе дә нәкъ менә Дамир шикелле ябык кына бер малай иде. Аннан соң инде утыз елдан артык вакыт узып киткән.

Һай, бу гомерләр, һай, бу онытылмас хатирәләр...

## IV

Ул чагында әле Хуҗи Җамалиев җир сөрә, икмәк үстерә иде. Беренче бөтен дөнья һәм гражданнар сугышы елларында җимереклеккә, ачлыкка, бөлгенлеккә дучар ителгән Россия чиксез зур авырлыклар кичерде, илдә кытлык һәм ялангачлык хөкем сөрде. Ләкин алда безне беренче бишьеллыклар, һәркемне бөек хезмәткә рухландырачак дәртле чакырулар көтә иде. Озак та үтмәде, дискуссияләр һәм бәхәсләр кызган кечкенә бүлмәләрдә зур-зур металлургия комбинатларының, куәтле электр станцияләре һәм химия заводларының беренче проектлары төзелде. Гражданнар сугышы фронтларында үзе шикелле үк меңнәрчә гади кешеләр тарафыннан яулап алынган яңа заманның көчле сулышы Хуҗи Җамалиевны да, ата-бабасы нигезеннән аерып, шәһәргә, ул чор өчен зур гигантларның берсе булган төзелеш кочагына суырып алды. Гомер буена игенчеләр булып саналган Җамалиевлар нәселенең Хуҗи һәм аның балалары аша эшчеләр династиясенә күчүе әнә шулай башланды.

...Март аеның буранлы бер төнендә, бөтен авылны иңеннән-иңенә яктыртып, аларның йортлары дөрләп янды. Коллективлашудан соң ике ел узган иде инде. Югыйсә, бөтен нәрсә инде үз урынына урнашкан һәм тыныч кебек иде. Ләкин кайбер каралты-йортларга ут төртү очраклары һаман булгалап торды... Хәләл көч белән тупланган барлы-юклы мал-мөлкәт урынында кап-кара корымлы кызган мич кенә утырып калды. Хуҗи, биш баласын һәм хатынын ияртеп, ят почмакларда каңгырап йөрергә мәҗбүр булды. Алай да, ярый әле, туганнары, дус-ишләре ташламадылар.

Ничектер бервакыт Хуҗига авылга килгән ниндидер вәкилне район үзәгенә илтергә туры килде. Менә шунда, ашханә каршында

атлар бәйләп куя торган баганага ябыштырылган кызгылт кәгазь кисәгенә язылган белдерү аның язмышын хәл итте.

— Бүген үк Казанга киту хәстәрен күрик, анда төзелештә эшләү өчен кешеләр кирәк икән,— диде ул районнан кайткач хатынына.— Тормышыбызны алга таба ничек итеп кору хакында картлар белән киңәшләштем. Кәшифәне үзем белән алам. Ә син Зәйнәп, Нуриәхмәт, Вәлиәхмәт һәм Рәисә белән хәзергә түзеп тор. Әйбәт кенә барып урнашсам, барыгызны да кайтып алырмын.

Аякларына чабата кигән, иңнәренә биштәр аскан беренче Җамалиевлар шәһәргә, төзелешкә әнә шулай кузгалдылар.

Казмашстрой, СК-4, кинопленка фабрикасы — утызынчы елларда Татарстанда барган иң эре удар төзелешләр... Аларның берсендә дә эшче куллар җитми, төзү материаллары җитми... Ә билгеләнгән сроклар чиктән тыш ашыгыч.

«Кинопленка фабрикасына ташчылар, арматурчылар, балта осталары, җир казучылар... таләп ителә». Шундый эчтәлектәге белдерүләр, чакырулар барлык газета битләрен, реклама витриналарын чуарлый.

...Маһруй үзенең кызлары Кәшифә һәм Зәйнәп белән төрле эшләрдә эшләде: кәрзингә тутырып ком, кирпеч ташыды, ат арбасына беркетелгән мичкәләр белән ерак Иделдән су китерде. Хуҗи үзе балта эшендә булды. Нуриәхмәт, Рәисә белән Вәлиәхмәт исә якында гына, эшчеләр яши торган бараклар тирәсендә чыр-чу килеп йөрделәр. Бик-бик кысан булсалар да, әйбәт, җылы иде ул бараклар. Сәкеләр өчәр кат итеп төзелгән шул баракларда гаиләләр бер-берләреннән кәгазь, картон яисә фанер такталардан торган стеналар аша аерылалар. Әмма балаларның чыр-чуы бер-берсеннән барыбер аерылмый, уртак кала: аларның тавышыннан картон стеналар дер селкенә. Әмма күрше белән күрше арасындагы татулыкка, дуслыкка бу һич комачауламый.

— Менә коноплянка төзиләр, шөкер, тиздән кибетләргә дә май чыгачак,— дип пышылдады шулай бервакыт Маһруй иренә.

— Нинди май? — дип сорап куйды Хуҗи, хатынының сүзен аңлап җиткермичә.

— Киндер мае,— дип җавап кайтарды аңа күрше хатыны Мәрфуга картон стена артыннан.— Майга тәмам тилмердек бит, югыйсә. Бәрәңге кыздырырлык та май табып булмый...

Хуҗи көлеп җибәрде һәм Мәрфуганың ире Хәмзәне үзләренең ягына дәшеп алды.

— Эх, сез чүбек башлар! Коноплянка түгел, кинопленка төзиләр. Менә кино әйләндерәләр бит... кешеләр стена буйлап йөгереп йөриләр. Әйдә, Хәмзә, клубка алып барыйк әле үзләрен. Дөньяның нинди зур икәнлеген күрсеннәр әле бер.

Ул вакытта Маһруй кино карарга курка иде әле. Һәм, гомумән, шәһәр үзе дә, аның зур йортлары да куркыта иде аны. Урамга чыксаң адашуың бар. Йортларның күбесе таштан салынган, аларның исәбе-хисабы юк. Кешеләр исә шундый күп, урмандагы кырмыскалар диярсең. Ә Хуҗига аңа нәрсә? Гражданнар сугышы елларында ул бөтен илне аркылыга-буйга иңләгән, һәммәсен күргән, һәммәсенә күнеккән. Соңыннан, ликбезга йөреп, укырга-язарга өйрәнде, эшендә дә гел беренчелекне алып килде...

Маһруйның уйларын Нуриәхмәтнең сүзләре бүлде:

— Шулай итеп, әти дә үлеп китте,— диде ул, үз-үзенә сөйләнгәндәй.— Нишлисең бит, табигать үзенекен итә... Менә ордер да кесәдә, ләкин әти яңа квартирабызның адресын гына белеп калды, ә үзен күрә алмады.— Аннан соң ул янындагыларга мөрәҗәгать итеп, өстәп куйды: — Чирмешәнгә кайтып килергә кирәк булыр.

Моннан өч-дүрт ел элек үк инде, үлә-нитә калсам, каберемә ата-анам кабереннән бер уч туфрак алып килеп салырсыз, дип васыять әйткән иде.

— Аның кабер өстенә бер уч туфрак кайтарып салудан ни файда? — дип сүзгә кушылды Нуриәхмәтнең олы улы Дамир. Әтисе аңа гаҗәпләнүле караш ташлады:

— Менә сиңа мә! Без үзебезнең кайсы җирлектән һәм кем булуыбызны һәр вакыт исебездә тотарга тиешбез. Сораган икән, кирәк булганга сораган. Аңа гына түгел, ул туфрак бәлки синең белән миңа да кирәктер әле...

Хуҗины татарның борынгы гореф-гадәтләренә туры китереп, хөрмәтләп җирләделәр. Ыгы-зыгылы тормышны дәвам итү Нуриәхмәт белән Вәлиәхмәткә һәм аларның балаларына калды.

## V

Яз килде, якты, җылы яз...

Хәзер тышка чыгарга иде дә саф һавада бераз йөреп керергә иде. Ләкин соңгы көннәрдә аны грипп бимазалый. Ә бит бүген ул заводка барырга, әйе, һичшиксез барырга тиеш иде. Башкалар өчен гадәти булган бүгенге көн Зөләйха өчен һич тә гадәти түгел. Аның заводта эшли башлавына бүген нәкъ чирек гасыр тулды. Бер карaганда әллә ни зур ара да түгел шикелле, әмма аерым бер кеше өчен чирек гасыр вакытның әһәмияте әйтеп бетергесез. Ни әйтсәң дә, аның иң кызыклы, шау-шулы еллары шул чорга туры килә, узган вакыт исә хәзер истәлекләр булып кына яңара.

Зөләйха тәрәзә янына килеп басты. Ләкин ул балалар чыр-чу килеп йөргән урамга караудан бигрәк, үз тойгыларына кереп чумды, үзенең йөрәк тибешен тыңлады.

Өй эче тып-тын. Вәлиәхмәт эштә. Кызлары мәктәпкә китте. Бу тынлык аңа ничектер сәеррәк булып тоелды. Аның каравы, өйдә бер ялгызың калып, уйлар канатында җилпенеп, күптән үткән көннәргә кире кайту Зөләйхага үзе бер рәхәтлек бирә иде...

Мең тугыз йөз кырык өченче елны ул — өстенә итәкләре чачакланган озын җиңле соры пальто, аякларына солдат итекләре кигән япь-яшь кыз — химзаводка эш эзләп килде. Әле дә хәтерендә: ул көнне урамда җепшек кар катнаш язгы яңгыр ява иде. Кечкенә гәүдәле Зөләйха, пальто итәкләреннән аккан суда аякларын чапылдатып, кадрлар бүлегенә килүчеләр рәтендә, ничек кенә булса да зуррак күренергә һәм елмаерга тырышып, шактый вакыт басып торды. Чираты килеп җиткәч, өстенә гимнастерка кигән сыңар куллы бер кеше, Зөләйхага күтәрелеп карап та тормастан, аны ниндидер бер хатын карамагына тапшырды.

Күп иде алар заводта Зөләйха кебек яшүсмерләр. Аның Вәлиәхмәте, Нуриәхмәтнең хатыны Әкълимә, сеңелләре Рәисә... Эш стажлары сугыш елларында башланганнар бер гаилә эчендә генә дә дүрт кеше. Ә йөзләрчә башка гаиләдәгеләрне саный китсәң, чуты-хисабына тиз генә чыгармын димә... Хәтергә кереп калган шул истәлекле көннән бирле аларның күбесенең кулларыннан эш төшми.

Кинопленка фабрикалары сугышка кадәр Переяславль-Залескидагы Шосток шәһәрендә булган. Сугыш вакытында бөтен илгә бердәнбер пленка фабрикасы — Казан фабрикасы гына кала. Ә хәрби промышленность өчен пленка чиксез-чамасыз күп кирәк. Моны һәркем бөтен йөрәге белән тоя. Фабрикадагылар тәүлегенә уникешәр сәгать эшлиләр, якшәмбе һәм бәйрәм көннәре бөтенләй истән чыга —

сугыш шуны таләп итә. Эштән соң алар сугышчылар өчен бүрекләр, бияләйләр тегәләр, госпитальдә концертлар куялар, яралыларның өйләренә хатлар язалар: «Хатымның беренче юлларында үземнең исән-сау икәнлегемне белдерәм...» дип башланып китә гадәттә ул хатлар...

Ил күгенә салют утларын сирпеп, җиңү көне килә. Европаны кичкән сугышчылар күкрәкләрендә орден һәм медальләр балкытып туган якларына әйләнеп кайталар. Кешеләрне авыр кайгы үзара берләштергән кебек үк, зур шатлык та аларны бер-берләренә якынайта. Зөләйха да моңарчы бер үк урамда, хәтта күрше баракта ук яшәгән Вәлиәхмәтне шушы язгы көннәрнең берсендә тәүге тапкыр күргәндәй була.

Ул төнне алар урамнар буйлап бик озак йөриләр. Янынннан атлап барган Вәлиәхмәттән Зөләйха шаян гына елмаеп сорап куя:

— Нәрсә, моңарчы мине бер мәртәбә дә күргәнең булмадымы әллә?

— Булды... Ләкин ничектер бүгенге сыман түгел. Бөтенләй башкачарак,— дип җавап кайтара аңа Вәлиәхмәт.— Беләсеңме, әйдә, ешрак очрашыйк. Заводка да бергә-бергә барырбыз, мин сине эшкә барышлый ала керермен...

Аннан соң инде чирек гасыр гомер үтте. Зөләйха инде күптән Җамалиевлар фамилиясен йөртә. Аларның өч кызлары буйга җитеп килә. Шушы егерме биш ел буена алар Вәлиәхмәт белән һаман бер үк заводта, бер үк цехта эшлиләр.

Зөләйха көзге каршына килеп басты. Шул чак ишек артында аяк тавышлары ишетелде. Бүлмәгә Антонина Волочкова, Рая Исмәгыйлова һәм Люба Дарышева килеп керделәр. Кулларындагы чәчәк бәйләмнәрен алар ашыга-ашыга Зөләйхага суздылар.

— Кая әле, бер үбим әле үзеңне,— диде Антонина Волочкова, иңнәреннән аны үзенә таба тартып.— Синең бәйрәмең безнең дә бәйрәмебез бит. Ни әйтсәң дә, егерме биш ел буе бергә эшләдек. Ачысын да, төчесен дә уртак татырга туры килде.

Ул арада ак ашъяулык җәйгән өстәл өстенә бер шешә җиңелчә шәраб менеп утырды. Көлешә-көлешә аны авыз иткәч, хатыннарның битләре алсуланып, телләре чишелеп китте:

— Исегездә микән,— дип сүз башлады калын тавышлы Рая,— сугыш елларында завод территориясендә, цехлар аралыгында бәрәңге түтәлләре бар иде. Сменабыз беткәч, җыйнаулашып шунда казына торган идек.

— Әйе, ул чакта халыкны шул бәрәңге коткарып калды, дускайларым, бәрәңге,— диде Зөләйха.

Хатыннар, бичара хатын-кызлар! Нинди генә кыенлыклар кичермәделәр, нинди генә эшләрдә эшләмәделәр алар сугыш дәверендә?! Алар яу кырындагы ирләрен һәм әтиләрен, абыйларын һәм апаларын, исәннәрне һәм һәлак булганнарны алыштырдылар. Әле балигъ булырга да өлгермәгән яп-яшь кызлар, олы яшьтәге апалары белән беррәттән, тыныч чорда ирләр генә башкара торган авыр эшләрне башкардылар. Менә шуңа күрә дә бүген Зөләйхаларның һәм Раяларның ул елларны тагын бер тапкыр искә төшереп, хатын-кызлар исәнлегенә тост күтәрүләре һич тә гаҗәп түгел иде.

Кунакларны озаткач, Зөләйха кинәт тынып, моңсуланып калды. Кызлары мәктәптән кайтып кергәндә, ул кечкенә тазга җылы су салып кер юарга тотынган иде.

— Инде ачыгып беткәнсездер,— диде ул кызларына, юеш кулларын алъяпкычына сөртә-сөртә.— Кайтуыгызга токмач пешергән идем, суына төшкәндер инде, хәзер җылытып бирәм.

— Син авырыйсың бит, әни, ятып торырга кирәк иде,— дип аңа каршы төштеләр кызлары.— Ял ит, ашарга үзебез әзерләрбез.

Балаларының кайгыртуын тойган бәхетле ананың бите буйлап әллә тир бөртекләре, әллә күз яшьләре тәгәрәде.

## VI

Мең тугыз йөз кырык беренче елның җәе матур килде. Казанлылар татар халкының милли бәйрәмен — сабан туйны бәйрәм итәргә җыенып йөргән көннәр иде. Көтмәгәндә Ватан күген кара болыт каплады. Тимер юл платформаларында илебезнең көнбатыш якларыннан эвакуацияләнгән предприятиеләрнең җиһазларын бушатуга әзерлек эшләре башланды. Сугышның беренче көннәрендә завод хроникасына менә мондый юллар язылды: «Бишенче көн... Партбюро өстәле өстендә фронтка җибәрүне сорап язылган дүрт йөз гариза ята. Завод коммунистларының дүрттән бер өлеше үзләре теләп сугышка китте... Сугышның егерменче көне... Ике йөз дә бер кеше фронтта. Алтмышынчы көн... Җиде йөз кеше... Һәлак булучылар турында беренче хәбәрләр...»

Шулай итеп, утызынчы еллардагы «Вакыт, алга!» чакыруы кырыгынчы еллар башында «Бөтенесе дә фронт өчен!» дигән сугышчан чакыру белән алышынды. Завод һәр көн саен үзенең дистәләрчә кадровый эшчеләрен сугышка озата торды. Аларга алмашка хатыннар, яшүсмер малайлар һәм кызлар килде. Фронтка китүчеләрне алыштыручылар арасында Казан кинопленка заводын үз куллары белән төзегән Җамалиевлар гаиләсенең икенче буын вәкилләре — әле мыек эзләре дә беленмәгән Вәлиәхмәт, аның сеңелесе Рәисә һәм бертуган Җамалиевларның булачак хатыннары Әкълимә белән Зөләйха да бар иде.

Менә ул вакытта заводта чыгып килгән күп тиражлы газетаның аерым битләре. Еллар үтү белән алар инде саргая төшкәннәр, рәсемнәре тоныкланган. Әмма коры һәм ашык-пошык язылган сүзләрдән заман сулышы бөркелә. Ул язмаларда заводның тарихы, Җамалиевлар гаиләсенең биографиясе шактый тулы чагыла: «1942 елда төзелгән массовый матбугат цехы беренче елларда аена алты йөз мең, ә аннан соң бер миллионга якын погонный метр «хәрби продукция» бирде. Бөек Ватан сугышы фронтларында төшерелгән «Сугышчан җыентыклар» аның производствосында эшләнде. Хроникаль материаллар нигезендә иҗат ителгән «Немец гаскәрләрен Мәскәү янында тар-мар итү» һәм «Царицын оборонасы» дигән тулы метражлы фильмнар да Куйбышев исемендәге Казан фабрикасында ишәйтелделәр».

Сугыштан соң, көннәрнең берендә, Вәлиәхмәт белән Зөләйха ниндидер бер клубка килеп керделәр. Анда сугыш елларында төшерелгән кинофильмнардан өзекләр күрсәтәләр иде. Вәлиәхмәт шул чак:

— Боларны безнең цехта төшергәннәр иде. Икмәктер менә безнең цехта,— дип кычкырып җибәрүен үзе дә сизми калды.

Экранда кечкенә генә булса да үз хезмәтенең җимешен күрү аны чиксез куандыра иде. Ни генә әйтмә, бу фильмнарны бөтен ил буенча миллионнарча кешеләр караган һәм карый бит!

Еракта калган коточкыч авыр еллар... Кешеләрдән бөтен көчләренә җигелеп эшләүне таләп иткән дәһшәтле сугыш еллары... Беренче карашка кечкенә һәм көчсез булып күренгән әнә шул кешеләр ил өчен, халыкның киләчәк бәхете өчен бөтен авырлыкларны җиңеп чыктылар. Алар күбәү иде, йөзләрчә, меңнәрчә, миллионнарча иделәр алар...

## VII

Бертуган Җамалиевлар үзләре күчәсе яңа йортны карарга, мөгаен, тугыз-ун тапкыр барганнардыр. Бу йорт бер ягы белән буп-буш киңлеккә, икенче ягы белән Киров һәм Ленин районнары арасында соңгы ике-өч ел эчендә калыккан берничәшәр катлы биналарга карый. Кайчандыр тирә-якта еракка җәелеп яткан сазлыкның хәзер монда эзе дә калмаган. Кая карама — төзелеш материаллары һәм өем-өем сап-сары ком. Йорт тирәләренә нәзек кәүсәле яшь агачлар утыртылган. Нуриәхмәт шул агачлардан ерак булмаган бер түмгәк өстенә утырган да тирән уйга чумган. Аның уйлары бүгенге белән генә чикләнми, туар көннәргә барып тоташа.

Әтисенең: «Кешене эш түгел, ялкаулык тупасландыра»,— дигән сүзләре аның хәтеренә бик нык уелып калган. Әгәр җанның ялкаулыкны сөйми икән, тормышта үз эшеңә карата мәхәббәттән дә көчлерәк нәрсә юк. Менә шуңа күрә дә ул үзенең көннәрен кайнап торган шау-шулы хезмәт эчендә үткәрергә ярата. Заводның пленкалар юа торган иске корпусы моңа кадәр аена җитмеш тонна продукция бирел килә иде. Хәзер исә план буенча бу санны йөз ун тоннага җиткерергә кирәк. Ә моның өчен мөмкинлекләр җитеп бетми. Шуны истә тотып, ашыгыч рәвештә киптерү һәм кисү агрегатлары төзү проектлаштырылды. Моннан тыш бик күп электр җиһазлары һәм кабель таләп ителә.

— Энекәш үзенең энерго-мастерскоеннан бераз өлеш чыгармый калмас калуын,— дип сөйләнде Нуриәхмәт үз-үзенә,— ләкин бу бик аз. Электрикларга хәзер үк эш бирергә, монтажлау эшләрен башкарырга кирәк, ә материал юк, аны каян табарга.

Дөрес, болар барысы да гадәти нәрсәләр. Элекке шикелле үк материалы да, башка кирәк-яраклары да акрынлап-акрынлап табылыр, әмма болай дип кенә үзеңне юатудан ни файда... Тормыш үз-үзеңне даими чыбыркылап торуны көннән-көн ныграк таләп итә.

Шушындый ыгы-зыгылар эчендә яңа квартирага күчү көненең килеп җиткәне сизелми дә калды. Өйдәгеләр моңа инде күптән әзерләнгәннәр иде. Тиз арада машинага өстәл-шкафлар, пианино-буфетлар, чемодан-төенчекләр чыгарып төялде.

— Шатлыктан абынып егылмасам гына ярый инде,— диде кулына телевизор күтәргән Вәлиәхмәт, шаяртып. Машина кузгалып киткәндә барысы да моңарчы үзләре гомер кичергән таныш урыннарга тагын бер тапкыр күз йөртеп алдылар.

Ул көнне Маһруй карчык, «ГАЗ-69» машинасы янында басып торган хәлдә, яңа квартираларга күченүчеләрнең йөгерә-очына әйбер ташуларын, үзара шау-гөр килеп гәпләшүләрен бик озак күзәтеп торды. «Заманалар ничек тиз үзгәрә,— дип уйланды ул эченнән.— Әле кайчан гына бу җирләрдә тоташ сазлык-баткаклык иде бит».— Аннан соң ул моннан күп еллар элек авылда йортлары янган март төнен исенә төшерде, колхоз активистлары рәтендә йөргән Хуҗины янә бер тапкыр күз алдына китерде. Һай, бу гомер дигәнең агым сулар белән бер икән.

Йорт тирәсендә машиналар сирәгәя башлады. Көзгеләр, шкаф һәм пианинолар, аш-су өстәлләре бүлмәләргә урнаштырылып бетте. Идәннәр буйлап шап-шоп басып йөргән аяк тавышлары, җыр авазлары ачык тәрәзәләрдән аермачык булып ишетелде.

Көндезге шау-шуларны басып, ай яктысы балкып торган тыныч төн килде. Вәлиәхмәт дүртенче каттан өченче катка Нуриәхмәт янына төште. Шушындый шатлыклы көнне аның абыйсы белән иркенләп бер сөйләшеп-гәпләшеп утырасы килә иде.

— Әкълимә, Әкълимә,— дип урыннан сикереп торды Нуриәхмәт, аны күрүгә,— әйдә, сыйларыңны әзерли башла... Азрак күңел күтәреп алыйк... Шунысы кызганыч, бу көнне эти генә күрә алмады...

Алар өстәл янына утырырга да өлгермәделәр, кемдер ишек шакыды. Нуриәхмәт бүлмәгә үзенең булачак күршесен ияртеп керде.

— Әйдәгез, түрдән узыгыз, табынга рәхим итегез,— диде хуҗа, аны ихлас күңелдән кыстап.— Бик вакытлы килеп кердегез әле, мактап йөрисез икән.

— Борчып йөрүем өчен гафу итегез, мин бер генә минутка,— дип сүз башлады күршесе.— Стенага кием элгечләр какмакчы идем. Әгәр рөхсәт итсәгез...

Нуриәхмәт аңа сүзен әйтеп бетерергә ирек бирмәде:

— Соңыннан иркенләп, күпме теләсәң шулай шакылдарсың, анысы вак мәсьәлә... Ә хәзер, әйдә, булган сый-хөрмәттән авыз ит әле, күрше.

Кунак артык кыстатып торуны кирәк санамады. Аш алдыннан бер рюмка шәраб эчеп куйганнан соң аның сүзгә болай да юмарт теле элеккедән дә ныграк чишелә төште:

— Заводта сезнең фамилиягез бик күптән билгеле. Шушы гаиләдән генә дә бит бездә дүрт кеше эшли. Ә инде башка туганнарыгызны саный китсәң... Мин моны шуңа әйтәм, Нуриәхмәт Хуҗиевич, сезнең кебек эшчән кешеләр белән күрше булу үзе зур бәхет ул...

Узган гомер, бүгенге көн һәм киләчәк турында куерып киткән әңгәмә төн урталарына чаклы дәвам итте...



## VIII

Нуриәхмәт бик озак йоклый алмыйча ятты. Чиксез ерак та һәм бик якын да булып тоелган истәлекле көннәр аның күз алдыннан бер-бер артлы тезелеп үттеләр.

...Каршыда тәбәнәк, сирәк куаклар. Аларның төбендә куе сазлыктан саркып чыккан су җемелди. Шул сазламыктан тагын әле ике йөз метр араны шуышып үтәсе бар. Ә үтелгән кадәресе күпме? Шуны белү өчен Нуриәхмәтнең артка борылып карыйсы килде. Ләкин ярамый. Дошманның сизеп алуы бар.

Яшел капчык эчендәге пакетны һәм ракета аткычны ничек кенә булса да иптәшләре ныгып калган биеклеккә алып менеп җиткерергә кирәк. Алар анда приказ һәм сигнал бирү өчен ракеталар көтәләр. Ап-аяз көндә, баш өстендә пуляляр корт урынына мыжлап торганда ике йөз метр араны шуышып үтү җиңел түгел. Монда сине коткарса бары тик җиргә сыену гына коткара ала.

Менә йөз генә метр калды. Әмма аның һәр метрында сине мәрхәмәтсез үлем сагалый. Тик ничек кенә булмасын, үрмәләргә, шуышырга, биеклектәге иптәшләре янына менеп җитәргә! Һич нәрсәгә карамастан үтәлергә тиешле приказ шуны сорый, шуны таләп итә. Ул, барлык көчен җыеп, гәүдәсен сазлыктан суырып алды һәм тагын берничә метр араны түше белән шуышып узды. Әче сызгырып, аның борын төбеннән генә бер-бер артлы пуляляр чыелдап үтте. Башын ул яңадан юеш түмгәк артына яшерергә мәҗбүр булды.

Шушы минутта ул сугышка алынган беренче көннәрен күз алдына китерде. Фронтка китәргә ничек ашкынганнар иде алар ул чагында! Тәүлекләр буена уздырылган тактик өйрәнүләр, хәрби занятиеләр, беркайчан да онытылмаслык булып, аның хәтеренә бик тирән уелганнар. Ашау-эчү яклары начар булганлыктан, алар

беренче атналарда ук ябыгып, хәлсезләнеп калдылар. Ә аннан соң Ленинград фронты... Сазлыкларга бил тиңентен күмелеп оборонада ятулар... Тукта, болай да кыен чакта үткәндәге газаплар искә төшеп нишләп җанны борчый соң әле? Ул, гәүдәсен басып торган авырлыкны җиңеп, тагын бер тапкыр зур гына сикереш ясады. Биеклеккә егерме метрлар чамасы калгач, аның каршысында яртылаш җимерелгән танк пәйда булды. Нуриәхмәт шунда әйтерсең лә үзен үлемнән саклап калачак бердәнбер көч шушы танк икәнлеген тойды: тәненә ниндидер җиңеллек йөгерде, арыган күз керфекләре ирексездән йомыла башладылар. Ләкин ул үзен бик тиз кулга алып өлгерде. Бу минутта кечкенә генә саксыз хәрәкәтең өчен дә тормышың белән түләвең бик ихтимал иде. Шулай да, ничек кенә булмасын, Нуриәхмәтнең күңеленә өмете кунаклады. Ни әйтсәң дә, юлның иң озын, иң авыр өлеше узылган иде инде.

Ә миналар һаман да якынга гына төшеп ярылалар. Күрәсең, дошман нәрсәдер сизенә. Нуриәхмәт, танк астыннан чыгып, соңгы метрларны үтү өчен, бөтен көченә алга ыргылды. Үлем бәҗрасын өзеп, үзебезнекеләр янына килеп җитте. Ләкин биредәгеләрнең берсенә дә приказ да, ракета аткыч та кирәк түгел иде инде. Нуриәхмәт әлеге биеклеккә менеп җиткәндә, безнекеләрнең берсе дә исән түгел иде.

...Псков янындагы сазлыкларны түш белән сөзеп үткән ике йөз метр ара... Кенигсбергны штурмлау алдыннан җәяү узылган егерме биш километрлы авыр поход юлы...

Байтак вакыт узгач, көннәрнең берендә аны ашыгыч рәвештә полк штабына чакырттылар.

Автоматын ут ачарга әзер тоткан хәлдә, юлсыз-нисез утыз чакрымга якын җир узганда, аны һаман бер үк сорау борчыды:

— Нәрсә өчен чакырттылар икән? Әллә берәр гаеп-мазар эшләп ташладыммы, югыйсә? Алай дисәң...

Юл буена ниндидер бәла турында уйлап, баш ватып килгән солдатка һич көтелмәгән бәхет елмайды... Моннан бер ел чамасы элек аларның зениткасы туры наводка белән атып, немецларның берничә танкысын сафтан чыгарган иде. Атышлар тынганнан соң, сүз иярә сүз чыгып, полк командиры подполковник Пугачевка ул үзенең Казаннан икәнлеген әйткән иде шикелле. Бу сөйләшүне һәм аның исем-фамилиясен подполковник ничек хәтерендә саклый алды икән соң? Менә хәзер ул үзенең туган ягы Мамадышка ялга кайтачак һәм бер айга Җамалиевны да үзе белән бергә алачак икән.

...Окоп тормышын бик-бик иртә татыды Нуриәхмәт. Мең тугыз йөз кырык икенче ел иде. Заводның төп эшчеләре — хатын-кызлар һәм яшүсмерләр. Мастерларның, тәҗрибәле эшчеләрнең барысы да диярлек кулларына корал алып, изге яу кырына киткән. Эшкә күнегеп-өйрәнеп киләм дигәндә генә Нуриәхмәтне дә хәрби комиссариатка чакырдылар. Чакыру кәгазен аңа табельче булып эшләүче яшь кенә бер кыз китереп бирде:

— Менә сиңа да чират килеп җиткән,— диде ул һәм кинәт моңсуланып калган күзләрен аска ия төште: — Сау бул... Бәлки бүтән очрашырга да насыйп булмас...

Менә хәзер, сугыш беткән көннәрдә, туган-үскән җирләренә ялга кайтып барганда, Нуриәхмәт яңадан шул кызны күз алдына китереп бастырды. Ябык йөзле, чем-кара күзле ул кыз бала аның каршында елмаеп тора башлады. Теге вакытта ул аны, сеңелесед әй якын күреп, сак кына үбеп тә алган иде шикелле. Яртылаш җимерелгән, таланган киң Россия юллары буйлап кайтып барганда нишләп шулай кинәт кенә Нуриәхмәтнең хәтеренә килеп төште соң әле ул? Сугышта йөргәндә ул кыз турында беркайчан да уйлаганы

булмады түгелме соң аның? Ә менә хәзер, гомеренең әле яңа башлануын, тормышының бөтен матурлыгы әле алда икәнлеген тойган ләззәтле минутларда бу яшь егетнең хисләренә Әкълимә дә кереп уралды.

...Бер елдан соң инде Нуриәхмәт армиядән бөтенләйгә кайтты. Погоннарсыз, озын итәкле соры шинелен киеп, Казан урамнары буйлап атлаганда, сугыштан соңгы тормышның кешеләр иңенә төшкән авырлыгын бөтен йөрәге белән тойды ул. Әйе, тормыш фронтта гына түгел, монда да зур көч, чыдамлык һәм батырлык таләп итә икән. Озак уйлап, озын сөйләшеп тора торган чак түгел иде. Армия хезмәтеннән кайтуына бер атна тулар-тулмас Нуриәхмәт үзе элек эшләгән заводка юл тотты. Кулларының эшкә сусавын, үзенең монда кирәклеген хәзер ул тагын да ачыграк аңлады. Заводтагы иске танышларының күбесе сугыштан кайтмаганнар. Аның карашы адым саен диярлек яңа кешеләр белән очраша. Ул әле аларның исемнәрен дә, биредә кайчан эшли башлауларын да белми. Ә шулай да, аратирә генә булса да, элек бергә эшләгән кайбер танышлары да күзгә чалынып киткәли. Аларны күрүгә, Нуриәхмәтнең эченә шатлык тула, йөзе яктырып китә. Үзенең беренче бригадиры Михаил Зеленихинны очраткач та нәкъ әнә шулай булды.

Аның исән-сау икәнлеген күргәч, Нуриәхмәт, үз-үзен белешмәстән, якын кешесенең кочагына ташланды. Шунда ул моннан берничә ел элек бригадирның стенага бармаклары белән төртеп: «Менә монда тишекләр тиш»,— дип, үз юлына китеп баруын исенә төшерде. Моны Зеленихин үзе дә онытмаган иде булса кирәк, сүзне шуннанрак башлады:

— Эшкә беренче тапкыр килгән көнең исеңдәме?

— Ничек инде истә булмасын ди?! Менә хәзер дә куркыбрак торам әле. Ток бәреп куймагае. Ничектер, куллар элеккеге эштән бизгәндер сыман.

— Башың һәм акылың бизмәсен. Үз-үзеңә һәр вакыт ышанырга кирәк. Үзеңә ышансаң, кул беркайчан да эштән бизми ул...

Нуриәхмәт шул ук көнне Әкълимә белән очрашты. Ул хәзер эшкәртү цехында бригадир булып эшли икән. Мастерлар хәзерли торган ниндидер курсларны тәмамлаган. Моннан бер ел элек поездда кайтканда күз алдына китергән Әкълимәгә Нуриәхмәт сөзеп-текәлеп карады. Шул ук шомырттай кара күзләр, шул ук эчкерсез, якты караш...

— Мине армиягә озаткан чакта моңаеп калганың хәтереңдәме, Әкълимә? — диде Нуриәхмәт, сүзне нәрсәдән башларга белмичә торганнан соң.

— Хәтеремдә булса, нәрсә дияр идең?

— Ә шуннан соң минем турыда уйладыңмы?

— Кош теледәй бер хат та язып салырга башына да китермәгән кеше турында уйладың ни дә, уйламадың ни...

— Эх, әгәр дә мин... белгән булсам.

— Нәрсәне белгән булсаң?

— Синең мәнә шушындый икәнлегеңне.

Кыз шаяру катыш сорап куйды:

— Күкрәгең тулы медальләр тагып кайткансың дип ишеттем.

— Бар инде шунда азрак. Ә тагын, беләсеңме, Әкълимә... Ә тагын синең артыңнан чабар өчен аякларымны, сине кочар өчен кулларымны исән-сау алып кайттым мин. Солдат өчен шуннан да зуррак нинди бәхет бар тагын...

Әкълимә матур тавышы белән тирә-якны яңгыратып көлде дә йөгереп китеп барды.

Озак та үтмәде, Җамалиевлар гаиләсендә берсе артыннан берсе диярлек өч туй булды. Нуриәхмәт һәм Вәлиәхмәт эшкәртү цехының бер үк участогында эшләүче Әкълимә белән Зөләйханы алып кайттылар. Алар артыннан сеңелләре Рәисә тормышка чыкты.

Сугыш чорында җир-ана бик күп улларын һәм кызларын югалтты. Аңа иртәнге зәңгәр томаннарга карап сокланучы, агачларга кунган кошларның өздереп-өздереп сайрауларын тыңлаучы, күпереп торган буразналар сызучы кешеләрнең сафын тулыландырырга, ишәйтергә кирәк иде. Исәннәрнең йөрәк тибешендә җир авазы тагын да көчлерәк ишетелде, тормыш дәрте тагын да көчлерәк ургылды. Миллионнар сафындагы алты яшь кеше җирнең бу чакыру авазын ишеттеләр һәм бер-берләре белән кушылдылар. Киләчәктә аларның гомер юлларын дәвам итәчәк яшь лачыннар дөньяга килә башлады.

Ул көннәрдә Хуҗи картның куанычы эченә сыймады. Оныкларына исем кушу мәҗлесләрендә, азрак кызып алгач, ул һаман бер үк сүзне кабатлады:

— Нәселебезнең тамыры корымаячак, карчык. Каныбызның тибеше бервакытта да туктамаячак. Тагын да күбрәк тусыннар. Җир иркен, бөтенесен дә сыйдырырлык, бөтенесен дә туендырырлык...

## IX

Ул үзенең ачулы, үткер карашын электрик Гвоздаревка текәгән. Озынча аксыл чырай, маңгайга бүселеп төшкән җирән чәч, күпме карасаң да бернәрсә дә аңлап булмый торган хәрәкәтсез күзләр... Электригының кинәт шундый чит-ят кеше булып күренүе болай да кәефе кырылып торган Нуриәхмәтнең җен ачуларын чыгарды:

— Эш вакытында исереп, кешеләргә комачаулап нәрсәләр кыланып йөрисең син? — Бу минутта ул үзенең кечкенә, тар бүлмәсенә сыя алмаслык хәлгә җиткән иде.— Эшләмәсәм, әни туйдырыр әле, синеңчә, ә?

Ана кеше бәлки туйдырыр да. Үз авызыннан өзеп, соңгы сыныгын бирер. Ә башкалар сине матур күзләрең өчен туйдырырга, киендерергә тиешмени? Син бригада члены булып исәпләнәсең һәм үзеңнең шушындый килеш-килбәтең, кыланышларың белән бүтәннәр исеменә дә тап төшерәсең. Сиңа бит инде аңларга вакыт.

— Нәрсәне?

— Кешеләр сиңа түгел, син аларга бурычлы икәнлегеңне.

— Ә мин моны күптән беләм. Җүләр түгел.

— Җүләр булмагач, үзеңне кешечә тот.

Бүлмәдә алар икәүдән-икәү генә иде. Шуңа күрә Нуриәхмәт ачыктан-ачык сөйләшүне артыграк санады.

— Менә нәрсә әйтмәкче булам мин сиңа,— диде ул, тавышын бераз йомшарта төшеп.— Кырык бишенче елда миңа егерме яшь иде. Аңлыйсыңмы, кырык бишенче елда бу! Ә аңа кадәр берничә ел элек безне — әле борын аслары да кибеп җитмәгән малайларны — ут эченә җибәрделәр. Нигә яшерергә, бик күбебез окоп төпләрендә мәңгегә ятып калды. Ул чакта без үтерергә дә, үләргә дә өйрәндек. Үтерү һәм үлү авыр нәрсә түгел. Ә менә яшәү авыррак. Тормышны аңларга, ул сузган дилбегәне кулыңда нык тотарга кирәк. Тормыш ул сиңа үз кулың, үз көчең белән яулап алганны гына бирә...

Минем каршымда унсигез яшьлек егет утыра, дип уйлады Нуриәхмәт. Озакламый минем өлкән улыма да унсигез тулачак. Тормыш әле аның өчен мәктәп классына эленгән шоп-шома язу тактасы. Әнә шул тактага нинди сүзләр, нинди җөмләләр язар ул? Кешеләрнең йөрәгенә үтеп керү бик читен. Үзләрендә берниндн җаваплылык

тоймыйча, агымдагы вакыйгалардан читкә тайпылырга тырышучылар да аз түгел бит әле бездә.

— Ә бит тормышта һәрнәрсәнең үз урыны бар,— дип дәвам итте ул.— Әйтик, гади бер гайканы гына алыйк. Аны ачкыч белән болтка борып кертергә кирәк. Моның максаты зур-зур металл әйберләрне бер-берләренә тоташтырып тору. Гайка гайка инде ул. Ә менә кеч-кенә, гади кешенең яшәү максаты нәрсәдән гыйбарәт соң?

Шунда Гвоздарев та телгә килде:

— Гайканы башка эш эшләргә бернинди сәләте булмаганнар борсын, әйдә.

— Син нинди сәләткә ия соң? — дип сорады Нуриәхмәт капылт кына.

— Моны мин үзем дә белмим. Нәрсәгә сәләтле икәнлегемне минем әле ачыклап бетерә алганым юк. Шулай булгач, ни өчен минем кем булачагымны, киләчәктә нәрсә эшләргә тиешлегемне башкалар белеп торырга тиеш? Мине менә кафега саксофонда уйнарга чакыралар.— Егет мәсхәрәле генә елмаеп куйды.— Эш авыр түгел, тузан эчендә бөтереләсе юк. Көне буе буш, үз иркендә. Торбага өрергә тыным җитәрлек...

Нуриәхмәт сүзсез-нисез генә башын селекте, аның чигә тамырлары бүртеп чыкты. Каршысында утырган егетнең күзләрендәге элеккеге салкынлыкны күргәч, бу сөйләшүнең хәзергә кирәксез бер нәрсә икәнлеген аңлаган хәлдә, өстәл өстендә яткан папирос кабына үрелде:

— Ярый, бар кит! Кешеләргә ни өчен өстән торып каравыңны аңласаң, яхшы эшли башларсың, аңламасаң — гариза язып китер.

— Барысын да аңладым,— диде Гвоздарев, әллә ни артык исе китмәгән кыяфәт белән.

— Юк әле, аңлап җиткермәдең. Тагын бер кат ныклабрак уйлан,— дип калды аның артыннан Нуриәхмәт.

Гвоздарев белән ике арада булып узган сөйләшү Нуриәхмәтнең нервларын ялыктырды, кәефен җибәрде. «Киләчәктә дә тәзәлми икән, безнең арабызда тагын бер бурычлы кеше артачак»,— дип уйлады ул эченнән генә.

Үзенә ышаныч күрсәтелгән кеше башкалар алдында һәр вакыт бурычлы булып кала. Түләрме ул әнә шул бурычны, әллә онытырмы? Кеше ифрат катлаулы организм. Аны ахырынача аңлап җиткерү авыр, ай-һай, авыр!

Шунда Нуриәхмәтнең уйлары яңа җайланмаларны монтажлауга барып тоташты. Ашыгыч рәвештә цехка киптерү агрегатларын, кисү машиналарын урнаштырырга кирәк. Бу машиналар Җамалиев тарафыннан тәэмин ителергә тиешле электрдан башка нәрсә эшли алалар? Шунсыз алар — үле капитал. Ә инде Нуриәхмәт Җамалиев бу эшне башкару өчен кирәкле материалны таба алмый икән, ул чагында нәрсә? Бу минутларда Нуриәхмәт үзен кем алдындадыр гаепле санады... Кирәкле нәрсәләрне складлардан табып булмый. Димәк, кемдер аларны база мөдиреннән аңа караганда алданрак эләктереп калган. Капиталь төзелеш бүлегендә инде ул үзе дә бик күпләрне туйдырып бетерде. Ә вакыт һаман уза. Җитмәсә, болай да җиткереп булмаган шул вакытны халык контролерларының завод мәктәбенә җитәкчелек итү өчен бүләргә кирәк. Чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, упаковка өчен кайтарылган ике вагон фанера кар астында күмелеп ята. Аны саклау өчен махсус биналар юк. Ул хакта кайгыртырга да бик вакыт.

Иртәгә мәктәптә занятие уздырыласы көн. Заводның баш энергетигы Коротышев электр энергиясен, парны, суны һәм акча чыгым-

нарын экономиялəү турында чыгыш ясарга тиеш. Ул, әлбәттә, Нурпәхмәт җитәкчелегендәге уналтынчы цехта электр энергиясенең ничек тотылуы турында да сөйлиячәк.

Алай гынамы әле сиңа?!

Шәхси һәм җәмәгать тормышына бәйләнешле мәшәкатьләре дә күп бит әле аның. Шул борчу-мәшәкатьләрдән аз гына вакытка булса да арынып тору өчен аңа хәзер өенә кайтып бераз ял итәргә, җылы карашлы Әкълимәсе янында булырга кирәк иде.

Ул ашыга-ашыга урамга чыкты. Салмак кына искән кичке саф җил аның барлык уйларын таратып, күңелен күтәреп җибәргәндәй булды.

## X

Бу гаиләнең язмышы — бер үк вакытта заводның, шәһәрнең һәм, ниһаять, илнең язмышы. Әйе, тамчы үзенә бөтен дөньяны сыйдыра, бәләкәй әйбердә зур нәрсәләр чагыла.

Җимерекләрне, сугыштан соңгы һәр төрле авырлыкларны җиңеп, Россия аякка басты. Аның шәһәрләре үз өсләреннән көл һәм тузанны кактылар. Яңа чор хыялга яңа канатлар куйды, хәтта кояш та яңа тугандай булып күренде. Һәм алар, Җамалиевлар да, җиргә ныграк тамыр җәйделәр, теш-тырнаклары белән эшкә беректеләр.

Шулай ук завод та үсте. Аның яңа биналарының түбәләренә кояш нурлары торган саен мулрак сирпелде. Сугыш бетеп, ике ел вакыт та үтмәде — Сумы, Тамбов шәһәрләреннән һәм башка заводлардан төрле яңа җиһазлар, җайланмалар кайта башлады.

...Рәисә гомере буе төп цехта лаборантка булып эшләде. Кырык җиденче елда цехка шатлык-сөенеч килде: су сипкеч яңа машиналар кайтты. Илнең аякка баса башлавын, заводның тамак кырып, селкенеп куюын күрү һәркем өчен куаныч иде. Ил кая — без дә шунда. Зур юлга чыгарса бары тик ил чыгара.

Күпме бәхәсләр, аңлашылмаучылыклар килеп чыкты ул чагында цехта! Яңа машиналарның алыптай гәүдәләре заводның иске стеналары арасына сыярга теләмәделәр. Ул стеналарны ватарга кирәк, ә аларны ваткан вакытта түшәм ишелеп төшәчәк иде. Бу эшне башкару өчен тимер каркас терәү хезмәтен үтәргә тиеш иде. Ә башка машиналар эшләп торганда бу ферманы ничек ябыштырырга. Шартлау була калса, бөтенесе көл-талкан булып, күккә очачак. Шуннан саклану чарасы итеп, түшәмгә кадәр брезент тарттылар. Рәисә Җамалиева, бәла-каза була-калса, брезентка сибү өчен күпме су ташыды ул чагында...

Ә аннан соң заводта эшләр бер-бер артлы җайга салынып китте... Мең тугыз йөз илленче елда пыялалар ябыштыру өчен пленка җитештерә торган цех сафка керде. Илле икенче елда илнең магазиннары прилавкаларында төсле пленка күренә башлады. Илле дүртенче-илле бишенче елларда тагын да куәтлерәк су сиптерү машиналары эшкә җигелде һәм пленканың барлык төрләрен эшләп чыгару ике тапкырга артты. Моннан тыш эмульсия сыекчасын синтезлау цехы үзләштерелде. Мең тугыз йөз илле җиденче елда суыткыч станция сафка басты. Ә инде зур куәткә ия булган яңа машиналар җидееллык башыннан артканнан-арта барды. Яңа корпусларның түбәләрен гүя күзгә күренмәгән нindидер көч күккә сөйри иде.

Читтән килүчеләр моңа гаҗәпләнми булдыра алмадылар:

— Нәрсә бу сезнең, төзелешме, әллә заводмы? — диләр иде алар.

Яңа корпусларга такта, җиһазлар, эремә һәм башка материаллар ташучы краннарның саны бермә-бер артты. Иңнәренә тимер-бетон каркаслар, корыч торбалар төягән көчле МАЗлар йөрешләрен тагын да тизләттеләр.

...Вафат булыр алдыннан Хуҗи карт, ничектер, көннәрнең берендә заводка килде. Вакытлы пропуск белән аны проходной аша уздырдылар. Уллары белән бергә ул заводны шактый вакыт карап йөрде. Күп нәрсәләр белән кызыксынды, үткәннәрне искә төшерде:

— Әйтерсең акрынлап җанымны үзгәрттеләр минем,— дигән иде ул чагында Хуҗи карт.— Игенчедән эшче сыйныф арасына килеп эләктем. Икенче төрле әйткәндә, җаным үз урынында калды, ә менә кулларга башка эш табылды.

Илленче... Алтмышынчы еллар...

Шушы елларда Вәлиәхмәт Җамалиев партия сафларына керде. Ә Нуриәхмәт күптән инде партиядә иде.

Шулай итеп, завод партия оешмасы тагын бер кадровый эшче исәбенә үсте. Дөрес, бу егет аңа кадәр дә үз эшен башкару белән генә канәгатьләнмәде. Аны әле завкомга сайладылар, парткомнан аңа әледән-әле поручениеләр бирделәр. Үз эшендә дә аны яхшы яктан гына беләләр иде.

Мең тугыз йөз илле өченче елда, армия сафларыннан ул яңадан заводка кайтканда, биредә, мәсәлән, электр ярдәмендә чорнаучылар юк диярлек дәрәҗәдә аз иде. Көчле моторлар яна, ә белгечләр җитми. Янган двигательне яки трансформаторны яңадан чорнау бик катлаулы һәм нечкә эш. Буталган схемаларны җентекләп тикшерү өчен ювелирга хас булган төгәллек белән эшләү сорала. Моторлар көн саен яналар, заводта исә алар меңәрләп исәпләнә. Беренче моторны чорнап бирү нинди зур шатлык булган иде Вәлиәхмәткә! Ә аннан эшләр акрынлап эзгә салынды. Аның үзенең шәкертләре барлыкка килде. Бригадир итеп билгеләделәр... Бу хакта барысы да беләләр иде. Ничә еллар буе кулга-кул тотынышып эшләделәр. Алда әле тагын күпме бергә эшләргә туры киләчәк. Ә шулай да Вәлиәхмәтнең күңеле тыныч түгел иде. Җыелышка ул барысыннан да алданрак килеп, бер ялгызы дулкынланып утырды. Аның мондый халәттә булуы бик табигый иде, әлбәттә. Бу хакта ул ни гомер хыялланып йөрде!..

...Моннан байтак вакыт элегрәк мастер Белов аңа болай дигән иде:

— Әйдә, Хузич, әзерлән. Рекомендация бирәм. Сиңа бер дә куркып торасы юк. Әгәр шулай әйтергә яраса, син бит инде күптән партияле кеше.

Бу сөйләшү болай гына, сүз арасында гына булып узган иде шикелле. Әмма ул онытылмады. Киресенчә, конкретлаша гына төште. Һәм аның ахыргы нәтиҗәсе кешене шатлыклы, шул ук вакытта иң җаваплы көнгә китерде. Вәлиәхмәт Җамалиев исә үзе бу көннең киләчәгенә күңеленнән күптән ышанган иде инде. Кеше организмы үзендә энергия запасы саклый. Вәлиәхмәт моны башка барлык кешедән дә ныграк тойды һәм үзендәге әнә шул энергияне тагын да арттырырга мөмкин булачагын ачык аңлады.

Әйе, үзеңне тормыш белән бәйләгән җепләрне өзәргә түгел, киресенчә, ныгытырга, тармакландырырга кирәк. Һәм менә шуңа күрә, актив кеше буларак, үз энергиясенең күпчелек өлешен ул җәмәгать эшенә бирде.

Тормыш шулай инде, дип уйланды ул, һәрбер шәхси эшең, барыннан да элек, тирән эчтәлекле гомуми эшкә ни дәрәҗәдә кушылуы

белән бәяләнә. Беренче моторны ничек эшләтә башлавы кинәт исенә килеп төште. Шул чак кемдер үзенең авыр кулларын аның иңенә салды. Вәлиәхмәт сискәнеп китте һәм артына борылып карады. Анда, күзләрен кысып елмайган хәлдә, озын буйлы мастер Белов басып тора иде.

— Нәрсә уйга чумдың, ә?

Вәлиәхмәт Җамалиев дистәләрчә күзләр каршында берүзе басып калды. Кызыл почмактагы пар батареялары артык нык җылыта идеме, әллә эчке дулкынлануы көчле булдымы — үзенең биографиясен кыскача сөйләгәннән соң, Вәлиәхмәт тирләп-пешеп чыкты. Бу минутта аның өчен электромоторларны ремонтлау биография сөйләүгә караганда җиңелрәк сыман тоелды. Залда утыручыларның бердәм кул күтәрүләрен күрү дә аның бу минуттагы хәлен җиңеләйтмәде.

Ә тормыш алга таба дәвам итүендә булды. Сабыйлар, бишекләреннән һәм коляскаларыннан төшеп, идән буйлап мүкәләп йөри башладылар. Тора-бара урындыкларга үрмәләделәр. Аннан, портфельләрен тотып, мәктәп юлы буйлап атлап киттеләр. Ара-тирә аларның инде соңгарак калып кайткан чаклары да булгалады...

Вәлиәхмәтнең олы кызы Зөбәрҗәт, кайбер көннәрне шулай соңгарыбрак кайта да, гаепле кеше сыман, өйдәгеләргә күтәрелеп карарга кыймый тора. Шул ук вакытта аның күзләрендә шатлык очкыннары уйнаклый... Яшьлек... Кешенең кешегә ныграк тартыла башлаган чагы.

— Син тиз керәсеңме инде, Дамир? — дип сорый Әкълимә улыннан.

— Мин монда гына, әни. Тагын азрак кына торыйм инде.— Ә күләгәдә кемнеңдер ак шәүләсе тирбәлеп кала һәм назлы үпкә катыш әйткән сүзләре ишетелә:

— Син әллә минем яныма әниең рөхсәте белән генә чыгасыңмы?

— Таптың сөйләр сүз. Әни ул болай гына, читтән генә булса да сиңа карыйсы, сине күрәсе киләдер.

— Шулайдыр инде. Ә син нигә безгә тагын кермисең? Дәресләрне бергәләп әзерләр идек.

— Уңайсыз бит.

Ана кече улы Әмирнең дә авыр-авыр сулап куйгалавын еш ишетә... Яшьлек... Гомернең кабатланмас чоры...

Әйе, тормыш дәвам итә. Аттестат һәм дипломнарны балалар гына алып калмады. Техник белемгә ия булулары турында Нуриәхмәт һәм Вәлиәхмәт Җамалиевларның үзләренең дә хәзер катыргы тышлы таныклыклары бар.

Ә бит кырыкны узгач моңа ирешү майлы ботка ашау түгел.

Вәлиәхмәтнең кыяр-кыймас кына атлап, беренче тапкыр завод капкасын ачып керүенә кайчан гына иде бит әле. Аннан бирле инде күпме сулар аккан. Ул инде завод электр мастерскоеның өлкән мастеры булып күтәрелде. Аңа обмотчиклар бригадасы белән дә, электр двигательләре ремонтчылары, артезиан скважиналарын эшләтү аппаратурасы һәм югары көчәнешле җиһазларны ремонтлаучылар белән дә җитәкчелек итәргә туры килде. Завод идарәсенең капиталь төзелеш бүлегендә инженер булып эшли башлагач, мәшәкатьләр тагын да күбәйде. Ул елларда Нуриәхмәт Җамалиевның да адымнары эредәнрәк китте. Ул егерме ел буе цех энергетигы йөген сөйрәде. Аның җаваплылыгына тапшырылган җиһазлар да артканнанартты, цехның куәте үсте, яңадан-яңа хезмәт бурычлары өстәлде.

Тормыш күз иярмәс тизлек белән алга баруында дәвам итте.

## XI

Уйлар тагын үткәннәргә әйләнеп кайта.

Иртәнге як иде. Хуҗи карт бит-кулларын салкын су белән юды да өстәл артына кереп утырды, ашыкмый гына тамак туйдырды. Аннан акрын гына торып, тәрәзә каршына килде. Аның уенча, бүген көн аяз һәм матур булырга тиеш иде.

Менә ул капкадан чыгып, салмак кына адымнар белән кырга таба юнәлде. Анда, бер-берләрен узышып, комбайннар эшли. Моннан кырык ел элек тә нәкъ шушындый ук якты, көнелле иртә иде. Ул чакта да урак өсте иде. Алар әле яңа гына тешәлгән уракларын иртәнге чыкта чылата-чылата ашлык урдылар. Аннан соң озак еллар буе шәһәрдә яшәргә туры килсә дә, уракка төшүнең беренче минутларында була торган рәхәтлек аның хәтереннән беркайчан да китмәде. Ул менә хәзер дә тәнендә шундый ук җиңеллек, шулай ук рәхәтлек тоеп, иген кырлары буйлап атлый. Кем белә, игеннәрнең җилдә талгын гына тирбәлеп утыруларын бәлки ул соңгы тапкыр күрә торгандыр...

Урак өсте... Крестьян хезмәтенең мәгънәсен бөтен тирәнлеге белән ачып бирә торган киеренке көннәр... Хуҗи картның тормышы да буеннан-буена урак өстенә охшап узды.

Вәлиәхмәт Җамалиев, язгы көннәрнең берсендә ата-бабасының эзләре калган һәм үзе шунда тәүге тапкыр күзен ачкан җирләргә аяк баскач, этисенең соңгы тапкыр басуга чыгып йөрүен исенә төшерде. Шунда аның күңелен бик күп төрле уйлар чолгап алды.

Һәркемнең туган җире, туган туфрагы бар. Кеше әнә шул туфракка күзгә күренмәс җепләр белән бәйләнгән. Соңгы елларда Хуҗи карт та Чирмешән якларына еш кайткалап йөрде, анда аның әле туган-тумачалары шактый күп иде. Үзе үлгәннән соң бу яклардан улларының да әйләнеп килүләрен, этисе һәм әнисенең каберләре өстеннән туфрак алып кайтып үзенең каберенә салуларын васыять итеп калдырган иде.

Менә авыл зираты. Тирә-якны тирән тынлык чолгап алган. Бары тик авылдагы кайсыдыр йортның ишегалдында казлар каңгылдашкан тавыш кына ишетелә. Якында гына кечкенә инеш ага. Аның аргы ягында күз күреме җитмәс кырлар сузыла. Авылга алар машинага утырып кайталар. Колхоз шоферы Вәлиәхмәтләрнең чыбык очы туганы икән.

— Туган туфрак тарта, диген, ә, Вәлиәхмәт абый? — ди ул, башланган сүзен дәвам итеп.— Шулай инде, һәркемгә үзенең туган ягы кадерле.

Үз уйларына чумган Вәлиәхмәт аңа кыска гына итеп җавап кайтара: — Сабый чактан ук кендегебез шунда бөреккән булгач, аратирә кайткалап китәбез менә.— Аның карашы кояш нурлары уйнаклаган кырларга, асфальт җәелгән тигез юлларга текәлгән, әйтерсең шул юллар чатында ул үзенең бала чагы белән кабат очраша.

## XII

Җәй үтеп китте. Инде имтиханнар да артта калды. Шактый еллар сине үз кочагыннан җибәргән мәктәп белән саубуллашканга байтак көннәр узды. Дамир ул көннәрнең күбесен Казанка буенда үткәрде. Салкынча суда коенып, кайнар комда кызынып ятулары үзе бер рәхәтлек бирә иде аңа. Менә ул судан чыга да кызган ком эченә күмелеп, елга өстендә йөзгән моторлы көймәләрне, ак болытларга үрелгән Сөембикә манарасын күзәтә. Кипшенгән тәне буйлап ком

шуыша. Вакыт та әнә шулай бер урында өелеп тора алмаган ком шикелле акрын гына каядыр ашыга. Аны бушка уздырмас өчен нәрсәдер эшләргә кирәк. Дамир нәрсәдер эшли башлаячак әнә шул көнне көтә.

Һәм ул көн җитте. Яшь егет кыяр-кыймас кына завод проходноенда торучы каравылчыга беренче тапкыр пропуск кәгазен сузды. Бу әле вакытлыча гына бирелгән пропуск иде. Икенче төрлерәк итеп әйткәндә, заводка беренче разведка гына иде әле бу.

Кайда гына булмадылар, нәрсәләр белән генә танышмадылар алар ул көнне! Нуриәхмәт улын завод белән таныштырганда, йөзенә бәреп чыккан горурлык билгеләрен яшерә алмады. Заводның бөтен тарихын ул янә бер тапкыр йөрәге аша үткәрде. Әйе, аның бөтен гомере диярлек шушында үтте. Ә улына завод ничегрәк тәэсир итәр? Дөрес, заводтагы эшләр турында өйдә һәр вакыт сөйләшәләр. Ул сөйләшүләр Дамирның канына бишектән үк сеңгән булырга тиеш. Тик шулай да аның өчен әле биредә һәрнәрсә яңа, һәрнәрсә серле...

Нуриәхмәтнең әнисе һәм хатыны Әкълимә озак еллар буе эшләгән визитаж участогында Дамирны күзгә төртсәң күренмәслек куе караңгылык каршылады. Бу караңгылыкның пленкага яктылык төшмәсен өчен кирәк булуын Дамир белә иде инде. Улы янында басып торган Нуриәхмәт тагын истәлекләргә бирелде, 1939 елда ул да үзенең хезмәт юлын нәкъ менә шушы урында башлап җибәргән иде.

— Менә сиңа өстәмә көч,— дигән иде мастер Виктор Попцев аны бригадирга тәкъдим итеп.

Бригадир яшь эшчене стена кырына алып килеп, кыска гына итеп әйткән иде:

— Электромонтаж эшләре алып барабыз. Менә стенага тишекләр тиш.

Дамирның да эше шулайрак башланып китте. Әтисе шикелле үк ул да электр эшен сайлап алды. Электромонтер булып эшли башлады. Ә инде унсигез яшь тулгач, КИП лабораториясенә күчте. Кичләрен химия-технология институтына лекцияләр тыңларга йөрде.

Көннәр агыла торды. Дамир эшкә күнеккәннән-күнегә барды. Заводта ул үзенә аерылмас дуслар, яхшы иптәшләр тапты.

Кайбер иртәләрдә алар, Җамалиевлар токымы вәкилләре, эшкә бергәләшеп баралар. Юлда очраган танышлары белән исәнләшәисәнләшә, завод капкасы янына якынлашканда, арадан берсе Дамирга күз кысып куя:

— Кара әле, Дамир, кем килә тегеннән?..

Егетнең йөзенә кызыллык йөгерә. Шул ук вакытта ул тормыш юлыннан бергә атлап барырлык тиң дус табуына сөенеп бетә алмый.

Көннәр агыла торды. Җитмешенче елның июлендә Дамир Җамалиевны да партия сафына кабул иттеләр, ә ике елдан соң ул үзенең туен уздырды.

Заводка килгән беренче көннәрендә ул үзенең киләчәктә зур хөрмәткә лаек кеше булачагы, пленкалар сынау станциясенең өлкән инженеры булып эшләячәге турында бәлки уена да китермәгәндер. Ул чагында аның эш стажы еллар белән түгел, нибары көннәр белән генә исәпләнә иде әле.

## Диләрә Зөбәерова

# ӘМАНӘТ



Кеше горур яңгырый, дигән остазыбыз М. Горький. Бу сүзләрне бик күп телләрдә миллионнар кабатлый.

Кеше планетага җан, ямь, мәхәббәт, җиңү, җыр алып килгән. Кеше — мәңгелек. Бабайлар гомерен этиләр, этиләр гомерен без дәвам итәбез. Безнең гомер әманәт булып яңа буыннарга күчә.

Даһи юлбашчыларыбыз белән бергә сәхифәләргә теркәлгән Аристотель, Суворов, Җәлил, Ландау һәм тагын бик күпләр бар. Шулар янәшәсендә үк исемнәре мәгълүм булмаган миллионнар яңгыраганнар. Алар газиз икмәк иккәннәр. Алар азатлык яулаганнар. Мәскәүне, Нева ярындагы гүзәл каланы, Помпейны, Болгарны, Парижны алар салганнар. Кеше галәмгә юл ачты. Кеше айга аяк басты. Чаллыда, әкияттәй, күз ачып йомганчы пәйда булган биек йортларны, таш пулатларны Кеше корды, кеше койды.

Бишьеллыкның бөек гигантлары
һаман үсә,
һаман күккә таба үрелә...

Такташыбыз калдырган әманәт хат һаман укыла, һаман үтәлә: инде без тугызынчы бишьеллыкның соңгы тупсасында... Үзенә дөньяның алты кыйтгасын җәлеп иткән атаклы автогигантны да Кеше сала, кеше күтәрә.

Кайда Кеше — анда кояш, кайда көрәш, анда корылыш. Кайда Кеше — анда бәхет, анда җиңү, анда мәхәббәт, анда туй, анда бишек.

* * *

«Батыр» якорь салган Чаллының бүген әнә шундый җанлы, әнә шундый шаулы чагы. Әле кайчан гына авыл сукмаклары белән тоташкан бу райүзәк хәзер өч каладан тора: Камгэс шәһәре, Яңа кала, Кызыл Чаллы.

Сиреньнәр хуш ис тараткан май киче. Җәлил проспекты буйлап дәртле яшьлек атлый. «Каенлык» кафесында «Туй җыры»н такмаклыйлар. Яшь наратлар буйлый салынган ак бинага таба маңгаена «Кызыл Хаҗ» тамгасы куңган машина чаба. Аны зәңгәр ишекләрен киереп ачып ак халатлылар каршылый.

ҚамАЗ кайнап торган данлы елларның артериясе, тормышыбызның яшәү пульсы ул. Географик карта каршына бас: аны чуарлаган шәһәрләрнең барысы белән дә Чаллы бәйләнештә. Шәһәрара телефон кенәнә илле кала белән кырык бер телдә сөйләшә. Монда илебезнең төрле почмакларыннан җыйналган ташчыны да, бульдозерчыны да, шоферны да, укытучыны да, сатучыны да, галимне дә, врачны да — барысын да бер исем берләштерә — алар автогигант төзүчеләр. Монда эшнең барысы да кызу темпта. Рекламалардагы өндәүнең, рупорларда яңгыраган чакыруның, төзүче күңелен дулкынландырган омтылышның мәгънәсе зур: тугызынчы бишьеллыкның өченче елы — хәлиткеч ел. Ил алдында рапорт бирәсең, хәзер бул!

Ашык — абынма. Арсаң — сер бирмә. Чорына лаеклы Қеше бул!

Утыз урынлы класста кырык биш бала укый. Өлгереш югары. Халык артисты концерттан соң кунарга Түбән Қамага китә. Қунак йортында урын юк. Аның каравы, күңеле шат аның. Илһамны ҚамАЗ ел саен алкышлый. Ул атаклы төзүчеләрнең җан дусты.

150 урынлы бала тудыру йортында — 200 кеше... Алар ыңгырашмый, алар тарсынмый. Алар ышанычлы кулларда. Илле врач урынына нибары 25 кенә. Шулай да алар өлгерә. Вакытлыча туган мәшәкать, минутлык ыгы-зыгы чыныккан яшьләрне какшатмый, кыюларны каушата алмый. Ә менә инде җиңел кәсеп, кызыл сәмән, шәп фатир гына өмет итеп килүче узгынчыларга ҚамАЗ төс түгел. Юл такыр аларга, эш сөймәгәннәр китә бирсеннәр. Бөек төзелешләр көчле рухлы кешеләрне генә таный. Қеше булган кеше генә монда үз урынын таба, тамыр җибәрә, гаилә кора, завод сала, трамвай йөртә, китап яза.

* * *

Тарихка «Батыр» яралган көн булып кергән 1969 елның унөченче декабрендә Илдар Мостафин туа. ҚамАЗ яшьтәше булган Илдар бүген озын чалбардан йөри. Беренче камазикны кабул иткән доктор Зәйтүнә ханым Қашапова автогигантка нигез салучылар сафында Коммунистлар партиясенә керде, беренче бала тудыру йортына баш врач итеп билгеләнде.

Қеше шулай күтәрелә. Ангара буендагы алтмыш йортлы авылда туып үскән Себер кызы бүген фасонлы заман каласында күренекле доктор. Себер сылуларына хас зифа буе, саргылт чәче, утызны узганда сирәгәя торган сипкеле, түгәрәк үткер күзләре белән хәтердә кала Зәйтүнә.

Хәбәрче теленә гел килә торган гадәти сораулар:

— Сез тумыштан доктор булып тугансыз. Профессиягездән канәгатьсездер, әйеме?

— Бу турыда уйларга вакыт юк.

— Сезне берәү шаяртыпмы, яратыпмы «ҚамАЗ бәбиләренең «кендек әбисе» диде әле, үпкәләмисезме?

— Безнең халык шундый шук инде ул, — диде докторым, елмайганда күз камаштыргыч ак тешләрен күрсәтеп.— Ә беләсегез килсә, минем дәү әнинең борынгы һөнәре булган ул. Әмма алар кулыннан күпме корбаннар узган...

Алайса, мин сезгә тормышымнан бер вакыйга сөйлим.

— Минем әнкәйгә унике кеше әнкәй дип дәште. Тик «дәү әни дию-чeләрен» генә ишетү насыйп булмаган аңа.

Узган кичерешләрнең шәүләсе күзләргә төшә. Менә ул йомшак куллары белән яңагын учлый, саран гына сүзләр белән үткәннәрен телгә ала.

* * *

Аның әнисе мәрхүмә Марзия апа итәк тулы бала белән яшьли тол калган. «Биш бала бит немало» дип сызлана торган булган ул сагышлы чакларында.

Аның әтисе мәрхүм Галим абзый да дүрт балага үзе ана, үзе ата вазифасын үти. Иргә хатын табылыр табылуын, тик балаларга ана табылырмы?..

Таулар белән таулар гына очрашмый, язмыш ике ялгызакны очраштырып кавыштыра, бәхетле итә.

Гөрләшеп гомер итәләр алар. Тугыз бала өстенә унынчысы, унберенчесе, ниһаять, уникенчесе дә өстәлә. Уникенчесе Зәйтүнәбез булсын, ди, унынчысы кем дип сорагыз сез?..

Зәйтүнә сүз бу уңайга борылгач халат кесәсеннән яулык эзли. Арган ул бүген, шуның өстенә — әче хатирәләр... Нишлисең, доктор да кеше бит. Аның да күңеле нечкәрә бела, аның да нервлары чылбырдан түгелләр.

Марзия апа шәфкать иясе була, иренең улларын үги итмәгән. Өлкәнен өйләндергәч, килененә ерак әбисеннән мираска калган көмеш беләзеген суза. «Туганлыгыбыз тышаулансын, гомергә берләшик».

Тик теләкнең барысы да кабул булмый шул. Үлем дигәнең яшенкартын тикшереп тормый, туйларына тугыз ай тулганда килен гүр иясе була. Ә бәбие... бәбие исән кала. Сәбәбе шул, үзе бала имезүче әнием икенче имчәген онычына каптырган.

Бала тапканда вафат булганнар ул заманда гадәти бәла генә. Әнисез ятимнәр әтисез ятимнәрдән дә күбрәк булган.

— Мин Могаззимә тәтәмнең Габдрахман агам кызы икәнлеген үсеп буйга җиткәч кенә ишеттем, — ди Зәйтүнә ханым. — Менә ни өчен әнкәй ашны башлап аңа бүлгән, аның күлмәкләрен генә чигеп, челтәрләп тегә торган булган икән. Кимсенмәсен, боегып үсмәсен, дигәндер инде. Менә ни өчен Могаззимә тәтә әнкәйгә «әнкәй», әткәйгә «бабай» дип дәшкән икән...

Могаззимә тәтәнең инде хәзер бүген тотып кияүгә бирерлек кызлары, солдатка алынасы улы бар. Минем дә малайлар үсеп беттеләр, тик дәү әни дип дәшәр кешеләре генә юк.

Мин моңсу уйларны таратмак булып сүзне икенчегә борам:

— Себер кызының бу якларга очып төшүе үзе бер тәэсирле хикәядер, ә?!

— Безнең әниебез, сөйләгәнемчә, нәфис күңелле, шигъри җанлы кеше иде. Аның гарәпчә, латинча, русча басылган Тукай китаплары, Фатих Әмирхан хикәяләре бар. Үзе бик күп җырлар, бәетләр белә. Эшләпә башлы граммофонында Габәши, Сәйдәш «табаларын» уйната. Шуңа күрәдер, без рус дуслар арасында бердәнбер татар гаиләсе саналсак та, туган теләбезнең теле туган телдә ачылды, урамда, мәктәптә русча сөйләшсәк тә, өйдә татарча аңлаштык. Мине Себер башкаласы — Новосибирск институтына озатканда әнкәем өч әманәт әйтте:

— Тәүфыйклы йөр. Тырышып укы. Кеше булып аякка баскач туган ягыңа кайт. Олыларга илтифатлы, сабыйларга мәрхәмәтле бул, — диде.

Әманәткә хыянәт итмәдем. Күрәсез...

Күрәм, күрәм. Зәйтүнә, КамАЗның бүгенге кешеләре барысы да синең кебек бәхетле, кыю, матур киләчәкле кешеләр булсын иде.

— Миннән көчлерәкләре, хөрмәтлерәкләре күбрәк!

Әлбәттә, барысы да бар. Әйтик, прораб Хәлиуллин сезнең күршегез икән?

— Асуанны төзешкән, татарча, русча, һиндчә сөйләшә торган батырмы?!

— Иптәшегез Исламның дусты бетончы Галимов...

— Аның рәсеме Мактау тактасында. Шигырьләр яза ул.

— «Ураган» исеме алган куәтле «МАЗ-543» машинасын йөртүче Сәлмән...

— Газетада рәсемен күрдем.

— Охотникова...

— Акушер-гинеколог Васильевнамы? Минем хезмәттәшем ул. Тимертаудан килде. Магнитка.ны төзешкән, ягъни нәни Магнитка кешеләрен кабул иткән «кендек апа»лары инде.

1973 елның 7 апрелендә район газетасы «Коммунизм байрагы»нда белдерү бар: «Ленинабадның үзәгендә барлык уңайлыклары, балконы булган ике бүлмәле квартирамны Чаллыдагы теләсә нинди почмакка алыштырам. Адресның иясе ирле-хатынлы инженерлар икән. Автозавод салышасылары, дөньяны шаулаткан бөек корылышның шаһите буласылары килә. Шундыйрак белдерүләр белән урам рекламалары тулган.

Дәүләтебезнең көч-куәтен арттырачак мондый төзелешләргә партиябез кемнәрне чакырасын яхшы белә. Дәүләт премиясе лауреаты, башкорт халык шагыйре Мостай Кәрим:

Ерак юлга иярлиләр
Атларның иң яхшысын,
Зур эшләргә озаталар
Ирләрнең иң затлысын! —

ди. Шәп әйтә.

* * *

— Рәхим итегез, — ди доктор кар төсле халат сузып, — битегезгә маска бәйләгез. Хәзер мин әнә шул затлы нәселнең киләчәк буыннары белән таныштырам үзегезне.

Таңда туган малай нәни башын ак мендәргә салып йокыга талган. Сул беләгендә белешмәсе. Хәзергә әнисе исемен йөртә: Мөгаллимә Шакирова. Буе — алтмыш сантиметр, авырлыгы — өч мең 750 грамм. Әтиәнисе Братск төзешкәннәр, хәзер Чаллыны яңарталар.

Тиманова инде икенче көнен яши... Әнисе башкорт кызы. Унтугызы гына тулган. Әтисе Мәскәү егете. Фельдшер белән шоферны КамАЗ кавыштырган.

— Теләкләре зурдан иде әле аларның, — ди ак калфаклы няня, елмаеп,— игез бала өмет иттеләр. Берьюлы уллы да, кызлы да буласылары килде, янәсе. Юк, мин әйтәм. Сабыр итегез әле...

Кулибякны инде «карт бәби» диләр. Бер атна яшәргә өлгергән... Кабул итү бүлмәсендә ефәк юрганын кочаклап әтисе утыра. Каршы алырга килгән.

Тик биләүдә төшләнеп көлеп ятучы менә бу сабыйның гына әтисе күренми...

— Шундыйрак бәхетсез аналар да очрап куя, — ди доктор, авыр сулап. Сез бая гына искә алган шагыйрь:

...Ирләр чәчәкләрне хатыннарга
Төнгә каршы бүләк итәләр,
Шиңгән чәчәк белән каршылана
Шуңа күрә бик күп иртәләр...—

диме?..

Шундый тыныч, ямьле заманда да этисез үскән сабыйларны күрсәм, йөрәгем әрни минем.

* * *

Яшь наратлыклар арасында калыккан бу больница шәһәрчеге әле төзелүен дәвам итә. Кеше сәламәт булса, акылы сәламәт аның. Дөнья акыллылар, кешелекләр алдында баш ия. Шуңа күрә ремонт-инструменталь заводы белән яңа больницага нигез бер көнне салынган.

Мин әле һаман шушы тирәдә йөрим, бала табу йорты каршында басып торам. Өченче каттагы тәрәзәләрдән бөркелгән яктылык күзне чагылдыра. Анда операция... кеше гомере өчен җан-фәрманга көрәш бара.

* * *

Төзелеш гөрелтесе арасындагы ак теплоходтай мәһабәт йорт аларныкы. Тәрәзәләрдә төрле нурлар. Ал, зәңгәр, яшел шторалар төрле төсләр биргән. Шулай.... һәркемнең үз төсе, үз нуры, үз моңы, үз көе бар. Ә менә бу кырый тәрәзәләрдәге утны Кашаповлар кабызган. Ачык балконнан «Айлы соната» агыла. Ринат музыка мәктәбенә йөри бит... Аталы-уллы икәү (Ислам белән Рөстәм) зәңгәр экранга төбәлгәннәр. Ә кухня өстәлендә бер сәгать элек җәелгән табын аны көтә. Мин икенче көнне сак кына кичәге операциянең нәтиҗәсен сорыйм. Зәйтүнә бер мәлгә ачылып китә. Димәк, җиңгәннәр! Әмма, бер сәгатьтән икенче операция...

— Медицина өлкәсендә гинекологиянең иң җаваплы тармак икәнен беләсезме? — диде ул соңгы тапкыр очрашканда.

— Чамалыйм.

— Чамалау — эшне нечкәлегенә кадәр аңламау, дигән сүз. Гинеколог бит берьюлы ике кеше өчен көрәшә. Аның кулында һәр вакытта да ике кеше язмышы. Ана һәм бала язмышы!

* * *

Мин, бүгенгә бишек кошы, әмма иртәгә бабалары-этиләре салган Кама автогигантында машина ясаячак бу кешеләр турында сөйләгәндә, аларның доктор апалары Зәйтүнә турында очраклы гына сүз катмадым. Хәзерге чынбарлыкта да очравы мөмкин булган авырлыкларны җиңүче, миһербанлы ата-ана тәрбиясен алган, Ватаныбыз тудырган уңай шартлардан файдалана белгән, максатына ирешкән һәм үзен бәхетле иткән ил алдында мәңге тугрылыклы бу Кеше бүгенге Чаллыда яшәүче меңнәрнең бер вәкиле.

* * *

Тагын бер көн узды. Кичәге сүлпән, болытлы көнгә алмашка кояшлы иртә туды. Яшь калада яңа калыккан ак бина каршында тормыш өзлексез дәвам итә. Ишек төбендә умырзая кочаклаган ерык авызлы этиләр йөри. Маңгаена «Кызыл Хаҗ» калфагы кадаклаган машиналар выжлап туктый. Шакмак билле таксилар бәби кочаклаган пассажирларын көтә.

* * *

Төкле аягың белән, яңа каланың яңа кешесе!

Бу аяз иртә, бу чәчәкләр, бу елмаю, бу күңелле дөнья — барысы да Синеке. Үтәр бер ел, син аякка басарсың. Үтәр унҗиде ел — мәктәп ишеген ябарсың. Алда мавыктыргыч юллар көтәр. Кайсын гына сайласаң да: тузан заводына атлыйсыңмы, институтка имтихан тотасыңмы, яисә сине илебезнең башка почмагында кабынган яңа утлар, яңа гөрелтеләр тартамы, анкета тутырганда беренче җөмләң КамАЗ дип башланыр. Шунда син бүгенге көннәрнең авырлыгын, шатлыгын, данын үз җилкәләрендә татыган әти-әниләреңне уйларсың. Бәлки бәби туең син дөньяга килгән көнне генә өлгергән яңа йортта гөрләгәндер. Бәлки сине больницадан тарсынмый үз фатирларына сыендырган киң күңелле кешеләр каршылагандыр. Бәлки... вакытлыча бер-ике атна электр елыткычлы тәгәрмәчсез вагонда яшәгәнсеңдер. Лифтлы, заллы, балконлы, кояшлы квартирага шуннан күчкәнсеңдер. Бу хакта сиңа шушы көннәрдә генә язылып ята торган романнар, поэмалар сөйләр. Андагы геройларны аналарың-аталарың, агаларың-апаларың итеп танырсың. Ә менә хәзер бүгенге бәби кеше, киләчәкнең олы кешесе, колагыңа үрелеп шуны әйтәбез:

— Ватаның, атаң-анаң әманәтен тот! Мөбарәк хәреф белән языла торган Кеше бул. Ил иминлеген сакла. Дәрәҗәңне акла. Җиргә үз сукмагыңны сал. Кулларың могҗиза корсын. Диңгездә йөзәр җилкәнең, галәмгә алып менәр канатың булсын. Кыскасы, күкләргә ашучы гигантлар күтәргән каладашларыңа лаеклы алмаш бул!

## Кәшиф Рәхим

# ТАБИГАТЬ БЕЛӘН ОЧРАШКАНДА

## Импорт товарлар арасында чыпчыклар



Әти мәрхүм әйтә торган иде: «Улым, берәр эшкә тотынырга ниятләсәң, сразы зурдан купма, башта вак-төяктән генә башла»,— ди торган иде.

Әти мәрхүмнең васыятен истә тотып, сүзне чыпчыклардан гына башлап җибәрергә булдым. Беренчедән, чыпчыклар безнең якның иң вак кошлары, икенчедән, алар миңа бик якыннар. Чыпчыклар мин йоклый торган кровать турысында тәрәзә наличнигы белән бүрәнә арасында гомер итәләр. Безне стена гына аерып тора. Ояларында һич тә тавышланышмыйлар. Йоклаганда авызларына кечкенә кавырсын кисәге яки яфрак шикелле берәр әйбер кабып йоклаганнарын беләм мин аларның. Таң беленә башлау белән, чыпчыкларның җиңелчә генә кыштырдаулары ишетелә. Бераздан өй эчендә йоклаган карт белән карчыкның берәрсе алдан уянып: «Торырга вакыт түгелме икән? Таң атты бугай, чәй куеп җибәрмисеңме?» — дию кебек итеп иренеп кенә чыркылдап куя. Икенче чыпчык аңар каршы әлеге йокылы-уяулы карчыкның: «Бүгенгә әллә самаварны үзең генә куясыңмы, әллә нигә билем авыртып тора»,— дию кебегрәк итеп җавап кайтара. Иртән торгач, юыну, өсне-башны тәртипкә китерү, физзарядка ясап алуны — барлык тере табигать өчен кагыйдә булган тәртипне чыпчыклар да белә. Алар, ояларыннан очып чыгу белән, алмагач ботагына куналар да, әле теге якка, әле бу якка карап сикергәләп, физзарядка ясап алалар, аннан соң нәни томшыклары белән канатларын, каурыйларын аралап тазарталар һәм тик шуннан соң гына көндәлек эшкә — азык эзләргә очып китәләр.

Минем чыпчыкларым бик күп: алты тәрәзә башында икешәрдән уникe оя, ә карнизларда күпмедер тагын? Мин үзебезнең чыпчыкларны барын да танып бетерә алмыйм. Бердән, алар бик күп, икенчедән, минем аларга тамга салып чыкканым да юк. Шулай булса да безнең

чыпчыклар минем үземне таныйлар, миннән курыкмыйлар, алай гына да түгел, оялары тирәсенә мәче килә башласа, чыркылдашып миңа мөрәҗәгать итәләр.

Бер укытучы I нче класста укучылардан: «Чыпчыклар нәрсә белән туеналар?» — дип сораган икән, укучылар бертавыштан: — «Тавыкларга куйган җим белән туеналар»,— дип җавап биргәннәр.

Бу дөресен дә шулай. Чыпчыклар тавык җимен бик яратып ашыйлар. Тавыкларга килсәк, алар чыпчыкларны үзләренә куйган азыктан куып җибәрү турында уйлап та карамыйлар. «Әйдә, ашасыннар бәләкәчләр!» — диләр, күрәсең. Кошларга перепись вакытында кара каргалар, чәүкәләр, күгәрченнәр, чыпчыклар, сыерчыклар үзләрен «йорт кошлары» дип яздыралар икән, ди. Бу, мөгаен, дөрестер.

Әмма шушы кечкенә кошчыкларга карата дошманлык саклап йөрүче өлкән кешеләрне дә очратырга туры килә. Күптән түгел генә минем ишек төбемә үк килеп бере артыннан бере ике чыпчык үлде. Авыр кышны уздырып, күңелле язны каршылаганда һәлак булу — кызганыч хәл. Мин чыпчыкларны ярып ашказаннарын тикшереп карадым. Тары ярмасыннан башка нәрсә чыкмады. Аларга агулы ярма ашатканнар, күрәсең. Кемнең дә булса берәр абыстайның тавык җимен ашарга барганнардыр. Ә абыстай тавыкларының күкәй салмавын шушы чыпчыклардан күргән булыр.

Моннан күп еллар элек безнең авылда да чыпчыкларга карата тискәре караштa торучы кешеләр бар иде. Һиндкытай халыкларын кырып бетерергә кыҗырап торган Америка хәрбиләре шикелле, чыпчыкларны җир йөзеннән юк итәргә кирәк дигән фикергә килә язганнар иде ул чакта. Хәтта председатель дә, агроном да, бригадирлар да чыпчыкларга бик нык ачуланганнар иде. Ачу килмәслек тә түгел иде шул: урман буена чәчелгән тарыдан югары уңыш көтеп торганда, әлеге шул вак кошлар буе йөз метр киңлектәге җирдән тары бөртекләрен чүпләп бетергәннәр. Үсемлекләрнең себерке шикелле коры сабаклары гына тырпаеп калганнар. Икенче елны чыпчыклар авыл янына чәчелгән бодайны шул хәлгә төшергәннәр. Хисапчыларның чутлап чыгаруы буенча чыпчыклар 250 центнер бодайны ашап бетергәннәр булып чыкты.

Менә шуның үчен алу өчен ау мылтыкларын бик вак ядрәле патроннар белән корып, чыпчыкларны атарга дигән тәкъдим әйттеләр. Әмма картрак колхозчылар бу эшкә бик каты каршы чыктылар: — Монда гаеп чыпчыкларда түгел, ә үзебездә,— диделәр алар.— Бодайны яки тарыны авылдан кимендә 200 метр читкәрәк чәчәргә кирәк иде. Чыпчыклар авылдан яки урманнан ерак китәргә кыймыйлар, карчыгадан куркалар, ә урман буена, авыл тирәсенә чыпчык ашамый торган иген — карабодай чәчү кирәк иде.

Шулай итеп, чыпчыкларга карата тәкъдим ителгән хөкем карары гамәлгә ашмый калды.

Ә менә Кытайда моннан байтак еллар элек галимнәр чыпчыкларның хуҗалыкка күпме зарар китерүе турында газета-журналларда үтә ялкынлы мәкаләләр белән чыкканнар иде. Аларның исәпләп чыгарулары буенча, чыпчыклар ел тәүлегенә берничә миллион тонна икмәкне йоталар икән. Менә шул коточкыч зур саннарны күргәч, җитәкчеләр «чыпчыкларны кырып бетерергә!» дип боерык биргәннәр. Чыпчыкларны үтереп бетерү өчен мылтыклар да, автоматлар да, туплар да кирәк түгел икән ләбаса. Чыпчыкка беркая да кунарга ирек бирмичә, 10—15 минут һавада очыртып йөртсәң, үзеннән-үзе егылып үлә, ди.

Бичаракайларны юк итү өчен күп вакыт кирәк булмаган. Ике көн рәттән бөтен халык, бердәм кубып, чыпчык куалар. Өченче

көнгә тере чыпчыклар калмый. Шулай итеп, «миллион тонна» икмәккә экономия ясыйбыз дип торганда, хәтергә дә килмәгән башка бер бәла килеп чыга. Икенче елны ук чәчүлекләргә, җимеш агачларына, яшелчәләргә корткыч бөҗәкләр һөҗүм итә. Кытайда халык бик тыгыз утырганлыктан, агулаучы матдәләр куллану да мөмкин түгел диярлек. Корткычлар үрчегәннән-үрчи баралар һәм иген уңышы бөтенләй юкка чыгу куркынычы туа. Әлеге шул ук галимнәр бу хәлнең сәбәбен чыпчыклар булмаудан дип табалар. Чыпчыкларны чит илләрдән китерергә туры килә. Ә чит илләрдә «чыпчык хәзерлеге», «чыпчык сәүдәсе» оешмалары да килеп чыга. Кытайлар вагоннарга төяп чит илләрдән чыпчык ташырга мәҗбүр булалар. Ләкин илне яңадан чыпчыкларга баету булган чыпчыкларны бетерү кебек ансат түгел икән. Үзләре кечкенә булсалар да, аларның да туган җирләре, төп ватаннары бар, сагыну, җирсү дигән нәрсәләрне дә беләләр икән бәләкәчләр. Аннары чыпчык кына булса да, теләсә нинди сыңар белән парланып семья төзеп, үрчи башларга да бик дәртләнеп тормыйлар икән әле алар.

Кытайда чыпчыкларны яңадан үрчетү бик кыйммәткә төшкән дип сөйлиләр...

Чыпчыклар, бик тәҗел эшләре бар шикелле, йорт тирәсендә әле тегендә, әле монда очалар, җиргә төшсәләр, шатлыкларыннан куш-аяклап сикерәләр. Тәрәзәдән карап утыручы балалар аларга карап куаналар. Һәрбер теле ачылып өлгермәгән сабый бала чыпчыкны үзенчә атый: тымтык, тыптык, сыпсык, чепи-чепи, бычык, бычыкый, чымчык һ. б. лар.

Чыпчыкларның ояда әниләреннән, этиләреннән азык сорап дөнья куптаручы ашамсак балалары бигрәк тә файдалы. Чөнки алар орлык бөртеге дә, тавык җиме дә ашамыйлар. Аларга аксымга бай, ашказаны җиңел эшкәртә торган йомшак азыклар кирәк. Бик күп төрле үсемлек корткычлары, күбәләкләр, көяләр, аларның курчаклары, чебеннәр, кигәвеннәр һ. б. лар нәни кошчыкларның иң яраткан азыклары. Шуның өчен дә чыпчыклар мондый корткычларның күпләп үрчүләренә киртә булып торалар да.

Чыпчыклар төнге күбәләкләрне һәм төнлә җир өстендә шуышучы корткыч бөҗәкләрне генә тота алмыйлар. Төнлә оядан чыгып йөрү мөмкин түгел, чөнки куркынычлы төн ерткычлары: ябалаклар, мәчеләр бар бит дөньяда. Шуның өчен төнге корткычлар белән көрәшүне хәзергә яркanatларга, бакаларга тапшырып торабыз.

Сүз юк, чыпчыклар файдалы кошлар. Әйе, аларны өйрәнергә дә, өйрәтергә дә кирәк. Бер вакыт мин яшелчә бакчамда яңа гына тишелеп үсә башлаган чөгендер түтәлләреннән чүп үләннәр утап йөрим. Эшемне бетердем дә кара туфрак өстендә рәт-рәт булып тишелеп чыккан яшел үсентеләргә сокланып карап торгач, көндезге ашны ашарга өйгә кереп киттем. Тамак туйдырып чыгуыма, ни күзем белән күрим: чыпчыклар чөгендеремне пыран-заран китергәннәр. Йолкый алган тиклесен йолкып, йолкый алмаганнарын имгәтеп бетергәннәр. Моның өчен чыпчыкларга ачуланыргамы, ачуланмаскамы? Кем белә аларның акылын. Бәлки, яхшы ният белән: «Бабай йолкып бетерә алмаганнарын йолкып бетерик, карт кешегә ярдәм итик»,— дип шулай эшләгәннәрдер?

Әгәр дә мин түтәл буйлый бер метр чамасы биеклектә тимер чыбык яки җеп тарттырып каз, күркә каннаты ише нәрсәләр аскалап куйган булсам, чыпчыклар якын да килмәгән булырлар иде.

Минем бакчамда кызыл, ак карлыган һәм крыжовниклар яңа кунаклар иде әле. Алар миндә бер-ике генә ел иркенләп үстеләр, өченче елларында, мин күреп өлгергәнче, яшел төстәге кискеч көяләр яфракларның байтагын ашап бетерергә дә өлгергәннәр иде. Тегенди-

мондый химик агулаучы матдә кулланырга мөмкин түгел, җимешләр өлгерә башлаганнар. Бердәнбер юл — көяләрне кул белән чүпләү. Ә тирәмдә чыпчыкларым очып йөриләр, күбәләкләр тоталар. Мин кружкага җыйган көяләрне түл өстенә таратып салдым да үзем бер якка киттем. Берничә минут та үтмәде, чыпчыклар мин таратып салган көяләрне бетерделәр һәм крыжовник куакларына кунып, әлегә минем кул тимәгән куактан көяләрне эзләргә керештеләр. Баксам, чыпчыкларым яшел яфрак астындагы яшел көяләрне моңарчы күрә алмый йөргәннәр икән. Әмма бу ысул да һәр вакыт уңышлы булып бетми. Кайвакыт шулай да була: чыпчыклар әзер көяләрне чүплиләр, ләкин үзләре яфрактан тоту белән кызыксынмыйлар.

Шулай да бу кечкенә генә тәҗрибәдән бер нәтиҗә ясыйсы килә: салкын кыш айларында бу кошлардан тавык җимен кызганмаска кирәк. Ә җәй көннәрендә йорт кошларын күзәтү астында туендырырга да арткан азыкны яшереп куярга кирәк. Юкса, чыпчыкларыбызның ялкаулыкка бирелеп, әзерне генә ашап ятарга гадәтләнеп китүләре бар. Шуның белән бергә чыпчыкларга иптәшкә песнәкләрне дә ияләндерү кирәк. Корткыч бөҗәкләрне аулауда алар чыпчыкларга үрнәк күрсәтә алалар. Чыпчыкларның песнәкләргә иярү гадәтләре бар.

## «Тиле» боярның акыллы хәйләсе

1954—56 еллар тирәсе иде. Ул чактагы Ютазы район газетасы «Коммунизмга» битләрендә шундый мәкалә басылып чыкты: «...«Байкал» колхозында кукуруз дошманнарына каршы көрәш киң җәелдерелде. Авылда соңгы ункөнлектә 200 карга үтерелде, бик күп йомыркалары алынды, барлык карга оялары туздырылды. Каргаларны юк итүдә укучы балалар аеруча активлык күрсәтәләр. Алдынгыларга кыйммәтле бүләкләр тапшырылды...»

Мин үзем кукуруз үстерү ягында, аны авылда башлап пропагандалаучыларның берсе. Ләкин, кукуруз дошманы дип, каргаларны кырып бетерү белән дә һич тә килешә алмыйм. Яратам мин ул кара бәрхеттән киенгән күк күзле кошларны. Мин әле дә аларга карап торып бала чакларымны, сабан сөреп уздырган үсмер яшьлегемне искә төшерәм. Март урталарында, колагыма беренче карга тавышы керү белән, бөтен тәнем яз җиткәнен тоя башлый.

Безнең ихата артыннан кечкенә инеш — Бәйрәкә елгасы ага. Әтиләр менә шул инеш буйлап яр буйларына өянке агачлары утыртканнар. Яз җитте исә менә шул мәһабәт өянкеләргә каргалар чыбык-чабыктан үргән «кара чалмалар» кидерәләр.

Безнең яшьтәшләрнең тере табигать белән очрашып танышулары менә шул өянкеләр астында башланды да инде.

Ул чакларда әле безгә әниләребез дә көч җитмәслек авыр эшләр йөкләмиләр иде йөкләвен: нибары — каз бәбкәләре саклау. Аның бер ние дә юк. Яшел чирәм түшәлгән урамда бибиләрне тилгәннәрдән саклыйсың. Бибиләр ачыгып китсәләр, ипигә сөт кушып чәйнәп, китек табага салып, алларына куясың. Аннан кулыңа башына иске чүпрәк бәйләгән озын таякны тотып: «Тилгән тилергән! Баганага бәйләнгән, башың-күзең әйләнгән! Бер күзеңә яфрак, бер күзеңә туфрак!» — дип, такмаклап ятарга гына кала. Әгәр дә көн аязлы болытлы булып, салкынча җил дә искәләп торса, озын киндер күлмәкнең эченә бөтен гәүдә белән кереп чүгәлисең дә: «Кояш, чык,

кояш, чык! Тәти кашык базарда, майлы ботка казанда, сөтле сыер абзарда! Эт кояшы, ары кит, тәти кояш, бире кил!..» — дип тезеп китәсең.

Әмма бу эш безгә — малайларга ни өчендер ошап бетми, без тизрәк су буена таба таярга җай чыкканын гына көтеп йөрибез. Анда безне канатлары җитлекмәгән килеш ояларыннан егылып төшкән карга балалары көтә. Алар безне, зур кызыл авызларын ачып, «га-га-га!» кычкырып каршы алалар. Һәм без килүгә, чиктән тыш шатлыкларын белдереп, кечкенә канатларын селеккәләп куялар. Суалчаннар, кортлар җыеп, карга балаларын туйдыра торгач, каз бәбиләрен генә түгел, кичке ашны да онытып җибәргән чаклар булгалый торган иде. Илле елдан артык шушы ихатада яшим. Каргалар һаман да бар әле алар. Авылдашлар менә шул яз хәбәрчеләреннән зарланалар: «Алар утырткан бер нәрсәне йолкыйлар, хәтта бәрәңгеләрне дә чокып алып ашап бетерәләр, атып үтереп бетерергә кирәк ул явызларны!» — диләр.

Бер елны минем бригадада эшләүче Сәгыйтов: «Кәшиф абый, зинһар, мылтыгыңны биреп тор, бәрәңгебезне каргалар ашап бетерә, бер-икесен атсам, әллә бизәрләр иде. Иртә торуыма бакчабыз тулы карга була, куып та китмиләр»,— дип мөрәҗәгать иткән иде. Мылтыкны кешегә биреп торырга ярамаганлыктан, үзем киттем. Чынлап та каргалар Сәгыйтовларның бәрәңгесенә каныкканнар икән. Ныклап тикшереп карагач, биредә каргалар түгел, Сәгыйтовлар үзләре гаепле булып чыкты. Алар, җәй ашыйсы бәрәңгене аерым бер почмакка утыртып, рәттән казып алмыйча, бәрәңге кирәк булган саен төрле җирдә йолкып яки чокып, эрерәген сайлап алгач,ваграк бәрәңгеләр җир өстендә кала икән. Билгеле, моны өлкәннәр түгел, балалар эшләгәннәр. Җир өстендә җәйрәп яткан бәрәңгене күргәч, каргаларның авызларына су килмичә хәле юк. Бәрәңге бакчасына каргаларның бер-икәве генә төшсен, калганнары җыелырга әзер торалар. Җир өстендә ачык яткан бәрәңгедән авыз иткәч, аның ярым ачык ятканына да күз төшә. Аннан туфрак астындагы бүлбене чокып алу да кыен булмый инде.

1950—60 елларда гомер булмаган хәл күзгә чагыла башлады: кара каргалар тавык чебиләрен, каз-үрдәк бәбкәләрен алып китә башладылар. Бу күренеш күп кешеләрнең каргаларга карата нәфрәтен тагын да арттыра төште. Хәтеремдә: шушы уңай белән колхоз председателе урынбасары авыл арасында булган кара карга оялардай барлык агачларны — өянке һәм топольләрне кисеп бетерергә дип җыелышта чыгыш ясаган иде. Күп өянкеләр, топольләр кисеп, төпләп ташланды. Әмма каргалар әле һаман да бар. Аз санда гына калсалар да, яшәп яткан көннәре. Кешеләрнең үзләрен мылтыклардан атып үтерүләренә, тере балаларын алып кукуруз басуында таякларга асып куеп җәфалап үтерүләренә карамастан, яз җитте исә авылга киләләр. Иң элек үзләренең биредә кышлый торган дуслары — чәүкәләр белән исәнләшәләр. Ә чәүкәләр! Чәүкәләр үзләренең карга дусларын шундый шатланып каршылыйлар, әйтерсең алар өчен бәхет тик шунда гына — карга дусларының килүендә генә. Каргалар җылы якларга китә башласалар, чәүкәләр алардан бер тотам калмый ияреп йөриләр, китмәгез, монда да кышларга була лабаса, диләр, күрәсең: «Так-так-так! Тут-та-так! Там-да-дак!» янәсе.

Карга тыныч кош. Ул талашырга-сугышырга яратмый. Чәүкә гәүдәгә кечерәк булса да, холыксызрак. Чәүкәләр үзара да чукышып алалар. Әмма кара карга белән чәүкәнең сугышканын беркемнең дә күргәне юктыр.

Карга-чәүкә дуслыгының бер сәбәбе бар. Аларның дошманнары уртак. Уртак дошманнарга каршы көрәштә алар бердәм хәрәкәт итәләр...

Менә төрле якка карангалап тавык карчыгасы авыл өстенә очып килеп җитә. Ул урман тирәсендә үзенә азык таба алмаган. Көртлекләр, боҗырлар аннан яшеренеп котылганнар. Ниһаять, ул авылга килеп гамьсез генә тырманып йөрүче берәр тавыкны, ул да булмаса, ялгызрак калган берәр карганы яки чәүкәне булса да эләктереп сызарга исәп тоткан. Карчыганы беренче тапкыр ерактан күреп алган карга үзенчәлекле бер тавыш белән кычкырып җибәрә. «Кар, кар! Карчыга бар!» — ди. Бу тавыш каргалар өчен дә, чәүкәләр, хәтта сыерчыклар өчен дә куркыныч турында уртак сигнал булып яңгырый.

Сигналны ишетү белән, кошларның иң көчле, тазалары югарыга күтәрелергә ашыгалар. Карчыга никадәр көчле, үткен тырнаклы булмасын, әгәр дә аңар югарыдан китереп канат белән бәрсәләр, һавада тизлекне югалтып, түбәнгә төшеп китәргә мәҗбүр. Берәү генә түгел, берничә кош бере артыннан икенчесе китереп бәрә башласалар, карчыгага җиргә мәтәлергә генә кала. Авыл өстенә төшү ерткыч кош өчен бик уңайлы түгел, анда аны малай-шалай да таяк белән кыйнап үтерә ала. Карга-чәүкәләр һавага күтәрелү белән, карчыга авыл тирәсеннән таярга ашыга. Тавык чебиләреннән авыз итәргә ниятләп авылга килгән тилгәннең бик югарыда гына очып күзәтүенең дә сәбәбе шунда.

Минем каргалар белән чәүкәләрнең колхоз тавык фермасына килгән карчыганы ничек итеп куып җибәргәннәрен карап торганым бар. Ул көнне кичкә таба каралты тирәсендәге зур-зур топольләрне, каргалар оялап йөдәтүдән туеп, кисеп аудардылар. Нишлисең, берни дә эшләп булмый. Дөнья шулай каршылыклы инде ул...

Бер елны майның соңгы яртысында шундый күренешкә тап булдым. Ул көнне миңа берничә хатын: «Бакча артындагы өянкеләрне я кисеп аудар, я каргаларны атып бетер, юкса, тавык-чебиләребезне чүпләп бетерәләр!» — дип инәлделәр. Ә кукуруз саклаучы малайлар ул көннәрне карга ояларыннан карга балаларын кырга алып китә тордылар. (Агач башыннан егылып төшеп имгәнүче малайлар да булгалады.)

— Әнә, әнә, күрәсеңме? — диде күрше карчыгы.— Синең өянкеңдәге каргалар баядан бирле минем тавык чебиемне ашыйлар...

Карга оясы минем өйгә 120 метр гына җирдә. Мин бинокль алып чыктым да күзәтәм. Ни күрим: оядa тере тавык чебие. Ике карга аның авызын ачтырып азык каптырырга азапланалар. Куркынган тавык чебие каргаларның шәфкатен һич тә аңларлык хәлдә түгел.

Соңыннан мин каргалар оялаган өянке төбеннән үлгән үрдәк бәбкәләре, тавык чебиләре очраткаладым. Мәсьәлә аңлашылды: үз балаларын югалткан каргалар тавык чебиләрен ашар өчен түгел, ә «асрау бала» итеп туйдырып үстерергә теләп алып китәләр икән.

Әле менә күптән түгел генә, апрель аенда урамнарда үлеп яткан каргалар еш очрый башлады. Аларны кемнәрдер вак калибрлы мылтыклардан качып-посып кына аталар, кемнәр атканын белеп булмый. Әле кукурузлар тишелә торган чор да түгел. Карга тавышы яратмаган кешеләр аларның ояларын гына боза торалар...

Моның да сере ачылды. Өянке, тополь башларына ояларга ирек булмагач, каргалар электр станциясенең мәһабәт чыршылар төсле басып торган биек баганаларына оялап йөдәтә башлаганнар.

Без ел саен кошлар көне уздырабыз. Ул көнне мәктәп балалары сыерчык оялары ясап куеп һәм... карга ояларын туздырып каршылыйлар.

Кара каргаларны үтерү әле һаман да дәвам итә. Киләчәктә бездә дә «Кытай чыпчыклары» белән булган кебек берәр хәл тумасмы?» — дигән сорау туа.

Колхоз җитәкчеләре андый сорауга болай җавап бирәләр:

— Булмас. Хәзер химия гасыры, үсемлек корткычларына каршы көрәштә карга-чәүкәгә мохтаҗлык булмас, корткычларны химик матдәләр белән юк итәрбез,— диләр.

Мин хәзерге заман агрохимиясенең көченә ышанам. Әмма «Җил тегермәне икәнен беләм дә, суы каян килә?» — дигән сыман сорау килә.

1967 елны безнең урамга 300—400 генә метрдагы кырга шикәр чөгендере чәчелгән иде. Июнь аенда шушы чәчүлекләр трактор ярдәмендә гексахлоран белән эшкәртелде. Көньяктан искән коры җил гексахлоран тузаны белән безнең урамнарны да «сыйлады». Күзләр пешегә, тын юллары әчетә иде. Бу хәл озакка бармады баруын. Берике көннән саф һава сулый башладык. Әмма...

1969 ел җәендә Казанга баргач, күз врачына күренергә туры килгән иде. Ул минем күзләрне карагач:

— Кайнар цехта эшләдегезме әллә? — дип сорады.

— Юк.

— Эш урыныгызда зарарлы газлар бар идеме әллә?

— Юк. Мин — укытучы,— дим. Шулай да күңелдә бер төен урнашты: теге елны гексахлоран тәэсире түгелме икән? Чөнки бу авыру безнең очта күбрәк таралды бит әле.

Каргаларның кимеп бетүе аркасында килеп чыккан кайбер күңелсез хәлләргә тукталып үтик.

1919 елның май аенда безнең авылда чигенеп баручы Колчак армиясе ятты. Шунлыктан бер генә игенче дә атларын җигеп кыр эшләренә чыга алмады. Ай буена безгә атлар, сабаннар белән урманнарда качып йөрергә туры килде, чөнки авылда яки кырда күренгән һәр атны аклар тотып алып олауга җиктерәләр иде. Ә акларга олаучы булып эләксәң, башыңның Себер ягына китеп олагасы көн кебек.

Ул чакта әле безнең якта туңга сөрү дигән нәрсә булмаганлыктан, басуларда узган елдан килгән камыллар язын да сөрелмәде. Менә шул елны каргалар бала үстерә алмадылар. Ә 1921—22 елларда ачыккан кешеләр каргаларны ите өчен ауладылар. Нәтиҗәдә бу кошлар азаеп калды. Өянке башларындагы «кара чалмалар» сирәгәйде. Элек тә һәрбер сабанчы артыннан буразна тулып ярыша-ярыша каргалар йөгерешә торган иде. Хәзер алар берәм-сәрәм генә калдылар.

1922, 1923, 1924 еллар җылы һәм явым-төшемгә бай булдылар. Әмма авыл халкы җирдән югары иген уңышы ала алмады. Ул елларны чәчүлекләргә саранчалар һөҗүм итеп йөдәтте.

Кызу эш өстендә крестьяннарны «саранча куарга» мобилизацияләргә туры килә, саранчага каршы көрәш атналыклары, ункөнлекләре уздырыла тора иде. Картрак крестьяннар: «Бу афәтнең безнең якта гомердә булганы юк иде, каян килеп чыкты соң бу шомлык?» — дип зарланганнары хәтеремдә. Саранчалар таралуның сәбәбен агроном Кошелов Николай карга-чәүкәләрнең саны кимүдән дип аңлатты. Һәм бу шулай булды да шикелле. 1926, 1927, 1928 елларда каргалар ишәйделәр һәм әкренләп саранчалар да югалдылар.

Бөйрәкә авылының урта бер җирендә иске каберлек бар. 1930 елларга кадәр читтән күзәткәндә бик матур урман булып күренә иде ул. Анда мәһабәт наратлар да, каеннар да, имән агачлары да күп иде. Кисәк шушы агачлар корый башладылар, унбиш-егерме ел эчендә күп агачлар юкка чыкты. Наратлар бөтенләй беттеләр. Ниһаять, анда үлән дә үсми башлады. Яз башында гына бер-ике

атна яшәреп тора да аннан сап-сары булып кибә дә бетә зират өсте.

1947 ел җәендә каберлекнең чирәмен каргалар эшкәртергә тотындылар. Таң беленгәннән башлап караңгы төшә башлаганчы каргалар эштә — томшыклары белән чирәм чукыйлар. Бер атна эчендә бу мәйдан тырмалап эшкәртелгән кебек уңдырышлы туфракка әверелеп калды. Икенче елны монда һәртөрле кәрешкәләр, тукранбаш һәм күп төрле болын үләннәре үсеп китте. 25 ел инде менә зират өстендә һәр елны печәннең мул уңышы үсә. Бәлки әһәмият биреп утыртучылар табылса, тиз арада кабат урман да үсәр иде бирәдә.

Каргаларның зират өстен генә түгел, кайбер болынлыкларны, көтүлекләрне эшкәртүләрен күп тапкырлар күрергә туры килгәне бар. Алар берьюлы ике төрле файда ясыйлар. Беренчедән, туфракны зарарлы бөҗәкләрдән, кортлардан арындырсалар, икенчедән, туфракның үзен яхшырталар.

1861 елгы реформа буенча патша хөкүмәте җирләрнең күп өлешен кисеп алып, арзан бәя белән алпавытларга тапшырган. Бу без яшәгән Бөгелмә өязендә бигрәк тә кискен төс алган. Авыл кешеләренә һәр ир җанына 4 дисәтинә исәбеннән (көтүлекләр, болыннар, яраксыз җирләр, тау һәм сазлыкларны да кертеп исәпләү) җир калдырылган.

Берничә ел эчендә крестьян общиналары җирләренең 50 проценттан артыгы алпавытлар кулына күчкән.

Алпавытлар солы, борай, арыш, тары игүне крестьяннарга калдырып, үзләре бу як өчен яңа культуралар: борчак, карабодай, мәк, горчица һ. б. кебекләрне чәчә башлаганнар. Крестьяннар алпавытларга җиңел генә бирелмәгәннәр. Алпавыт хуторларына «кызыл әтәч» җибәргәләгәннәр. Терлекләрен куып алып киткәннәр, төнләтөнлә көлтәләрне урлап ташыйлар икән байларның.

Ә каргалар? Каргалар да авыл кешеләрен якларга тырышканнар. Алпавытларның борчак басуларына һөҗүм итә торган булганнар.

Бөгелмә өязендәге күп санлы яңа алпавытлар арасында Елатчич дигән бер алпавыт булган. Татарлар аны Ялатич дип йөргәннәр. Баштарак аны «тиле алпавыт», «дурак барин» дип тә атаганнар.

Базарларда суйган куян түшкәсе 5 тиен торганда Ялатич 50 тиен биреп тере куян сатып ала икән. 2 сумга менә дигән төлке тиресе барында ул 20 сум түләп тере төлке сатып ала торган булган. Тере килеш тотып илтсәң, ябалак өчен дә акча биреп чыгара торган булган Ялатич. Үзендә бик күп тере җәнлекләр асраган. Аннары аларны күреп туйгач, ирекә чыгарып җибәргән. Эшчеләргә башкалар кебек каты булмаса да, аның җиренә кереп аучылык белән маташырга һич тә мөмкин булмаган.

Бер елны шул Ялатич бик күп борчак чәчтергән. «Барыбер каргалар ашап бетерә ич, нигә шул кадәр күп борчак чәчтерәсең?» — дигәннәр күрше алпавытлар.

Борчаклар бик матур булып үсеп киткәннәр. Ялатич борчак чәчүлекләре арасына бишәр, унар метр биеклектә итеп карачкылар ясатып куйдырган.

Борчаклар өлгереп каргалар төшкәли башлагач, Ялатич тере каргалар сатып алырга керешкән. Һәрбер тере карга 1 сум. Ул чакта ялчылар 50 тиенгә көн буе печән чабалар икән. Ялатич тере каргаларны әлеге зур карачкылар янына арканлап бер-ике көн асрагач, үз кулы белән ирекә очырып җибәрә икән. Шуннан соң каргалар борчак басуындагы карачкыларны күрү белән, бер чакрым читләтеп уза башлаганнар. Ялатичның борчагына зыян килмәгән. Икенче елны күрше алпавытлар «тиле алпавыт» эшләгәнчә эшләгәннәр. Алар тере карга җыюны икенче, өченче, дүртенче елларда да дәвам иттергәннәр. Ялатич тере карга бәйләп асрауны бер генә ел эшләгән.

Әкренләп бу эш өязгә таралган. Тора-бара каргалар карачкы булмаганда да борчак чәчүлекләренә һөҗүм итми башлаганнар.

Ул заманнан халык телендә «борчак карачкысы шикелле» дигән сүз генә калган. Мәсәлән, өстен-башын чишенмичә түргә узган кешегә: «Нәрсә син борчак карачкысы кебек утырасың»,— диләр.

Елатчичның «Хайваннар психологиясе» дигән китабы (1926 елда булса кирәк) татар телендә дә басылып бик тиз таралып беткән иде шикелле.

Без машиналар белән җиңел идарә итәбез. Тере табигать белән дә шулай идарә итә белергә кирәктер. Һәрбер җәнлекне кечкенә «гөнаһы» өчен дә үлемгә хөкем итү гаделлек түгел. Бик ачыккан төлкенең авылга килеп бер тавык урлаганы өчен кызып китәргә ярамый. Ул мәхлукның кыш буе тычканнар белән генә туенуын исәпкә алырга кирәк. Бер оя карга баласы туйдырып үстерү өчен центнерлап азык кирәк икән. Ә ул азык нәрсәдән гыйбарәт соң? Алар — игенчелек корткычлары, бигрәк тә аларның туфрак эчендә яши торганнары, ягъни әлегә безнең химия көче генә җитмәстәйләре.

В. И. Ленин тормышыннан алып язылган бер очерк бик нык хәтердә калган. Бер ял көнне Ильичны иптәшләре үзләре белән ауга алып чыгалар да, аны бер зур агач төбендә яшеренеп торырга калдырып, үзләре төрле якка таралалар. Алар төлкенең Ильич ягына таба үтүен тәэмин иткәннәр, күрәсең. Төлке Ленинннан 20 генә метр кала туктап иснәнеп торган да әкрен генә китеп барган. Ә аркасына ике көпшәле мылтык аскан Ильич төлке күздән югалганчы сокланып карап торган. Соңыннан аңа иптәшләре килеп:

— Нигә атмадыгыз, Владимир Ильич, төлке Сезгә 20 генә метр җирдә туктап торды ич! — дигәннәр.

Ленин:

— Бигрәк матур иде шул ул! — дип җавап биргән.

Мин аркасына мылтык аскан Ленинның үзенә якын ук килгән төлкегә сокланып карап торуын ачык күз алдыма китерәм. Шундый рәсем иҗат итеп — хәер, андый рәсем бар да бугай — күпләп бастырылып таратылуын теләр идем мин. Ә ул очеркны балаларыбыз өчен китап итеп чыгару яшь буынны табигать сөючеләр итеп тәрбияләүдә зур урын тотар иде.

## Ике ат бәясе торган бурсык

Бәйрәкә авылында узган йөзнең сиксәненче еллар тирәсендә ярлы крестьян семьясында туып үскән Моратша Зайдулласы дигән таза гына гәүдәле бер агай бар иде. Бик тырыш, шуның белән бергә гел баю турында гына исәпләп йөри иде ул. 1919 елда тоз белән сату итәргә дә маташып караган иде дә, беренче сәфәрендә үк тотылып, барлык мөлкәтеннән язды.

Шулай да Заһидулла агай 1921—22 елгы ачлыкларны җиңел уздырды. 1924 елда аның бик таза ике баш аты, салам түбәле булса да, алты почмаклы өе, келәте һ. б. бар иде.

1924 елның март аенда шушы Заһидулла абзыйга БАССРның Туймазы районыннан бер кардәше кунак булып килә. (Безгә Туймазы районы уникe генә километр).

— Сезнең якта нинди яңалыклар бар? — дип сорый Заһидулла, исәнлек-саулык сорашканнан соң.

— Безнең якта яңалык шул,— ди кунак,— Туймазыга «әмиркеләр» килде. Бурсык җыялар. Бер бурсык алтын белән 200 сум.

— Булмас ла!?

— Валлаһи газыйм, ипи, тоз, кояш, шушы көн!..

— Димәк, бер бурсык ике ат хакы тора.

— Нәкъ менә шулай.

Кунакны озату белән, Заһидулла агай бурсык тиреләре җыярга ашыга. Баштарак һәр тирегә 5—10 сум түли, соңрак 25 әр сумнан да алгалый. Билгеле, бурсык тиресе җыю өчен акча кирәк. Заһидулла күп уйлап тормый, йөзәр сумнан ике атын берьюлы сатып җибәрә.

Моратша Заһидулласы бурсык тиреләре төяп Туймазыга юнәлә. Үзе, «әмиркеләр» кайтып кына китмәгән булсалар ярар иде, дип борчыла.

Менә бурсык тиреләре төягән олау Туймазыга барып керә.

Бурсык җыючы «әмиркеләр» кайтып китәргә өлгермәгәннәр икән өлгерүен. Ләкин...

Ләкин Заһидулла абзыйга аларның кайтып китәргә өлгермәүләреннән ни файда? «Әмиркеләр»гә бурсык тиреләре түгел, ә тере бурсыклар кирәк икән. Аларның да парлы, ягъни аталы-аналы булуларын шарт итеп куялар икән алар. Шулай итеп, тиз баерга исәп тоткан Заһидулла агай язгы чәчүгә чыгар алдыннан гына ике атыннан да колак какты.

Ә без: «Әмиркеләргә тере бурсыклар нигә кирәк булды икән?» — дип баш ваттык. Чынлап та, бер пар аталы-аналы бурсыкка «4» ат хакы түләп алып, аларны баллы ипи белән тамакларын туйдыра-туйдыра асрау нигә кирәк булды икән?

Бу күренеш минем өчен унбиш еллар дәвамында сер булып калды. Ә халык арасында шушы уңай белән бик күп төрле «имеш-мимешләр» таралды. Барыннан да бигрәк бурсык маеның үпкә авыруларыннан, коры сызлау һәм ревматизмнан ышанычлы дару булуы турындагы хәбәрләр ишетелде. Бурсык мае белән дарулаучы имтомчыларга яңа керем чыганагы ачылды. Спекулянтлар да буш калмадылар. Гади майның килосы 50—60 тиен торганда, бурсык маена 15—20 сум сорый торган булып киттеләр. Соңга таба бурсык мае гына түгел, ите дә дару булуы турында хәбәрләр таралды. Мулла абзыйлар бурсык итенең хәрам булуы турындагы элекке карашларыннан тәмам ваз кичтеләр.

Ул чакта әле безнең яктагы таулы урыннарда суырлар да (байбаклар) бик күп иде. Әти белән язгы сабан сөреп ашлык чәчкәндә буш араларда үзебезнең җиргә якын гына булган «Туры тау» дигән түбәдә суырларны күзәтә идем мин. Мәчедән зур, эттән кечерәк булган бу җәнлекләр көне буе мәш килеп яталар. Убаларыннан (өннәреннән) чыгалар да, кулларын алга сузып, кеше шикелле ике аякка басып озак карап торалар, көтүчеләр кебек итеп теш үтәли бик каты сызгыралар. «Энтыйф, энтыйф!» дигән кебек итеп кычкыралар. Басып торган суыр янына 10 адым калганчы барып була. Тагы да якынрак килә башласаң гына, «энтыйф»ны кабатлап, койрыгы белән җиргә бәрә-бәрә убасына кереп китә. Әти миңа суырларга кагылмаска, аларның убаларына якын килмәскә куша. «Күрәсең бит: кыйблага карап аяк өсте басалар да кулларын күтәреп дога кылалар! Көннәрнең җылы булып, яңгырларның яугалап китүен, үләннәрнең, игеннәрнең тиз үсүен телиләр алар!»

Атларны чирәмгә ашарга җибәреп үзебез кара чиләктә тозлы каз ите турап пешергән борай өйрәсен ашагач, йокыга киткәнче әти миңа суырларның тарихын сөйли.

«Борын-борын» заманда бик ярлы бер кеше булган. Аның бар карап торган байлыгы үзенең өлешенә тигән тау башындагы җире

булган. Әмма ул җирдә иген үсмәгән, сарыклар асрап кына яшәргә мөмкин булган ул җирдә. Ә җир хуҗасының сарык нәселе тергезеп тә җибәрерлек хәле булмаган. Бердәнбер көнне Антыйф исемле алпавыт шушы ярлыдан сорамый-нитми шул җирдә сарыкларын көттерә башлаган һәм ул җирләрне үзенеке дип игълан иткән. Ярлы кеше Антыйфны судка биргән. Ә Антыйф шундый ук бер ярлы кешене яллап хәйлә оештырган һәм судьяларга әйткән. «Кемнеке икәнен җирнең үзеннән барып сорагыз»,— дигән. Судьялар әлеге ярлы җир хуҗасын үзен дә ияртеп килгәннәр дә:

— Җир! Син кемнеке? — дип кычкырганнар.

Ә җир эченнән:

— Антыйф, Антыйф! — дигән аваз ишетелгән.

Шул рәвешчә өч тапкыр кабатлагач, судьялар җирне Антыйфныкы дип карар чыгарып кайтып киткәннәр, ди.

Актык җиреннән дә мәхрүм калган ярлы кеше. Судьялар кайтып киткәч, бу күренешкә аптырап, яңа казылган туфрак күренгән урынга барган да таяк белән төртеп караса: ни күзе белән күрсен, анда үзенең күршесе күмелеп ята. Судьяларның соравына «Антыйф! Антыйф!» дип җавап биреп ятучы да шул сатлык булган икән. Шунда инде әйтә моңар әлеге ярлы кеше:

— Байга сатылып, мине актык җиремнән мәхрүм иттең, сабый балаларымны ачтан үлүгә дучар иттең. Шуның өчен мин сине йөрәгем белән каргыйм. Үзең генә түгел, хатының, балаларың, моннан соңгы бөтен нәселең җир астында яшәүче җәнлекләр булып калсыннар иде! — дип әйткән ди. Ярлы кешенең каргышы төшеп теге сатлык шунда ук суырга әверелгән, ди. Аны эзләп килгән хатыны да суыр булып калган, ди.

— Менә шуның өчен суырларны рәнҗетергә, хәтта аларга кагылырга да ярамый,— ди иде эти.— Алар кешеләргә зарар салмыйлар, буш калган тау үләне — кылган белән канәгатьләнеп яшиләр. Күрәсең, безнең бер башагыбызга да тигәннәре юк. Мең еллар элек бабалары эшләгән эшәкелек өчен алар гаепле түгел. Әгәр суырларга кагылсаң, алар үзеңне каргарлар. Авырырсың, кулың корыр... дип әйтә торган иде эти. Әмма спекулянтлар, карак аучылар (браконьерлар) бер нәрсәдән дә тукталып калмадылар. Бурсык ите, бурсык мае, дип алдап сату өчен суырларны да ауларга керештеләр. Хәзер инде безнең тирәдә бу җәнлекләр дә бетте дияргә мөмкин.

Эти мәрхүмнең сөйләве буенча, бурсык та кешедән килеп чыккан, имеш. Әмма аның тарихы суырныкына караганда бераз гына башкарак. Аның тарихын эти болай сөйли торган иде.

«Бер байның үсеп буйга җиткән улы, мин сине үземә хатын итеп алам дип, үзләрендә асрау булып торучы ятимә кызны алдаган, ди. Кызның йөкле булуы беленгәч тә бай аны йорттан куган. Ә авыл кешеләре аны бөтенләй авылдан да куганнар. Йөкле хатын урманда бер зур агач ышыгында чүп-чарлардан үзенә куыш ясап яши башлаган һәм шунда бер малай тапкан. Урмандагы җәнлекләр боларга төрле азыклар китереп торганнар: тиеннәр чикләвек җыеп китергәннәр, куяннар какы, кузгалак, балтырган ише үләннәр ташыганнар, бүреләр, төлкеләр үзләре ашый торган иттән өлеш чыгаралар икән. Ана пошилар, боланнар җиленнәре тулы сөт белән килеп, саудырып китә торган булганнар.

Малай көннән-көн үскән. Унбиш яшьләрендә ул дөньядагы иң көчле кешеләрнең берсе булып танылган. Аның даны якын-тирәгә генә түгел, чит илләргә дә таралган.

Ул чагындагы закон буенча, иң көчле кеше илгә җитәкчелек итәргә тиеш булган. Яшь батырның атасы билгеле булмау гына

моңар комачаулык иткән. Әнисеннән ул әтисенең кем булуын әйтүне үтенә. Ана улын әлеге үзе асрау кыз булып торган йортка алып килә. Бу чакта инде карт бай үлеп, яшь бай, ягъни егетнең атасы үзе хуҗа булып калган һәм бер бай кызына өйләнеп тора башлаган икән. «Сине бер батыр чакыра!» дип хәбәр иткәч, бай болдырга чыгып баса. Егет аңар:

— Мин синең улың! — ди.

Әнисе дә:

— Ие, бу синең улың! — дип хаклап тарихны сөйләп бирә.

Бай үзенең хатынын кочаклап:

— Ялган! Минем менә шушы кешедән башкага өйләнгәнем юк, тизрәк күземнән югалыгыз! — ди.

— Үз сүзеңнең дөреслегенә шаһитың бармы? Нәрсә белән ышандыра аласың? — ди егет.

Байның хатыны:

— Ант ит, карт, ант ит кояш белән, ай белән, икмәк, тоз белән ант ит,— дип, иренең колагына пышылдый.

— Кояш белән ант итәм, син минем улым түгел! — ди бай. Әмма, шул сүзне әйтеп бетерүгә, кояш аның өстендәге киемнәрен көйдереп төшерә.

Бай моны егет тарафыннан эшләнгән сихер галәмәте дип белеп, ачуланып болдырдан төшеп җиргә баса.

— Тагын нәрсә белән ант итәсең? — ди егет.

— Җир йотсын, менә шушы көнне күрмим! — дип әйтеп бетерүгә, бай, хатынын култыклаган килеш, бурсыкка әверелеп җир астына кереп киткән, ди. Ул да суыр шикелле җиргә казып оялаучы нәселен калдырган. Әмма ул бай сыйныфтан — тәмле тамаклардан булганлыктан, бурсыклар баллы нәрсәләр: төклетура, шөпшә, җиләк-җимеш һәм гөмбә ише нәрсәләр белән туеналар икән, ди».

Безнең бабайлар үсемлекләр дөньясы белән дә, тере табигать белән дә бик нык таныш булганнар. Аларның кешегә нинди файда китерүләрен яхшы белгәннәр. Файдалы кошларны, җәнлекләрне үтерергә ярамавын коры сүз белән генә түгел, суыр, бурсык, үрмәкүч һ. б. ларның «килеп чыгулары» турындагы әкиятләр белән балаларның күңеленә беркетә торган булганнар. Дөрес, бу әкиятләр фәнгә нигезләнмәгән, күп очракта дин буявына буялган булганнар. Әмма аларның әдәби кыйммәте бар, дидактик әһәмиятләре зур. Мәсәлән, әлеге без телгә алган әкиятләрне генә алып карыйк: биредә суырларны, бурсыкларны үтерергә ярамавы турындагы фикерләр байларга, комсызларга, алдакчыларга, сатлыкларга, гомумән, намуссыз кешеләргә карата тирән нәфрәт тудыру белән бергә үрелеп бара. Аерым әйтемнәр, мәкальләрдә дә тирән хакыйкать бар. Мәсәлән: «Каргага тимә, каргар, йортың янар», «Бака үтермә, ашың тәмсез булыр», «Кош баласына тимә, атаң-анаң үләр, үксез калырсың», «Кышкы җәнлек — тәңгә азык, җәйге азык — җанга язык», «Йоклаган җәнлеккә атма, үзеңә тияр», «Танымаган җәнлеккә таяк атмыйлар», «Тилгән оясына тигән тинтәк», «Кош баласын кеше баласы кебек сакла», «Сабый килеш бүре баласы да кызганыч».

Халык телендә, бигрәк тә карт аучылар арасында мондый мәкальләрне бик күп ишетергә мөмкин.

Бурсыклар, суырлар турында да әйтергә теләгәннәрне әйтеп бетерик.

1939 ел җәендә Бәйрәкә авылы, «Авангард» колхозының умарталыгында булырга туры килгән иде. Умартачы Хафизов Рәхимҗан белән урманга таба чыгып барганда балалар баш киеменә охшаган нәрсәләргә күз төште дә:

— Бу нәрсә? — дип сорыйсы иттем.

— Бу — оя, бөҗәк оясы,— диде Хафизов, теге нәрсәгә аягы белән тибеп.— Күрәсеңме, әнә җирдән казып чыгарылган. Бурсык актарып чыгара аны. Божаннар, шөпшәләр умарта кортларының явыз дошманнары. Аларны юкка гына умарта корты бүреләре димәгәннәр. Менә бу җир астына казып кереп оялый торганын филант диләр. Берүзе көнгә 25 умарта кортын очып барган җирендә үтерә. Ул үз балаларына умарта кортының бавырын изеп ашата. Болар үрчегән җирдә умартачылык белән шөгыльләнергә мөмкин дә түгел.

— Аларга каршы көрәш чаралары бардыр бит? — дип сорыйм.

— Китапларда язылган чаралар безнең шартларда мәгънәсез. Әйтик, божанның оясын табып, агулаучы матдә сибәргә кушалар. Ул инде «тычканны тоткач күзенә сибә торган дару» дип, базарда кирпеч оны саткан шәкерт сыманрак. Божанның оясын табуы мөмкин түгел, икенчедән, агулаучы матдә сипкәч, умарта кортлары үзләре дә үлә бит.

Ә менә безнең дүрт аяклы дусларыбыз — бурсыклар божаннарга-шөпшәләргә каршы көрәштә иң ышанычлы һәм файдалы җәнлекләр. Алар үзләренең озын танауларын сузып сак колаклары белән тыңланып, астындагы божан оясын да, җир өстендәге куаклардан шөпшә ояларын да табып алалар.

— Әле менә урманга чыгуымның да сәбәбе шунда. Моннан ерак түгел бурсык убалары бар. Менә шуларга кемдер капкын корып киткән,— дип сөйләп бирде Хафизов.

1942 ел язында Хафизов, Ватан сугышы фронтларыннан яраланып кайткач, теге умарталыкны элекке урыныннан 7 километр көнбатыштарак булган Әрчү дип аталган имәнлеккә күчертте.

— Теге урында бурсыкларның нәселен бетерделәр,— дип аңлатты аның сәбәбен умартачы.— Кыш өстендә убаларын казып актарып ташлаганнар. 1940 елда ук инде анда керем алу кимеде, ә 1941 ел җәендә корт семьялары бөтенләй зәгыйфьләнгәннәр. Анда хәзер адым саен божан оясы... Ә Әрчүдә, Баланлы урманында, әлегә бурсыклар бар...

Әрчү умарталыгы берничә ел рәттән зур табыш бирде. Әмма браконьерлар «Баланлы» урманындагы бурсыкларның да нәселләрен корыттылар. Соңыннан бу умарталык «Натравис урманы» дигән урынга күчерелгән иде. Биредә инде умарталыкта каравылчы булып торган Мифтахетдин агай үзе үк капкын корып бурсык ауларга кереште. «Мин тотмасам да, аларны сунарчы Нигъмәтҗан аулап бетерә, ул бер ел эчендә генә 70 ләп бурсык алган»,— ди иде ул.

«Натравис»та да бурсыклар бетерелде. Хафизов Рәхимҗан да умартачылык эшен бөтенләйгә ташлап, «пүләвәй» булып эшләп, вафат булды. Ютазы райзосында район буенча умартачы булып эшләгән Корнеев та бурсыкларның умартачылык дуслары булуын раслап сөйли иде.

Хәзерге «Коммунизмга» колхозы территориясендә элек 8—9 умартачылык булып, 1941—45 елларда барысының уртача еллык бал табышы 400—500 центнерга җиткән. Хәзер инде бал уңышы ул вакыттагыга караганда ун мәртәбәгә кимрәк.

«Коммунизмга» колхозының 8000 гектардан артып киткән чәчүлек җирләре дүрт яктан да дәүләт урманнары белән уратып алынган. Юкә кебек баллы үсемлекләргә бай булган 4000 гектар мәйдандагы урманнардан бик күп бал алырга мөмкин булыр иде. Икенчедән, карабодайның да уңышы 40 процентка күтәрелер иде.

Хәзер инде умарталыкларга файда китерерлек санда бурсыклар юк шул. Шөпшәләр, божаннар, уклы чебеннәр аркасында колхоз

умартачылыгының түбәнгә тәгәрәвенә тагын бер дәлил. Колхозның урман буенда урнашкан умарталарыннан, шунда гына карабодай һәм башка баллы үсемлекләр чәчүлекләре дә булуга карамастан, һәр оядан уртача 10—15 килограммнан артык бал табышы алынмый. Ә авылдагы һәвәскәр умартачыларның «ташка үлчим» умарталары 30—50 кг бал бирәләр. Чөнки авыл арасында бөжаннар, шөпшәләр юк.

Менә шуннан инде 1924 елны «әмирке»ләрнең тере бурсыклар җыеп алып китүләренең серен аңларга була.

Ул заманда һәрбер фетр эшләпә кигән кешене «әмиркеле» дип хисаплау гадәт иде. Бәлки ул кешеләр бик еректан да булмаганнардыр.

Умартачылыкны алга җибәрергә дибез икән, безгә дә каян да булса бурсыклар алып кайтып үрчетү кирәк булмасмы икән?

Бабайларыбызның бурсык ите ашауны кеше ите ашау белән бердәй итеп санауларының да хикмәте аңлашылса кирәк. Ә инде суырлар турында эшнең ничек булганын 1970 ел азагында телевизордан күреп кенә аңларга туры килде.

Ул җәнлекләрнең күп авырулары кешеләрнеке белән уртак икән. Әйтик, алардан чума авыруы йоктыру да мөмкин икән.

Шуның белән бергә алар безгә бик кирәкле җәнлекләр дә булып чыкканнар. Моңарчы безнең медицина галимнәребез, төрле авыруларны өйрәнү, даруларны сынап карау өчен чит илләрдән бик кыйммәт бәягә маймыллар сатып алырга мәҗбүрләр иде. Соңгы вакытта, билгеле булганча, суырлар бу эштә маймылларны алыштыра алалар булып чыкты.

Мирфатих Зәкиев

# АЙ һӘМ ЙОЛДЫЗ ЯКТЫСЫНДА

## СТАМБУЛ БЕЛӘН БЕРЕНЧЕ ТАНЫШУ

Самолет Мәскәүдән Стамбулга һәм Анкарага атнасына ике генә тапкыр оча. Бу рейс белән барсаң, конференциягә я ике-өч көн алдан киләсең, я бер көнгә соңга калуың бар. Шуңа күрә без Төркиягә, урау булса да, башка рейс белән, София аркылы китәргә булдык.

1972 елның 25 сентябрендә көндез, «ТУ» маркалы совет самолетына утырып, Софиягә юл тоттык. Самолет салонында туган якларына кайтып баручы төрле чит ил кешеләре дә, башка илләргә ярдәм итәргә баручы совет белгечләре дә бар. Шулар арасында без — Анкарада булачак беренче тюркологик конференциядә катнашырга баручы делегация членнары да урын алганбыз. СССР Фәннәр академиясе тарафыннан оештырылган бу делегация составында совет тюркологларыннан унбер кеше очабыз. Бу группаның җитәкчесе — филология фәннәре докторы, профессор Әдһәм Рәхимович Тенишев. Ул тюркологиядә уйгур теле белгече буларак танылган. Берничә ел буе Кытайда гыйльми командировкада булып, уйгур телен яхшы өйрәнгән һәм шуның буенча зур-зур хезмәтләр язган, хәзер СССР Фәннәр академиясенең тел гыйлеме институтында төрки телләр секторы мөдире булып эшли, Төркиягә беренче баруы. Аның ярдәмчесе — Ленинградтан СССР Фәннәр академиясе член-корреспонденты Андрей Николаевич Кононов. Ул моңа кадәр дә Төркиядә берничә мәртәбә булган. Тюркология өлкәсендәге, аерым алганда, төрек теле буенча булган хезмәтләренең әһәмиятен истә тотып, төрекләр аны үз гыйльми җәмгыятьләренә мактаулы член итеп сайлаганнар. Шуңа күрә аңа тюркология буенча Төркиядә чыккан хезмәтләр килеп тора, андагы яңалыклар белән ул таныш.

Делегация составында Төрек тел җәмгыятенең мактаулы членнары булган һәм Төркия юлларын моңа кадәр дә берничә мәртәбә таптаган тагын ике кеше бар: Мәскәүдән тел гыйлеме институтының өлкән гыйльми хезмәткәре профессор Эрванд Севортян һәм Бакудан тел гыйлеме институтының директоры, «Советская тюркология» журналының баш редакторы, Әзербәйҗан Фәннәр академиясенең академигы профессор Мамед Ширалиев. Өлкән буын тюркологлардан Смет Кенесбаевның да Төркиягә икенче баруы икән. Ул үзе Алма-Атадан, анда тел гыйлеме институтының директоры һәм Казагыстан Фәннәр академиясенең гуманитар фәннәр буенча вице-президенты булып эшли. Бу биш галимгә командировка Фәннәр академиясе тарафыннан бирелгән.

Калган алты кеше Фәннәр академиясе делегациясенә гыйльми турист итеп кертелгәннәр, шуңа күрә болар, конференциядә катнашудан тыш, турист буларак, Төркия

белән танышып та йөрергә тиешләр. СССР тюркологлары делегациясенең гыйльми туристлары арасында Мәскәүдәге тел гыйлеме институты өлкән гыйльми хезмәткәре Людмила Покровская да бар. Ул төрки семьяга керә торган гагауз теле төзелешен тикшерә һәм шуның буенча докторлык диссертациясен тәмамлап килә. Төркиядә конференциягә ул гагауз теле буенча доклад әзерләгән. Аннан тыш бу группага биш доктор-профессор кергән: Әзербайҗан дәүләт университетының уку-укыту эшләре буенча проректоры Әлүәвсәт Абдуллаев, шул ук университетның филология факультеты деканы Агамуса Ахундов, тюркология кафедрасы мөдире Фәрхад Зәйналов; Үзбәкстан Фәннәр академиясе тел гыйлеме институтының бүлек мөдире Эргәш Фазылов һәм Казан педагогия институтыннан — мин.

Кишинев һәм Бухарест шәһәрләре өстеннән очып, самолетыбыз өч сәгатьтән София аэродромына килеп төште. Мондагы аэровокзалда без биш сәгать буе София — Стамбул — Дамаск рейсын көтеп тордык. Безне каршылап озатырга Болгария тюркологлары ирле-хатынлы Молловлар һәм тагын бер-ике коллега килгән иде. Алар белән бергәләп дөнья хәлләрен сөйләшеп, тюркология яңалыклары турында фикер алышып йөрү үзе бер файдалы очрашуга әйләнде. Кызганычка каршы, бу сөйләшүләрдә Смет Кенесбаев юньләп катнаша алмады, башын аска иеп, йоклаган кешегә охшап утырды. Ул күтәрелеп:

— Хәл яман, Мирпәтик, организмда су җитми, эчәсем килә,— дип зарланып кына алгалады.

Чәй дә, кока-кола да, минераль су да эчеп карый, яхшырып киткән кебек була. Шул арада кызыклы хәлләр сөйләп безне көлдереп тә ала. Ләкин хәле тагын начарлана.

Эрванд Севортян күбрәк үзенең Төркиягә элегрәк баруы турында сөйли. Мамед Ширалиев та аңа кушыла. Төркиянең зур филологлары турында алар безгә кыска гына мәгълүмат бирәләр.

Аннары без тагын самолетка кереп утырдык һәм, бер сәгать дигәндә, Стамбулның Яшел көй (Яшел авыл) аэродромына килеп тә төштек. Сентябрьнең 25 еннән 26 сына каршы төн, безнең вакыт белән сәгать бер иде.

Аэропортта гыйльми туризм буенча баручыларны «Контуар туризм» вәкиле каршы алырга тиеш иде. Бу учреждение бер кешенең хосусый милке икән. Хуҗа эшне яхшы оештыра алмаган, ахрысы. Рус телендә сөйләшә белә торган эшчеләре юк, андыйлар Төркиядә гомумән бик аз, шуңа күрә алар туристларны йөртү өчен бик кыйммәт хакка гына яллаualар икән. Шуны истә тотып булса кирәк, «Контуар туризм» безгә төрек телендә сөйли торган гид тәкъдим итте.

Делегациянең командировкалы вәкилләре Стамбулда калмаска, якындагы рейс белән Анкарага очарга тиешләр иде. Ләкин Смет ага Кенесбаев үзен начар хис иткәнлектән, алар да безнең гыйльми туризм группасы белән Стамбулга барып кунарга булдылар.

Әйберләрне автобуска төягәнче, без Төркия төненә игътибар итеп, бераз фикер йөртеп алдык. Төн бездәге кебек түгел, күк аяз булуга карамастан, кап-кара төн. Бары йолдызлар һәм ай гына ачык булып ялтырый, ләкин алар җиргә бөтенләй яктылык бирмиләр кебек.

— Бирედә төн дә караңгырак бугай,— дим мин иптәшләргә.

— Көньякка киткән саен, төн караңгылыгы куера бара,— дип, сүзгә катыша бер әзербайҗан юлдаш.

— Төн караңгы булганга, кешеләр иң элек айга, йолдызга игътибар иткәннәр, аларны хәтта караңгыда да яктылык бирә ала торган җисемнәр итеп санаганнар,— ди бер өлкән иптәш.

Караңгыда кем белән кем сөйләшкәнен, кемнең кемгә җавап биргәнен абайлавы да кыен, ләкин әңгәмә һаман җанлана.

— Шундый куе караңгыда иң элек ай белән йолдыз кирәк булганга, алар күп кенә көньяк илләренең дәүләт гербында һәм байракларында да урын алганнар.

— Алай гына булмаска тиеш, ярты ай сурәте басып алучылар эмблемасы булган ат дагасы сурәтенең әкренләп үзгәрүе, кыскаруы нәтиҗәсендә туган булуы да мөмкин.

— Төркия байрагындагы айны сапсыз урак белән тиңләгән иде бер төрек егете,— ди Төркиядә электән булган бер юлдаш.

— Монысы булмас, бу, чынбарлыктан бигрәк, шундый теләк булганга әйтелгәндер бәлки.

— Элек нәрсә булгандыр, хәзер аны һәр төрек ай-йолдыз дип аңлый, караңгыда яктылык бирә, юнәлешне күрсәтә торган җисем сурәте дип саный.

Төн караңгылыгына чумгач туган бу фәлсәфә шактый дәвам иткән, ахрысы. Безнең багажларны төяп бетергәннәр, гид, бик эшлекле кыяфәт белән, автобуска утырырга чакырды. Кузгалып киткәч, ул роленә кереп, безнең алга чыгып басты. Хәзерге яшьләр кебек озын буйлы, кап-кара чәчле, бакенбардлы һәм мыеклы, Кавказ халыкларындагы шикелле озын һәм кәкре борынлы, елмаеп кына сөйләшүче 30—35 яшьләрдәге бер кеше иде ул.

— Төркия җиренә аяк басуыгыз белән сезне тәбриклим, әфәнделәр! Минем исемем — Угур Аййолдыз.

— О-о! Кара ничек туры килә! Ай-йолдыз яктысында, Аййолдыз җитәкчелегендә, ай-йолдыз иленең борынгы башкаласына барабыз,— дип көлешеп алдык.

— Туристларны каршылау программасы буенча, мин сезне төрек тарихы белән кыскача гына таныштырырга тиешмен,— дип сүзен дәвам итте Угур, әле генә көлешеп алудан җитди төскә керә алмыйча.— Сез тюрк телен һәм тарихын өйрәнүче галимнәр булгач, миннән күбрәк беләсездер, сөйләмәсәм дә ярыйдыр?

— Юк, юк, сөйләгез, Төркиягә килгәч, без үзебезнең элек белгәннәрне яңартырга тиешбез. Төрек тарихын гына түгел, Стамбул тарихын да сөйләрсез: әле барасы юл озын,— дип җавап бирә Фәрхад Зәйналов барыбыз өчен дә.

Шунысы игътибарга лаек: гид төрек тарихын үзенчәрәк сөйли. Аның аңында «төрек» һәм «төрки» дигән ике төшенчә урынына, «тюрк» дигән бер генә төшенчә бар. Төрекләр турында сөйләгәндә, ул «Төркиядәге тюрклэр» тезмәсен куллана. Аның өчен тарихта төрекләрнең халык булып, аннан соң милләт булып формалашулары да юк. Халыклар формалашу чорында ук аерым тарихи берәмлек булып оешкан төрки халыклар хәзер инде аерым-аерым милләтләр булып үсеп җиткән булуга карамастан, безнең гидның авызында алар барысы да бер «тюрк милләте».

— Сез даталарны дөрес беләсез, ләкин тюрки милләтләрне барысын бергә бутыйсыз,— дип әйтеп куя Фәрхад, ирек куйсаң, ул төрек тарихын яңадан сөйләп чыгар иде. Булса да була икән сүзгә бай һәм туктамый сөйли ала торган кешеләр! Без нәрсә әйтергә дип уйлап торганчы, ул әйтеп тә куя, нигездә, дөрес әйтә. Әзәрбәйҗан теле төрек теленә бик якын, шуңа күрә аңа бәхәсләшеп алу да берни тормый.

Гидның артка шактый авышкан төрек тарихын турайтып һәм бераз өстәп тә сөйләсәң, болайрак була.

XI йөз башларында көнчыгыштан күчмә төрки кабиләләр Иранга, Әзәрбәйҗанга, Әрмәнстанның бер өлешенә, Иракка һәм Сүриягә ташкын булып килеп керәләр. Алар күбрәк угызлардан һәм төркмәннәрдән торган булалар, төрки-сельҗуклар дип йөртеләләр һәм бик зур территориядә «Бөек Сельҗукидлар» дәүләтен төзиләр. Шул ук йөзнең 60 нчы елларында, Византия гаскәрләрен җиңеп, Анатолий ярым утравын яулап ала башлыйлар һәм шунда «Бөек Сельҗук» хакимлегенә рәсми генә буйсынган Рум солтанлыгы төзиләр. Рум дип ул вакытта сельҗуклар Византия грекларын атыйлар. Алардан тартып алынган җирдә төзелгәнгә, дәүләтнең исемен дә шулай кушалар. Рум солтанлыгы, башка төрки кабилә союзларын да яулап алып, XII—XIII йөзләрдә сельҗукларның бик зур дәүләтенә әйләнә. Аның халкы составында огуз, төркмәннәрдән башка тагын бик күп төрки кабиләләр — печенеглар, кыпчаклар — һәм төрки булмаган җирле кабиләләр — греклар, әрмәннәр, көрдләр, лазлар, грузиннар, славяннар һ. б. була. Яулап алучы төркиләр күпчелек тәшкил иткәнлектән, җирле халыклар да әкренләп төрки телне кабул итәләр, төркиләр үзләре, җирле халыкның җитештерү культурасын үзләштереп, утрак тормышка күчәләр. Бу монгол яулап алуларыннан соң, XIII йөз ахырында туган Госман дәүләте чорында тагын да көчәя һәм XVI йөзнең беренче яртысында, элекке төрки һәм төрки булмаган төрле җирле кабиләләр кушылып, төрек халкы формалашып җитә.

Төрекләрнең милләт булып оешуы бик озакка сузыла, чөнки Госман империясе, чит ил капиталына буйсынганлыктан, феодаль мөнәсәбәтләрдән котыла алмый интегә, социаль-экономик яктан һаман артта кала бара, капиталистик үсеш юлына күчә алмый. Төрек халкының буржуаз милләт булып оешып җитүе XX йөзнең 10—20 елларында гына реаль булып чыга. Моның өчен Мостафа Кемаль Ататүрккә, Госман империясен җимереп, 1923 елдагы революциядән соң, төрек буржуаз республикасын төзергә кирәк була. Төркиядә шуңа күрә Ататүркне ихтирам итәләр, аңа зур-зур һәйкәлләр куйганнар.

Аңлашылса кирәк, төрекләрнең әкренләп формалашу тарихын безнең Угур болай сөйли алмый, чөнки аларда Төркия тирәсендәге халыкларның гына түгел, бәлки Европа халыкларының да төрекләрдән килеп чыгулары турында язылган пантюркистик китаплар да аз түгел. Төркиянең хәзерге вакыттагы халык санын әйткәндә дә ул «Төркиядә 36 миллион төрек яши» дип белдерә.

— Башка халыклар бармы соң? — дип сорыйбыз.

Болай туры сорау биргәч, безнең гид көрдләрнең, грекларның булуын әсти. Ә төрки халыкларны аерып сорагач, аптырап кала, бераз уйлагач, «әзәри төрекләре дә бар»,— дип куя.

Менә без Стамбулның машиналар, кешеләр тулган, йортлары нигезләреннән алып түбәсенә кадәр рекламалар белән чуарланган тап-тар урамнарына килеп керәбез.

— Сәгать төнге ике тула, шәһәр йокламаган. Ни өчен шулай? — дип сорыйбыз Угурдан.

— Бездә сәгать бер генә тула әле, сәгатьләрегезне кучереп куегыз,— дип кенә чикләнә гид, башкасын аңлатмый. Күрәсең, ул да арыган, без дә талчыкканбыз. Ни әйтсәң дә, йокы вакыты бит.

Шактый текә урамнан күтәрелеп, Таксим (бүлү, бүленеш) дигән мәйданнан уңга борылдык һәм, тагын да таррак урамда туктап, автобустан төштек. Бер йортның ишегалдына кердек. Анда тагын бер кечкенә бина бар икән. Монысы «Кеннеди отель», ягъни Кеннеди исемендәге кунакханә. Монда бары ирләр генә хезмәт итә икән, алар әйберләребезне безнең өчен алдан әзерләнгән бүлмәләргә бик тиз ташып бетерделәр. Һәр бүлмәгә икешәр кеше бүленеп урнаштык. Самолетта бераз черем итеп алган идек, йокы килми, бит-кулларны югач, йокы тагын да ачылды. Җирле вакыт белән икенче яртыда төнге Стамбулны карарга чыктык.

Урамда халык тагын да арткан. Машиналар бертуктаусыз кычкыртып узалар. Урамның тротуары шул тикле тар — ике кеше янәшә барырлык та түгел. Машина таптап китмәсен дисәң, бер-бер артлы йөрергә кирәк. Йортларның урамга чыгып торган якларында, беренче катта, вак-вак кибетләр. Аларның кайберләрендә әле сату итәләр. Кибет хуҗасы я малае, я хатыны белән бергәләп сата. Төнлә сигарет, сагыз һәм кыздырылган каштаннан башка нәрсәләр бик үтми булса кирәк.

Тәрәзәң урам якка чыкса, төнлә йоклыйм дип уйлама икән. Машиналар тавышына кешеләрнең кычкырып сөйләшүләре кушыла, тирә-як шау килә. Шуңа күрә без дә бөтен шәһәрне тутырып кычкырып сөйләшәбез:

— Безнең шәһәрләр төнге бердән соң гел бушап кала, ә монда, киресенчә, төннең икенче яртысында хәрәкәт арта гына бара икән.

— Күбесе яшьләр. Бай балалары кәеф-сафа коралар.

— Эш юк, уку йортлары аз, нишләсеннәр, башка чара юк.

Ерак китмик, төнлә адашырбыз дип, кунакханәгә борылып кайтабыз. Менә кайда икән әле капитализм төне! Ишегалдында төнге клуб. Ул тирәдә йөргән яшь кызларның һәм ир-атларның килеш-килбәтләре, кыяфәтләре һәм кыланышлары аларның холык-фигыльләрен, эш-шөгыльләрен күзгә бәреп күрсәтеп тора. Мондагы төн үз һөнәрләренең килереннән казнага өлеш кертүче законлаштырылган фахишәләр дөньясы икән! Бу — капитализм өчен гадәти бер күренеш, чөнки бер якта байлыкның аерым кешеләр кулында тупланиуы, икенче якта ярлылыкның үсүе кешенең хезмәтен генә түгел, рухи дөньясын да эксплуатацияләүгә китерә. Бу хәлләрне күрү урамдагы кибетләрнең ялтыравын күңелдә берьюлы тоныкландырып җибәрде. Капитал дөньясы чыннан да тыштан ялтырый, эчтән калтырый икән.

Иртән торып ашау залына җыелгач, Угур Аййолдыз да килеп җитте. Ләкин аның кайгысы бездә түгел: безнең гостиницада тору, ашау-эчү, багажны төяү-бушату,

автобуста йөрү хаклары, тегендә-монда хезмәт күрсәтүчеләргә чәйлек кебек бурычлар алдан түләп куелган. Ә минә командировкалы иптәшләр мондый мәшәкатьләрдән азат түгел. Гид өчен алар — кызыктырырлык объектлар. Безнең өчен бирелгән автобуста аэропорттан шәһәргә килү, отельда бер төн куну һәм иртәнге аш командировкалы юлдашларыбызга 240 ар лирга төшкән. Бу — Төркиядә бер гади кеше бер айга ала торган хезмәт хакының яртысы дип әйтерлек. Моңа без генә түгел, Төркияне элегрәк күреп белгән аксакаллар да игътибар иттеләр булса кирәк. «Яшәү кыйммәтләнгән икән!» — дип куйдылар.

Смет Кенесбаевның хәле тагын да авырая төшкән иде. Дарулар, чәйләр эчерткәләп аны юлга әзерләдек тә, иртәнге рейс белән Анкарага очу өчен, командировкалы иптәшләрнең барысын да аэропортка озаттык.

Без, гыйльми туристлар, бүген көне буе Стамбул белән танышырга тиешбез. Анкарага безнең рейс кичке аштан соң гына була.

Ниһаять, Угур безне автобуска чакырды, Стамбул белән таныштыра башлады.

Шәһәр Византия императоры Константин тарафыннан IV йөздә салынган, XV йөз уртасында төрекләр яулап алганчыга кадәр, ул Константинополь дип аталган. Яулап алгач, төрекләр аны үзләренең башкалалары итәләр һәм шәһәрнең бер өлеше йөрткән исеме белән Стамбул (Истамбул) дип атыйлар. Хәзер Стамбул җиде тауда урнашкан, халкы 3 миллионга якын, ул — Төркиянең иң зур шәһәре. Зуррак өлеше Европада, кечерәге — Азиядә. Шәһәрнең бу ике өлешен тоташтыру өчен Босфор аркылы күпер сала башлаганнар. Гидның әйтүенә караганда, ул зурлыгы ягыннан дөньяда дүртенче күпер булачак. Босфорның ике як ярында бик биек ике челтәрле тимер багана күтәрелеп, алар өстән корыч арканнар белән тоташтырылганнар. Бер мең биш йөз метр арада башка баганалар булмаячак,— дип өсти гид,— күпер шул арканнарга асылынып торачак.

— Без хәзер күпер янына ук бармыйбыз, Стамбулдан китәсе көнне сез аның яныннан паромда чыгарсыз,— дип, гид безне төп җамиларны (мәчетләрне) карарга алып китте.

Менә Сөләймания җамигы, ул XVI йөз башында хакимлек иткән төрек солтаны хөрмәтенә төзелгән. Дүрт манаралы, һәр яктан биек таш койма белән уратып алынган. Төп бина уртада бер зур гөмбәз, аның дүрт ягында дүрт кечкенәрәк гөмбәз астындагы гаҗәеп зур биек залны тәшкил итә. Койма тышындагы урам буйлап төзелгән кечкенә биналарның түбәләре дә бер үк төрле гөмбәзләрдән торалар. Бу — төрек архитектурасының гүзәл бер үрнәге, дип аңлата гид. Сөләймания зиратында Төркиянең иң мәшһүр әһелләре күмелгән. Анда төрек эпитафиясенең төрле чорларга караган истәлекләре саклана.

Сөләйманиянең иң зур байлыгы аның төрки, гарәп, фарсы кульъязмалары китапханәсе икән. Беренче кульъязмаларны монда XVIII йөзләрдә җыя башлаганнар. Соңыннан Төркия солтаннарының, аларның туган-тумачаларының шәхси китапханәләре дә Сөләймания җамигына тапшырыла килгән. Угур Аййолдызның әйтүенә караганда, бу китапханәдә кульъязмаларның һәм иске китапларның библиография таләпләреннән чыгып эшкәртелгәннәре генә дә 100 меңнән артып китә. Китапханә эшчеләренең җитмәве аркасында, бик зур милли байлык булган кульъязмаларның шактый зур өлеше эшкәртелмичә тора; фән өчен кыйммәтле материаллар дөнья күрмичә ята.

Борынгы Византия грекларының Ат мәйданына куелган төрле һәйкәлләренә карагач, без янәшәдәге Солтанәхмәт җамигына килдек. Таш койманы үтеп ишегалдына кергәч, безне үсмер малайлар уратып алдылар һәм төрле рәсемнәр тәкъдим итә башладылар. Бу рәвешттә сату итү монда тыела булса кирәк: кемдер килеп чыккач, малайлар бер-берсенә «кач, кач!» дип кычкырышып, төрле якка шәрә табаннарын ялтыраттылар. Солтанәхмәт җамигы башкаларыннан алты манаралы булуы белән аерылып тора.

Менә Төп Капы җамигы. Монда, Кремльнең Оружейное палатасындагы кебек, алтын-бриллиантлардан эшләнгән төрле әйберләр тупланган. Дәүләт байлыгын тәшкил иткән кульъязмалар да Төп Капыдагы махсус китапханәләргә урнаштырылганнар.

Шәһәр белән танышуның планына кертелгән соңгы җами — Айя-София. Бу — борынгы Византия архитектурасының гүзәл бер истәлеге. 532—537 еллар арасында

төзелгән, Ат мәйданы белән бер ансамбль тәшкил итә. Хәзерге көндә бу изге София храмы музейга әйләндерелгән.

— Сез Төркиянең байлыгын Стамбул базарыннан да күрә аласыз. Теләгегез булса, Капалы чаршыга барабыз,— ди Угур, автобуска кереп утыргач.

Өсте ябык базар төрекчә чаршы дип йөртелә, капалы — ябык, бикле дигән сүз. Димәк, без Стамбулның ябык базарында. Аркылыга һәм буйга сузылган бик күп урамнардан тора ул. Монда нәрсә генә юк! Әйберләр кыйммәт, алучы аз, сатучылар, кибет ишеге төбенә чыгып, үз әйберләрен сатып алырга өндәп торалар. Әйберне сораган хакка алу юк монда. Сатулашып арыгач, кибет хуҗасына нәрсәдер сатырга насыйп булса, алучыны ул чәй янсә кофе белән сыйлап җибәрә. Чөнки сатып алучы булмаса, алар банкротлыкка төшәчәкләр. Шуңа күрә сатучыга караганда алучы кадерлерәк. Бу инде — төрек халкының сатып алу мөмкинлеге бик түбән дигән сүз.

26 сентябрьдә кичен безне Яшел көй аэропортына илтеп куйдылар. «Контур туризм»нан бер төрек кызы озата килде. Билетларны хисапка алдыргач, хәзер соң инде дип, аны Стамбулга кайтарып җибәрдек.

Менә бер вакыт самолетка утырту башланды. Чемоданнарны алдан аерым алып киттеләр, ә кулдагы портфельләрне, кесәләрне бик җентекләп тенти башладылар. Пыш-пыш сөйләшү китте.

— Корал эзлиләр.

— Әле күптән түгел кораллы кешеләр бер самолетны пассажирлары белән бергә алып качканнар.

— Бу мыскыл итү була бит инде.

— Юк, тентесеннәр. Юкса, безне дә самолет белән бергә урлап качарлар...

Тентүне үтеп, «Боинг-707» самолеты янына киттек. Аңа «Төркия һава юллары» дип язылган. Кереп утырдык, ләкин һаман кузгалмыйбыз, нииндидер ыгы-зыгы бара. Пассажирларны самолеттан чыгарырга тырышалар, ә кешеләр тартыша. Ниһаять, без тагын аэровокзалда. Имеш, кергәндә бер кешедән пистолет тапканнар, аның юлдашларын яңадан тентергә уйлаганнар. Ни булса да булган, безне ярты сәгатьтән соң самолетка яңадан кертеп утырталар.

Бу юлларны язганда, минем кулга «Правда»ның 23 октябрь саны килеп керде. Анда, 22 октябрь көнне коралланган дүрт кеше нәкъ шул рейс белән оча торган «Боинг-707» самолетын Софиягә алып киткәннәр, дигән хәбәр бар. Самолет бортында 66 пассажир һәм экипаждан 9 кеше булган. Шундый җентекле тентүне ничек үткәннәр икән бу кораллы кешеләр, дип аптырамас җиреңнән аптырарсың.

## АНКАРАДА ОЧРАШУЛАР

Бер сәгать дигәндә, самолет Анкара аэродромына килеп төште. «Контуар туризм» вәкиле, яшь кенә бер егет, безне Ататюрк бульварындагы Мола отеленә китереп урнаштырды. Һәрбер этажында икешәр кешелек алты бүлмәсе булган бу кунакханә француз капиталына салынган, хуҗасы — француз. Димәк, чит ил капиталы кешегә хезмәт күрсәтү сферасына да үтеп кергән икән.

Иртән торып, тәрәзәдән карауга беренче тәэсир: Стамбул тар урамлы шәрык шәһәре икән. Анкара көнбатыш шәһәрләренә тартымлырак киң урамлы икән. Кичә кич гид сөйләгәннәрне, онытылганчы дип, блокнотка яза башлыйм.

Анкара шәһәренә безнең эрага кадәр VIII йөзләрдә нигез салынган. XI йөздә Анкараны төрекләр-сельҗуклар яулап ала. Кемаль Ататюрк милли азатлык хәрәкәте белән Анкарадан торып җитәкчелек итә. 1923 елда, бу хәрәкәт тәмамланып, республика игълан ителгәч, Төркиянең башкаласы Стамбулдан Анкарага күчерелә. Анкарада хәзер 1 миллион 200 меңнән артык кеше яши. Бу — Стамбулдан кала илдә икенче зур шәһәр.

Чит җирдә соң ятылса да, иртә торылган. Мин тагын тәрәзәдән, җиденче каттан, шәһәрне күзәтәм. Монда Стамбулдагы кебек зур җәмиләр күп төрле. Дүрт манаралы берәү күренә, аны, ремонтлау өчен, такта корылма белән уратканнар. Башкала булгангадыр, эре-эре биналар күзгә чалына, ләкин шәһәрнең күпчелек өлешен

бер катында бер гаилә генә урнашырлык тар, дүрт-биш катлы йортлар тәшкил итә. Болары — аерым хуҗалык галәмәтләре. Урамда рекламаларның иге-чиге юк; беренче каттан башлап соңгы катка кадәр тезелгәннәр. Дүртенче катта теш врачы тора икән, ул шунда үз тәрәзәсе турына реклама яздырып элгән: фәлән-фәлән теш врачы шушында тора, янәсе.

Менә без, гыйльми туристлар, иртәнге ашны ашагач, Ататүрк бульвары буйлап Анкара университетының тел, тарих һәм география факультеты бинасына юнәләбез. 27 сентябрь иртән сәгать 9 да анда җыелып, Ататүрк каберенә зыярәт кылырга тиешбез. Кичә соң килгәнлектән, без белми калганбыз: Иран шаһы килү уңае белән программаның бу өлеше соңгарак кичектерелгән икән. Конференция 10 да гына ачылырга тиеш. Шулай да без факультетның актлар залын эзләп табарга булдык. Эчкә үтәрлек түгел, халык җыелган. Болар да конференциягә килгән дип торсак, алай түгел икән. Бүген конкурс йомгаклары буенча I курска алынучыларның исемлеге эленгән. Халык шул исемлекне карарга җыелган булып чыкты. Безне эчкә үткәрделәр, актлар залында конференциягә килүчеләрне каршылап торучы бер-ике кеше генә бар иде. Без, совет галимнәре, залда урын алып, конференциянең программасы турында фикер алыша башлыйбыз. Көткәндә вакыт озак үтә. Коридорга чыгабыз, шунда бер укытучынымы, канцелярия эшчесенме табып, университет турында сораштырабыз. Ул бик сүзчән кеше булып чыга. Безгә күп кенә мәгълүмат бирә.

Анкара университеты әле бик яшь уку йорты икән, ул 1946 елда гына төзелгән. Аның сигез факультеты бар: филология, тарих һәм география, табигать, юридик, медицина, ветеринария, авыл хуҗалыгы, политика һәм теология факультетлары.

Анкарада тагын БМО хисабына ачылган Урта көнчыгыш техник университеты эшли. Моның дүрт факультеты бар икән: администрация, архитектура, техник һәм филология факультетлары. Бу университетта укыту инглиз телендә алып барыла, һәм анда Урта һәм Якын Көнчыгыш илләре студентлары белем ала.

Төркиядә барлык гыйльми эшләрне координацияли торган гомуми учреждение юк. һәрбер фән буенча галимнәрнең җәмгыятьләре оештырылган. Мәсәлән, тарих, тел, экономика, юриспруденция, геология, медицина, физика һ. б. бик күп ирекле җәмгыятьләр. Без катнашачак конференцияне Төрек тел җәмгыяте (Тюрк дил куруму) оештырган һәм ул төрек теле буенча беренче гыйльми конференция (Биринҗе тюрк дили билимсел курултае) дип атала. Безне бигрәк тә беренче сүзе җәлеп итә. 40 елга беренче конференция!

Төрек тел җәмгыяте Ататүркнең ризалыгы һәм кушуы буенча 1932 елда оештырылган, хәзер дә Ататүркнең килеренә яши. Аның дүрт этажлы махсус бинасы бар. Шунда директор, генераль секретарь, канцелярия, галимнәр өчен бүлмәләр, китапханә һәм киңәшмәләр үткәрү өчен заллар бар. Бу җәмгыять төрек теле буенча гыйльми тикшеренүләр җыентыгы һәм «Төрек теле» дип аталган журнал чыгара. Журналга «айлык тел һәм әдәбият журналы» дигән аңлатма да бирелә.

Конференция Тюрк дил курумының 40 еллыгына һәм Мәхмүт Кашгарлы тарафыннан төзелгән «Дивану Лугат-ит-тюрк» сүзлегенең 900 еллыгына багышланган.

Программага караганда, конференциядә катнашу өчен, галимнәр дөньяның бик күп шәһәрләреннән җыелганнар: Анкара, Стамбул, Мәскәү, Ленинград, Баку, Казан, Ташкент, Алма-Ата, Бухарест, Будапешт, Прага, София, Сиэтл (АКШ), Тирана, Белград, Геттинген (ФРГ), Гамбург, Токио, Берлин, Осло, Копенгаген, Париж, Варшава, Упсала (Швеция), Приштина (Югославия).

Беренче танышканда ук безне:

— О, иң зур делегация Советлар Берлегеннән! — дип каршыладылар.

Сәгать 10 җитте, актлар залы тулды. Менә бер вакыт фоторепортерлар колагына ишетү аппараты тыккан карт кына бер кешене йөгерешә-йөгерешә әле сәхнәдән, әле халык арасыннан торып рәсемгә төшерә башладылар. Төрек галимнәреннән сорап белдек: бу Ататүрктән соң ил белән 30 елга якын идарә иткән, Төркиянең иң өлкән дәүләт эшлеклесе, Халык республикасы партиясенә нигез салучыларның берсе Исмет Иненю булып чыкты. Димәк, төрекләр бу конференциягә бик зур игътибар бирәләр, аны политик бер чара дип саныйлар.

Сәхнәдә президиум өстәле һәм урындыклар юк. Трибуна һәм аның янында кечкенә өстәл. Трибуна артында Тюрк дил курумы президенты, философия фәннәре докторы, профессор Мәҗит Гөкберк чыгып баса, кечкенә кереш сүздән соң конференцияне ача һәм сүзне дәүләт министры Исмаил Арарга бирә. Димәк, бу конференциягә төрекләр дәүләт күләмендә әһәмиятле эш дип карыйлар.

Министр кунакларны Төркиягә килү белән котлады, конференция эшендә уңышлар теләде. Тюрк дил курумының 40 еллыгы белән котлап килгән телеграммалар укылгач, сүз курумның генераль секретаре Өмәр Асым Аксойга бирелде. Алда гына сөйләгән ораторларның сүзе һәм Аксой доклады Тюрк дил курумының 40 ел эчендә бик күп эшләр башкаруын күрсәттеләр. Җәмгыятьнең тюркология фәненә кергкән иң зур өлеше — борынгы төрки кульязмаларын эшкәртеп дөньяга чыгару. Төрек галимнәре хәзерге көндә дә бу өлкәдә зур һәм мактаулы эш башкаралар. Ләкин теоретик яктан сайлык та сизелә. Беренчедән, шуны әйтергә кирәк: төркиләрнең тарих тарафыннан берничә төрки халыкка аерылуын, шулар нигезендә инде күп кенә төрки телдә сөйләүче милләтләрнең формалашуын танымаска тырышалар. Төрки телләрнең кайсында гына язылган истәлек булмасын, алар өчен ул — тюрк теле истәлеге. Кайчандыр төрки халыкларны Төркия флагы астында берләштерү хыялыннан туган пантюркизм идеясе һәрбер лингвистик эзләнүләрнең нигезендә ята. Икенчедән, Тюрк дил курумы галимнәре пуризм (тел чистарту) идеясе белән коралланганнар.

— 1932 елларда төрек телендә төрек сүзләре 35—40% кына иде, Тюрк дил курумы эшчәнлеге нәтиҗәсендә безнең телдә үз сүзләребез 70—75 процентка җитте,— дип белдерде Өмәр Аксой.

Билгеле, чит телдән кергән һәм халыкка аңлашылмый торган атамалардан телне чистартырга кирәк. Ләкин инде халыкка аңлашыла һәм халык кулланган торган алынмаларны чыгарып ташлау, алар урынына, үз сүзләреңнән диген булып, аңлашылмый торган яңа сүзләр тәкъдим итү телне халыктан аеруга алып бара. Төрекләр бу хәл белән исәпләшмиләр, халыкка аралашырга ярыймы ул, юкмы, аңа карамастан, телгә яңа ясалма сүзләр тәкъдим итеп торалар. Төрек телен элеккерәк чыккан дәреслекләрдән өйрәнгән кешеләргә Өмәр Аксойның үз теле дә бик авыр аңлашыла.

Өмәр Аксойдан соң конференциядә катнашучыларны төрле ил делегацияләре тәбрикләделәр. Беренче сүзне Совет делегациясе исеменнән профессор А. Н. Кононов алды. Конференциянең председателе утырышның башыннан ахырына кадәр трибуна янындагы өстәл янында басып торды.

Өйләгә тәнәфес игълан ителгәч, безне элекке танышлар урап алды. Иң элек:

— Зәкиев абый, безне таныйсызмы? — дип, Бухарестан Әнвәр һәм Нәдрәт Мамутлар килеп күрештеләр. Алар Румыниядәге Добруҗа татарларыннан булып, моннан берничә ел элек Казан университетының татар филологиясе бүлеген тәмамлаган иделәр. Алар хәзер икесе дә Бухарест университетында эшлиләр: Әнвәр — тел, Нәдрәт фольклор укыта.

Конференциянең калган барлык утырышлары Тюрк дил курумы бинасында булды. Алар ике секциягә бүленгән иде. Турыдан-туры төрек теленә һәм тел материалларыннан чыгып төрек тарихын өйрәнүгә караган докладлар «Төркия төрекчәсе» дигән секциядә укылды. Чыгышларның башка төрки телләргә караганы «Төркия тышындагы ләһҗәләр» дигән секциягә тупланган иде. Ике секциядә дә докладларның юнәлешләре бик чуар иде. Биредә фонетика да, лексикология дә, морфология дә һәм борынгы текстларны өйрәнү дә бар. Ләкин шунысын әйтергә кирәк: барлык докладлар да билгеле дәрәҗәдә теге яки бу төрки халыкның формалашу тарихы белән бәйләнгән иде. Татар теле һәм тарихы турында Токиодан килгән профессор Широ Һаттори «Төрки телләр арасында татар теленең урыны» дигән чыгыш ясады. Башта ул телләрнең формалашу процессында булган фонетик үзгәрешләргә тукталды, ягъни фонетик закончалыкларга таянып, үз докладына фәнни нигез бирде. Шуннан соң төрле галимнәрнең фикереннән чыгып, Идел болгарлары теленнән 12 сүз китерде, аны чувашча, татарча, команча сүзләр белән чагыштырып, Идел болгарларының теле чуваш телендә, коман (кыпчак) теле татар телендә сакланып калган дигән нәтиҗә чыгарды.

Менә Ш. Һаттори таблицасы (транскрипциясе үзгәртелде):

| Һаттори фикеренчә, Идел-болгар сүзләре | Чувашча | Татарча | Команча |
|---|---|---|---|
| һир | хӗр | кыз | кыз |
| жүр | ҫӗр | йөз | — |
| алты | улттӑ | алты | алты |
| жал | ҫул | йәш | йаш |
| жиети | ҫичӗ | жиде | — |
| сәкир | саккӑр | сигез | сегиз |
| әлев | аллӑ | илле | — |
| биел | пиллек | биш | беш |
| тухыр | тахар | тугыз | тогуз |
| йон | ванна | ун | — |
| күән | кун | көн | күн |
| түәтим | тӑват | дүрт | дөрт |

Таблицага анализ биргәч, бик тулы булмады дип уйласа кирәк, Ш. Һаттори тагын болай дип белдерде: Идел татарлары — нигездә Идел болгарларыннан калган халык, ләкин алар бу җирләрне яулап алган һәм Алтын Урда дәүләте төзегән татарлар белән аралашканнар һәм шуларның кыпчак телен кабул иткәннәр.

Һаттори үзенең докладын төрек телендә сөйләде. Төрекчә белү минем дә шуның кадәр генә булганлыктан, докладтан соң ук без сораулар биреп аңлаша алмадык. Фикер алышуны тәнәфестә икәүдән-икәү генә дәвам итәргә туры килде. Широ Һаттори төрек теленә караганда татарчаны яхшырак белә икән.

— Һаттори әфәнде, сез Волга-болгар (Волга елгасын без Идел дибез), ягъни Идел-болгар теленнән 12 сүз китердегез. Аларны сез кайдан алдыгыз һәм аларның Идел-болгарныкы булуын ничек исбат итә аласыз?

— Бензин һәм Поппе хезмәтләреннән һәм башка гыйльми чыганаклардан. Кызганычка каршы, Идел-болгар теле үрнәкләре сакланмаган, шуңа күрә ул сүзләрнең болгарларныкы булуын төрле тикшеренүләрдән генә белеп була. Бик мөмкин: бәлки болгарча алай булмагандыр да.

— Рәхмәт, Һаттори әфәнде, 10нчы йөздә Идел болгарлары ислам динен кабул иткәннәр, соңыннан гарәп язуында күп кенә тарихи һәм әдәби әсәрләр калдырганнар дигән фикер бар. Идел болгарлары культурасының соңгы буыннарга тапшырылу процессы турында нәрсә әйтә аласыз? Чувашларда һәм татарларда болгар культурасының нинди традицияләре бар?

— Әфәндем, мин культура тарихын әйтә алмыйм, мин тел проблемалары белән генә шөгыльләнәм.

— Рәхмәт. Тагын бер сорау бирергә рөхсәт итегез, Һаттори әфәнде. Сезнең таблицада китерелгән сүзләрне Идел болгарларыныкы дип исбатлый алган очракта да, 12нең алтысы гына чуваш сүзләренә якын, калган алтысы татар сүзенә якынрак. Мәсәлән, болгарча-татарча: алты — алты, җиети — җиде, әлев — илле (чувашча — аллӑ), йон — ун, күән — көн, җал — йыл (җыл). Соңгысын сез таблицада ялгыш күрсәткәнсез. Йәш чувашча да яшь, чувашча ҫул — болгарча җал — татарда йыл (диалектта — җыл). Сез боларга ничек карыйсыз?

— Һичшиксез, болгар-чуваш, болгар-татар проблемалары хәл ителеп тәмамланган проблемалар түгел. Бәлки киресенчәдер. Эшләргә, исбатларга кирәк. Моның өчен телнең закончалыкларын өйрәнү-ачу иң ышанычлы юл.

— Туры җавабыгыз өчен рәхмәт, Һаттори әфәнде. Инде хәзер турыдан-туры докладыгызга карамаган бер тәкъдим. Әйдәгез, чәй эчәргә чыгабыз, юкса арыгандырсыз.

— Юк, талчыкмадым, ләкин чәй эчү — ярый торган эш.

Көн бик эссе, 30—33°. Без Һаттори белән чынаякларны тотып, чәй эчә-эчә коридорда әңгәмә алып барабыз.

— Сез, Һаттори әфәнде, алтаистиканы яхшы беләсез инде. Бу теория буенча төрки, монгол, тунгус-маньчжур телләре ерак тарихта бер телдән аралганнар. Шунда ук корея һәм япон телен дә кертәләр. Төрки телләрен һәм япон телен яхшы белүче буларак, Сез моңа ничек карыйсыз?

— О, мин моңа уңай карыйм. Мин үземнең хатыным Мәһирә ханымнан татарча өйрәнгәндә үк моңа игътибар иттем. Япон һәм төрки телләре лексик яктан бик нык ераклашканнар, ләкин синтаксик төзелешләре боларның нәкъ бер төрле. Димәк, төрки һәм япон телләре бик борынгы чорда я бер телдән аерылып киткәннәр, я кайчандыр бер-берсенең төзелешенә бик нык тәэсир итешкәннәр.

Конференциянең беренче өлеше шуны күрсәтте: Төркиядә дә, башка илләрдә дә күбрәк игътибарны язма әдәби телләр, төрле борынгы язмалар өйрәнүгә бирәләр. Шул ук вакытта иске язма әдәби телнең башка тел (дин теле) сүзләре белән чүпләнмәгән булуы да исәпкә аз алына, бу ясалма алынмаларның борынгы тарихны тел материаллары аркылы өйрәнүгә комачау итүләр бөтенләй әйтелми. Җанлы телләрне тикшереп, халыкның борынгы тарихын өйрәнүгә өлеш кертү буенча нигездә совет тюркологлары эшлиләр икән. Теоретик яктан да безнең докладлар башкалардан уңай якка аерылып торды. Моны төрек галимнәре дә таныдылар һәм утырышларга күбрәк совет тюркологлары җитәкчелек иттеләр. Тагын шунысын әйтергә кирәк: төрек тюркологлары Советлар Союзында басылган хезмәтләрдән бик нык файдаланалар, аларны читләтеп үтә алмыйлар.

Конференциянең икенче өлеше иске төрки ләһҗәләре (диалектлары) һәм «Дивану Лугат-ит-тюрк» дип аталган иде.

Иртәнге утырышта Әзербәйҗан университетының уку-укыту эшләре буенча проректоры профессор Әлүәвсәт Абдуллаев председательлек итте һәм конференциянең икенче өлешен ачу алдыннан кереш сүз сөйләде.

Моннан 900 ел элек Мәхмүт Кашгарлы тарафыннан төзелгән «Дивану Лугат-ит-тюрк» сүзлеге төрки халыкларның һәм аларның күршеләренең тарихын, этнографиясен, әдәбиятын, фольклорын һәм телен өйрәнү өчен энциклопедик чыганак хезмәтен үти, дип башлады Ә. Абдуллаев.— Бу бөек истәлекнең 900 еллыгы Советлар Союзында нәкъ бер ел элек билгеләп үтелде. Аерым алганда, 1971 елның 7—9 октябрендә Фергана шәһәрендә бөтен Союз күләмендә өч көнлек конференция булды. Анда 105 тюрколог катнашты, Советлар Союзының 20 гә якын шәһәреннән 43 доклад тыңланды. Шушы конференциянең эшендә актив катнашкан тюркологлардан бер төркем СССР Фәннәр академиясе тарафыннан Төркиядәге конференциягә җибәрелде. Абдуллаев тагын Мәхмүт Кашгарлы хезмәтен СССРда өйрәнү тарихына һәм шул хезмәтләрнең кыскача эчтәлегенә тукталды.

Шуннан соң Төркия дәүләт театрының бер артисты Хәсни Дагларҗа тарафыннан Мәхмүт Кашгарлы истәлегенә язылган шигырьне укыды.

Конференциянең бу өлешендә СССРдан ике доклад укылды: иртәнге утырышта — «Төрки синтаксик системасын өйрәнүдә «Дивану Лугат-ит-тюрк»ның әһәмияте» дигән минем доклад, кичкесендә — «Мәхмүт Кашгарлы «Дивану...»ның төрле басмалары» турында — Ташкенттән Э. Фазылов докладны.

Төрекләр конференциядә төрек, немец, инглиз, француз телләрендә генә сөйләргә рөхсәт иттеләр. Совет делегациясе вәкилләре үз докладларын төрек телендә, ә милли республикалардан килгәннәре үз телләрендә укыдылар.

Смет Кенесбаев конференциядә бөтенләй катнаша алмады: Анкарага килеп җитү белән аны Совет илчелеге аркылы больницага салырга туры килде. Аның докладын казакъ телендә Әдһәм Тенишев укыды. Смет Кенесбаевның үзен, хәле бераз рәтләнгәч, самолетка утыртып, туган илгә озаттык. Аңа яхшы юлдаш та булды. Измирдәге ярмаркада берничә ай буе эшләгән Роза Юсипова иде ул. Роза Юсипова, тюрколог

буларак, конференциядә катнашты һәм төрек телендә тирән эчтәлекле доклад сөйләде.

29 сентябрьдә көндезге аштан соң конференциядә катнашучыларны, автобусларга утыртып, Ататюрк каберенә алып киттеләр. Ул бер калку урында төзелгән берничә бинадан һәм төрле корылмалардан тора. Төп бинасы төрек милли фрескалары белән бизәлгән. Венок кую тантанасының башында Тюрк дил курумы генераль секретаре Өмәр Асим Аксой һәм профессор Андрей Николаевич Кононов бардылар. Конференциядә катнашучылар исеменнән венок куюны А. Н. Кононовка тапшырдылар һәм ул мондагы истәлекләр журналына галимнәрнең фикерен язып калдырды. Димәк, төрек галимнәре Совет тюркологларын әйдәп баручылар итеп таныйлар.

Конференция тәмамланган көнне кичен Анкара шәһәре муниципалитеты башлыгы Әкрәм Барлас галимнәрне коктейльгә чакырды. Ататюрк бульварындагы Бульвар Паласның зур залы. Бер якка өстәлләр, урындыклар төзелгән, өстәл өстендә тәлинкәләргә кытырдап торган, киптерелгән бәрәңге куелган. Залның икенче яртысы буш. Әңгәмә башта өстәл тирәсендә утырып, әкрен генә кипкән бәрәңге кетердәтүдән башланды. Официантлар эчемлек өләшергә тотынгач, кешеләр залның буш калган өлешен тутырдылар. Очрашулар, танышулар, фәнни бәйләнеш урнаштыру, фикер алышулар башланды. Миңа монда Татарстан галимнәренең татар тарихы, әдәбияты һәм теле буенча эшләре турында берничә мәртәбә сөйләргә туры килде, чөнки күп кенә чит ил галимнәре кызыксыну белдерделәр, күп кенә гыйльми хезмәтләр җибәрүемне үтенделәр. Күп әңгәмәләрнең берсе турында әйтми мөмкин түгел. Венгриядән фәннәр докторы Жужы Какук ханым үзенең татар текстларын дөньяга чыгарырга әзерләнүен әйтте. Беренче бөтендөнья сугышы елларында әсирлеккә эләккән татарлардан бер венгр галиме җырлар, әкиятләр, бәетләр, мәкальләр, табышмаклар яздырып алган, ләкин ул аларны үзе эшкәртеп чыгара алмаган. Менә шул күп томнарга җитәрлек язмаларны эшкәртеп матбугатка әзерләүне Жужы Какук ханым үз өстенә алырга булган, ләкин безнең тарафтан булышу кирәк икән. Бу эштә мин аңа ярдәм итәргә әзер булуымны белдердем.



## Ике сәяхәт

### БЕРЕНЧЕ СӘЯХӘТ

Төрек галимнәре үз кунакларына Төркиянең аерым урыннарын күрсәтүне программага баштан ук керткәннәр иде. 30 сентябрь көнне иртәнге 9 да Тюрк дил курумы янынннан автобусларга утырып ике көнлек сәфәргә чыгып киттек.

Әйткәнемчә, Анкара таулы-чокырлы урынга урнашкан. Аның янындагы авыллар да теп-текә шәрә тауга утырганнар. Гомумән, табигать монда бик ярлы. Без таулар арасыннан барабыз. Ул шәрә тауларга нарат кебек агачлар утыртылган, ләкин алары да әйбәт үсмәгән. «Җир, табигать тузса да туза икән» дигән гаҗәпләнү тойгысы белән ала. Кеше туздырган бит аны, дөресрәге, билгеле бер кешелек җәмгыяте туздырган. Тузмыйча мөмкин дә түгел. Бу җирләр бит — кешелекнең иң борынгы бишекләреннән берсе. Монда әле безнең эрага кадәр ике мең ел элек хеттларның колбиләүчелек дәүләте барлыкка килгән. Безнең эрага кадәр VIII йөзләрдә бу җирләр борынгы Персиягә, аннан соң Македониягә кергән. Соңгысы чорында җирле халыклар греклашканнар. Безнең эрага кадәр II—I йөзләрдә бу җирләр римлеләр кулына эләгә. Рим империясе таркалганда, монда Византия империясе төзелеп кала, бу чорда Анкара тирәләрендә уңдырышлы, бай табигатьле җирләр була, авыл хуҗалыгы бик нык алга китә. XI йөзнең ахырында бу тирәләрне күчмә тормышлы сельҗуклар яулап ала, чәчү җирләре башта көтүлекләргә әйләндерелә, электән үк тузып килгән табигать тагын да ярлылана, ташландык җирләр барлыкка килә.

Без мена шул җирлардан барабыз. 33—35 градуслы коры эсселектан кереп сыенырга бер генә күләгә урын да юк, бер генә агач та юк. Ара-тирә зур шәрә тау итәгенә янсә текә тау ярына сыенган кечкенә авыллар күренеп кала. Тигез түбәле балчык өйләр янында сирәк-мирәк кенә хатын-кызлар күренгәли. Алар я авырлы, я яшь бала күтәргән, я берсеннән-берсе бәләкәй өч-дүрт бала иярткән. Үләне корып кибеп беткән ташлы җирдән ашарга нәрсәдер табып, ара-тирә ишәкләр чемченеп йөри. Кечкенәрәк шәһәрләр, зуррак авыллар үтәбез. Аларның бик борынгы икәннәре күренеп тора, һәрберсе, дошманнан сакланырга җайлы булсын өчен, текә тау борынына утырганнар. Бер урамнан икенчесенә күчү өчен, текә таудан күтәрелергә яисә төшәргә кирәк. Олы яшьтәгеләре, бала-чагасы, ире, хатыны — барысы да ишәк өстендә. Текә ярдан күтәреләләр, төшәләр, әйбер ташыйлар, мәктәпкә баралар. Ишәккә атланган хатыннар, җыелышып, авылның соңгы хәбәрләрен сөйләшеп торалар. Ишәкләр булмаса, текә тау битендә бу халык ничек яшәр иде икән? Күп кенә урамнарына машина белән керермен димә. Авыл урнашкан тау шундый текә: берәр, икешәр катлы йортларның бер ягы тауга сыенып тора, тау хәтта кайбер йортларның стенасы хезмәтен үти. Безнең авылларда булган кебек келәт, мунча, абзар-каралтылары юк. Аларны, тау тишеп, җир астына ясаганнар. Мондый шәһәрчекләрдә йортлар балчыктан түгел, ә таштан салынган. Иң элек ташны зур кисәкләр итеп чыгаралар, йорт салынасы җирләргә ташыйлар. Шунда алардан, берәмтекләп, яртышар метр озынлыгындагы зур шакмаклар ясыйлар. Шулардан әкренләп йортлар салына. Кирпеч куллану күренми. Кечкенә генә йортлар да бик күп еллар буе салына булса кирәк. Чөнки яңа төзелеш бара торган һәр җирдә бер үк хәлгә тап буласың: астагы катта кешеләр инде тора, ә өске каты салынып ята. Ләкин анда да стена салучылар күренми. Өч-дүрт кеше тәртипсез формалы зур ташлардан аста дүрт почмаклы зур кирпеч ясап азапланалар. Төп хезмәтне шул эш ала, күрәсең. Әзер булган берсен илтеп стенага салалар, тагын ниндие кирәк, шундыен ясарга керешәләр. Бөтен нәрсә кулдан чүкеч белән эшләнә. Бездәге кебек күтәрү краннарын кечкенә шәһәрләрдә түгел, зурракларында да күрергә туры килмәде.

Без бара торган Анкара — Невшеһәр маршрутындагы юлга бик тигез итеп асфальт җәелгән, аны игътибар белән карап, төзәтеп торалар. Соңгы елларда юлларның төзеклегенә төрекләр үзләре генә түгел, бәлки НАТО һәм СЕНТО да бик зур әһәмият бирә икән. Стратегик әһәмияткә ия булганлыктан, юлларның күбесе дәүләт карамагында. Анкара тирәсендә, илнең үзәк районында тимер юллар җитәрлек булмаганга, автомобиль юллары бик тыгыз. Ташыла торган йөкләрнең бик күп өлеше шушыннан үтә булса кирәк. Шуңа күрә бу юлларда машинада йөрү куркынычлы. Юл буена тәгәрәп төшкән ватык машиналар да, әле хәзер генә булган аварияләр дә шактый еш очрый.

200—300 км китеп, күзгә күренердәй бер елга очрамады, кечкенәләре дә бик сирәк. Мена безнең автобус бер гаҗәеп күл буеннан бара. Өсте күзгә кебек тигез, җил булуга карамастан, дулкын юк, бездәге сулар кебек зәңгәрләнеп, яшелләнеп тә тормый — ап-ак. Бу Төркиянең иң зур тоз күле булып чыкты. Күлнең якын тирәсендә берниндн үсемлек һәм җан иясе күренми, тик теге як ярында уенчык кебек кенә булып тоз чыгаручы машиналар күренеп тора.

Тоз күлен үтеп бераз баргач, уйсурак җирләрдә чәчүлекләр күренә башлый, ләкин бездәге кебек зур иген басулары түгел алар. Вак-вак өлешләргә тәртипсез итеп бүленгәннәр. Бер участокта хуҗа арбасын юл читендә калдырган да җирен трактор белән сөрә, күршесендәге хуҗа, бер төрәнле сабанны бер ябык кына аттан тарттырып, кечкенә генә җирен сөреп азаплана. Ара-тирә кырда бәрәңге алучылар күренеп китә. Халык кайда да халык: чит ил туристларын йөртүче автобусларны танып, эшләреннән туктап кул болгап калалар.

Көндезге ашны юл буена туристлар өчен махсус салынган ресторанда ашаттылар. Бу тирәдә шактый гына агачлар күренә, шуңадыр ресторанны да «Агачлы» дип атаганнар. Өйләдән соң тагын күп кенә авыл һәм шәһәрчекләрне үтеп, сельҗуклар тарафыннан салынган кәрвансарайлар һәм архитектура истәлекләре белән танышатаныша, кичен Невшеһәргә килеп җиттек. Бу — урта куллы гына административ үзәк. Өйләр, мәчет манаралары — барысы да таштан салынган. Җиңел промышленностька кадрлар әзерләүче бер лицей бар. Лицей каршында юл аркылы гына мәктәп булса

кирәк: аның янында 8—9 яшьлек балаларга гимнастика ясатып, бер хатын-кыз укытучы басып тора.

— Сездә дә укытучыларның күбесе хатын-кызлармы? — дип сорыйбыз гид хезмәтен дә үтәүче шоферыбыздан.

— Әйе, 65 проценты хатын-кызлар,— ди ул.

Төркиядә республика игълан ителгәч, балаларга мәҗбүри башлангыч белем бирү кертелә. Башлангыч белем бирү ике баскычлы. Беренче баскычта уку — өч ел, икенчесендә — ике ел. Башлангыч мәктәпнең ике баскычын да тәмамлаган бала урта мәктәпкә керә ала, урта мәктәп өч еллык. Урта мәктәптән тыш, белгечлек бирә торган лицейлар да бар. Профессиональ-техник белем махсус башлангыч һәм урта мәктәпләрдә дә бирелә.

Кемаль Ататюрк революциясеннән соң укырга, белем алырга барлык хокуклар игълан ителә. Ләкин рәсми хокук бирелү — эшнең башы гына, моны тормышка ашыру өчен материаль мөмкинлекләр кирәк. Аның булмавы аркасында, хәзерге көндә Төркия халкының яртысы дип әйтерлек укый-яза белми. Балаларның күп кенә өлеше уку урынына эшләргә мәҗбүр булалар.

Невшеһәрдәге туристлар кунакханәсендә ял итеп, икенче көнне, 1 октябрьдә, иртән җир асты шәһәрен карарга киттек. Без барыбыз да башта аны табигать тарафыннан төзелгән зур тау тишеге дип уйлаган идек. Автобус югарыга күтәрелгән саен, текә тау битен күзәтеп бардык: тау тишегенең башын эзләдек. Менә без тауның өстенә үк менеп, тагын 5—10 км чамасы киттек. Ниһаять, бер авылда туктадык һәм безне кечкенә бер җир тишегенә алып керделәр. Бу табигый тишек түгел, ташны миндидер үткен әйберләр белән тырмап ясаганнар, иелеп кенә кермәсәң, баш тия, кара-каршы килсәң, ике кеше бер-береңә юл биреп үтә алмыйсың. Менә без җир астында зур залда. Монда инде иелмичә басып торып була. Түшәм-стеналары капкара корым. Элек шәм яндырганнар булса кирәк. Ә хәзер туристлар өчен электр үткәрелгән. Экскурсовод, шул зур залда безне җыеп, кечкенә лекция укыды, миннән башка бер тишеккә дә кермәгез, адашырсыз, диде. Алай-болай адашсагыз, бер урында гына тавыш биреп торыгыз, күчеп йөрмәгез. Шулай итсәң генә монда адашкан кешене табып була, юкса, бөтенләй югалуыгыз бар, янәсе. Бу зур залдан төрле якка берәр кеше генә үтәрлек тишекләр тишелгән, алар тагын шундый ук бүлмәләргә илтәләр. Аларның кайберләре махсус ашау бүлмәсе итеп эшләнгән. Тауны кискәндә, уртада озын өстәл һәм ике яклап эскәмия калдырылган. Бүлмә стеналарына виноград сыгып шәраб ясау өчен резервуарлар уелган. «Чыннан да, шәһәр икән бу! Күр, ничә бүлмә, санап бетерерлек түгел»,— дип, туристлар хәйран калып йөриләр. Боларның барысын да каты ташны нәрсә беләндер уеп ясаганнар бит. Уелган вак ташларны шул тар юллардан чыгарырга кирәк булган. Күпме колның гомере өзелгәндер монда! Беренче тәэсирләргә бәя биреп өлгермисең, безне урап-урап төшә торган тишектән аска алып төшәләр. Анда шәһәрнең икенче каты икән. Шундый ук бүлмәләр, шундый ук заллар.

— Тагын төшәбезме?! — дип шаярта берәү безнең гидны. Аныңча, җир асты шәһәренең тагын бер каты булу һич мөмкин түгел.

— Әйе, төшәбез, әфәнделәрем,— ди гид.

Без әле ышанмыйбыз. Менә икенче катны да карап бетердек. Үзеңне җир астында хис итү җанны да изә, моннан чыгу юлын эзлисе килә. Ләкин җир астындагы бу бетмәс-төкәнмәс юллар, бүлмәләр арасыннан бернәрсә табарлык түгел. Без, җир өсте кешеләре, кояшка карап якны билгеләргә өйрәнгәнбез. Монда кереп, бер-ике бүлмәне карарга өлгермисең, ориентирны югалтасың.

— Җир өстенә чыгып, якты дөньяны күрер көннәр бар микән?— дип сөйләну, уфтану-шаяру тавышлары да ишетелә башлый.

Шул вакыт гид:

— Әфәнделәр, чыгабыз! — дип, безне тагын бер юлдан алып китте.

Бу нәрсә?! Тагын аска төшәбез түгелме?! Әйе, аска төшәбез! Менә шәһәрнең өченче каты! Менә, ниһаять, дүртенче каты! Юк, башка төшмибез инде. Безнең борчылулар, уйланулар гидка да күчте булса кирәк:

— Башка төшмибез, әфәнделәр. Бу җир асты шәһәре — җиде катлы, калган өч каты әле гасырлар буе тупланган туфрактан арындырып та бетерелмәгән. Килегез, кое күрсәтәм,— дип безне бер читкә чакырды.

Гид, кулындагы газеталарга ут төртеп, коега ташлады, без күзәтәбез. Бу коеның төбе бармы икән? Газеталар яна-яна төшәләр, янып бетәләр, ә төпкә төшеп җитмиләр. Якынча 1 метр $\times$ 70 см зурлыгындагы бу кое ташны шундый тигез кисеп ясалган — исең китәр. Шушы бер кое җир асты шәһәренең барлык җиде катын да тоташтыра. Шәһәрне борынгы Византия империясе V йөздә коллардан төзеткән. Анда 20 мең кеше, беркая чыкмыйча, бер ел буе дошманнан качып ята алган. Аскы катларда салкынрак, өстәгеләрендә җылырак булганга, монда һава тиз алмашына, тәмәке төтеннәре дә шундук каядыр китеп юк була.

Җир асты шәһәре кешеләргә мең ел чамасы хезмәт иткән, 15 нче гасырда аны ташлаганнар. Ул вакыт тузаны белән капланган. 1960 елларда төрекләр, чистартып, электр утлары үткәреп, аны туристлар өчен ачканнар.

Ниһаять, без җир өстендә! Яшәсен якты дөнья! Кешегә күп кирәкмени? Барысы да җир астыннан соң якты дөнья күрүгә куанышалар.

Менә без тауның каршы ягына килеп җиттек. Автобуслардан төшеп, өстән иңкүлекләрне күзәтәбез. Гаҗәеп күренеш!

— Марс өстенең фантастик рәсемнәрендә генә мондый күренешне күзәтергә мөмкин дип уйлый идем. Җир өстендә аннан да җиллесе бар икән! — дип гаҗәпләнә башлыйбыз.

Күз күреме җитмәслек тигезлек эреле-ваклы чүмәләләр, манаралар белән тулган. Болар барысы да — дөрес формалы тоташ таш таулар. Кайбер таш манараларның өстенә, гаҗәеп зур бүрек булып, икенче таш кунган. Вулкан атылганда төрле якка очкан ташлар шулай кунганнар дип аңлата гид. Табигатьнең үзе тарафыннан ясалган бу тоташ таш чүмәләләр, манаралар үзләре үк кешене актив хезмәткә этәргәннәр. Шул тауларны чокып кереп, кешеләр үзләренә торак урыннары ясаганнар, гыйбадәт кылу өчен зур заллар тишкәннәр. Зуррак таш чүмәләләрдә 5 әр, 6 шар катлы тораклар тишелгән. Аларда хәзер инде тормыйлар, ләкин шул чүмәләләр арасына салынган торак пунктларында алар склад, келәт хезмәтен үтиләр.

Тау-таш арасында әйбер үстерерлек җирне табуы кыен. Шуңа күрә борынгы кешеләр җирне ашлауга бик зур игътибар биргәннәр. Тау ташларын матур итеп колонналап кисеп, күгәрченнәргә махсус оялар ясалган. Бу ояларда хәзер миллиардлаган күгәрченнәр тереклек итә, һәм алар кешеләргә ничә мең ел инде җир ашлау өчен ашлама бирәләр.

Бу тирәләрдә йөзем плантацияләре еш күренә. Шунда ук вино заводлары очрый. Крестьян балалары, ишәкләргә төяп, йөземне шушы заводларга алып килеп саталар. Урыны-урыны белән помидор утырткан басулар да күренгәли. Чокырлырак, дымлырак урыннарда бездәге таллар кебек куаклар үсеп утыра. Гид безгә аларның ботакларын сындырып, бер кочак алып килә. Ни күрик, тал түгел, ә хөрмә агачы икән! Хөрмәсе инде җитешкән. Барыбыз да авыз итәбез.

Невшеһәрдә әйлә ашын ашагач, бер автобус безне, гыйльми туристларны, туры Анкарага алып китә. Башка галимнәр Анкарага әйләнеч юлдан, әле без күрмәгән шәһәрләр аркылы кайтачаклар.

Кичке сәгать 6 да без, Анкарага кайтып җитеп, Мола отеленә туктыйбыз. Безне «Контуар туризм» вәкиле Анкара аэропортына алып китә һәм без Измирга очабыз.

## ИКЕНЧЕ СӘЯХӘТ

Измирга төн уртасында килеп төштек. Безне Угур Аййолдыз каршы алды. Ул, безнең белән йөрү өчен, Стамбулдан Измирга махсус килеп торган. Стамбулдагы «Контуар туризм» безне йөртү өчен микроавтобус җибәргән. Шул автобус белән аэропорттан шәһәргә кайттык һәм «Измир палас» дигән кунакханәгә урнаштык.

2 октябрьда иртән борынгы Эфес шәһәре хәрабәләрен карарга киттек. Табигать гаҗәп бай. Биек-биек таулар урман белән капланганнар, түбәнрәк урыннарда мамык һәм тәмәке плантацияләре. Измир тирәсендә тәмәке үстерү бик нык алга

киткән булырга тиеш, чөнки шәһәрдә дә, авыл җирләрендә дә атлаган саен дип әйтерлек «Тәтенчеләр банкысы» (тәтен — тәмәке) очрый. Бу тирәдә җирләр вак кисәкләргә бүленмәгән. Эре кулак яисә дәүләт хуҗалыклары өстенлек ала, күрәсең. Җир эшкәртүдә күбрәк машиналар кулланыла, ләкин җир өстендә эшләп йөргән батракларны еш күрәсең. Тау битләрендә, тау өстендәге ачык урыннарда йөзем плантацияләре очрый.

Без биек бер тауга урата-урата күтәреләбез. Алдыбызда Эгей диңгезе җәелеп ята. Урман эчендә, туристларга күрсәтү өчен, төрле корылмалар ясалган. Бу — «Мәрьям ана өе», ягъни «Изге Мария торган өй». Төрекләр аны элекке легендаларга таянып 1951 елда реставрацияләгәннәр һәм туристларга күрсәтә башлаганнар.

Шуннан соң без борынгы Эфес шәһәре хәрабәләрен карарга киттек. Бу — ике тау арасында Эгей диңгезеннән ерак түгел бер урынга салынган. Гаҗәеп озын бер урамнан тора, урамның буеннан-буена тип-тигез итеп таш җәелгән, күп урында өсте каплаулы булган. Йортлар бер-берсенә терәлеп үк торалар. Алар ак мәрмәрдән бизәкләп, колонналап салынганнар. Гидның аңлатуына караганда, әле төрекләр монда килгәнче үк, ниндидер чир таралып, Эфес шәһәренең халкы үлеп бетә язган, исән калганнары яңа җирләргә күчеп киткәннәр. Шәһәр төрле күчмә кабиләләр тарафыннан таланган, кайчандыр җир тетрәүдән җимерелгән, хәрабә хәленә килгән. Гасырлар үткәч, тора-бара ул җир астында калган. Шәһәр XIX йөз ахырында XX йөз башларында гына археологлар тарафыннан ачылган. Анда әле дә казу эшләре алып барыла, яңадан-яңа йортлар, бүлмәләр, архитектура истәлекләре табыла. Эфес шәһәрендә культура бик нык үскән булган. Андагы укыту биналарының, китапханәләрнең, театрларның зур зәвык белән эшләнүе моның шулай икәнен сөйли. Ике театрның зуррагы ярты түгәрәк формасында хәзерге стадионнар кебек эшләнгән, 66 рәт утыру урыннары тоташ кыйммәтле таштан салынган, 25 мең кешелек. Монда хәзер казу эшләре тәмамланган һәм менә берничә ел инде Төркиянең җыр конкурслары шушында үткәрелә башлаган.

Измирга кайтышлый, безгә Торбалы шәһәрендәге махсус музейда Эфестан табылган истәлекләрне күрсәттеләр. Алар тагын бер мәртәбә Эфестагы культураның югары дәрәҗәдә булуын исбатлыйлар.

Измирда ел саен халыкара ярминкә була. Без шунда киттек, анда танылган тюрколог Н. А. Баскаковның улы тәрҗемәче булып эшли, диделәр. Ярминкә моннан бер атна чамасы элек ябылган, шулай да гид барып аңлаткач, безне аның территориясенә керттеләр. Совет павильонын эзләп таптык, анда машиналарны җыеп ящикларга тутырып яталар иде. А. Баскаковны очраттык, ул директор тәрҗемәчесе булып эшли икән. Директор белән таныштык. Хәл-әхвәлләр сорашкач, күргәзмәнең эше турында сүз китте. Гадәттәгечә, Совет күргәзмәсе быел да иң зур уңыш казанган.

Измирда шәһәрнең үзе белән танышырга да вакыт калган иде. Бу шәһәр зурлыгы ягыннан Төркиядә өченче урынны алып тора. Хәзер анда 700 меңнән артык халык яши, күбесе төрекләр, икенче бөтен дөнья сугышы вакытында греклар һәм әрмәннәр шәһәрдән читкә куылганнар. Йортларның күбесенә су һәм канализация үткәрелгән. Төркия өчен бу — бик сирәк күренеш. Стамбулдагы кебек монда да бик зур ябык базар бар. Аның тар урамнарында сатучылар тавышы яңгырап тора. Кибетләрдә Америка, Англия, Франция, Италия һәм башка илләрдән кергән товарлар күп очрый. Нәкъ менә шул чит ил товарлары күпләп кергәнгә күрә, Төркия үзенең эшләп чыгару предприятиеләрен ныклап үстерә алмый һәм шуңа күрә илдә эшсезлек күп урын ала.

Кичен Эгей диңгезе ярындагы бульварда үтеп йөрерлек түгел иде. Портка Италия флотының унлап корабльдән торган бер берләшмәсе килеп туктаган. Анда тротуарларга, урамнарга өстәлләр, урындыклар куеп, кәеф-сафа корып утыралар. Кем кайсы телдә сөйли: аерырлык түгел. Ниндидер сату-алу эшләре дә бара. Матрослар арасында шикле хатын-кызлар буталып йөри. Нәрсә генә юк бу Эгей төнендә!

3 октябрьда без иртүк тордык һәм үзебезнең микроавтобуста 650 километр ара үтеп, кичке тугызларда Стамбулның Азия өлешенә килеп җиттек. Бу — шәһәрнең Ускюдар дип аталган җире, эшчеләр, һөнәрчеләр шәһәре. Босфор бугазын үтеп, Стамбулның төп өлешенә — Европа ягына — чыгу өчен паромга килдек. Паром

янындагы машиналарны куырган чиклэвек сатучы малайлар сырып алды. Без бу тамашаны озак карап тора алмадык: паромга чират бик тиз житте, чөнки чираттагы машиналарны берьюлы берничә паром кабул итә.

Паромга керү белән, без Босфорны якыннан карарга ашыгабыз. Төн шомлы, салкынча көчле җил исә. Босфор тыныч түгел, аның кара болганчык дулкыннары паромга китереп-китереп бәрәләр, без, тирбәлә-тирбәлә, үз юлыбызны дәвам итәбез.

Моннан тирә-якны ачык карап булмый: Босфор төрле зурлыктагы пароходлар белән тулган. Төркиянең иң зур шәһәрен — Стамбулны ерактан карыйсыбыз килә. Шул теләк безне паром өстенә алып менә. Европа белән Азияне тоташтырачак күпер яныннан үтәбез икән ләбаса! Мондый күпер турында борынгы греклар да хыялланганнар. Материкларны тоташтыру җиңел эш түгел икән шул!

Төркиягә бер килүдә Стамбулны икенче тапкыр күрәбез. Монысы бигрәк тә кызыклы: ерактан, биектән карыйбыз. Аның йортлары да, урамнары да, мәчет манаралары да күренеп, аерылып тормый. Әйтерсең карт тарих бу тирәдәге берничә тауга үзенең йолдызларын чәчеп җибәргән дә, кояш чыгып, көн туганчы, аларга яктылык биреп торырга кушкан.

Без тагын «Кеннеди отель»гә кайтып йокларга ятабыз.

## КАЙТЫР КӨН

Иртән торып күзне ачу белән башланган күңел күтәренкелеге һаман арта бара. Бу нидән? Әйе, үз илеңә кайту шатлыгыннан. Кайтыр көн бүген, 4 октябрь. Туган илнең тарту көчен чит җирләргә чыккач кына беләсең икән.

Бүген өйләгә кадәр гидтан башка гына Стамбулны карап йөрергә тиешбез: план шулай. Аны тормышка ашырырга дип, өчәр кешелек ике төркемгә бүленеп, Стамбул урамында әкрен генә йөрибез. Ара-тирә кибетләргә дә кереп чыгабыз. Сирәк кенә булса да дәүләт кибетләре дә бар икән. Анда «сатулашмак юк» дигән белдерүләр язып эленгән.

— Әйе, сатулашмагы да юк, сатып алучысы да юк,— дип нәтиҗә ясыйбыз, ул белдерүне укыгач.

Стамбул белән беренче танышкан көнне, кибетләрдәге алтын һәм кыйммәтле ташлардан ясалган бизәнү әйберләренең күплеген күреп, минем башка мондыйрак фикер килгән иде: «Бизәккә тулгандыр инде бу Төркия хатын-кызлары». Юк икән, хәтта профессор хатыннарында да бизәнү әйберләре ялтырамый. Димәк, кибеттә әйбернең булуы байлык дигән сүз түгел икән әле ул.

Без шәһәрдә озак йөрмибез, кунакханәгә кайтабыз: әйберләрне җыйгаларга кирәк.

Кунакханә балконына чыгып ял иткәндә, ерак түгел җирдә йорт төзүчеләрне күреп алам. Бу йортның бер катында бер гаилә иркенләп урнашырлык та түгел, ә үзен сигез кат итеп өйгәннәр. Аны аерым хуҗалык салганы күренеп тора. Беркинди төзү техникасы юк. Йортның өстенә бик кечкенә күтәрү краны беркеткәннәр. Ул электромотор белән эшли, ә стреласын бер 10—12 яшьлек малай борып тора, моторны да шул малай тоташтыра. Астагы эшчеләр аңа: «Күтәр!», «Төшер!» — дип боерык бирәләр. Бездәге кебек зур төзелеш краннары күренми Стамбулда. Айя-София, Солтанәхмәт, Сөләймания, Төп Капы кебек мәһабәт җамилардан башка зур күләмле йортлар да юк дип әйтерлек. Төп урамнар бик кечкенә, ләкин 5—8 катлы йортлардан торалар. Алар бер-берсенә терәп салынганнар, араларында бакча кебек бушлыклар бөтенләй юк. Шундый тыгынлык монда, хәтта борылырга да урын юк кебек. Ләкин кешe яраклашкан. Беренче катның бер өлешендә — гараж, икенче өлешендә — кибет, өченче почмагында торак бүлмәсе урнашкан. «Бу кадәр тар урамнарга машина кертми торганнардыр инде» дип уйлап бетермисең, әллә кайдан зур автобуслар килеп чыгалар, җиңел машиналар колакларны ярырдәй кычкыртып үтеп китәләр, ә син стенага аркаңны терәп, машина үткәнен көтеп торасың. Кер элү өчен дә хәйлә тапканнар. Бер стенадан икенчесенә урам аркылы ике катлы бау сузганнар. Ул бауның бер катын үзеңә таба тартасың, икенче каты үзеңнән читкә

китә. Шул юл белән керне урам уртасына 3 каттан башлап 8 катка кадәр югарылыкта элеп куялар. Адәм баласы нәрсәгә генә күнекми дә, нинди генә кыенлыктан чыгу юлын тапмый!

Без көн саен төрек газеталарын укыштыргалап тордык. Бүген дә берничә газета алып кердек, таныштык. Төркиянең контрастлар иле булуын газеталардан тагын да ачыграк күрәсең. Без барганда, илдә бик нык чуалчык чак иде. Газеталар илне тәртипсезлекләр белән тутырган анархистларны ачуланып язалар. «Анархист» сүзе белән янәшә «коммунист» сүзен дә кулланмыйча калмыйлар. Коммунистлар куркыныч кешеләр итеп сурәтләнәләр. Шул ук вакытта китап кибетләрендә рус совет язучыларының тәрҗемә әсәрләре сатыла. Хәтта М. Горькийның «Ана» романын да төрекчәгә тәрҗемә итеп басып чыгарганнар һәм кибетләрдә аны һәркемгә саталар.

Газетаның бер битендә Төркияне инсафлы кешеләр иле итеп күрсәткән хикәя басылган, икенчесендәге хикәяне укысаң, урамда көндез йөрергә дә куркырсың: янәсе, Төркия үтерүләр, көчләүләр белән тулган.

Газеталар бик еш кына «пантюркизм» идеясен алга сөрәләр. Төрки халыкларны берләштерү уе яңа уй түгел, бу бик борынгыдан килә. Вакытында Кемаль Ататюрк бу хыялның реаль булмавы турында бик ачык әйткән, пантюркистларны гаепләп чыккан. Кызганычка каршы, аның васыятьләрен хәзерге төрек журналистлары онытканнар. Төрки халыкларның күбесе Советлар Союзында яшәгәнлектән, төрек пантюркистлары безнең бакчага әледән-әле таш атып торалар. Алар, бу идеологияне алга сөреп, төрки халыкларны Төркия тирәсенә берләштерү, төрекләштерү уе белән хыялланалар. Бу хыялның төрки халыкларны үзара сугыштыруга китерүен аңламыйлар булса кирәк.

Мене шул турыда сөйләшеп, өйлә ашын ашарга төшкәндә, безне бер төрек көтеп тора иде. Ул — бер парфюмерия фабрикасының хуҗасы, милләте әзербәйҗан. Икенче бөтен дөнья сугышында катнашкан, Советлар Союзында да булган. Безнең янга чын әзербәйҗаннарны күрергә дип килгән. Карашлары таркаурак булса да, бу кешенең дөньяга күзе ачылган күренә. Халыклар арасындагы дуслык, үзара ярдәмләшү һәм тынычлык идеяләре ят түгел булса кирәк аңа.

Минем Казан татары икәнне белгәч, бу әзербәйҗан Стамбулдагы Казан татарлары турында, аларның «Казан» дигән журнал чыгарулары турында сөйләп алды. Ул журналның сәясәт белән бәйләнмәгән булуын кат-кат әйтте. Мин «Казан» журналының булган саннарын карап чыгуымны, аның үзенә күрә бик тә сәяси журнал булуын әйттем. Бу журналга карап, татарлар һәм татар культурасы Октябрь революциясенә кадәр генә булган икән дип уйларга мөмкин. Татарларда хәзерге чорда культураның үсүе, чәчәк атуы турында ләм-мим. Бәлки болай язу анда мөмкин түгелдер, ләкин журнал «Казан» булгач, хәзерге Казан турында берни әйтми ярамый бит.

Әзербәйҗан агае тагын үзенең Казан татарларыннан дуслары, танышлары булуы турында сөйләп алды. Алар арасында төрле кешеләр булуын әйтте.

— Алар Казан татары килгәнне белгән булсалар, һичшиксез, сезне күрергә тырышырлар иде,— дип уфтанып та куйды.

Мин аның белән бу турыда сөйләшеп тора алмадым: китәр вакыт җиткән иде. Ләкин аэропортка барганда, үз-үземә уйланып бардым. Әйе, Төркиядә йөргәндә, эмигрант нәселеннән килә торган күп кенә татарларны күрергә, алар белән сөйләшергә туры килде миңа. Чыннан да, төрлесе бар аларның. Бер төрлеләре инде үз телләрен дә онытып өлгергәннәр, пантюркизм идеясенә тырышып хезмәт күрсәтәләр. «Татарларны саклау», «татар культурасын саклау» турында сафсата саталар. Билгеле инде, аны саклауны алар төреккә әйләндерү юнәлешендә генә аңлыйлар. Шулай булмаса, алар үзләренең төрекләшүләренә басым ясамаслар иде, татар булып калуларын күрсәтергә тырышырлар иде.

— Сезнең төрки халыкларны «саклау», аларны «кушу» теориягез аларны төрекләштерүгә кайтып кала түгелме соң? — дидем берсендә.

— Әйе, төрекләр — иң алдынгы милләт,— диләр алар, пантюркизмның асылын бер дә яшермичә.

Боларны бигрәк тә минем хатынымның татар булуы гаҗәпкә калдыра, кайберсе хәтта ышанмый:

— Булмас, анда бит татарларны русларга көчләп өйләндерәләр,— дип әйтеп куя.

Бу уйдырмаларны бәлки алар төрле төрек чыганакларыннан алганнардыр, ләкин без газеталарда мондый дәрәҗәдәге ялганнарны күрмәдек.

Миңа татарларның Татарстан дигән дәүләте булуы, анда культураның, әдәбиятның, телнең үсеше турында конкрет фактлар белән сөйләргә туры килде. Татарлардан, хәтта татар хатын-кызларыннан докторлар, профессорлар күп булуны, Татарстандагы тугыз институтның ректоры татар булуны да әйтеп сөйли башлагач, тыңлаучыларның йөзе төрлечә үзгәрде. Кайберләре «пропаганда бу» дип китеп бардылар, кайберләре йотылып тыңладылар, дәшмәделәр.

— Нинди кыен хәл,— дип уйладым мин,— үз фикерләрен белдерергә дә хокуклары юк шул боларның.

Бу фикерләрдән арынганчы, без аэропортка да килеп җиткәнбез. Билетларны җайга салып, кайбер аңлашылмаучылыкларны җиңеп, ниһаять, үзебезнең ил самолетына кереп утырдык. Барыбыз да үзебезнең газеталарны йотлыгып укырга керештек, ул арада самолет кузгалып та китте. Менә без яңадан Анкарага очабыз, бу — безнең Төркия өстеннән көндез беренче очуыбыз. Мин тәрәзәдән карап барам. Гел таулар, файдаланмый торган буш таулар. Бик сирәк кенә шәһәрләр күренә, зур төзелеш булган җирләр дә бар.

— Боларның кайберләрен безнең СССР төзи торгандыр инде,— дип уйлыйм мин, Н. В. Подгорныйның апрель аенда гына Төркиядәге сөйләшүләрен искә төшереп.

Әйе, В. И. Ленин үз вакытында К. Ататюрк белән яхшы мөнәсәбәтләр урнаштырып җибәргән иде. Алар күп еллар онытылып тордылар, чөнки Төркия хөкүмәте бигрәк тә сугыш елларында Германия белән мөнәсәбәтне өстенрәк күрде. Хәзер инде СССР һәм Төркия хөкүмәтләре арасындагы мөнәсәбәтләр якынаю ягына авыша башлады. Бу — ике ил кешеләре өчен дә куанычлы хәл. Совет галимнәре делегациясе дә төрек галимнәре белән эшлекле мөнәсәбәтләр урнаштырды. Төрки халыклар тарихы, әдәбияты, теле буенча нәтиҗәле сөйләшүләр булды.

**Октябрь — декабрь, 1972.**

# ТАРИХЫБЫЗНЫҢ ПОЭТИК СӘХИФӘСЕ

Нурихан Фәттахның «Әтил суы ака торур»[1] романы безнең бүгенге әдәбиятта шактый үзенчәлекле урын алды. Әсәрнең төп яңалыгы — тормыш материалында, моңарчы язучылар кулы тимәгән, укучыларга аз таныш булган өлкәне — ерак үткәнебезне сәнгать чаралары белән сурәтләп бирүендә.

Тарихи романнар моңа хәтле дә языла килде. Сугыштан соңгы татар совет прозасы аеруча тарихи-революцион тематиканы яктыртуда зур казанышларга иреште. Бу темага язылган аерым әсәрләр илебезнең, Татарстан республикасының югары бүләкләренә лаеклы дип табылды. Ләкин язучыларыбызның күз карашы, кайбер либреттодрамаларны исәпкә алмаганда, егерменче, күп булса унтугызынчы гасырдан да еракка-рак үтеп керә алмый иде әле. Нурихан Фәттах бу җәһәттән зур сикереш ясады. Халкыбызның ерак тарихын, моннан мең еллар элек булып үткән хәлләрне, борынгы бабаларыбызның тормыш-көнкүрешен, шөгыль-кәсепләрен, сәнгать-культурасын, гореф-гадәтләрен, кыскасы, Болгар дәүләте дәверен, үтә киеренке көрәш вакыйгаларын сәнгатьчә тасвирлап бирде.

Бу җитди әсәр турында, анда хикәяләнгән катлаулы дәвернең ни дәрәҗәдә тарихи дөрес бирелүе хакында тарихчыларыбыз да үз фикерләрен әйтер дип уйлыйм. Автор бит художник буларак кына түгел, галим буларак та зур эш башкарган. Мин исә бирелә романның башлыча идея-художество эшләнешенә игътибар итмәкче булам.

Муса Җәлилнең «Алтынчәч», Галимҗан Ибраһимовның «Казакъ кызы», Мохтар Ауэзовның «Абай» әсәрләрендәге кебек үк, монда да таркау ырулар күрәше, алар арасында барган ызгыш-талашлар хәтсез урын ала. Шуңа күрә әсәрдә, коллар-«каралар», игенчеләр, көтүчеләр, балыкчылар, сугышчылар, сәүдәгәрләр, табиплар, чәчәннәр һәм башка социаль катлам вәкилләре белән беррәттән, шушы ыруларның башлыклары — биләр, ханнар образы да шактый җентекле сурәтләнә.

Моннан мең ел элек булып узган тормыш, билгеле, безнең бүгенге яшәешебездән нык аерыла. Яшәү рәвешендәге үзгәлек шул чор кешеләренең фикер сөрешендә, хис-кичерешләрендә дә чагыла. Иң әүвәл автор әлеге даими талаш шартларында яшәгән геройларның борчылулы уйхисләрен сурәтләүгә киң урын бирә. Бу борчулардан ханнар, биләр дә имин түгел. Ырулар ызгышы, сарай интригалары, табигатькә бәйлелек, хаста-сырхау күренешләре геройлар күңеленә хәвефле уйлар сала. Власть ияләренең рухи дөньясын сурәтләгәндә автор аеруча дәүләт, политика, сугыш, сәүдә, байлык, йола мәсьәләләренә, ыру һәм туганлык мөнәсәбәтләренә нык игътибар итә.

Ныклы экономик база булдыру, дуслык мөнәсәбәтләре урнаштыруда автор кабиләләр арасындагы сәүдә бәйләнешләренең бәрәкәтле, уңай ролена басым ясый. Сәүдә мөнәсәбәтләре мәгълүм дәрәҗәдә талау сугышларына каршы куела. Бу хактагы фикерләр бигрәк тә романдагы Алмыш хан образы аша бирелә.

Монархларга хас деспотлык, миһербансызлык-кансызлык сыйфатлары Алмыш ханда да җитәрлек. Ул — ыруларны туздыручы, аларны үзенә буйсындыручы һәм талаучы, туры сүзле чәчәннең телен кисүче. Әмма шул ук вакытта ул, автор сурәтләвенчә, басып алу юлы белән ыру-

[1] Нурихан Фәттах. Әтил суы ака торур. Тарихи роман. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1972 ел, 424 бит.

ларны берләштереп булмаслыгын төшенерлек зирәк дәүләт эшлеклесе дә. Аныңча, төрле ырулар арасында барган ызгыш-талашлар дәүләтнең хәлен авырайта гына. Алмыш хан Болгар дәүләтен идеологик корал — мөселман дине ярдәмендә берләштерү идеясен күтәреп чыга һәм шуны тормышка ашыра. Аңлашыла ки, мөселман динен ул үзенең эгоистик, тар социаль мәнфәгатьләренә, властьны ныгыту, баеп калу максатларына буйсындыра. «— Үзем мин бөтен өем белән чумак йоласына күчтем,— ди ул.— Йола-дин алыштырудан да бигрәк, миңа бүген акча кирәк, акча!» (144 бит.)

Ата-бабалар йоласыннан тирән эчке газаплар белән баш тартып, геройлар куркаөркә яңасын — чумак йоласын — мөселман динен кабул итәләр. Йола кануннары аеруча баш герой Тотышның рухи дөньясына әрнеткеч йогынты ясый, аның шатлык-куанычын тартып ала.

Тотыш — кайнар йөрәкле, тиз кабынып китүчән, алдын-артын уйламыйча эш итүчән егет. Аның шатлыгы да, кайгысы да тиз кабынып китүчән, кызу канлы булуыннан, ярсулы йөрәгеннән килә. Ул йола кануннарының эзлексез булуын, бер очракта бар нәрсәдән көчле саналып та, икенче мәлдә алтын-байлыкка буйсынганын күреп-сизеп яши, яңа кабул ителгән мөселман диненең кешенең табигый хисләрен кимсетүенә, колларны хайваннар хәленә төшереп түбәнсетүенә аптырап карый. Ялкынлы мәхәббәте хакына ул ике дә уйламыйча борынгы бабалар йоласыннан баш тарта, әмма хәтәр ситуациядә, авыр минутларда аның күңелен шомлану, үкенү хисләре биләп ала.

Дөресен әйткәндә, мин үзем әсәрне беренче кат кулга алган чакта аңа артык зур өметләр багламаган идем. Ни дисәң дә, без күрмәгән, белмәгән, таныш булмаган дәвер... Ләкин, укый башлагач, «Әтил суы...» үзенә бик тиз бөтереп алып кереп китте. Бүгенге кешеләргә дә бик якын һәм аңлаешлы булган хисләр, мөнәсәбәтләр әсәрне укучыга якын итә.

Роман мәйданының иң үзәгендә хәрәкәт итүче баш герой Тотыш «Кыйссаи Йосыф» сюжетына тиң үтә киеренке вакыйгалар, көрәш-бәрелешләр эчендә тасвирлана. Романда без Тотышны бик хәтәр, куркынычлы хәлләрдә күрәбез. Күп кенә очракта аның язмышы кыл өстендә кала. Әгәр менә шушы ягы белән дә, ягъни сюжетының киеренкелеге, герой язмышының кискен борылышлары белән дә кайбер романнардан аерылып тора. Сер түгел, кирәкле генә темага язылган кайбер бүгенге романнарны укыйсың да, аларның умыртка сөяген таба алмый аптырыйсың. Алардагы вакыйгаларны чиксез дәвам иттерергә дә була, уртадан өзеп калдырсаң да артык зыян килми. Каян килә соң мондый таркаулык? Минемчә, вакыйгаларның кеше язмышына бәйләнешсез рәвештә генә тезелүеннән. «Тик кешеләр язмышы турында язылган китаплар гына кешеләргә якын булып җитә ала!» [1] Ф. Хәснинең бу сүзләрендә күпләрне уйландырырдык зур дөреслек бар. Киеренке, мавыктыргыч язмышны сурәтләү ягыннан «Әтил суы ака торур» классик әдәбиятның иң яхшы традицияләрен дәвам иттерә.

Шул ук вакытта автор, Тотыш тормышындагы иң кискен, җитез агышлы тышкы вакыйгаларны рәсемләгәндә дә, аның психологик кичерешләрен, эчке дөньясын истән чыгармый. Ул яшь героеның, мәсәлән, дошманның өч батырына каршы көрәшкә чыккан вакыттагы хисләрен, алыш барышында, дәһшәтле минутта сөйгәне Тәңкәне искә төшерүен, аңына килгәндәге, терелеп аякка баскандагы тәүге сөенечле тойгы-кичерешләрен тасвирлый, сугыш вакытында каршылыклы карарларының яшен тизлегендә алмашынып торуын күрсәтә. Каршылыклы уйлар аның каршылыклы хәленнән килеп чыга. Капка төбенә дошман гаскәрләре килеп баскач, я мал, я сугыш! — дигән таләп куелгач, Тотыш ике дә уйланмыйча яуга ташлана, туган ыруын, Акбүреләр йортын саклап көрәшү кирәклеге хакында анда ике төрле фикер юк. Ә менә алдарак искә алып киткән Алмыш ханга мөнәсәбәте шактый катлаулы, каршылыклы. Алмыш хан — Тотышның ыруын талаучы, аның үзен пленга алучы. Шуңа күрә Тотыш пленнан ычкыну белән Казаяклар ыруы, Ямгырчы би ягыннан торып Алмыш ханга каршы яуга ташлана. Әмма шул ук вакытта ул әлеге Алмыш ханның кызы Аппакны ярата. Шуңа күрә, Аппак тирмәсе янына килеп җиткәч, коралын дусларына каршы борып, Аппакны саклау чарасына керешә һәм Казаякларны куып китә. Бу борылыш иң әүвәл герой психикасында башкарыла. Шул ук вакытта мондый кичешләр, әле бер яктан, әле икенче яктан торып сугышу күренешләре ыру талашларының бик үк принципиаль булмаганлыгын күрсәтү өчен дә китерелгән.

[1] Фатих Хәсни. Сайланма әсәрләр. II том. Казан. 1967 ел. 357 бит.

Нурихан Фәттахның Тотышы, Ф. Хөснинең «Йөзек кашы»ндагы Айдары һәм башка күп кенә геройлары кебек, нинди дә булса эш кылыр алдыннан артык күп уйланып тормый. Тотышның сөйгәне, Алмыш ханның кызы Аппакны Каган егерме алтынчы хатынлыкка тартып алганнан соң, Алмыш хан Тотыш алыпны башка юл белән ризалатмакчы була. Аппакның сеңлесе Айтулдыны тәкъдим итә, тарханлык титулы бирә, ягъни бөтен ыруын ясак түләүдән, солдат, коллар бирүдән, басып алулардан коткара.

Әмма Тотыш:

«— Мин синең ярлыгыңа өйләнергә килмәдем, хан!» — дип, ярлыкны йомарлап идәнгә ыргыта, өстәвенә, үзенең билек дәрәҗәсеннән дә баш тарта. Бу юлларны укыгач, Виктор Гюгоның «Көлә торган кеше» романындагы Гуинплен образы искә төшә. (Гомумән, Н. Фәттах ул язучыга зур ихтирам белән карый.) Кайнар, саф мәхәббәтне, яшь йөрәктәге бөек хисне бернинди титул да, дәрәҗә-мәртәбә дә алыштыра алмый, дип раслый Н. Фәттах. Югыйсә, бу урында сюжетны башкачарак, логик эзлекле итеп тә төзеп булыр иде бит. Китапны укып чыккан кешеләр хәтерли булыр, моннан соң Тотыш сөйгәнен Каган тырнагыннан коткарыр өчен ерак сәфәргә юл тота. Аңлашыла ки, власть-дәрәҗә дә, шул властька бәйле гаскәр дә Аппакны йолып алуга комачаулык китермәс иде, киресенчә, ярдәм генә итәр иде. Ләкин болай булганда, образның бөтенлегенә кимчелек килер иде. Тотышның кешелек сыйфатлары төссезләнеп, югалып калыр иде, ул үз кәефе-рәхәте өчен яшәүче монархлардан бер ягы белән дә аерылып тормас иде. Сюжетның башкача, логик эзлеклелектә төзелмәве әнә шуның белән аңлатыла.

Кыскасы, Тотыш табигать баласы булып калырга тели. Ул бары тик үзенең ялкынлы, темпераментлы-дәртле мәхәббәтен генә белә. Әмма иҗтимагый төзелеш, ырулар көрәше, сарай интригалары аңа табигать баласы булып калырга ирек бирми. Ул тигезсез көрәшләргә, яуларга катнаша, ахырда интригалар корбаны була. Әсәрнең азагы трагик рәвештә тәмамлана.

Роман сюжетының финалга таба тарая төшүе, көрәшнең ырулар арасындагы өлкәдән мәхәббәт сферасына күчүе хакында матбугатта кайбер фикерләр әйтелде инде. Өстәп тагын нәрсә диярга?.. Гомумән алганда, финалга таба сюжет гадәттә киңәюгә бармый, күп булса, элекке рамкалар кысасында кала яки тагы да тарая, җыела төшә. Безнең романнарда, хәтта аларның һичшиксез талантлы язылганнарында да әле тараю янына тагын сюжет сүлпәнлеге килеп кушыла. «Әтил суы...»нда без соңгы ноктага кадәр андый сүлпәнлекне тоймыйбыз. Киресенчә, герой язмышын ахырга кадәр киеренке кызыксыну белән күзәтеп барабыз. Әмма шулай да сюжет җепләренең башлыча мәхәббәт өчен көрәш тирәсенә җыела төшүен танымыйча мөмкин түгел. Ләкин моның да үзенең эчке бер мәгънәсе бар. Беренче карашка, мәхәббәт хакына һәлак булу акылсызлык, башсызлык кебек. Трагик финал укучыда гомумән кызгану, ризасызлык тойгылары уята. Ләкин, фәлсәфи планда караганда, мәхәббәт — үлемнең үзеннән дә көчлерәк күренеш ул. Сугыш нәтиҗәләре кешелеккә зур афәтләр, үлемнәр китерә. Мәхәббәт исә сугыш тудырган бушлыкны тавыш-тынсыз гына тутыра тора. Мәхәббәт — тормышка кайсы да булса бер ноктада сүнеп калырга ирек бирмәүче, яшәүне дәвам иттерүче, үлемне җиңүче көч ул. Шуңа күрә әдәбият тарихының буеннан-буена мәхәббәт хакына батырлык-тәвәккәллекләргә, хәтта һәлакәткә бару күркәм сыйфат дип бәяләнеп килгән. «Әтил суы...» да сүнәр-сүнмәс пыскучы хисләрне түгел, бәлки кайнар йөрәкле яшьләрнең романтик олы мәхәббәтен сурәтли.

Болгар дәүләтенең үз чорында иҗат ителгән әсәрләрдән «Йосыф вә Зөләйха» кыйссасында хатын-кыз типларыннан Зөләйха ялкынлы мәхәббәтенә ирешүдә зур активлык күрсәтүче натура итеп бирелә. Аның активлыгы башлыча шул өлкә белән чикләнә. Аннан соңгы әсәрләрдә исә бик күп гасырлар буена татар хатын-кызларының мәхәббәт өлкәсендәге активлыгы да тиешенчә чагылмый килде. Тик совет чорында гына Муса Җәлил Тугзак ананы иҗтимагый актив натура итеп, басып алучыларга каршы көрәшне оештыручы патриот итеп, ыру башлыгы итеп бирә. «Әтил суы...»ндагы Тотышның әнисе Койтым бикә образы белән Нурихан Фәттах мәгълүм дәрәҗәдә Муса Җәлил традицияләрен дәвам иттерә. Койтым бикә башыннан да үтә катлаулы хәлләр кичә. Сугыш вакытында ул ирләр белән бер сафта кулына кылыч алып көрәшә, коллык-кырнак ачысын да җитәрлек татый, ыру башлыгы булып та тора. «Алтынны юлга ташласаң да — алтын, шүрлеккә куйсаң да, утка тотсаң да — алтын!»

(136 бит) — диләр аның хакында. Автор Койтым бикәнең ыру-дәүләт эшләре белән идарә итүдәге зирәклегенә, үткен һәм житез акыллы, төптән уйлап эш итүче, сылу, чибәр, горур, бала җанлы булуына аеруча басым ясый.

Кыскасы, башлыча ике нәрсә — үзенчәлекле ачык характерлар, киеренке сюжет әсәрне мавыктыргыч итә.

Романның стиле аның специфик сурәтләү материалына ярашып тора. Әсәр бүгенге матур әдәби образлы тел белән язылган. Шуның белән бергә әсәрдә архаизмнар да беркадәр урын ала. Беренче кат очраганда алар әле сәеррәк тоелалар. Андый стиль үрнәкләре бездә күренгәне юк бит. Ләкин тора-бара күнегеп китәсең. Икенче тапкыр укыганда инде гадәти нәрсә рәвешендә кабул итәсең. Моннан мең ел элек яшәгән кешеләрне бүгенгечә уйлатсаң, бүгенгечә сөйләтсәң, бу үзе сәеррәк булыр иде кебек. Архаизмнарның функциясе тик бер генә төрле бит: чорның колоритын төгәл бирү, төсләрен, төсмерләрен укучыга сиздерү. Китапның ахырында аларның сүзлекчәсе, географик атамаларның, ил, халык, кеше исемнәренең аңлатмалары бирелгән, килеп чыгышы, тамыры, этимологиясе аңлатылган.

Кайбер халык иҗаты әсәрләре, мәкальәйтемнәрә дә шул чорга, шартларга яраклаштырып кулланылганнар. Ил картлары, мәсәлән, ясак таләп итеп килгән Алмыш ханга мөнәсәбәтләрен белдереп, «Эт күнеле — бер сөяк» (95 бит), — диләр. Икенче урында «Ханга ышанма, Әтилгә таянма!» (163 бит) — дигән мәкаль кулланалар. Хан гаскәрләренә мөнәсәбәт антитеза юлы белән белдерелә: «Җиңүчеләрне елмаеп каршы алдылар, йодрык күрсәтеп озатып калдылар» (156 бит).

Архаизмнарның үзенчәлекле бер төре чынбарлыкны фәнни дөреслегеннән читләшкән, борынгы халыклар аңлаган формада, дөньяны аңлау дәрәҗәсенә яраклы рәвештә тасвирлау. Яралы Тотышны дәвалау турында түбәндәгечә хикәя ителә: «...Барлык им-том шуның белән төкәнде. **Кояш җир астына төшеп, яңадан күк читеннән килеп чыкканчы** аңына килә икән, куйган азыкны ашап, суны эчә икән — димәк, тереләчәк...» (145 бит). Еш кына автор вакыйга-күренешләрне герой күңеле аркылы үткәреп сурәтли. Әсәрдә табигать күренешләренә мөрәҗәгать итү зур гына урын ала. Романда алар без бүгенге көндә аңлый торган художестволы сынландыру булып кына килмиләр, борынгы кешеләрнең аң дәрәҗәләрен дә, ягъни табигатьне олылауларын, курку-шомлануларын, бар табигатьне җанлы дип тануларын аңлаталар.

Шулай итеп, «Әтил суы ака торур» романы белән Нурихан Фәттах безгә халкыбызның озын тарихының бер битен ачып күрсәтте, аңа сәнгать нуры төшерде.

**ФӘРИТ ХАТИПОВ,**
филология фәннәре кандидаты.

# ТАТАРСТАНДАГЫ АВЫЛ ИСЕМНӘРЕ

Гомәр Саттаров укучыларга туган ягыбызның топонимнарын өйрәнүче галим буларак таныш. «Ни өчен шулай аталган?» дигән китабында, төрле җыентыкларда һәм газета-журналларда басылган күп санлы мәкаләләрендә ул республикабыздагы шәһәр, район исемнәренең килеп чыгышына караган кызыклы мәсьәләләрне күтәргән иде. Узган ел Казан дәүләт университеты нәшрияты галимнең топонимика мәсьәләләренә караган тагын бер хезмәтен дөньяга чыгарды. «Татарстан АССРның антропотопонимнары» дигән ул хезмәт бездәге авыл исемнәренә, аларның килеп чыгышын өйрәнүгә багышланган.

Хезмәтнең беренче өлешендә кеше исемнәренә, фамилияләргә һәм төрле кушаматларга нисбәтле авыл атамалары (фәндә аларны антропотопонимнар дип йөртәләр) хакында сүз бара. Авыл атамаларының күбесе — бик борынгы исемнәр. Ә борынгы тел ядкарьләре, билгеле булганча, язма рәвештә бик аз сакланып калган. Бу хәл автордан күп көч куюны, фәннең төрле тармаклары буенча хәзерлекле галим булуны сораган. Шикләнми әйтергә мөмкин, Г. Саттаров үз алдында торган

кыенлыкларны шактый уңышлы ерып чыга алган. Шул ук беренче кисәктә автор фигыль нигезле исемнәргә туктала, безне төрки, шулай ук угро-фин телләренә нисбәтле ясалган атамалар, аларның төрле катламга караган төркемнәре белән таныштыра.

Китапның икенче кисәге моңа кадәр бөтенләй диярлек өйрәнелмәгән өлкәгә — болгар чорыннан калган авыл исемнәренә багышланган. Бу бик катлаулы һәм җаваплы бурычны да автор нигездә уңышлы башкарган диясе килә.

Без борынгы болгар телен бик аз беләбез. Язма истәлекләр сакланмаган диярлек. Сакланганнары да тел галимнәре тарафыннан җитәрлек өйрәнелмәгән. Шәрыкны өйрәнүче галимнәр хәзерге телләрдән борынгы болгар теленә иң якын торганы чуваш теле дип исәплиләр. Танылган тарихчы һәм тел галиме А. П. Ковалевский, мәсәлән, болай дип яза: «Чувашларның бабалары Идел буеның җирле халкы булганнар, аларның Болгар дәүләте составында яшәгәннәре дә, аннан читтә яшәгәннәре дә үз телләрен оныткаannar һәм яулап алучы болгарларның телләрен кабул иткәннәр; моның нәтиҗәсендә алар үзләре болгар булып китмәгәннәр, әмма болгар телендә сөйләшә башлаганнар». Бу — шактый кызыклы һәм игътибарга лаек фикер. Кайбер кешеләрнең ни өчен соң болгар теле чувашлар арасында сакланып калган да, болгарларның төп варислары саналган татарлар арасында сакланмаган, дип гаҗәпләнүләре мөмкин. Моның төрле сәбәпләре булган. Чувашларга язма культураның тәэсире азрак булган, алар ислам динен кабул итмәгәннәр, башка төрки халыклар белән азрак аралашканнар. Ислам диненә күчү, башка төрки халыклар белән интенсив аралашу нәтиҗәсендә татар теле күп үзгәрешләр кичергән. Менә шуңа күрә дә Гомәр Саттаров күп кенә авыл атамаларын хәзерге чуваш теленең лексик байлыгына таянып аңлата. Бер уңайдан ул татар халкының этногенезын ачыкларга ярдәм итәрдәй кызыклы фикерләр әйтә.

Китап аерым җитешсезлекләрдән дә азат түгел. Кайбер фикерләр ышандырып җиткерми, кайсыбер атамаларның җитәрлек дәлилләнмәгән булуы күзгә ташлана. Әле күп кенә татар авылларының исемнәре өйрәнелмәгән, һәрхәлдә, Кама аръягы районнарындагы авыллар китапта аз күренә.

Китабын язганда автор төрле халык галимнәренең шушы өлкәгә караган бик күп хезмәтләрен укыган. Моның өчен аны гаепләп булмый, билгеле. Күп кенә зур галимнәр күрше халыкларның тел тарихын өйрәнүгә зур өлеш керткәннәр. Ә татар теле, аның тарихи үсеш этаплары аз өйрәнелгән. Шунлыктан автор әнә шул төрле халыкларның әдәбиятын киң файдаланырга тырышкан. Без, әлбәттә, моңа каршы килмибез. Ләкин махсус әдәбият та тикшеренүче галимгә артык басым ясамаска тиеш. Мәсәлән, аерым башкорт ыругларының атамалары Апас районындагы Ябалак авылының яки Казан арты авылларының исеменә туры килгәнлектән генә Апас һәм Арча районнарында борын заманда башкортлар яшәгән дип нәтиҗә чыгару (166—168 битләр) аз дигәндә сәер бер тәэсир калдыра.

Китапта барлык антропотопонимнар һәм аларның килеп чыгу вакытлары әле ачыкланмаган. Ләкин бу зур хезмәт (антропотопонимнар исемлеге) киләчәктәге эш. Авылларның килеп чыгуын, яшәвен һәм атамаларын археологик, этнографик, лингвистик, тарихи материаллар нигезендә барлап, аңлатып биргән җыентык төзү күп вакытны, күп кешеләрнең бергәләп эшләвен сорый. Халыкны аерата кызыксындыра торган атамалар катламын өйрәнү лингвистларга, тарихчыларга һ. б. фән тармакларында эшләүчеләргә, шулай ук студентларга, укытучыларга яхшы ярдәмче булуы белән дә китап зур әһәмияткә ия булып тора. Ул шулай ук үз чиратында тугандаш күрше халыкларның фәнни әдәбиятын үстерүгә дә файда китерер. Топонимия буенча күп санлы хезмәтләр авторы Г. Саттаров татар тел фәненең яңа бер өлкәсе ономастиканы тагын бер хезмәт белән баетты.

**С. АЛИШЕВ,**
тарих фәннәре кандидаты.

# КИЛӘЧӘКНЕ УЙЛАП...

Өлкән әдипләребез әдәби алмашка ярдәм һәм тәрбия кирәклеген һәм бу эшнең чиксез зур әһәмияткә ия булуын әледән-әле күрсәтеп киләләр. Әйтергә кирәк, яшь талантларга ярдәм итү, аларга тәрбия бирү җәһәтеннән караганда, Татарстан язучылар союзы идарәсе күп эшләр башкара. Газета редакцияләре дә бу эштән читтә тормыйлар, өлкәннәрнең яшьләр иҗатына багышланган мәкаләләрен сирәк булса да ел саен басып киләләр. Китап нәшриятының да әлеше юк түгел: шагыйрь Зәки Нури тарафыннан төзелгән «Язучылык хезмәте турында»[1] исемле мәкаләләр җыентыгы бүгенге көндә яшьләрнең өстәл китабы булып тора. Ләкин тынычланыр өчен нигез юк. Заман таләпләре зур, чишелергә тиешле мәсьәләләр күп. Бүгенге көнгә кадәр тупланган тәҗрибә исә тагын да баетуны, яңартуны көтә.

### ТАЛӘПЧӘНЛЕК ТУРЫНДА

Ни җитми соң ул тәҗрибәгә? Барыннан да элек шул: әдәби алмаш тәрбияләү мәсьәләсе гамәлдә җитәрлек дәрәҗәдә киң куелмый. Асылда аның эчтәлеге таләпчәнлекне арттыруга гына кайтып кала. Өлкән әдипләребездән Фатих Хөсни, мәсәлән, болай яза: «Таләпчәнлек һәрберебезгә карата да, таләпчәнлек бигрәк тә әдәбиятка яңа килүче каләмнәргә карата нык, ташламасыз, принципиаль булсын». («Социалистик Татарстан» газетасы. 31 май. 1970 ел.)

Хәлбуки, таләпчәнлек — тәрбия чараларының берсе, бары тик берсе. Бөтен тәрбия эшен берүзе хәл итәргә ул көчсез. Ләкин, шуңар да карамастан, гамәлдә әлеге хакыйкать игътибардан төшеп кала. һәм барлык хокуклар таләпчәнлеккә генә бирелә. Аның көченә ышаныч шундый зур ки, хәтта тәрбияләнүчеләр алдына алар күтәрә алмаслык таләпләр куюдан да тартынып тормыйбыз.

«Шигырь, — ди Нурихан Фәттах, — сине күкләргә ашырырлык дәрәҗәдә тетрәндерерлек, өр-яңа кешегә әверелдерерлек дәрәҗәдә көчле һәм дәртле булырга тиеш! Шигырь сандугачтай сайрап торырга тиеш! Шигырь, нык тартылган нечкә кыллар шикелле, чыңлап торырга тиеш!» («Татарстан яшьләре» газетасы. 1965 ел. 17 июнь.)

Шигърият алдында торган гомуми таләп сыйфатында әдипнең бу сүзләрен укучы, шөбһәсез, котлап кабул итә. Ләкин мәкаләдә әлеге таләпләр редакциягә беренче шигырьләрен генә җибәргән яшь каләмнәрнең иҗат продукциясен бәяләүдә үлчәү, критерий итеп файдаланыла. Бу очракта инде язучының таләбе чиктән ашкан. Чыннан да, ничек итеп беренче адымнан ук укучыларны «күкләргә ашырырлык дәрәҗәдә тетрәтерлек» шигырь язарга?

Беренче адымнан ук «күкләргә ашырырлык дәрәҗәдә тетрәтерлек» шигырьләрне хәтта иң зур әдипләр дә яза алмаган. Андый шигырьләр Муса Җәлилдә дә, Тукайда да, Гетеда да юк.

Әлбәттә, әдәбият мәйданына омтылучы яшьләр хезмәтен беренче адымнан ук шундый күтәрә алмаслык таләпләрдән чыгып бәяләү аларны иҗат эшенә тартуга хезмәт итми. Киресенчә, яшьләрне читкә этәрә, башлаганны ташларга мәҗбүр итә. Кызганычка каршы, мондый тискәре күренешләр безнең әдәбият практикасында шактый еш очрый. Альйк менә мондый мисалны: 1950 елдан башлап 1970 елга кадәр чорда «Татарстан яшьләре» газетасына 1236 автор шигырь җибәргән. Бу — әдәбият мәйданына керергә ел саен 61 кеше беренче омтылыш ясап караган дигән сүз. Инде

[1] Язучылык хезмәте турында. Казан. 1958 ел.

мена икенче сан: шул ук 20 ел вакыт эчендә Язучылар союзына 63 кеше алынган. Бу — елга 3 кеше әдәбият мәйданына аяк баскан дигән сүз. 61 кешедән 3 кеше! Ә калган 58 е, димәк, ел саен төшеп кала барган. Ә бит әлеге 61 кеше дә төгәл сан түгел. Аның эченә «Ялкын», «Яшь ленинчы», «Социалистик Татарстан», «Казан утлары» һәм «Азат хатын» редакцияләренә җибәрелгән шигырьләрнең авторлары керми. Димәк, чынбарлыкта төшеп калучылар саны икеләтә-өчләтә күбрәк дигән сүз.

Бу — табигый күренеш, каләм тибрәтүче һәр кеше шагыйрь яки әдип булмый, дикләре мөмкин. Әйе, хак сүз. Ләкин мәсьәләнең икенче ягын да онытырга ярамый. Кеше редакция хәтле редакциягә шигырь җибәрергә җөрьәт иткән икән, димәк, авторда ниндидер талант «бөртеге» бар. Үсәр өчен шартлар тудырганда, вакытында игътибар һәм ярдәм булганда, әлеге «бөртекнең» ачылып китү, үсү ихтималы бар. Шагыйрь чыкмый икән, әдәбият өчен кирәкле башка кеше чыгар. Менә берничә мисал. К. Тәхаутдинов 1951 нче һәм 59, 65, 66 нчы елларда «Татарстан яшьләре» газетасында 4 шигырь бастырган. Аңардан шагыйрь чыкмаган, ләкин бүгенге көндә ул журналист. Р. Гарипов 1950—58 елларда шул ук газетада 12 шигырь бастырган, ул да шагыйрь түгел, ләкин тәҗрибәле журналист. Марсель Бакиров 1952 һәм 1954 елларда «Татарстан яшьләре»ндә 2 шигырь бастырган. Аңардан да шагыйрь чыкмаган, аның каравы, М. Бакиров — әдәбият галиме. Болар әдәбият өчен, аның үсеше өчен кирәкле кешеләрме? Әйтәсе дә юк.

Ниһаять, яшь каләмнәрнең һәркайсыннан шагыйрь чыкмас, аның каравы, китап дусты чыгар. һәм ул шүрлекләрдә хәрәкәтсез яткан китапларны кайнар дәрт, тирән мәхәббәт белән хезмәт ияләре арасына алып килер, укырга димләр, чакырыр.

Әйе, яшь каләмнәрнең һәркайсыннан шагыйрь чыкмас, аның каравы, шигырьне зурлаучы, димәк, матурлыкны зурлаучы, сәнгатьчә сүз кадерен белүче нәфис сүз осталары чыгар һәм алар тавыш-тынсыз яткан әсәрләрне авыл, шәһәр эстрадаларына алып менәрләр.

Шуңа күрә дә «каләм тибрәтүче һәр кеше шагыйрь була алмый» дигән фикерне гамәлдә сак кулланырга кирәк. Чөнки ул фикер астына яшеренеп, яшь талантларны бер селтәнү белән юкка чыгарырга мөмкин. Хәер, мөмкин генә түгел, еш кына шулай эшләнә дә.

## ТӘРБИЯ ДӨРЕС ТОН, ТАКТ СОРЫЙ

«Поэзиядә ритм, рифма дигән төшенчә бар бит әле. Алар — шигырьләрнең «әлифбасы». М. Бәйрашов исә менә шул «әлифбаны» да белми», — дип яза Марс Шабаев «Татарстан яшьләре» газетасының 1958 елгы 9 апрель санында. Әлбәттә, М. Шабаев әлеге юлларны начар ният белән язмаган. Ләкин тон дөрес алынмаган, педагогик такт бозылган.

Редакциягә килгән шигырьләрне күзәтүгә багышланган башка мәкаләләрдә дә кульъязманы бер карау белән кырт итеп кисеп ташлау кебек урынсыз дуамаллык очраклары еш күзгә ташлана.

«Өстәлдә шигырьләр, шигырьләр, шигырьләр, — дип яза М. Хәсәен. — Аларны төрле һөнәр кешеләре язган һәм туп-туры әйтик: әдәби әсәр булудан бик ерак тора алар». («Татарстан яшьләре». 1961 ел. 4 февраль.)

Күрәсез, мәкаләсенең беренче юлларыннан ук М. Хәсәен шигырьләрне юкка чыгара. Аннары шунда ук авторларны тиргәргә керешә:

«Әдәбият теориясен бөтенләй белми торып иҗат эшенә тотыну — үзе гафу ителми», — ди ул.

Билгеле, мондый сүзләрдән соң яшь каләмнәрнең кайберләре әдәбиятка бөтенләй кул селти. Ульянов өлкәсеннән К. Салихов тынып кала, Ворошиловградтан — Ә. Сибгатуллин, Магнитогорскидан — Р. Бикташев, Карагандадан — Н. Нуретдинов, Оренбург өлкәсеннән — С. Муллабаев, Горький өлкәсеннән — Р. Ибраһимов, Куйбышев өлкәсеннән — Ф. Тимеркәев, Свердловск өлкәсеннән — Х. Шәнгәрәев, аннары Ташкент, Пенза, Мәскәү, Пермь өлкәләреннән язучылар. Әдәбиятны туендыручы җирлек тарая, элемтәләр кими...

Әгәр, шушы рәвешчә, ел саен 100 дән артык яшь каләм югала торса, татар әдәбиятының киләчәгенә зур зарар килергә мөмкин. Димәк, бу хәлгә чик куярга кирәк. Ничекме? Барыннан да элек, яшь каләмнәр белән эшләү алар арасыннан шигырь сайлап алуга гына кайтып калмасын. Мондый юлдан атлау, күреп үткәнебезчә, күпчелек яшьләрне әдәбияттан биздерә генә. Шуңа күрә дә алар белән эш итү аерата кайгыртучанлык, җаваплылыкны сизү, таләпчәнлек рухында алып барылырга тиеш. Мондый рухта эшләү үрнәкләрен эзләп куршеләргә йөрисе юк. Үрнәкләр үзебездә дә бар. Мисал итеп беренче чиратта Татарстан язу-

чылар союзы идарәсе каршындагы консультация бюросында озак еллар Гази Кашшаф, аннары Газиз Иделле, ниһаять, Әнәс Камал һәм Гали Хуҗиевлар алып барган эшчәнлекне искә төшерик. Аларның әдәби алмаш тәрбияләүгә багышланган хезмәте бик күп яшьләргә әдәбият мәйданына юл ачты. Хәзерге көндә уңышлы иҗат итеп килүче шагыйрьләребезнең, әдипләребезнең кайсы гына бу олы җанлы кешеләрнең кайгыртучанлыгын үзендә тоймады икән.

Яшь каләмнәр белән эшләүдә Г. Әпсәләмов, Х. Туфан, С. Хәким, Г. Хуҗи, Г. Бәширов, И. Гази, А. Әхмәт, Ш. Маннур, Ә. Давыдов, Н. Арсланов, Г. Мөхәммәтшин, Барлас Камалов керткән өлеш тә зур игътибарга лаек. Аннары килеп Зәки Нури мәкаләләрен алыйк. Аларда тәҗрибәле шагыйрь әдәби алмаш тәрбияләүгә кагылышлы мәсьәләләрне күтәреп кенә калмый, бу эшнең төп принципларын да билгели.

«Әдәби алмаш белән эшләүнең төп принцибы, — дип күрсәтә ул, — безнеңчә, ...индивидуаль шефлык методы булырга тиеш. Индивидуаль эшләү яшьләрне таләпчән иҗатка, әдәби осталыкка өйрәтү өчен генә түгел, ә бәлки актив җәмәгать эшлеклесе булырга өйрәтү өчен дә кирәк». («Татарстан яшьләре» газетасы. 1958 ел. 10 июнь.)

Күрәсең, бирелә яшьләргә борын чөереп карау юк, аларны кимсетү юк. Киресенчә, сүз хуҗаларча кайгыртучанлык рухында бара. Тагын шуны да икърар итәргә кирәк: шагыйрь тарафыннан күтәрелгән индивидуаль шефлык методы яшь каләмнәр белән эшләүдә даими кулланыш тапты. Бүгенге көндә аңардан иң уңышлы файдаланучы шагыйрьләребез Хәсән Туфан белән Сибгат Хәким дисәк, хата булмас шикелле.

Ниһаять, менә Шәрәф Мөдәррис хезмәтләре. Аларда иң беренче булып игътибарга ташланган сыйфат — ул әдәби алмаш турында кайгыртучанлык. «Әсәр, гомумән, өлгереп җитмәгән дә булсын, теле һәм әдәби эшләнеше йомшак та булсын — ләкин бит аның нинди дә матур орлыгы булуы мөмкин. Менә шуларны сизә алырга, андый авторларга үз вакытында тиешле ярдәм күрсәтә белергә кирәк», — ди ул. («Татарстан яшьләре». 1954 ел. 10 октябрь.) Игътибар итик: бирелә кульязмаларга нинди зур саклык, кайгыртучанлык белән якын килена. Моны бүгенге тәрбиячеләр өчен методик кулланма итеп карарга була. Әйдә, файдалан гына! Менә шул ук Шәрәф Мөдәрриснең әдәби консультантка киңәше: «Минемчә, консультант яхшы әсәрләрне сайлап альманахка бирү белән генә чикләнеп калырга тиеш түгел. Ул үз кулына кергән өметле әйберләрне теге яки бу редакциягә тәкъдим итәргә, алар язмышы белән даими кызыксынырга, кирәк икән — алар өчен «тарткалашырга» да тиеш».

Билгеле, бу киңәшләр, күрсәтмәләр яшь каләмнәрне тәрбияләү эшенә актив хезмәт күрсәтәләр. Алда торган бурыч шул: тупланган уңай тәҗрибә гамәлдә шулай файдаланылырга тиеш ки, яшь каләмнәрнең берәве генә дә әдәбият өчен югалмасын. Әйе, 14—20 яшьлек чорда әдәбият белән мавыккан бер генә кеше дә соңыннан әдәбиятны нигә дә санамаучы обывательгә әйләнмәсен, иң кимендә югары зәвык иясе, әдәбият дусты, аны пропагандалаучы булып калсын. Әдәбиятның үсүе өчен андый кешеләр шагыйрьләр шикелле үк кирәк. Ниһаять, бу уңайдан тәнкыйтьче Рафаэль Мостафин фикерен дә истән чыгармыйсы иде: «Әдәбиятка килүче яшь көчләр ташкыны никадәрле көчлерәк булса, әдәбиятның базасы, аны туендырып торган туфрак шул кадәр баерак, яшь авторлар арасыннан яңа Тукайлар, Такташ һәм Җәлилләр чыгачагына өмет һәм ышаныч шул кадәр зуррак булачак». («Казан утлары» журналы. 1972 ел. 1 сан. 169 бит.)

## ТАШКЫН БАРЛЫККА КИЛСЕН ӨЧЕН...

Әлбәттә, һәр ел саен үз-үзеннән әдәбиятка яшь көчләр ташкыны килер, дип көтеп яту беркатлылык булыр иде. Юк, ташкын барлыкка килсен өчен, көндәлек фидакарь хезмәт кирәк. Һәм ул хезмәт балалар бакчасыннан ук башланырга тиеш. Нәкъ менә бирелә, балалар бакчасында, тумыштан килгән сәләтләрнең ачылуы өчен беренче нигез ташлары салына. Талантлы тәрбиячеләр кул астында бала музыка тыңлый, әкият ишетә, уйный, кул эшләре белән шөгыльләнә, рәсем ясый, табигать матурлыгын күрергә өйрәнә. Балада ритм хисе, матурлык хисе уяна, күзаллау үсә, хыял хәрәкәткә килә.

Мәктәптә уку дәверендә исә әлеге сыйфатлар бермә-бер үсәләр, камилләшәләр. Бу чорда тел-әдәбият укытучысының роле әйтеп бетергесез зурая, күтәрелә. Ул, олкән әдибебез Гомәр Бәширов сүзләре белән әйтсәк: «әдәбият укытуны... балаларда сәнгатькә мәхәббәт уятырлык итеп оешты-

рырга»[1] кирәк. Моның өчен дәресләр генә җитми, билгеле. Аларга башка чараларны, шул җөмләдән әдәби түгәрәкләр эшен өстәү зарури булып тора. Соңгыларын чын-чынлап файдалы итеп оештыру — хәзерге көндә проблема түгел. Татарстан язучылар оешмасы зур, әдәби түгәрәкләргә шефлык итәргә язучыларның берсе дә каршы килмәс кебек. Чакыр гына.

Хәлбуки, хакыйкать ачык: әдәбият укытуны класстан тыш эшләр белән бергә кушып алып барганда гына әдәбият белән чын-чынлап мавыгу башлана, беренче шигырьләр дөньяга килә. Гадәттә беренче шигырьләр танылган әдипләр, мәшһүр шагыйрьләр иҗат иткән үрнәкләргә ияреп язылалар. Иҗат эшчәнлегенең башлангыч чоры өчен бу — котылгысыз күренеш. Билгеле, бу чорда язылган шигырьләр матбугатта басып чыгарырлык булмыйлар. Ләкин барыбер автор үз эшчәнлегенең нәтиҗәсен үз күзе белән күрергә тиеш. Алай булмаганда язу белән шөгыльләнү өчен кирәкле этәреш югалырга мөмкин. Ничек итеп иҗат дәртен сүндерми тотарга соң? Андый чара бармы? Әйе, бар. Һәм алар җитәрлек. Стена газеталары, кулдан язылган журнал (мәктәпләрдә), яшьләр кичәләрендә сәхнәгә чыгып шигырь сөйләү — аларның кайберләре менә шулар. Әйтелгәннәргә башлап язучыларның авыл, районара иҗат ярышларын оештыруны өстәргә кирәк. Әлбәттә, санап чыккан эшләрне оештыруда төп хезмәт әдәбият укытучылары, комсомол оешмалары һәм яшь каләмнәрнең үз җилкәләренә төшәчәк. Әйдә, төшсен. Максат көч сарыф итүне тулаем аклый. Чөнки әлеге чараларны тормышка ашыру борын төрткән сәләтләрне ачарга, үстерергә ярдәм итү белән генә чикләнми, бәлки әдәбият аша барлык яшьләрнең эстетик зәвыкларын камилләштерүне дә, аларда коммунизм төзүче сыйфатларын тәрбияләүне дә үз эченә ала. Мондый кешене — коммунистик җәмгыять төзүче кешене тәрбияләү исә XXIV съезд тарафыннан кабул ителгән бөек эшләр программасында иң әһәмиятле бурычларның берсе итеп куела.

Ниһаять, югарыда саналган чараларның тагын бер әһәмияте бар. Аларны тормышка ашыру барышында тупланган белем һәм тәҗрибә нигезендә яшь каләмнәр, ияреп язудан туктап, мөстәкыйль иҗат итү юлына басалар. Һәркемдә үз тавышы ачыла, үз кызыксынулары, ыбанулары билгеләнә.

Талант үсешенең бу чорында яшь каләмнәрне стена газеталарында, кулдан язылган журналларда басылу гына канәгатьләндерә алмый. Аларга хәзер киңрәк трибуна — басма газеталар, журналлар һ. б. кирәк. Әлбәттә, андый трибуналар бар, ләкин аларның эше яхшыртуга мохтаҗ шикелле. Билгеле булганча, «Идел» альманахы елга дүрт мәртәбә чыгарга тиеш иде. Чынлыкта исә аның саны елына бердән артмый. 60 нчы елларда «Беренче карлыгачлар» исемле яшьләр җыентыгы чыгып килә иде. Ул да хәзер чыкмый башлады. «Татарстан яшьләре» газетасында 50 нче елларда ел саен уртача 60—70 яшь автор шигырь бастыра иде. 1973 елда исә бу газетада 2 айга (февраль, март айларында) барлыгы 5 автор шигырь бастырган. Әле анда да күпчелекне башлап язучылар түгел, бәлки күптән танылган шагыйрьләр алып тора. «Яшь ленинчы» газетасында мәрхүм Г. Мөхәммәтшин җитәкчелегендә «Яшь хикәячеләр» түгәрәге эшләп килә иде. Ул да хәзер үз эшчәнлеген йомшартты шикелле.

Хәлбуки, өлкәннәрнең әдәби алмаш алдында бурычы зур. Яшьләр үзләренең иҗат эшчәнлеген өзлексез дәвам итсеннәр, язсыннар, язсыннар. Төп хезмәттән тыш, иң кимендә 2—4 сәгать вакыт иҗатка багышлансын. Шуны онытмыйк: кешедә бер генә сәләт тә эшчәнлектән башка үсә алмый. Киресенчә, кулланууда булмаган талант тутыга, күгәрә, бетә. Теләсә кайсы өлкәдәге уңыш — ул билгеле максатка юнәлтелгән хезмәт нәтиҗәсе. Ләкин безнең әдәби хуҗалыкта иҗат эшчәнлеген даими алып баруга комачаулый торган киртәләрне алып ташлауда яшьләргә ярдәм итү җитенкерәми шикелле. Алыйк мондый күренешне: теге я бу автор җыентык чыгара: берне чыгара, икене... Аннары төшеп кала — басылмый башлый. Шундый язмышка дучар булган авторлар татар әдәбиятында аз түгел. Менә аларның кайберләре: С. Гыйлемханов — бер җыентык авторы. Н. Зариф — ике җыентык авторы. Бу исемлеккә 20 елга якын матбугатта басылып килгән Н. Вафинны өстәргә кирәк. Аннары Р. Сатгаровны, М. Саттаровны, И. Галләмовны, И. Мозаффаровны... Тагын... бик күпләрне: Гадәттә бу күренешне талант булу-булмау белән аңлаталар. Авторның әсәрләре басылмый икән, димәк, таланты беткән.

### ТАЛАНТ НӘРСӘ УЛ?

Бу — әдәби алмаш әзерләү эшен үз агымына тапшыруга илтә торган караш.

[1] Г. Бәширов. Яшьләрне бергәләп үстерик. «Татарстан яшьләре», 1954 ел. 19 ноябрь.

Әйтик, бөтен нәрсә бары тик талантка гына бәйле икән, ул чагында нигә ярдәм, нигә тәрбия? Хәлбуки, әдәбият мәйданыннан төшеп калу күп төрле сәбәпләргә бәйле. Шуларның берсе — иҗади эшчәнлеккә комачаулык итүче киртәләр. Алыйк китап чыгаруны. Безнең әдәби хуҗалыкта китапны бастырып чыгару мәшәкатьләренә сарыф ителгән вакыт еш кына әсәрне язуга тотылганнан берничә мәртәбә артып китә. Мондый хәлләр иҗат эшчәнлегенә тоткарлык китерәме? Әйе. Ләкин яшь каләмнәр үзләре дә талант-фәлән дигән булып тик ятарга тиеш түгел. Талант — табигать бүләге. Ләкин ул тәрбиягә мохтаҗ. Тәрбияче исә — беренче чиратта, каләм тибрәтүче үзе, аның көндәлек фидакарь хезмәте, үз өстендә тирләп-пешеп эшләве. Тарихта, мәсәлән, мондый гыйбрәтле сабак бар: мәгълүм булганча, Демосфен борынгы Грециядә иң көчле оратор, иң зур политик эшлекле булып саналган. Ничек ирешкән соң ул шундый югары дәрәҗәгә?

...Көннәрдән бер көн яшь Демосфен танылган оратор чыгышын тыңлап тора. Оратор шундый тәэсирле итеп сөйли ки, кешеләр аны тын алырга да базмыйча йотлыгып тыңлыйлар. Яшь Демосфенны бу күренеш сокландыра, әсир итә. Шул көннән башлап ул оратор булу хыялы белән яши башлый. Ләкин табигать аны бик нык кимсеткән була. Ул гаять чандыр, авыру кыяфәтле күренә, тавышы — зәгыйфь, сулышы — кысан, сөйләме — буталчык була.

Оратор исә, шул чор таләпләре буенча, бик чибәр, сәламәт тәз гәүдәле, көр тавышлы, киң сулышлы булырга тиеш. Ләкин Демосфен мондый сыйфатлар миндә юк, мин оратор була алмыйм икән дип тормый, җиң сызганып ораторлык сәнгатен өйрәнергә керешә. Иң яхшы ораторлардан дәрес ала башлый. Тик шулай да беренче нәтиҗәләр уңышсыз килеп чыгалар. Аннары уңышсызлык кабатлана, тагын, тагын... Ниһаять, яшь Демосфен карарга килә: ораторлык сәнгатенә өйрәнүнең гамәлдәге алымнары аның өчен нәтиҗә бирерлек түгел икән. Димәк, ул үзенә яраклысын үзе уйлап табарга тиеш. Һәм таба да.

Плутарх язуына караганда, яшь Демосфен ораторлык сәнгатенә өйрәнү өчен җир астында үзенә махсус бүлмә әзерли. Көн саен шушы бүлмәгә килеп актерлык осталыгына өйрәнә, тавышын ныгыта. Аннары килеп-китеп йөрү күп вакыт алгач, ул җир асты бүлмәсеннән бөтенләй чыкмас була, айлар буенча шунда ябылып өйрәнүне киеренке рәвештә дәвам иттерә. Бүлмәдән чыгып китү теләген бастыру өчен Демосфен башындагы чәченең бер өлешен кыркып ташлый. Чөнки мондый килеш кеше күзенә күренү оят санала.

Үзендәге тумыштан килгән кимчелекләрне бетерү буенча да Демосфен бик тырышып эшли. Авазлар яңгырашының ачыклыгына, төгәллегенә ирешү максаты белән ул, мәсәлән, авызына вак чуерташлар каба һәм шул килеш яттан шигырьләр сөйли. Тавышны ныгыту, сулышны киңәйтү өчен исә берәр нәрсә турында речь сөйләгән хәлдә текә-текә үрләргә чабып менә. Айлар буена өзлексез рәвештә кабатланган шундый күнекмәләр ярдәмендә яшь Демосфен үзендәге кимчелекләрне җиңә.

Нәтиҗә инде мәгълүм: Демосфен үз заманында иң көчле оратор, талантлы политик эшлекле булып танылa.

Кызганычка каршы, безнең яшь каләмнәргә әнә шундый ачык максатка юнәлтелгән фидакарь хезмәт, тырышлык җитенкерәми шикелле. Беренче авырлыклар килеп чыгу белән әдәбиятка кул селтәү фактлары, безнеңчә, шул турыда сөйли.

Ниһаять, сүз ахырында әдәби әсәрләрне көндәлек агитация-пропаганда эшләрендә куллану мәсьәләсенә тукталып үтәсе килә. Беренче караштa мондый эшнең яшь каләмнәрне тәрбияләүгә катнашы юк шикелле. Ләкин чынлыкта алай түгел. Эш болай тора. Филология фәннәре докторы Ибраһим Нуруллин күрсәткәнчә, «Яшь кеше кулына каләм алсын өчен, аның ниндидер «әдәби атмосферага» эләгүе кирәк»[1]. Андый атмосфераны тудыруга исә, башка чаралар белән бер рәттән, әдәби әсәрләрне көндәлек агитация-пропаганда эшләрендә файдалану да ярдәм итәр иде. Әйтик, телевидениедән, радиодан шагыйрьләр, әдипләр чыгышын атна саен оештыру, ата-аналар белән эшләүдә шигырьләрдән файдалану, әдәби кичәләр, шигырь ярышлары үткәрү һ. б.

Югарыда әйтелгәннәрдән чыга торган төп нәтиҗә шул: яшь каләмнәр — әдәбиятыбызның киләчәге. Аларның сәләтләрен ачу, үстерү, камилләштерү өчен кирәк булган барлык чараларны күрү — әнә шул киләчәккә хезмәт итү дигән сүз. Хезмәт нинди булса, нәтиҗә шундый булачак. Бу — бәхәссез.

**ШӘРӘФ ӘХМӘДУЛЛИН,**
**КДПИның чит телләр кафедрасы мөдире, доцент.**

[1] И. Нуруллин. Аяк белән йөрүгә ни җитә? «Казан утлары», 1973 ел, 3 сан.

# ПРОФЕССОР МӨХЕТДИН КОРБАНГАЛИЕВ

Тууына 100 ел тулу уңае белән

Татар халкының күренекле галиме, танылган педагог һәм методист, атказанган фән эшлеклесе, орденлы профессор Мөхетдин Хафиз улы Корбангалиевнең тууына 100 ел тулды.

Ул 1873 елның 9 декабрендә (иске стиль белән 26 ноябрьдә) элекке Алабуга өязенең Биектау авылында (хәзерге Әгерҗе районы) ярлы крестьян семьясында туа. Үз авылларындагы рус-татар мәктәбен тәмамлагач, ул Казандагы татарская учительская школага укырга керә. Учительская школада укыганда К. Насыйри янына килеп йөри, шул ук вакытта шәһәрнең алдынгы фикерле студентлары белән аралаша.

Учительская школаны тәмамлагач, 1895 елда элекке Мамадыш өязендәге Чирче авылына укытучы булып китә. Шушы вакыттан алып аның озак елларга сузылган педагоглык хезмәте башлана.

1903 елның көзендә М. Корбангалиев Казандагы татар приютына мөдир һәм укытучы итеп күчерелә. Монда килгәч, ул алдынгы фикерле татар яшьләре белән аралаша башлый, алар белән берлектә «яшьләр түгәрәге» оештыра. Түгәрәккә рәсми төс бирү өчен, түгәрәк әгъзалары «Шәрык клубы» ачалар. Шул вакыттан башлап Февраль революциясенә кадәр М. Корбангалиев бу клубның старшинасы хезмәтен үти. Шул ук елларда ул Казандагы «Җәмгыяте хәйрия»нең секретаре булып та тора.

1905 елгы революция елларында М. Корбангалиев политик эшләргә бирелеп китә. Казан студентларының һәм учительская школада укучыларның революцион хәрәкәтендә катнаша...

Февраль революциясеннән соң М. Корбангалиев Казандагы балалар приютында укытучы һәм шул ук вакытта татар мәктәпләренең инспекторы булып эшли. Казан өязе һәм губерна земствосы шәһәр думасында һәм Бөтенроссия татар учительләренең союзында член булып тора. Әнә шунда эшләвеннән файдаланып, ул мәгариф өлкәсендә күп кенә эш эшли: татарлар өчен яңа мәктәпләр ачтыруга ирешә, укытучылар өчен курслар оештыра. Үзе үк шушы мәктәп һәм курслар өчен программалар төзи, укытучылар хәзерли торган курсларда укыта.

Җитәкчелек эшләрендә эшләү белән бергә, М. Корбангалиев бертуктаусыз укытучылык эшен дә алып бара. Ул Казан татар педагогия техникумында һәм хәрби команда курсларында (1920—1922), Шәрык академиясендә, педагогия техникумында, җир эшләре төзелеше техникумында, татар коммунистлар университетында (1922—1924) рус һәм татар телләре укыта, Татнаркомпросының Гыйльми үзәгендә председатель урынбасары була, анда гыйльми һәм педагогик эшләр белән җитәкчелек итә (1924—1927), юристлар хәзерләү курсларында татар теле укыта (1928—1930). Шул ук вакытта Казан дәүләт университетында татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире була һәм татар телен укыта (1928—1940).

1931—32 уку елында М. Корбангалиевкә университетта үтелә торган барлык фәннәр буенча татар телендә гыйльми терминнарны эшләү өчен терминология комиссиясе

төзү һәм аның белән җитәкчелек итү эше тапшырыла. Аның җитәкчелегендәге бу комиссия бер ел эчендә 17.500 гыйльми термин эшли.

Аның методика өлкәсендәге хезмәте шулай ук ифрат күп тармаклы: башлангыч мәктәпләрдә укырга-язарга өйрәтү, урта һәм югары мәктәпләрдә грамматика укыту, зурлар мәктәбендә укыту, русларны һәм гомумән татарлардан башкаларны татарча укыту буенча методик хезмәтләр яза, төрле методик кулланмалар, методик хатлар язып бастыра.

Укытучылык-педагоглык, методистлык эшләре һәм гыйльми, иҗтимагый хезмәтләре өстенә, ул йөзләрчә дәреслек һәм кулланманың (135 исемдә) авторы һәм редакторы була. Ул 1912—13 елларда ук башлангыч мәктәпләр өчен әлифбалар, арифметика дәреслекләре, уку китаплары һәм соңга табарак грамматика һәм география дәреслекләре төзеп бастыра. Урта мәктәпләр өчен грамматика китаплары, зурлар мәктәбе өчен әлифба һәм уку китаплары, татар башлангыч мәктәпләре өчен букварь һәм рус теленнән уку китаплары, шулай ук татар телен өйрәнүче рус һәм башка халыклар өчен махсус китаплар төзеп бастыра. Латин һәм рус графикасы нигезендәге алфавит һәм орфография кагыйдәләрен төзү эшендә башлап йөрүче ул була. Аның җитәкчелегендә русча-татарча һәм татарча-русча сүзлекләр төзелә.

М. Корбангалиевнең укыту-тәрбия, гыйльми, иҗтимагый һәм оештыру-җитәкчелек итү өлкәсендәге хезмәтләренә югары оешмалар һәм халык тарафыннан зур бәя бирелгән: 1921 елның февралендә 25 еллык гыйльми, тәрбияви хезмәтләре һәм Совет учрежденеләрен төзү һәм ныгыту юлында тырышып хезмәт итүе өчен, аңа мәгариф эшчеләренең гомуми җыелышында «Хезмәт каһарманы» исеме бирелә. 1928 елның 2 гыйнварында эшче-крестьян һәм Кызыл Армия депутатларының Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты Советы Президиумы карары нигезендә М. Корбангалиевкә «Хезмәт Герое» исеме бирелә һәм ул Мактау грамотасы белән бүләкләнә. 1940 елда, Татарстан Совет Социалистик республикасы төзелүгә 20 ел тулу уңае белән үткәрелгән юбилей көннәрендә, М. Корбангалиевкә СССР Верховный Советы Президиумы Указы белән а т к а з а н г а н ф ә н э ш л е к л е с е исеме бирелә һәм ул Хезмәт Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә.

1941 елда Мәскәү учпедгизы рус мәктәпләреннән башка мәктәпләрнең VIII—IX—X класслары өчен рус теле дәреслеге төзү эшен планлаштыра. Һич булмаса, авторлар коллективын төзеп, алар белән җитәкчелек итүне һәм дәреслекне редакцияләүне үз өстенә алуын сорап, учпедгиз редакторы профессор М. Корбангалиевкә хат яза һәм дәреслекне август аена хәзерләүне үтенеп, соңгы сүзендә болай ди: «...Әгәр Сез бу коллектив белән җитәкчелек итсәгез генә, учпедгиз дәреслек төзүне Казан коллективына тапшыра ала. Авторлар коллективын сайлау сезнең карамакта».

1941 елда, сәламәтлеге аеруча начар булуга да карамастан, М. Корбангалиев югарыда күрсәтелгән дәреслек төзүне үз өстенә ала һәм аны күрсәтелгән вакытка өлгертергә сүз бирә. Дәреслекне төзү эшенә Х. Шабанов һәм Р. Газизовларны да тартуын һәм дәреслекнең кайбер өлеше 15—20 июньгә әзер булуын әйтеп, 3 июньдә хат яза. Ләкин шул көнне кичкә таба сәламәтлеге аеруча начарлана һәм аның йөрәге тибүдән туктый.

Ф. ВӘЛИЕВА, доцент.



# Фәрит Яруллин

*(1914—1943)*

Талантлы татар композиторы Фәрит Заһидулла улы Яруллинның тууына шушы елның январенда 60 ел тулды.

Фәрит Яруллин Казанда халык музыканты Заһидулла Яруллин семьясында туып, кече яшьтән үк музыканы аңлап, яратып үсә.

Өч ел эчендә ул әтисеннән фортепьяно уйнарга өйрәнә.

1930 елда Ф. Яруллин Казан музыка техникумына укырга керә, виолончель һәм фортепьяно классларына йөри.

1933 елны музыкага һәвәс егетне Мәскәү консерваториясе каршындагы рабфакка җибәрәләр. Ә тагын бер елдан ул татар опера студиясендә укый башлый. Бу вакытта ук инде Фәрит Яруллин виолончель белән фортепьяно өчен соната, симфония яза, «Зөлхәбирә» операсының беренче кисәген иҗат итә. Аның «Комсомолка-партизанка», «Егерменче елларда», «Колхоз кызына» шикелле лирик җырлары һәм романслары тиз арада халык арасына таралып, халык мәхәббәтен яулап өлгерә.

Студиядә укыган чагында яшь композитор Г. Тукай иҗаты белән якыннан кызыксына. Аңа бигрәк тә «Шүрәле» әкияте тынгылык бирми. Бу әсәрнең халыкчанлыгы, тирән драматизмы, яктылыкка өндәве, пейзаж элементларының җанлылыгы Ф. Яруллинны балет язарга рухландыра.

«Шүрәле» балетының аерым эпизодлары 1939 елда языла. Ләкин рәхимсез сугыш композиторга бу зур полотноны әсәрен билгеләнгән вакытка тәмамларга мөмкинлек бирми.

1941 елны Ф. Яруллин Ульяновскидагы хәрби училищеда укый, яңа әсәрләр иҗат итә. Училищены тәмамлагач, кулына корал алып, фронтка китә. 1943 елны укчы взвод командиры, композитор Фәрит Яруллинның гомере өзелә.

Ф. Яруллинның «Шүрәле» балеты 1945 елда Татар дәүләт опера һәм балет театрында беренче тапкыр куелды. Тамашачылар аны хуплап каршы алдылар. Бу балет илебезнең Мәскәү, Ленинград, Одесса, Киев, Львов, Рига, Таллин кебек зур шәһәрләрендә генә түгел, чит илләрнең театрларында да зур уңыш казанды.

Журналыбызның бу санында татар совет музыка сәнгатен үстерүгә һәм баетуга күп көч куйган кыска гомерле композитор Фәрит Яруллинның фронттан гаиләсенә язган берничә хатын урнаштырабыз.

*7 сентябрь, 1941 ел.*

*Хәерле көн, кадерлем!*

Әле генә синең открыткаңны алдым һәм җавап язарга ашыгам. Бүген ял көне, шуңа күрә вакыт та иркенрәк. «Шүрәле» чынлап та егермесендә куеламы? Нигәдер



ышанасы килми, тик өметне өзмим. Үз күзләрем белән күрәсе иде дә бит, ләкин... Кайчагында куркып та куям: спектакль уңыш казанырмикән? Чөнки аны кыскарткаччар да бугай, аннары вакыты да ул түгел, халык йөрер микән театрга?..

Әгәр «Шүрәле» турында бирәр мәкалә-фәлән чыкса, җибәрә күр инде берүк. Бәлки Якобсон игъланын бирер. (Спектакльне күрмәсәм, игъланын тотып карасам да күңел булыр иде сыман.) Бәләкәч турында ни уйлыйсың? Кабатлап әйтәм, үзеңнең сәламәтлегеңне саклыйсың килсә, берниндн им-томнарга юл куйма. Сәламәтлегең болай да әйбәт түгел. Әгәр дә миңа тагын бер шатлык бүләк итәргә телисең икән, нинди генә кыенлыкларга да карамастан, бәләкәчне сакла. Менә нинди күңелсез хатлар язам мин сиңа, акыллым.

Әнкәйгә һәм күршеләргә сәлам әйт. Якобсонны котлыйм. Үз дигәнен иткән бит тәки!

*Сине үбеп*
*Фәрит.*

*Сөеклем Галина!*

Синнән хәбәр ала алмадым. Хәзер мин хат язган җирләремнән бик еракта. Хәер, белмим, ул хат сиңа барып ирештемикән. Мин инде фронтта. Алдагысын күз күрер. Бу минутта теләгем бер генә — сөйгән һөнәремнән, хатынымнан, туганнарымнан аерылырга мәҗбүр иткән әшәке немец илбасарларын мөмкин кадәр күбрәк кыру.

Барысы да мин уйлаганча килеп чыкса, тагын да шәбрәк әсәрләр язарга исәп.

*Фәритең.*

*15 октябрь, 1941.*
*Әтигә хат яз.*

*19 июнь, 1942 ел.*

*Кадерлеләрем минем!* [1]

Кичә сездән 4 хат алдым. Барысы өчен дә рәхмәт. Элемтә хәлләре белән таныш булмаганга күрә, шушы көннәрдә генә сиңа да, әтигә дә үпкәләп хатлар язган идем. Ярый, барысы да әйбәт икән. Үпкәм язылды, ачуым басылды.

Исән-имин булуыгызга шатланам. Баланы саклагыз. Кара аны, кызыбыз өчен беренче чиратта син җаваплы. Кыен заманда тудыргансың икән, сакларга да тырыш. Ә мин хәл кадәренчә ярдәм итәрмен. 5—6 мең акча алсам, бер тиененә чаклы сезгә җибәрер идем.

Нәҗипкә һәм Симага игътибарлары өчен рәхмәт.

[1] Хатның бер читенә сугыш рәсеме ясалган, Рәсем астында язу: «Янгын манзарасын күрәсең, ләкин «Шүрәле»дән түгел»,

Хәлимә Терегулова белән танышуыңа шатланам. Фәрештә җанлы кеше ул. Ильская белән дә сөйләшеп утырасы килә. Мин бит аны чын күңелдән хөрмәт итәм. Аларның икесенә, аннары А. Измайловага миннән кайнар фронт сәламнәре тапшыр. Адресларын белсәм, үзем язар идем. һич булмаса, үзләре язып салсыннар инде. Нәҗипкә, Симага, Светланага ялкынлы сәламнәр!

Бүкәй Шүрәле.

Үзем исән-сау. Сезне кочып һәм үбеп эти кеше...

*Кадерлеләрем, газизләрем!*

Синнән хат-хәбәр ала алмавым өчен бик борчылам. Хатың Селижскига килеп җиткәндә, мин моннан еракларда булырмын инде. Бүгенге вакыйгаларның иң кызу урынындадыр бәлки. Хәлләр шулайрак тора. Ватанны саклаудан да изгерәк максат юк бит хәзер. Фронтка горурлык хисе белән китәм. Тормышыбыз кояшын капларга җыенучы кара болытларны тарату өчен бездән коточкыч күп көч, зур киеренкелек сорала. Безнең җиңүебезгә шикләнмә. Нәрсә эшләргә мөмкинлегең бар — бөтенесен эшлә, күбрәк эшлә. Китәр алдыннан мин сиңа әнә шуларны әйтергә теләгән идем. һәр вакыт һәм һәр җирдә синең

Фәритең.

*Кадерле хатыным һәм кызым!*

Әле открыткаларыгыз еш килгәли иде, соңга таба сездән нишләптер бер генә хәбәр дә алганым юк. Семья хәлләреннән тыш, мине Нәҗип, Ключарев, Хәбибуллин шикелле дусларымның нинди эшләр майтарып ятулары кызыксындыра. Нәҗипкә мин бер хат кисәге язган идем, тик үзеннән җавап алганым юк әле. Мин хәзер, әлбәттә, музыка белән шөгыльләнә алмыйм, әмма музыка һәр вакыт минем йөрәгемдә, һәр вакыт минем белән. Беркайчан да мин музыкасыз яши алмам, ахрысы. Миңа бигрәк тә соңгы вакытта симфоник оркестр белән идарә итү теләге тынгылык бирми. Үз әсәремне, һичшиксез, үз әсәремне! Шүрәлемне өзелеп сагындым. Сөембикә лейтмотивлары яңача яңгыраш алды. Ул минем язылачак симфониямнең урта өлешен тәшкил итәчәк. Хыялларымның әле хәзер үк тормышка ашмавы гына кызганыч...

Ярый, тәмамлыйм. Барыгызны да кысып-кысып кочасым килә. Бигрәк тә сине һәм кызымны.

Адресым бераз үзгәрде. 1681 кыр почтасы, 237 часть. Ә инде калганы сиңа мәгълүм.

*24 декабрь, 1942 ел.*

Бүген, мөгаен, минем иң шатлыклы көнемдер: берьюлы 10 хат алдым. Синнән өчне, Нәҗиптән берне, берне Заһидтан, икене Мәскәүдән, икене Генрих Ильич Литинскийдан[1] һәм әтидән. Барысы да шулай көтмәгәндә булды, хәтта бераз аптырап калдым. Хатлар иске адреска язылганнар иде. Аларның барысын бергә җыеп, яңа адрес белән җибәргәннәр. Мине бигрәк тә синең хатлар, әти хатлары һәм Генрих Ильич хатлары куандырды. Ул бөтен җаны-тәне белән, чын күңелдән безнең бәләкәчкә ярдәм итәргә тели. Сезнең адресны сорап язган. Җибәрдем. Миңа иң читен чакларымда ярдәм кулын сузган, аякка басарга булышкан бердәнбер кеше бит ул. Мин аңа барысы өчен дә, бар кешегә караганда да күбрәк бурычлы. Тиздән ул сезгә бәләкәчебез язмышы белән кызыксынып хат язар. Дусларымның ташламаулары һәм һәркайсының ничек булса да ярдәм итәргә тырышуы мине бик сөендерә. Монысы әйбәт. Ләкин мине синең авыруың борчый. Аз гына булса да хәлеңне җиңеләйтә алсам икән! Сөекле кызыбызның бәхетле киләчәге өчен үзеңне сакла.

Барлык дус-ишләргә кайнар сәлам.

---

[1] Композитор, профессор, Ф. Яруллинның укытучысы.

8—15 июльдә язылган хатны алдым... Әгәр дә ул-бу була калса, мин теге дөньядан да үзем турында хәбәр итәрмен. Бөтен җиһан асты-өскә килгән заманда госпитальдә тыныч кына ята аламмы соң инде! Сводкалар белән танышып барсаң, минем урыным кайда икәнлеген аңларсың дип уйлыйм. Без беразга сугыштан чыгып торсак та, калган егетләр төньяктан да, көнчыгыштан да, көньяктан да тегеләрнең тетмәләрен тетәләр. Безнең «Катюша»лар авыр туплар белән бер ансамбль тәшкил итеп, шундый көчле симфония башкаралар ки, гитлерчылар хәтта керер тишек таба алмыйлар. Мондый симфонияне минем әле дөньяның бер генә музыка әдәбиятында да очратканым юк. Шуңа шатланам, мин дә шул симфониянең бер молекуласы, бер кисәкчәсе...

Ярый, бу сүзләрем яңа түгел. Соңгы җиңүгә кадәр, кадерлеләрем!

Сугышта төрле хәлләр була... Ләкин безнең рухыбыз көннән-көн үсә, ныгый. Италиядәге вакыйгаларга гына күз сал һәм безгә каршы торучыларга карата нәтиҗә чыгар.

Әлегә барлык дусларга да хат язарга мөмкинлек булмаганлыктан, Нәҗипкә, Симага, Салихка, Ильскаяга, Измайловага, Сарымсаковка, Терегуловага, Биккенинга, Җ. Фәйзигә, Хәбибуллинга, Мозаффаровка дусларча кайнар сәлам тапшыруыңны үтенәм.

Күрәсең, дусларым никадәр минем. Ә кайтсам, тагын да күбрәк булачак.

Кәгазем бетә, адрес язам.

Кыр почтасы 25562 Г.

Күңелем һәр вакыт синең белән.

## ҖИТДИ СӨЙЛӘШҮ

Татарстан язучыларының узган елгы 28 сентябрьдә үткәрелгән партия җыелышы язучыларның җәмәгать активлыгы хакында сөйләшүгә багышланды.

Гариф Ахунов докладыннан соң Хәй Вахит, Нәби Дәүли, Туфан Миннуллин, Ләбибә Ихсанова, Рафаэль Мостафин, Афзал Шамов иптәшләр чыгыш ясап, актив иҗтимагый тормыш белән яшәүнең иҗатка уңай йогынты ясавын язучылар коллективы тормышындагы мисаллар белән дәлилләп сөйләделәр.

Җыелышка партия оешмасы секретаре Габдрахман Минский йомгак ясады.

## АЗИЯ ҺӘМ АФРИКА ИЛЛӘРЕ ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ V КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

1973 елның сентябрь аенда Алма-Ата шәһәрендә Азия һәм Африка илләре язучыларының бишенче конференциясе булды. Ике зур континентның прогрессив язучылары һәм безнең илнең утызга якын язучысы катнашында үткәрелгән ул конференциядә сүз тынычлыкны ныгыту өчен көрәш, кешеләрне гуманизм рухында һәм колониализмга каршы тәрбияләү хакында барды.

Азия һәм Африка илләре язучыларының бишенче конференциясендә Татарстан язучылар союзы идарәсе председателе шагыйрь Зәки Нури да делегат булып катнашты.

## ЛЕГЕНДАР ДИВИЗИЯ ВЕТЕРАНЫ

Үткән елның июль аенда «Сиваш» дивизиясенең төзелүенә 55 ел һәм аның Курск дугасындагы сугышларда катнашуына 30 ел тулды. Шул уңай белән КПССның Курск өлкә комитеты чакыруы буенча, әлеге дивизия ветераннары заманында үзләре дошманга каршы кискен сугышлар алып барган җиргә — Курск өлкәсенең Поныри районына җыйналдылар. Алар Курск дугасында «Сиваш» дивизиясе сугышып үткән эз буйлап йөрделәр, Поныри районы хезмәт ияләре алдында чыгышлар ясадылар, сугыш музейларын карадылар. Шул ветераннар арасында гражданнар сугышы елларында «Сиваш» дивизиясе составында дошманга каршы сугышкан һәм соңыннан атаклы «Сиваш» повестен язган өлкән әдибебез Гомәр Бәширов тә бар иде.

«Сиваш» ветераннарыннан утызлап кешене, шул исәптән Гомәр Бәшировне дә, КПССның Курск өлкә комитеты һәм КПССның Поныри район комитеты һәм район башкарма комитеты үзләренең Почет грамоталары белән бүләкләделәр.

Үзенең әдәби иҗаты белән «Сиваш» дивизиясенең данын үстерүгә булышлык иткәне өчен, Гомәр Бәширов сугыш ветераннарының бөтен Союз комитеты тарафыннан рәхмәт грамотасы белән дә бүләкләнде.

## ТУКАЙ ПРЕМИЯЛӘРЕ ТАПШЫРЫЛДЫ

Әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә ирешкән уңышлары өчен 1973 елда бер төркем культура эшлеклеләренә Г. Тукай исемендәге республика премияләре бирү турында КПСС өлкә комитеты бюросы һәм Татарстан АССР Министрлар Советы карарын журнал укучыларына хәбәр иткән идек инде. Үткән елның 17 сентябрендә ТАССР Министрлар Советының конференц-залында шул премияләрне тапшыру тантанасы булды.

Тантанада республика иҗат оешмалары союзлары җитәкчеләре, язучылар, композиторлар, художниклар, театр сәнгате вәкилләре, партия, совет работниклары, журналистлар катнашты.

Тантананы ТАССР Министрлар Советы Председателе урынбасары, Г. Тукай исемендәге республика премияләр комитеты председателе М. Хәсәнов ачты.

КПСС өлкә комитеты бюросы һәм ТАССР Министрлар Советы карары нигезендә, диде М. Хәсәнов, иҗат өлкәсендә зур уңышларга ирешкән әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләренә ел саен бөек шагыйрь исемендәге премияләр бирелә. Быел андый премияләр әдәбият өлкәсендә «Хәзинә», «Чикләвек төше» әсәрләре өчен РСФСРның атказанган культура эшлеклесе, язучы Гариф Ахуновка, музыка һәм театр сәнгате өлкәсендә «Су анасы» балеты өчен ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, композитор Әнвәр Бакировка, балетның либретто авторы И. Смирновка, дирижер Хәсби Фазлуллинга, спектакльдә Алмай ролен башкаручы Ревдар Садыйковка, художник Б. Кноблокка бирелде.

Аннары М. Хәсәнов яңа лауреатларны КПСС өлкә комитеты бюросы һәм ТАССР Министрлар Советы исеменнән зур бүләк алулары белән кайнар котлады, күп милләтле совет әдәбиятын һәм сәнгатен үстерүдә янадан-яңа уңышлар теләде. Лауреатларга лауреат значоклары һәм дипломнары тапшырылды.

Лауреатлар исеменнән И. Смирнов, Г. Ахунов сөйләделәр. Алар әдәбият һәм сәнгать кешеләренең хезмәтенә партия һәм хөкүмәтебезнең югары бәя бирүе, тирәнтен кайгыртуы өчен рәхмәт белдерделәр, киләчәктә чорга лаек замандашларыбыз образларын иҗат итү өчен тагын да тырышыбрак эшләячәкләрен әйттеләр.

## ЯҢА СИМФОНИЯ

Татарстан дәүләт симфоник оркестрының концерт сезонын яңа әсәр белән башлап җибәрә торган гадәте бар иде. Оркестр шул әйбәт гадәтенә бу юлы да тугрыклы булып калды. 1973—1974 елгы концерт сезонын СССРның халык артисты композитор Нәҗип Җиһановның яңа әсәре — Дүртенче симфониясе белән ачты. Дүрт кисәктән торган һәм республикабыз башкаласы Казанның борынгы тарихы һәм бәхетле бүгенгесе хакында лирик уйлануларга нигезләнгән анлаешлы тел, җылы хисләр белән сугарылган бу әсәр тыңлаучыларда әйбәт тәэсир калдыра.

## КАЗАНДА КИНО БӘЙРӘМЕ

Үткән елның сентябрь аенда республикабызның Чаллы, Түбән Кама, Зәй районнарында һәм Казан шәһәрендә халык кинофестивале булды. Фестиваль көннәрендә Мәскәү артистлары — Маргарита Володина, Владимир Этуш, Людмила Шагалова, Джемма Фирсова кино сөючеләр алдында чыгышлар ясап, аларга үзләре кинода уйнаган рольләрне ничек иҗат итүләре турында сөйләделәр. Фестиваль көннәрендә кинотеатрларда «Азатлык — татлы сүз», «Иван Васильевич профессиясен алыштыра», «Привалов миллионнары», «Сезнең ятраканыгыз бармы?» исемле картиналар күрсәтелде. Тамашачылар белән очрашулардан тыш, Мәскәү артистлары Казанның югары уку йортлары һәм предприятиеләре белән дә таныштылар.

## УФА ТАМАШАЧЫЛАРЫ БЕЛӘН ОЧРАШУЛАР

РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Тукай премиясе лауреаты композитор Заһид Хәбибуллин, РСФСРның һәм ТАССРның халык артисткасы Венера Шәрипова, ТАССРның халык артисткасы Әлфия Афзалова, ТАССРның атказанган артисты Эмиль Җәләлетдинов, шагыйрь Гөлшат Зәйнашева һәм баянчы Ирек Галимов тугандаш башкорт халкының башкаласы Уфа шәһәренә барып, унлап концерт биреп кайттылар. Татар һәм башкорт халкының күптәннән килә торган какшамас дуслыгына багышлап, Уфа шәһәренең театрларында һәм культура сарайларында үткәрелгән ул концертларны тамашачылар бик яратып карадылар.

Республикабыз сәнгать осталары Уфадагы матбугат йортында Башкортстан журналистлары һәм нәшрият хезмәткәрләре белән дә очрашып, аларга үзләренең иҗатлары турында сөйләделәр, яраткан әсәрләрен уйнап һәм җырлап күрсәттеләр, сорауларга җаваплар бирделәр.

* * *

Казанның Ленин комсомолы исемендәге яшь тамашачылар театры Уфа шәһәрендә гастрольдә булып кайтты. Театр коллективы Башкортстан тамашачыларына М. Анчаров һәм Б. Равенскихның «Драматик җыр», В. Катаев повесте буенча эшләнгән «Полк улы», Т. Янның «Кыз һәм апрель», Ю. Яковлевның «Ә Воробьев тәрәзә ватмады», А. Кузнецовның «Ни булса — шул булыр», А. Линдгренның «Пеппи — озын колак», Е. Шварцның «Золушка» исемле әсәрләрен күрсәтте. Яшь тамашачылар театры куйган барлык спектакльләрне дә уфалылар кызыксынып карадылар. РСФСРның атказанган һәм ТАССРның халык артисткасы П. Неменко-Баковская, ТАССРның атказанган артистлары В. Глушков, А. Пешкова, Б. Роскин, В. Козлова уйнаган рольләр тамашачыларда аеруча зур тәэсир калдырды.

## ЧАЛЛЫДА ҺӘМ КАЗАНДА

Рус халык җырларын яратып, тыңлаучыларны дулкынландырырлык итеп башкаручы җырчы, Ленин премиясе лауреаты Людмила Зыкина, безнең якларга гастрольгә килгәч, иң элек Чаллыга барып, Кама автомобиль заводын төзүчеләргә концертлар бирде. Аннары Казанга кайтып, җырын Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында дәвам итте. Аның бернечә көн рәттән бирелгән концертларын Казан тамашачылары яратып тыңладылар.

## ЯКТАШЫБЫЗ ИСТӘЛЕГЕНӘ

СССРның халык артисты, «Иван Сусанин» спектаклендә Сусанин ролен оста башкарганы өчен СССР Дәүләт премиясе лауреаты исемен алуга лаек булган Михаил Дормидонтович Михайловны заманында безнен илдә генә түгел, чит ил сәнгать сөючеләре дә яхшы белә иде. Аның көчле һәм зур тәэсирле тавышы ССР Союзының Зур театры залында кырык ел дәвамында яңгырап торды.

Михаил Дормидонтович — безнең якташыбыз, иҗат юлын Казанда башлаган артист иде. Әгәр исән булса, хәзер аңа 80 яшь тулар иде. Менә шул уңай белән бу атаклы җырчыга багышлап, В. И. Ленин исемендәге дәүләт китапханәсендә «Көчле тавыш» дигән күргәзмә булды. Зур театр үзенең быелгы сезонын якташыбыз Михаил Дормидонтович яраткан «Иван Сусанин» спектакле белән башлап җибәрде.

## ЗУР БҮЛӘК

Совет әдәбиятында уңышлы эшләгәне өчен һәм 60 яшь тулу уңае белән язучы **Тихон Кононович Журавлев «Почет билгесе»** ордены белән бүләкләнде.

## ИҖАТ БӘЙРӘМЕ

Татар балалар язучысы, республикабызның атказанган культура работнигы Ләбибә Ихсанова илле яшь тулган көннәрдә әдибәнең туган җире — Түбән һәм Урта Шөн авылларының (Киров өлкәсенең Вятские Поляны районы) культура сарайларында, аннары Казан шәһәрендәге Пионерлар сараенда юбилей кичәләре үткәрелде. Л. Ихсанованың каләмдәшләре һәм артистлар белән берлектә үткәрелгән ул кичәләрдә юбиляр адресына килгән күп санлы котлау телеграммалары, котлау адреслары һәм бүләкләр тапшырылды.

Шул көннәрдә Ләбибә Ихсанова өчен тагын бер куаныч булды. Совет әдәбияты өлкәсендәге хезмәтләре өчен һәм 50 яшь тулу уңае белән **Ләбибә Фәиз кызы Ихсанова** КПСС өлкә комитетының һәм Татарстан АССР Министрлар Советының **Почет грамотасы белән бүләкләнде.**

## РӘССАМ СЕРГЕЙ ЛЫВИНГА 50 ЯШЬ

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, республикабызның күренекле рәссамы Сергей Осипович Лывинга 50 яшь тулды. Лирик пейзаж остасы Сергей Лывин ярты гасырлык юбилеен зур иҗат күтәренкелеге белән каршылады. 50 яшьлегенә багышланган һәм Казанның сынлы сәнгать музеенда уздырылган шәхси күргәзмәсендә аның йөздән артык әсәре күрсәтелде. Күргәзмәгә рәссамның төрле темаы чагылдырган һәм төрле буяулар белән эшләнгән әсәрләре куелды. Аларның барысын да берләштерә торган уртак сыйфат — туган якка, аның табигатенә мәхәббәт. Шуңа күрә юбилярның күргәзмәгә куелган картиналары тамашачылар күңеленә дә хуш килде. Рәссамның «Казан, Лобачевский урамы», «Сөембикә манарасы», «Февраль азагы», «Камада», «Кышкы юл», «Буровой янында», «Баулы кырлары», «Татарстан юллары», «Татарстан кичкелләрендә» исемле картиналары аларда аеруча зур тәэсир калдырды.

## СУГЫШЧАН ДУСЛЫК БҮЛӘГЕ

Атаклы Арктика очучысы М. Н. Каминский лаеклы ялга чыкканнан соң китаплар язу белән шөгыльләнә. 1973 елда «Молодая гвардия» нәшрияты аның «Чукотка күгендә» дигән китабын бастырып чыгарды. Яшьлегендә очучы һәм язучы Салих Баттал да М. Каминский житәкчелегендә авиациядә хезмәт иткән. Автор үзенең бу китабында сугышчан дустының кешелек сыйфатларын, очу осталыгын, тырышлыгын, характерын, төс-битен бик яратып сурәтли. «Батталов яхшы иптәш иде. Якшәмбе көннәрендә семьясы булган очучы дуслары урынына дежур торырга бик теләп бара иде. Һәр мәсьәлә һәм һәрбер кеше турында аның үз фикере булды, ләкин ул аны беркемгә дә көчләп тагарга маташмады», — дип яза автор.

М. Н. Каминский «Чукотка күгендә» дигән китабын Салих Батталга бүләк итеп җибәрә һәм аңар: «Техник прогрессның «Эшче бал корты»на — дустыма, хезмәттәшемә, очучы Салих Батталга авиациядә үткәргән яшьлегебез истәлеге» дип автограф яза.

## КЫЗЫКСЫНЫП КАРАДЫЛАР

М. Горький исемендәге культура һәм ял паркындагы күргәзмә залында Казан рәссамы А. Хуторовның шәхси күргәзмәсе булды. Казанлылар рәссамның иллегә якын экспонаттан торган һәм төрле темаларга багышланган картиналарын кызыксынып карадылар. «Балерина», «Яльчик», «Казанкада», «Камышлыкта» дип аталган картиналар аларга аеруча нык ошады.

## РЕСПУБЛИКАБЫЗ ТЕАТРЛАРЫНДА

Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры «Чикләвек төше» исемле яңа спектакль күрсәтте. Баш геройлардан коммунист Халикъ Саматовны артист Илшат Йомагулов, Рокыяны артистка Нәҗибә Ихсанова зур осталык белән башкардылар. «Чикләвек төше» спектаклен сәхнәгә яшь режиссер Ришат Хаҗиәхмәтов куйды, рәссамы — Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Әнәс Тумашев.

* * *

Казан курчак театры Нурихан Фәттахның «Энҗеле үрдәк» пьесасын сәхнәгә куйды. Бу әкият-пьеса танылган прозаик Н. Фәттахның беренче сәхнә әсәре. Спектакльнең режиссеры Р. Батуллин, рәссамы В. Губская, композиторлары Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе С. Садыйкова белән Р. Гобәйдуллин, спектакльдә театрга яңа гына кабул ителгән артистка Тәлига Ялалова уңышлы дебют ясады. Спектакль курчак театрында зур уңыш белән бара.

* * *

Республика күчмә театры язучы Р. Батуллинның «Туйлар узгач...» комедиясен сәхнәгә куйды. Бу пьеса Р. Батуллинның өлкәннәр өчен язган беренче әсәре. Спектакльнең режиссеры Р. Бикчәнтәев, рәссаме П. Баландин, композиторы С. Садыйкова. Спектакльдә мәхәббәт гүзәле Лэйлә ролен әле быел гына Ленинградта укып кайткан яшь артистка Л. Шакиржанова башкара. Спектакль Татарстан авылларында күрсәтелә башлады.

## СОЦИАЛИСТИК ЯРЫШ АЛДЫНГЫЛАРЫ ТУРЫНДАГЫ МАТЕРИАЛЛАРГА КОНКУРС

Татарстан журналистлар союзы идарәсе, «Социалистик Татарстан», «Советская Татария» һәм «Татарстан коммунисты» журналы редакцияләре тугызынчы бишьеллыкның социалистик ярыш алдынгылары эш тәҗрибәләрен уңышлы чагылдырган иң яхшы очеркларга, публицистик мәкаләләргә һәм репортажларга конкурс игълан иттеләр. Конкурска адресланган очерклар һәм публицистик мәкаләләрнең күләме 8—10 биттән, репортажларның күләме 4—6 биттән артык булмаска тиеш. Барлык материалларның да татар һәм рус телләрендә язылган һәм машинкада басылган булуы таләп ителә.

Конкурска килгән материалларның яхшы дип табылганнары конкурс игълан иткән газета һәм журнал битләрендә басылып барачак.

Конкурс 1974 елның 31 декабрена кадәр дәвам итә.

Конкурста иң яхшы дип табылган материалларга премияләр бирелә. Публицистик мәкаләләр һәм очерклар өчен беренче премия 150 сум, икенче ике премия 100 әр сум, өченче өч премия 75 әр сум; репортажлар өчен беренче премия 75 сум, икенче ике премия 50 шәр сум, өченче өч премия 30 ар сум күләмендә билгеләнде.

Конкурска дигән кулъязмалар конкурс игълан иткән газета һәм журнал редакцияләре адресына җибәрелергә һәм аларның конвертына «Социалистик ярыш алдынгылары» конкурсына» дип язылган булырга тиеш.

## ӘДИПНЕҢ ЮБИЛЕЙ КИЧӘСЕ

Үткән елның 12 ноябрендә Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры бинасында ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, күренекле драматург Риза Ишморатның тууына 70 ел тулуга багышланган юбилей кичәсе булды. Ул кичәгә әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре, партия, совет, профсоюз, комсомол хезмәткәрләре, журналистлар, Казан шәһәре хезмәт ияләре килгән иде. Кичәне Татарстан язучыларының партия оешмасы секретаре, «Казан утлары» журналының баш редакторы Гариф Ахунов ачты. ТАССР Министрлар Советы председателе урынбасары М. Х. Хәсәнов КПСС өлкә комитеты бюросы, ТАССР Верховный Советы Президиумы һәм Министрлар Советы исеменнән Риза Ишморатны кайнар котлады.

Тууына җитмеш яшь тулу уңае белән һәм әдәбиятыбызны үстерүдәге хезмәтләре өчен **Риза Ишморат** хөкүмәтебезнең зур бүләге — **Хезмәт Кызыл Байрагы ордены** белән бүләкләнгән иде. М. Х. Хәсәнов СССР Верховный Советы Президиумы исеменнән Риза Ишморатка шул орденны тапшырды һәм драматургка киләчәктә дә иҗади уңышлар теләде.

Кичәдә юбилярның тормышы һәм иҗат юлы турындагы докладны филология фәннәре кандидаты Азат Әхмәдуллин ясады. ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе, СССР Язучылар союзы идарәсе секретаре шагыйрь Зәки Нуриның юбилярга СССР һәм ТАССР язучылары исеменнән әйтелгән котлау сүзләреннән соң, Риза Ишморат адресына килгән күп санлы котлау адреслары, бүләкләр тапшырылды.

Соңыннан республикабызның сәнгать осталары көче белән спектакль-концерт бирелде.

## КОНКУРС НӘТИҖӘЛӘРЕ

Татарстан АССР Министрлар Советының нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре идарәсе, полиграфия һәм нәшриятлар фәнни-техник җәмгыятенең өлкә идарәсе республикабызда узган елда чыгарылган китапларның полиграфия һәм художество оформлениесенә конкурс үткәргәннәр иде. Күптән түгел шул конкурска йомгак ясалды. Беренче урын урта мәктәпләр өчен чыгарылган «Татарстан АССР тарихы» дәреслегенә бирелде. Муса Җәлилнең «Сайланма әсәрләр»е икенче урынга лаек булды.

Бу китапларны чыгаруда катнашкан полиграфия һәм нәшрият хезмәткәрләренә акчалата бүләкләр бирелде.

## КОТЛЫЙБЫЗ

Башкару осталыгы һәм совет музыка сәнгатен пропагандалаганы өчен, Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе җырчысы **Эмиль Усман** улы **Җәләлетдиновка** Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1973 елның 13 ноябрендә игълан ителгән Указы нигезендә **Татарстан АССРның халык артисты** дигән мактаулы исем бирелде.

Совет сынлы сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре өчен, СССР Художниклар союзы члены, якташыбыз **Сергей Осипович Лывинга** Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының үткән елның 22 ноябрендә игълан ителгән Указы нигезендә **Татарстан АССРның халык художнигы** дигән мактаулы исем бирелде.

Бу иптәшләрне без чын күңелдән котлыйбыз һәм киләчәктә тагын да зуррак уңышларга ирешүләрен телибез.

IIIIIIIIIIIIIIII

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210